МОСТАЙ КӘРИМ

Озын-озак балачак

МОСТАЙ КӘРИМ

Озын-озак балачак

Повесть

Кулъязма һәм һирәк
китаптар бүлеге

Отдел рукописной и
редкой книги

ҠАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1981

С(Баш)2
К95

Художнигы И. ВОРОБЬЕВ

111934

Баш. республиканская
БИБЛИОТЕКА
им. Н. К. КРУПСКОЙ

К $\frac{70303-161}{М132(03)-81}$ 67—81

© Татарстан китап нәшрияты, 1981.

АЛДАН ӘЙТЕЛГӘН СҮЗ

Бу китап — могҗизаларга ышанучан, сәеррәк, шаукымлырак, беркатлырак, чаярак кешеләр турында. Аларның көнкүреше без яшәп яткан көндәлек тормыштан чак кына калкурак, чак кына тылсымлырак, чак кына фаҗигалерәк. Бер-беренә карата алар гадәттәгедән чыдамлырак, рәхимлерәк; гаепләргә, хөкем итәргә ашыгып бармыйлар. Бу кешеләр бәхетне дә, әҗәлне дә сабырлык белән кабул итәләр. Шатлыктан түеп сикермиләр, казадан коелып ук төшмиләр.

— Нигә, сезнең авылда шундыйлар гына яшимени? — дип сораучылар була калса, алдан ук җавап кайтарам:

— Мин күргәне шулар иде. Бүтәннәре хәтердә калмаган.

Китапта үлем-җитем турында сүз күбрәк тоелса, укучы гаҗәпләнмәсен. Яшәү белән үлем икесе дә тиң хокуклы. Ләкин икенчесе турында сүз барганда беренчесенең кадере, куанычы, мәгънәсе раслана.

Мондагы язмышлар, әйткәнемчә, нигездә, мин үзем күреп белгән, бергә дөнья көткән яки бер кисәк юл үткән адәмнәр язмышы. Үтә яхшыларының һәм үтә яманнарының исемнәрен алмаштырдым, бүтәннәрен шул көе калдырдым.

Хикәячесе — мин үзем һәм... үзем генә дә түгел...

Автор

Барысы да әйләнә

Мин теремен икән әле. Зәп-зәңгәр булып туңып, катып калган күкне күрәм. Шул күккә калтайган бакыр кояш ябышкан. Бакыр түгәрәккә кемдер, ахры, таш белән бәрә: доң, доң, доң... Кояш калтыранып куя. Болай булса, күпкә чыдамас, кубып төшәр, мөгаен...

Мин теремен икән әле. Якында гына, бүлкелдәп, чишмә чыгып ятканын ишетәм. Кинәт дертләп китәм. Сәер. Ул чишмә җирдән түгел, минем күкрәгемнән бүлкелди: бүлт, бүлт, бүлт...

Мин акрынлап зиһенемне туплыйм. Хәзер ап-ачык ишетәм: сулыш алган саен күкрәгемнең сул ягыннан кан катыш пырхылдап тын чыга. Сызлау да, газап та юк. Әйтерсең, бу мин түгел, бүтән берәү. Ә мин исә, ике катушка йөкләп, әле булса алгы сызыкка, ут сызыгына элемтә тартам. Анда-санда ярылган миналарга игътибар итми, кола ялан буйлап йөгерәм. Миннән алда озын шәүләм сузылган. Димәк, инде кояш та калыккан. Күләгәмнең башы ниндидер ызан сымак җирдә утырган ялгыз имәнгә килеп төртелә. Шул чак янымда гына гөлт итеп ут күбәсе кабынып сүнә. Күбәнең бер очкыны минем күкрәгемне үтеп ала. Мин кинәт тукталып калам. Бераз чайкалып торам...

Мин әле булса чайкалам. Юк, хәзер мине җир үзе тирбәтә — бишектәге кебек. Офык берчә артка чигенә, берчә якын килә. Бая йөгергән солдат белән без икебез янә бер кешегә әйләнәбез. Монысы яхшы. Бөтенләйгә аймылышсак, аянычч булыр иде.

Әйе, мин теремен инде. Баш очымда имән ботаклары тирбәлә. Агач тирәли, кулга-кул тотынышып, вак балалар әйлән-бәйлән уйный. Алар арасында мин дә, минем кече туганнарым Сәлисә белән Ильяс та бар. Башта без күңелле җыр җырлыйбыз, шаярышып зык кубабыз. Аннан нәрсәгәдер ызгышып елашып алабыз. Тагы татулашабыз. Үзебез һаман әйләнәбез, әйләнәбез, әйләнәбез... Без генә түгел, шушы имән тирәли бөтен җир, бөтен күк әйләнә. Кояш, ай, йолдызлар әйләнә. Ә агач кымшанмый да тик тора.

Бу имән минем Олы инәем булып чыга. Аның тирәсендә инде балалар гына түгел, безнең бөтен гаиләбез — әтием, Кече инәем, абыйларым, апаларым әйләнә. Хәтта бер пар күк атыбыз, ике ала сыерыбыз, бозауларыбыз, сарыкларыбыз, тавык-казларыбыз әйләнә. Шул кеше тирәсендә безнең барлык бәхет-шатлыкларыбыз, кайгы-хәсрәтләребез, көндәлек мәшәкатьләребез, өмет-хыялларыбыз әйләнә — дөньябыз әйләнә. Минем Олы инәем шушы әйләнеп торган дөньяның үзәге ул. Шуңа күрә тыныч һәм хәвефсез басып тора. Аның өчен, әйтерсең, һәлакәт тә, газап та юк. Йөзендә шәфкатьле елмаю...

Имән яфракларында иртәнге нурлар сикерешеп уйный. Әллә нурлар, әллә яфраклар үзләре талгын гына кыштырдый. Җирдә сугыш та, үлем дә юк. Тик кояшка һаман да нәрсә беләндер сугалар: гөп, гөп, гөп...

Канатларына кара тәре тамгалары сугылган шөкәтсез кошлар каяндыр килеп чыга да һавада әйләнә башлый. Алар тирәсендә гөп тә гөп зенит туплары ярыла. Мин чалкан яткан килеш барысын да күреп торам. Менә әлеге кошларның корсакларыннан кара чебиләр сикерешеп чыга башлады. Алар ажгырышып җиргә, минем өстемә омтылалар. Әйтерсең, һәр бомба миңа гына, бары миңа гына тәгаенләнгән. Санап ятам: бер, ике, биш, ун... Бер кешегә күбрәк түгелме? Менә-менә, җир тетрәтеп, шартлаулар башланыр. Менә, менә...

Бер көнне икенче тапкыр үләсе килми. Егерме ике ел буе көнләп, сәгатьләп, минутлап җыелган гомерне берьюлы гына түнтәр дә ташла, имеш. Юк инде. Кая-дыр торып йөгермәкче итәм. Хәлем юк. Бары йөзтүбән әйләнеп ятарлык кына көчем калган. Куркып, җиргә капландым. Өзлексез шартлау башланды. Һәр бомба ярылган саен туфракка сеңә барам, сеңә барам. Үзем өчен үзем хурланып киттем. Борыным белән балчык чокырга сукыр тычканмыни мин? Яу эчендә кеше ара-сында куркаклардан исәпләнми идең бит. Йөрәкле егет-мен дисәң, син япа-ялгыз чакта батыр бул. Менә хә-зер, адәм күрмәгәндә... Хәер, күрергә тиеш кеше сине барыбер күрә ул. Әйтик, иң яраткан кешең. Аның өчен ара да, вакыт та юк. Әҗәлеңне чәбәләнми генә көтә белү — үзе ирлек түгелме? Чәбәләнмә!

Мин яңадан чалкан әйләндем. Әйдә, күземә карап килсен үлем! Юк, килмәде бу юлы. Минем егерме ике яшьлек гомеремә тимер ярчык белән билге сугып, кая-дыр башка тарафка китеп барды. Яланда шартлаулар сүнде. Күк йөзе баягыча чалт аяз. Җирдә тын куырыр-лык тынлык. Хәтта куркыныч.

Кинәт җан тетрәткеч, газаплы, әрнүле бер тавыш минем колагыма, юк, колагым аша йөрәгемә бәреп кер-де. Бу ыңгырашу да, елау да, ялвару да түгел иде. Мондый авазны гомеремдә беренче тапкыр ишетәм. Мин, сагаеп, тавышның кабатлануын көттем. Озак көт-тем. Ул кабатланмады, әмма минем күңелемә гомерлек-кә сеңеп калды. Димәк, яу кырында кемдер бердүү актыккы сулышын алды, күкрәгендә калган соңгы аваз-ны дөньяга шулай сытып чыгарды.

Нәкъ шул вакыт минем аңымда, минем хәтеремдә унарлаган бүтән өннәр кабаттан терелеп, яңгырый башлады. Болары инде — яңа туган сабыйларның җи-һан киңлекләренә очырган беренче авазлары. Бала чагымда аларны мин күп ишеттем. Хәзер менә шушы фаҗигале, шушы саф иртәдә кешенең беренче һәм

соңгы авазы минем рухымда бергә килеп кушылды; һәм миңа аларны көннәремнең иң йончуларына, иң моңсуларына кадәр үзем белән алып барырга насыйп булачак. Чөнки моннан соң мин елганың ярлары ни өчен икәү булуын аңладым. Аларның берсе — фанилык, икенчесе — мәңгелек икән, ә уртадан сулар ага. Шул ук ярлар арасыннан Замана үзе ага. Ә кеше гомер бакый, әлеге ике ярны тоташтырмакчы булып, агачтан, таштан, тимердән, фикердән, хыялдан күпер сала. Күперен ташкыннар алып китә, давыллар җимерә, галактикалардан килгән утлар ялмап көл итә; кеше үзе һәлак була, яңадан туа һәм төп эшенә керешә: күпер сала. Чөнки аның йөрәгендә баягы ике аваз яши.

...Имән тайчанып киткәндәй булды. Юк, ул кузгалмады. Кемнәрдер мине сак кына күтәреп носилкага салды. Алып киттеләр. Аяк очымнан носилканы чебек кенә солдат күтәреп бара. Мин аның бары төшенке кулбашларын һәм арык аксыл йөзен генә күрәм. Аның ике яңагыннан, бормалы ике сукмак булып, кара тир ага. Арбаучан соры күзләре миңа төбәлгән. Ул күзләр, әйтерсең, мине каядыр еракка — мәрхәмәтле җирләргә, хәвефсез заманнарга чакыра. Әллә бөтенләй киресенчәме — тавышың да әйләнеп кайтмас шомлы якларга әйдиме? Күңелемне кинәт шик баса. «Миннән ал шул күзләреңне. Шунда гына калдыр мине...» — дип ялвармакчы булам, әмма тавыш урынына авызымнан бөркелеп кан чыга. Янә аның ияк өстендәге озынча гына аркылы җөйне шәйлим. Бу күптәнге яра эзе булырга тиеш... Шушы аксыл чырай, соры күзләр, иягендәге җәрәхәт эзе минем бөтен игътибарымны бер ноктага тарта. Кайда соң ул нокта? Минем кан эчендәге авыр гәүдәмне көч-хәл белән күтәреп барган кеше кем соң ул? Хәтерли алмыйм, зиһенемнең куәте җитми. Соңыннан мин аны исемә төшерәчәкмен, бик ачык итеп төшерәчәкмен. Ә хәзер ул мине әҗәлем сагалап торган һәла-

кәт яланыннан абына-сөртенә күтәреп алып чыгып китте.

Теге ялан хәзер миннән утыз елга артта торып калды. Мине ышыгына алган имән әле исәндерме-юктырмы, белмим. Шул имәнне хәтерләткән минем Олы инәем инде аннан да элек үзенең мәңгелек йортына күчкән иде. Ул киткәндә талпынып-талпынып күбәләк кар ява иде. Аның йорт түбәсен шунда ук ап-ак кар каплады. Ләкин Олы инәем әле булса минем берчә кояшлы, берчә болытлы, берчә чәчкәле, берчә кар-буранлы язмышым яланының уртасында басып тора. Аның тирәсендә минем бөтен язмышым әйләнә.

Ачык хәтерлим: гомеремдә мине беренче тапкыр җитәкләп алган кул — аның кулы булды. Аннан соң без җитәкләшеп бик күп йөрдек. Менә әле дә атлыййөгерә Түбән очка табан китеп барабыз. Ул атлый, мин йөгерәм. Кая шулай ашыгалар болар, диме икән кешеләр! Атап кына сорасалар, әйтермен: «Кеше тудырырга!»

Кеше тудырырга

Минем Олы инәемне «кендек әбисе», ә үземне «кендек бабасы», дип йөртәләр. Мин бәләкәймен әле. Олы инәемнең камзул кесәсенә буем чак-чак җитә. Ул тылсымлы кесәдән тәмле-томлы нәрсәләр һичвакытта да өзелми. Я берәр шакмак шикәр, я дүрт-биш бөртек йөзем җимеше, я прәннек валчыгы, я кипкән шомырт, я куырылган борчак була. Хәтта ара-тирә бакыр тәңкәләр дә чылтырап куя. (Без акчаның кодрәтен күптән беләбез!) Торганы белән бер хәзинә инде ул кесә — бетмәс-төкәнмәс хәзинә.

Әле дә кулымны тыгуым булды, зур гына ике өрек учыма килеп тә эләкте. Берсен шунда ук уртыма кыс-

тырып куйдым. Бездә тәмле нәрсәне берьюлы гына комсызланып ашый торган гадәт юк. Без аны рәхәтләнеп суырып кына йөрибез. Икенче өрекне бүген генә киеп чыккан яңа чалбарымның кесәсенә яшердем. Аны-сын кайткач сеңелем белән энемә бүлеп бирермен. Бәлки, шуннан башлап минем чалбарымның да кесәсе тылсымлыга әйләнер. «Юмарт кулга мал керер»,— ди Олы инәем.

Без Түбән оч Кара Йомаголларга китеп барабыз. Аның бичәсе бәбигә чирләгән. Безгә, безгә дип ни инде, Олы инәемә йөзе көл кебек агарган Кара Йомагол үзе килеп хәбәр итте. Итте дә, җавап-фәлән көтеп тормыйча, кире чыгып йөгерде. Бу инде кунакка чакыру гамәле түгел. Кунакка чакыручы башта җайлап түргә уза, урындыкка утыра. Ашыкмый гына дога кылалар. Йорт-җирнең, мал-туарның иминлеген сорашалар. Хәтта ут күрше булсын, барыбер сорашалар. Шулай тиеш. Мин моның буш йола гына түгеллеген бары үскәч аңладым. Әйе, кунакка чакыручы синең дөньяң имин, кәефең урынында икәнен үз колагы белән ишетергә, үз күзе белән күрергә тиеш. Чөнки күңеле китек адәмдә кунакка йөрү кайгысы булмау ихтимал. Шуны да әйтергә кирәк, безнең авыл кешеләре, туган-тумачадан тыш, дәрәҗәгә, абруйга, мөлкәткә карабрак аралаша. Һәркемнең үз коры [1] бар. Һәр корның үз җыры бар:

Байлар, байлар бал эчә,
Урта хәлләр сыра эчә,
Безнең кебек ярлылары
Бәкегә ятып су эчә.

Минем әтием сыра эчүчеләр корында. Монысын яхшы беләм. Әле яңа гына өй-кура юнәтеп, бәке тирәсеннән узмаган Кара Йомагол, әлбәттә, безнең салкын суыбызны да уртлаганы юк. Ә минем әтием бал эчүче

---

[1] **Кор** — табын, даирә.

кайбер йортларның тупсасын да аша атламаган. Я чакырмаганнардыр, я чакырылып та бармагандыр. Мөгаен, үз корының түр башында утырырга күнеккән горур зат өлкәнрәк дәрәҗәле чит корның ишек төбенә төшәргә теләмәгәндер. Бу хакта мин хәзер, үзем балалар атасы булгач, шулай уйлыйм.

...Олы инәем белән безгә урыс капкалы, калай түбәле, биек болдырлы өйләрнең дә, җиргә сеңеп беткән балчык алачыкларның да ишекләре шар ачык. Бәгъзеләре, беләм, ачмаслар да иде, ачтыручылары бар. Һәр өйдә диярлек *языны-көзенә, иртәсенә-кичен*ә, *явымына-аязына карамый, үз вакыты җиткәч, кеше туа. Шул кешене каршы алырга без кирәк.*

— Шул баланы гел үзеңә ияртеп йөртмәсәң булмыймы, көндәшем? — диде бая Кече инәем.

— Юк, Вазифа, шул сабый якын-тирәмдә булса, хатыннар җиңелрәк бәбәйли сымак.

— Инде...— Кече инәем сәер генә көлеп куйды,— шулкадәр дә сихерләр икән берәүне берәү.

— Ирем кисәге — итем кисәге. Бар сихере шунда.— Шуларны әйткәч, Олы инәем көрсенеп куйгандай итте. Бәлки көрсенмәгәндер дә.

Нәрсә ул «ирем кисәге — итем кисәге»? Моның төп мәгънәсен мин бик күп еллар үткәч, талпынып-талпынып күбәләк кар яварга бары бер генә көн калгач төшенәчәкмен.

— Ихтыярыңда...— диде Кече инәем гаепле кеше сымак, башын иде.— Ни кылсаң да син хаклы.

— Һәркайсыбызның үз хакыйкате, үз иманы, Вазифа. Без икебез бер дөреслек белән яши алмыйбыз. Хаклы булсам да, мин үзем өчен генә хаклымын...

Инәемнәр сөйләгән бу сүзләрнең һәрберсен аерым-аерым аңлыйм, ә бөтенесе бергә кушылгач, аларның мәгънәсе минем башыма сыймый, төрле якка чәчелә дә һавада эреп югала. Шулай да күңелемдә сагыш катыш билгесез шом торып кала. Йөрәгемне килеп-

килеп уртага булгән ул шом бик озак еллар буенча мине ташлап китмәячәк. Чөнки шул ике хатын сыны бөтен юлларым буйлап мине озата барачак. Ике мәхәббәтнең шәүләсе булып гел генә ике сагыш иярәчәк миңа.

Әйе, мин берьюлы ике ананың мәхәббәтен татыдым һәм үземнең бер мәхәббәтемне аларның икесенә тигез бүләргә тырыштым. Үземне-үзем уртага аердым. Торабара мин моның рәхәтен генә түгел, үземә аңлашылып та җитмәгән әчке газапларын да кичерәчәкмен. Әмма газаплары татлы булачак.

...Әлегә мин уртымдагы өрекне суыра-суыра Олы инәем яныннан тыр-тыр йөгерәм. Менә Кара Йомаголларның капка төбенә дә килеп җиттек. Келәт алдында бау ишеп торган хуҗа, эшен ташлап, атлый-йөгерә килеп капка ачты. Олы инәем туп-туры өйгә юнәлде. Моннан ары мин үз көнемне үзем күрәчәкмен. Өйгә кереп йөрергә миңа ярамый. Монысын күптән беләм. Төптән юан Кара Йомагол, шешенке кабаклары астындагы кысык күзләрен чылт-чылт йомып, Олы инәемә инәлде:

— Малай була күрсен инде, зинһар,— ди,— тәүге бала бит. Мәңге онытмам, әбекәем.

Олы инәем Кара Йомаголның йомшак кына аркасыннан кага:

— Ярар,— ди,— сайлап алырга туры килсә, син теләгәнне сайлармын. Бар, эшеңдә бул.— Шуны әйтте дә үзе өйгә кереп югалды.

— Шулай итә күр инде, зинһар өчен,— Кара Йомаголның нигәдер иреннәре калтырый.

Ул, кире келәт янына килеп, эшенә керешә. Мин аннан ерак түгел түмәр башына менеп утырам. Үз дәрәҗәмне, урынымны яхшы беләм — мин кендек әбисенең улымын. Вак-төяккә кысылып бармыйм, олыларның аяк астында уралмыйм. Үзем теләгән җирдә әдәпле генә утыра бирәм, сабырлык күрсәтәм. Шуңа күрә бәби туар өйдә олылар да миңа «әй, малай!» дип эндәшергә җөрьәт итми. Исемемне тутырып әйтәләр.

Байтак утыргач кына Кара Йомаголга сүз кушам:

— Нәрсә ишәсең? — дим.

— Аркан. Бау ишкәндә вакыт тиз үтә ул. Очы да, чиге дә юк аның — иш тә иш кенә.— Кара Йомагол йомык кешеләрдән санала, «аның авызыннан сүзне көрәк белән каерып алырга кирәк», диләр. Бүген теле телгә йокмый. Бераз тынып тора да дәвам итә:

— Бау ул, энем, дөньяның тоткасы. Бау булмаса, бөтен дөнья таралып төшәр иде.

Чынлап та, дөрес әйтә бит. Бар әнә, җепсез-баусыз көн күреп кара. Бу сүзләре белән шаккатыргач, Кара Йомагол тынып калды. Ишә-ишә дә ул, йорт ягына колак салып, сагаеп тора. Тагы ишә.

— Арканыңны кайчан ишеп бетерәсең инде? — дим эчем поша башлагач.

— Ишәм әле, малай туганчы...

— Оһо! Әгәр ул тиз генә тумаса?

— Туар. Ә юкә миндә бер йөк, хет биш көн иш...

Өйдән Олы инәем бер-ике тапкыр чыгып күренде, бер яшь хатын өч көянтә суга барып кайтты. Көн инде кичкә авышты. Теге өрек әллә кайчан авызда эреп юк булды. Аның чикләвеге абайламастан кызыл сандыкка төшеп китте. Эчемдә минем бер нәрсә дә юк. Тик әлеге өрек чикләвеге генә дөбер-дөбер тәгәрәп йөри. Бая су ташыган килен көтү кайтыр алдыннан гына безгә ашарга чыгарды. Каты-котыдан булса да тамак ялгап алгач, күңел күтәрелеп китте.

Кара Йомагол янә эшенә тотынды, ә мин шул ук түмәр башына менеп кунакладым. Хәзер аның арканы, сузсаң, мөгаен, мәчет аена җитәр иде. Күп иште.

— Ә шулкадәр озын арканны син нәрсә эшләтәсең?

— Хәбибулланың унҗидесе тулганчы ул шушы келәттә сакланачак. Унҗидесе тулгач аңа тапшырачакмын.

— Ә унҗидесе тулгач нигә аңа аркан кирәк?

— Нигә дисеңме? Алайса тыңла...

Кара Йомаголның кысык күзләре кинәт зураеп китте дә ниндидер тылсымлы нур чәчә башлады. Нур тәүдә аның итләч йөзенә таралды, аннан соң ул ишеп торган аркан буйлап йөгерде. Әйтерсең, әнә ул бөгәрләнеп-бөгәрләнеп яткан нәрсә хәзер саргылт юкә бау түгел, ә шушы ямьсез кешенең ике күзеннән агылып чыккан нур тасмасы. Үрелеп тотмакчы итәм шул тасманы, әмма, мин кагылсам, тылсымы югалыр дип шикләнәм.

— Алайса тыңла...— дип кабатлый Кара Йомагол. Аның тавышы да элеккечә тамак төбеннән чыелдап түгел, күкрәгеннән, тирәннән гөрләп, ургылып чыга. Торганы белән җыр җырлый диярсең... Хәзер миңа моңа кадәр адәм күзе күрмәгән, адәм колагы ишетмәгән сер ачылачак. Мин сабыр гына көтәм. Ә ул, йорт ягына колак салып, беравык катып кала. Ләкин тынлыктан башка нәрсә ишетелми. Хәбибулла әлегә билге бирми.— Әнә, күрәсеңме офыкны? — Кара Йомагол ияге белән еракка күрсәтә.— Шуның аръягында Урал дигән биек тау бар, тау түбәсендә адәм үтмәслек кара урман, урман эчендә түп-түгәрәк аклан, түп-түгәрәк аклан эчендә түп-түгәрәк күл булыр. Күлнең аркылыбуе җитмеш колач, ә төбендә төп юк, имеш. Ул күлдә балык та, бүтән төрле җәнлек-җанвар да юк, имеш. Анда бары алтын яллы, көмеш тояклы, җилдәй җиләр, коштай очар, теләгән җиреңә җиткерер, уйлаган уеңны башкарыр, үткәнеңне кайтарыр, көткәнеңне китерер, адәм белән адәмчә сөйләшер, ходай белән ходайча серләшер бер Акбузат яши, ди. Елның иң кыска төнендә, чикләвек чәчәк аткан сәгатьтә, юкәдән бал тама башлар мәлдә, үлән кыяклары ширбәттән тулышкан чакта, күлнең өстен уртага ярып, алтын ялын чайкый-чайкый, Акбузат килеп чыгар, ди. Таң сызылганчы, һичнәрсәдән өрекми-курыкмый акланда үлән утлап йөрер, ди. Шул арада кем дә кем аның муенына җитмеш колач озынлыгы корык салып өлгерә, ат шуныкы булыр, ди.

Көндез йолдыз күрерлек, төнен җанвар ауларлык, эчендә ут янса да уфтанмас, өстенә тау ауса да сыктамас ир егет кенә корыклый алыр, ди, ул атны. Ай үсәсен көн үсәр оланым, ел үсәсен ай үсәр, яше унҗидегә җитәр, иңенә җитмеш колачлы шушы арканны салыр да чыгып китәр ырыс[1] толпарын ауларга. Морадына ирешер, иншалла... Менә нәрсәгә кирәк булачак бу аркан!

Мин эчемнән көнләшеп куям. Хәбибулланың эшләр көйле. Үзе әле тумаган да, аны инде кара урман эчендәге түгәрәк күл буенда керт-керт үлән утлап йөргән Акбузат көтә, атны корыкларга аркан да әзер. Була бит котлы кешеләр!

Чынлап та, әле батып барган кояш яктысында ялтырап яткан алтын-саргылт бау нәкъ унҗиде елдан соң ак толпарның муенына уралачак. Туачак Хәбибулла да минем күз алдыма алтын чәчле, көмеш тырнаклы галәмәт зур пәһлеван булып килеп баса. Менә кемне көтәбез без!

Әңгәмәсен сөйләп беткәч, Кара Йомагол ни эшләптер күңелсезләнеп калгандай итте. Өй ягына омтылып карады да кире туктады. Тагы ишәргә керешге.

Җиргә сыек зәңгәр эңгер төшә башлады. Тып-тын зәңгәрлек. Әйтерсең, су өсте шулай тынып калган. Мин уем белән яңадан теге күл янына китеп олактым. Аның ярында әле тумаган Хәбибулла түгел, мин үзем корык тотып утырам, менә-менә су астыннан атның матур башы күренер. Әйе, әнә ул килеп тә чыкты, әче тавыш белән кешнәп тә җибәрде: «И-һа-һа-һау!..»

— Туды! — дип сөрәнләде Кара Йомагол. Үзе чүгәләп төште.— Туды!! Минем малай туды!!!

Ул атылып торып өй ишегенә ташланды, кинәт кире борылды. Йөгереп янә келәт янына килде. Кызу-кызу арканын ишәргә тотынды. Кулларына күз иярми. Кең-

[1] Ырыс — бәхет, кот.

дек әбисе чыгып сөенче алганны Кара Йомагол чыдам гына көтеп торырга тиеш тә бит, күрәсең, чыдый алмый. Исәр.

Ә мин түмәр өстендә, аякларымны сәлендереп, кымшанмый да утыра бирәм. Чәбәләнүдән ни файда? Хәбәре килер. Бер тугач, кире әллә кая китмәс... Шулай да Олы инәем нигә күренми соң әле? Күңелемә шик төшә башлый. Кара Йомаголның куркынган күзләре тагы кабаклары астына кереп бата. Ул кинәт эшеннән туктала. Күрсенә. Хәзер инде матур аклан да, аклан уртасындагы күл дә, күлдән чыгып килгән Акбузат та кайдадыр рәшә эченә чумып кала. Җирдә уралып яткан нур тасмасы кабаттан гади юкә арканга әйләнә. Инде мин өй ягына карарга да куркам, менә ишек ачылыр да, аннан Кара Йомагол өчен коточкыч бәла килеп чыгар сымак. Хәер, алай булмас, анда минем Олы инәем бит.

Баягыдан да көчлерәк һәм ачыграк яңа тавыш өйдән тышка бәреп чыкты. Кара Йомагол дертләп китте. Минем буыннарым буйлап ниндидер рәхәтлек йөгерде. Бу тавыш тиз генә тынар өчен яралмаган булып чыкты.

...Байтак заманнар узгач, аяз иртәдә имән төбендә яткан чагымда берәүнең дөнья белән хушлашу авазыннан соң нәкъ шушы үткер тавыш, минем аңымда яңадан терелеп, җанымны тетрәтәчәк...

Менә болдырга минем Олы инәем чыгып басты.

— Сөенче, Йомагол! — диде ул, тораташ төсле, селкенми дә.

— Кем бар! — Тегесе «ә» дигәнче Олы инәемнең алдына килеп тезләнде.

— Ике улың.

— Икәү? Берьюлымы? Нигә икәү? Икенчесе ни исемле?

Олы инәем көлеп үк җибәрде:

— Исәр, берәүгә караганда икәү яхшырак ла... Исеменә генә калгач, анысын табарсың инде.

— Әйе, әйе, яхшырак, икәү яхшырак. Исемен табарбыз. Аллаһы әкбәр! — Тезләнгән көе ул дога кылды.— Сөенчесенә, әбекәй, сиңа бер сарык. Юк, ике сарык! Аллаһы әкбәр! — Ике кулы белән янә битен сыйпады.

— Арык атның күгәне киң, диме. Шашма! Бер бәрән бирсәң, хәттин ашкан.

Безнең эштә бу хәл — игезәкләрне әйтәм — бары икенче тапкыр гына булды. Бүресе улады Кара Йомаголның! Бер бәрән генә, әлбәттә, азрагын азрак та. Кендек әбисеннән узып, мин нәрсә әйтә алам?

Олы инәем, болдырдан төшеп, Кара Йомаголның аркасыннан какты:

— Бәхет-тәүфыйклары белән килсеннәр бу дөньяга. Малайларыңның игелеген күрергә язсын. Ә хатының торганы белән инә арслан. Бичәләрнең кеме кем икәнлеге бала асраганда сынала. Кадерен белеп яшә.

Бәби тугач, боларның эше бетте инде, әлеге сөенче бәрәнен җитәкләрләр дә кайтып китәрләр дип уйлыйсызмы? Юк шул. Безнең кадер, тормышның рәхәте бәби тугач башлана. Ул рәхәтлек атна буена бара. Хәтта ашып та китә.

Менә ничек була ул.

Бәби туган йортка, аның мөлкәтлеме, мөлкәтсезме булуына карамастан, икенче көнне үк сый агыла башлый. Күрше-күлән, туган-тумача, дус-иш, таныш-белеш хатыннар, тиңдәшләр, ахирәтләр, кодагый-кодачалар бала анасына күчтәнәч ташый. Берәүләр кызу табада коймак, икенчеләр бәлеш, өченчеләр кыстыбый, дүртенчеләр тутырган тавык, бишенчеләр катлама, алтынчылар бавырсак, җиденчеләр... тагы әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр китерә. Һәркем хәленнән килгәненчә дә, артыгын да тырыштыра, үзендә булмаганны күршедән әҗәткә алып тора. Менә нинди сыйлар белән хөрмәтлиләр яңа туган баланы!

Иртәдән кичкә кадәр түрдән самовар төшми. Түр

башында мамык мендәр өстендә кендек әбисе утыра, аның янында кем дисезме — мин. Бер атна буена шулай утырабыз. Хәтта ашып та китә. Бу күркәм тормышны тик бер генә нәрсә боза. Ул да булса — бәби мунчасы. Бала тугач, көн саен мунча ягалар. Олы инәем ходайның биргән һәр көнендә, башкалар кереп чыккач, мине алып барып мунча чаба. Үсәрсең, ди. Кыен булса да түзәргә туры килә. Бер кыенның мең рәхәте бар. Мунчадан кайткач, без янә түр башына менеп кунаклыйбыз. Тирләп-пешеп, баллап-майлап чәй эчәбез...

Иртәгә мин Кара Йомаголның түр башында булачакмын. Ә бүгенгә миңа бары бер тустаган җылы сөт белән бер сынык икмәк кенә бирделәр. Аннан соң келәт идәненә йокларга салдылар. Бер кышка куян тиресе дә чыдаган, диләр. Бер төнгә түзәрбез. Яңа көндә яңа тормыш башланачак.

Һәм шулай булды да. Уянганда ук, минем танавымны ярып, кыздырылган май исе бәреп керде. Тик бер атна узгач кына Кара Йомагол сайлаган ак бәрәнне ияртеп өйгә кайтып киттек. Олы инәем мине, мин, муенына бау тагып, ак бәрәнне җитәкләп алдым.

Әлбәттә, гелән бәйрәм, гелән туй гына да булып тормый. Тикәй[1] көннәр дә еш килә. Чөнки адәм тууда без көтмәгән тоткарлыклар килеп чыга. Шул чакта мин үз тиңдәшләрем белән туйганчы уйнап калам. Бара торгач, уен да җиләтә. Эч поша башлый. Яңа туган бәбинең үзе хакында, сөрәнләп, дөньяга хәбәр салуын ишетәсем, куанычтан бөтенләй юләрләнеп калган аталарның кыланышын читтән генә күзәтәсем, моңача ямьсез генә күренгән хатыннарның баладан соң ямьләнеп, нурланып киткән йөзен күрәсем килә.

Яшь ананың тәү тапкыр бала имезгәнен чаршау ярыгыннан карап торганым бар минем. Әле күзе дә ачылмаган кып-кызыл җан иясенең иреннәре алсу им-

[1] Эш көннәре.

Баш. республиканская
БИБЛИОТЕКА
им. Н. К. КРУПСКОЙ
111934

чәккә тиюе була, ананың аксыл йончу маңгае кинәт балкып яктырып китә. Алар шул түшәктә яткан килеш, гүя, акрын гына югарыга, һавага күтәреләләр. Түшәге дә, имеш, түшәк түгел, ак болыт. Болыт эчендә, ләззәткә чумып, икәү йөзә — ана һәм бала. Нигә шулай икән — үтә рәхәт булганда кеше я оча, я йөзә сымак? Болар кинәт җиргә егылып төшмәсеннәр дип куркып, мин чытырдатып күзләремне йомам һәм чаршау янынннан китеп барам.

Авылда озаграк бала тумый торса, минем бер сихерле чарам бар. Башкача чыдарлык әмәл калмагач, соңгы чиктә мин шуңа килеп төртеләм.

Безнең бакчада бер чикләвек куагы үсә. Бу агач бездә тылсымлы исәпләнә. Әгәр җиде төн уртасында аның чәчәк аткан чагына тап булсаң, әгәр бер чәчәкне өзеп өлгерә алсаң, әгәр уч төбеңне үткер пәке белән ярып, шул чәчкәне тирең астына кыстырсаң, сине һичнинди адәм заты күрмәячәк. Бер рухка әйләнәсең дә куясың. Теләсәң кая бар, теләсәң нәрсә эшлә — сине һичкем тыя алмаячак. Соңрак, беләккә көч, йөрәккә тәвәккәллек керә башлагач, әтиемнең сакал-мыек кыра торган иң үткер пәкесен тотып, күпме җәйге төннәрне мин шул чикләвек төбендә үткәрмәдем! Күзгә күренми торган затка әйләнгәч, мин нәрсә эшләячәгемне яхшы белә идем: җир шарындагы бөтен буржуйларны берәм-берәм кырып бетерәм дә изелгән колларны азат итәм.

Чикләвек, әлбәттә, миңа күренеп чәчкә атмады. Әмма мин аннан соң да, кара чәчләремне еллар соры көлгә әйләндереп беткән заманда да, чикләвекнең чәчкә атачагына ышандым, ышаначакмын. Шуңа ышанмасам, яшәвемнең кызыгы калмаган булыр иде.

Хәзергә минем төннәр буе бакчада ялгыз утырырлык кыюлыгым да, бөтен буржуйларны кыйратып, барлык колларны азат итәрлек дәрманым да юк. Теләгемне ялварып сорарлык телем генә бар. Әтием өйлә намазына киткәч, көннең иң изге мәлендә, мин бакчага

чыгып, чикләвек куагы алдына тезләнәм. Ул серле агач минем дә, ходайның да телен аңлый төсле. Шуңа күрә, ике кулымны югары күтәреп, аның аша күктәгенең үзенә эндәшәм. Алла белән ничек сөйләшергә кирәклекне беләм мин. Ул шаштырып мактаганны ярата. Моны мин әллә кайчан инде Олы инәемнән төшенеп алдым.

— Әй ходаем,— дим мин.— Кодрәтең дә, рәхимең дә чиксез синең. Бар өметебез синдә генә. Изге ихтыярың белән сабыйлар тагы, тагы, тагы дөньяга яралсын. Сиңа иман китерер гөнаһсыз җаннар тусын! Теләкләремне кабул ит!! Ишетәсеңме мине, тәңре?!

Чикләвек яфраклары бердәм кыштырдап куя. Монысы инде, минем үтенечем иясенә барып юлыкты һәм кабул кылынды, дигән сүз.

Ходай вәгъдәсендә тора. Ике-өч көн үтми, авылның кайсыдыр очында я берәр малай, я берәр кыз туа. Әлбәттә, мин, әрсезләнеп, алланы артык еш борчырга тырышмыйм. Бая әйткәнемчә, ул минем иң соңгы чарам.

Дөньям шулай ипле генә бара. Тамак сыйга тиенеп тора. Олы инәемнең камзул кисәсенә генә түгел, минем чалбар кисәмә дә кот керде. Энем белән сеңелемә аннан өлеш чыгып кына тора. Дустым Әсгать тә очрагалда буш калмый. Шулай да көйле дөньяның ара-тирә көе киткәләп куя. Барысы да шул малайлар аркасында. Минем шулпа өстендәге өре төсле яшәвемнән көнләшеп, алар мине үчекли, хәтта кыерсыта башладылар. Башта: «Кендек бабае! Кендек бабае!» — дип ирештерделәр. Монысына артык исем китмәде. Дөресе шул булгач, ни кыласың? Әйдә, әйтә бирсеннәр!

Тик моннан ары булганы минем намусыма нык сукты. Баягы явыз малайлар бер заман мине, бөтенләй мәсхәрә итеп, коры «Кендек» кә торгызып калдырдылар. Урамга чыгар хәлем юк, уң яктан да, сул яктан да тик бер генә сүз ишетәм:

— Әй, Кендек!

— Нихәл, Кендек?

— Бәби коймагы тәмлеме, Кендек?
— Кендегеңне күрсәт әле, Кендек!
— Кендек! Кендек! Кендек!

Хәтта арабызда иң юаш, иң тыйнак исәпләнгән Аркылы баш Хәмитҗан да тел-теш күрсәтә башлады.

Байтак ара мин үз яшьтәшләремнән бизеп тордым. Алар да миннән суындылар. Тик бер Әсгать кенә ташламады.

Хәзер инде авылда яңа кеше туу да миңа, элекке кебек, куаныч китерми. Олы инәемә дә сирәгрәк иярәм. Барасым килмәгәндә, ул да ныгытып кыстамый.

— Үсә башлавың шушы микәнни?— дип бары битемнән генә сөеп ала. Ул башка барлык кешеләрнең аркасыннан кага, бер мине генә битемнән сөя. Аның йомшак кулы битемә кагылгач, мин бөтенләй бәләкәч булып калам. Барлык әрнүләрем берьюлы юк була. Күңелемә тынычлык кайта. Үсеп буйга җиткәч тә, тәүге мәхәббәт газапларын татып, акылдан шашканда да шулай булачак: йомшак кына бармаклар яңагыма тигәч тә йөрәгемдәге әрнүләрне алып ташлаячак һәм мин яңадан сабыйга әйләнәчәкмен.

Гомер узган саен хагы да, нахагы да артта кала торды, яхшысы да, яманы да онытыла барды. Ә «Кендек»не берәү дә онытмады. Ул миңа гомерлеккә тагылды. Күп кеше авылда минем чын исемемне дә белми. Үзем дә күнектем. Кемдер берәү миңа ерактан язып-ялгышып үз исемем белән эндәшсә, мин башта тирә-ягыма каранып алам, миңамы икән дим. Шуннан гына җавап бирәм. Ә «Кендек» тирә-якта берәү генә. Бәлки, үтә начар да түгелдер әле. Минем кушаматым миңа хәтта ошый. Ә иләшкәнче күпме җәфа, күпме бәла, күпме күз яшьләре китерде ул миңа. Хисапсыз. Мин аңа каршы канга батып көрәштем, үземне аямый көрәштем. Тешем-тырнагым, җаным-тәнем белән карыштым. Мин карышкан саен ул ныграк ябышты.

Беренче канлы сугыш менә шулай булды.

Бәйрәм ашы — кара-каршы

Бүген бәйрәм. Корбан бәйрәме. Күпме заманнар мин акрын гына якынлашып килгән шушы иртәнең сихере астында яшәдем. Аның кайтавазы, ерак офык читендәге ак болытларда чагылып уйнаган таң нурлары сымак, әллә кайчан инде минем иләс күңелемә килеп сарылды. Кояш әле чыгып та җитмәгән, дөнья инде яп-якты. Нәкъ менә шулай килә корбан бәйрәме. Үзе әле ары — шаукымы инде бире.

Узган төнне мине озак йокы алмады. Башымнан төрле-төрле уйлар узды. Бәйрәм килгәч тә, җирдә бөтен нәрсә кинәт үзгәрер төсле тоелды миңа. Олы инәем сөйләгән әкияттәге сымак, ут белән су бергә кушылыр, бүреләр белән сарыклар аралашып, бер көтүдә йөрер, явызлар — изгегә, дошманнар дуска әйләнер. Моңа мин куанам да, бераз шикләнәм дә. Сарыклар өчен борчылам. Аңгармастан гына аларны мәкерле бүреләр буып ташламагае. Ут өчен дә хәвефләнәм. Абайламастан су үзен сүндереп куймагае. Дуслар өчен дә күңелем урынында ук түгел. Дошманнар, хәйлә корып, үзләрен харап итмәгәе дим...

Барыбер минем шатлыгымның чиге юк. Аның башы — кара бәрхет түбәтәй белән бер пар резин галош булды. Калага он сатарга барган җиреннән бәйрәм бүләге дип, аларны Мортаза абыем алып кайтты. Әллә ничә көн инде шул түбәтәй белән галошлар минем такыр башымны, янә «чебиләре» һаман да төзәлеп бетмәгән тәпиләремне көтә. Көтсеннәр әйдә! Мин дә аларны күп көттем. Шуның өстәвенә Олы инәем, үземә үлчәп, ак буйлы кызыл киндер ыштан тегеп куйды — ике кесәле. Җае килгәндә әйтеп үтим, кырык еллар узгач, шундый буйлы-буйлы кызыл ыштан кигән купшы егетләрне мин Европаның иң мәшһүр калаларында бик күп очраттым. Әһә, мин әйтәм: безгә дә иярер

көнегез җиттеме? Тик сез әле кигәннәрне без күптән киеп туздырган, модасын уздырган! Әмма Европа ыштаннарының йөзе-күренеше безнекенә охшаса да, товары күп кайтыш иде. Үзем капшап карадым.

Бер кешегә никадәр мөлкәт, никадәр яңа кием-салым дип аптырыйсыздыр әле, мөгаен. Аптырау гына түгел, әле шаккатачаксыз. Әнә теге кештәгә эленгән зәңгәр нәрсә ул? Буран Абдулла Шәрифәсе тегеп биргән зәңгәр күлмәк — кыек якалы сатин күлмәк ул.

Бу бәйрәмгә мине әнә ничек баштанаяк киендерделәр. Кызык инде, өстеңә яңа, матур кием кигәч, ничектер, күңелең дә бөтәеп, ямьләнеп киткәндәй була. Әнә шулай тыштан-эчтән яңарып, ялтырап мин урамга чыгачакмын. Бәйрәм дигәнең бары урамда гына була. Өйгә сыеп беткән бәйрәм — бәйрәм түгел ул.

Минем тагы да куанычым, иң зур куанычым бар. Анысын әлегә сер итеп саклыйм дигән идем дә, чыдап буламыни? Әйткәч, әйтим инде. Мин Акманайда ат йөздереп кайткач, кичке җиләстә без Олы инәем белән икәү генә, күк алашаны җигеп, Сайран авылына аның кияүдәге өлкән кызына — минем Гайникамал апаема кунакка барачакбыз. Юлда, тарантас башына утырып, күк алашаны үзем әйдәячәкмен. Югыйсә үшән ул. «Кунак егете» булгач, Сайранда Олы инәем белән мине дә өйдән өйгә ашка йөртәчәкләр, түр башына утыртачаклар. Түр башында утырган бар, анысын килештереп була. Менә кайчан ул кара бәрхет түбәтәй, резин галош, кызыл ыштан, зәңгәр сатин күлмәк сайраннарга кемнең кемлеген төшендереп бирәчәк. «Агач күрке яфрак, адәм күрке чүпрәк»,— диде берчак Олы инәем. Шулай булгач, сизгәнсездер инде, кем аркасында мин патша малае урынына чуктай итеп шулай киенеп алганмын. Олы инәем аркасында...

Корбан гаетенә баручылар, тукталып тәкбир әйтә-әйтә, Түбән очка, мәчет ягына үтеп китте. Минем этием дә чыгып аларга кушылды. Иртәнге чәй гаеттән соң

эчелә. Бездә бүген тары тәбикмәге пешкән. Олы инәемнең кулы тисә, аннан майлар тамып торачак. Нинди әйбәт нәрсә — бәйрәм.

Яңа ыштанның бер кесәсенә көнбагыш, бер кесәсенә кипкән шомырт тутырып мин капка төбенә чыгып бастым. Авыл өстендә селәгәйне агызырлык тәм аңкый. Һәркем, хәлдән килгәнчә, таба кыздыра. Ел буе «сыер агы» кермәгән — катык-сөт затын без шулай дибез — өйләрдә дә бүген үзенә күрә чож-пыж чыга. Берәүләр тәбикмәк, икенчеләр коймак, өченчеләр кыстыбый, дүртенчеләр май күмәче пешерә. Бераздан, бу җиңел-җилпе ашларның исе таралып бетәр-бетмәс үк, һавага пешкән ит исе күтәреләчәк. Менә шул чакта инде син күкрәк тутырып сулыш алуның чын тәмен татыйсың.

Баш очымда гына карлыгачлар кыйпылып үтә. Яшел үлән өстендә тургайлар сикерешә. Әйтерсең, кошлар да кешеләр бәйрәмен бәйрәм итә.

— Әй, Кендек! Әй, Рукавказ! — Бу Шаһидулла тавышы — Шаһибәкләр тыкрыгы ягыннан килә. Мине чакыра. Үзе күренми. Шаһидулла безнең башлыгыбыз. Ул исемне эндәштеме, син елт итеп аның янына килеп басарга тиешсең. Кабатларга яратмый. Мин шунда ук башлык тавышы килгән якка йөгерәм.

— Рукавказ! — Әмерне бу юлы тыңкыш Вәлетдин кабатлады.

«Рукавказ» минем икенче кушаматым — сугышчан кушаматым. Теге берчак бөтен малайлар, икегә бүленеп, сугыш уйнар алдыннан һәрберебезгә яңа исем — ил исеме тагылды. Арабызда иң көчлесе Шаһидулла үзе «Рәсәй»не алды, аннан кала тыңкыш Вәлетдин «Америка», Искәндәр Ибрае «Япония» булды, бүтәннәргә «Англия», «Франция», «Австрия», «Төркия», «Германия», «Кавказ» эләкте. Бөтен төбәктә мин иң бәләкәе. Миңа җиткәч, илләр бетте дә куйды. «Дөньяда бүтән ил юк!» — диде Шаһидулла. Башлыктан узып, яңа илләр эзләп, берәү дә баш ватмады. Мин тәүдә

коелып төштем, аннан тавышсыз гына елап җибәрдем. «Ничек инде ул,— димен эчемнән генә,— бер миңа калгач кына ил бетәр икән? Шулкадәр дә котсызмын микәнни? Бүтәннәр, ил-ил булып, рәхәтләнеп сугышып йөргәндә, бер ялгызың исемсез-затсыз читтә торып кал инде...»

Шаһидуллаерактанрак булса да безгә нәсел тиешле. Шуңа күрә мине кызганды, ахрысы. Җирән башын азрак тырнап торгач, аннан бик яхшы бер сүз чокып чыгарды.

— Онытканмын, малайлар, җир шарында үтә гайрәтле, үтә гарьчел, үтә хәтәр тагы да бер ил бар. Ул да булса — Рукавказ! Кендек! Син — Рукавказ!

Теге Рукавказ гарьчелдерме, юктырмы — белмим. Ә миндә исә гарьчеллек чамадан ашкан: Шаһидулла миңа азрак төрттереп китте бугай. Шуңа карамастан, бу юлы хәтта теге мәсхәрә кушаматны әйтүенә дә үчекләшмәдем. «Берсен төшерми, икенчесен күтәреп булмый»,— ди этием. Харап икән — Кендек! Рукавказ мең Кендеккә дә бирешерлек түгел...

...Бәйрәм иртәсендә башлык, мөгаен, сугышчан оран салгандыр. Токтымалга «Рукавказ» дип чакырмас. Мин барып җиткәндә, малайлар тыкрык тулы иде инде. Тик Әсгать кенә юк. Кайсылары көнбагыш яра, кайсылары чертләтеп кипкән шомырт чәйни.

— Тә-тә-тә-тә! — диде Ибрай, мине бер кат әйләнеп чыгып.— Мәкәрҗәдән килгән купецмыни? Көмеш чылбырлы сәгате генә юк. Хәер, чылбыры монда асылынып тора икән! — Ул минем байтак ук сәленеп торган ыштан бавын тартты. Ярый ыштан чишелмәде. Ибрай ул минем дустым Әсгатьнең бертуган агасы. Нишләптер үзе миңа гел каныгып тора.

Шаһидулла башта минем килүемә дә, өс-башыма да артык игътибар итмәде. Тик, кулы белән ишарә ясап, Ибрайны гына минем яннан куып җибәрде.

— Нәрсәгә шулай ике ыштан балагың бүлтәеп чык-

кан? — Бу сорауны бераздан соң, ияген чөеп кенә, башлык бирде.

— Бер кесәдә көнбагыш, Шаһидулла агай, икенчесендә кипкән шомырт. Көнбагыш шундый эре. Лекарь урысы Тимофей китергән иде.

— Син,ыштансыз, барыбер кешегә өләшеп бетерерсең. Көнбагышын да, шомыртын да күчер минем кесәләргә!

Аның өр-яңа яшел чалбар кесәләренә мин тәүдә көнбагышны, аннан соң кипкән шомыртны уз учларым белән шатлана-шатлана ташыдым. Бөртеге калмаса да үкенмим. Ашамаган ашмы. Ахырда үземнең чиксез юмартлыгымны һәм ихласлыгымны раслау өчен элек уң кесәмне, аннан сул кесәмне әйләндереп күрсәттем.

— Шәп егет син, карун түгелсең,— дип мактады мине башлык. Үзенең олы учы белән бер уч көнбагыш, бер уч шомырт кайтарып бирде. Чынлап та, була бит киң күңелле, гадел кешеләр! Шуларның берсе — безнең башлык.

Харап мәзәк ул Шаһидулла агаем. Уйлап чыгармаган уены, әйтмәгән табышмагы юк аның. Менә әле дә уен дисәң, уен түгел, табышмак дисәң, табышмак түгел, бер мәзәк тамаша уйлап чыгарды.

— Малайлар! — диде ул. Без бөтенебез дә аның авызына төбәлдек.— Кем ызбасы иң биек, малайлар?

Безнең карашларыбыз, әлбәттә, иң элек сатучы Шәмсулланың чардаклы өенә юнәлде.

— Шәмсулланыкы! — диде һәрнәрсәгә алдан тыгылып баручы Ибрай. Шунда ук Шаһидулланың кырлы зур йодрыгы тегенең яңагына килеп кунды. Без, аптырап, тынып калдык.

Шул ук тавыш белән шул ук сорауны кабатлады ул:

— Кем ызбасы иң биек, малайлар?

Бу юлы башлыкның яшьтәше тыңкыш Вәлетдин үзенең зирәклеген, тапкырлыгын күрсәтмәкче булды:

— Хет ас, хет кис, иң дөресен үзем әйтәм: самай, самай биеге — Базар урамындагы Әхмәр мулланың ызбасы. Ышанмасаң... «ышанмасаң...» нәрсә булачагын Вәлетдин әйтеп бетерергә дә өлгермәде, баягы йодрык аның колагын өтеп алды.

Безне тәмам каушау алды. Авылда без белмәгән, без күрмәгән, тик башлыкның берүзенә генә билгеле биектән биек өй бардыр, күрәсең. Тагы бер-ике малай, Ташбулат карт белән Әгъләм тимерченең өен атап, бәхет сынап карады. Әмма аларның җавабына да шул ук бәһа бирелде.

Кинәт кайдандыр югарыдан төшеп, минем башыма искиткеч акыллы фикер килеп керде. Шул чак бөтен тәнемә рәхәт бер калтырау таралды. Йөрәгем леп-леп тибә башлады. Менә хәзер әйтәм дә бөтен малайларны берьюлы кырып салам. Мин белгәнне берәү дә белми. Үзем дә сизмәстән, бөтен урамны яңгыратып, сөрән салдым:

— Мәчет манарасы!

Башлык тәүдә шаккатты. Бер агарынды, бер бүртенде теге. Сипкелле танавына тир бәреп чыкты. Бераз вакыттан әлеге йодрык минем икмәк шүрлегенә — авыз-борын тирәсен без шулай дип йөртәбез — елт итеп килеп җитте. Ләкин кагылмады, әкрен генә түбән төште.

— Мәчет ул ходай йорты,— диде башлык,— мондый ызбалар рәтенә керми. Шуны да белмисең, исәр.— Күрәсең, телгә алганым «ходай йорты» булганга, биш бармактан укмашкан кырлы тукмак мине аяп үтте. Әмма Шаһидулланың исәп-чамаларын мин ярыйсы чуалтып ташладым, ахрысы. Уенның кызыгы китте. Малайлар арлы-бирле буталыша башлады. Ләкин башлык чигенмәде. Аңа иң дөрес, иң тапкыр, иң гадел җавап кирәк иде.

— Соңгы тапкыр сорыйм — кем ызбасы иң биек?

Авыз ачып эндәшергә берәүнең дә йөрәге җитмәде.

Шомлы тынлык. Бары тыңкыш Вәлетдиннең танау тартканы гына ишетелә. Шул чак уенга да, бәхәскә дә сирәк катнаша торган малай — хәйләкәрлеге өчен Төлке кушаматы йөрткән Шәйхаттар кинәт телгә килде. Ул бер сүзне әйткәч, икенчесен көтә-көтә арып бетәсең.

— Кайсы яктан карыйсың бит,— диде Төлке,— бер яктан караганда, Шаһидулла агай, сезнең ызбаның кыегы калку, икенче яктан караганда, морҗасы югары. Шулай булгач, иң биеге сезнең ызба булып чыга инде. Сезнең ызба!

Аңа кушылып, тагы ике-өч малай кабатлады:

— Сезнең ызба! Сезнең ызба! Иң биеге — сезнең ызба!!! — Кемдер кәпәч тә чөеп җибәрде.

Башлыкның йөзе балкып китте. Җирән чәч бөртекләрендә ниндидер бакыр нурлар чагылып уйнады. Шулай да бөтенләй эреп төшкәнен күрсәтмәскә тырышты ул. Эре генә йомгак ясап куйды:

— Әнә шулай, күрә белгән күзгә күренә ул. Биекне тәбәнәктән аера белергә кирәк! — Ул теш арасыннан черт итеп төкереп куйды. Ә үзе Шәйхаттар ягына әйләнеп тә карамады.

Күреп торабыз: әнә каршыда гына Шаһидулланың атасы Кашфулла агайның бер якка янтая төшкән салам түбәле тәбәнәк өе утыра. Урамга караган ике тәрәзәнең берсенә аскы өлге урынына мендәр тыгылган. Морҗасы да әллә кая китмәгән. Әмма төтене туры чыга, биек күтәрелә. Бик биек күтәрелә төтене.

Шундый иң тапкыр, иң дөрес, иң гадел җавап табылгач, малайлар хәстәрдән бушап, иркенәеп калды. Күпме баш ваткан булдык. Баксаң, табышмакның ачкычы якында гына торган икән!

Минем эчемдә шулай да бер төер калды. Дөресен генә әйткәндә, кем ызбасы биек соң әле? Тик үсә төшкәч кенә мин ул сорауга бер чама җавап табачакмын — кемнең йодрыгы каты, шуның ызбасы биек була...

Мәчет манарасыннан мәзиннең азан авазы яңгырады. Җаныма яңадан бәйрәм рухы кайтты. Җиргә бүген шундый изге көн килде. Бөтен ызбалар да биек, бөтен адәмнәр дә тигез. Кайдадыр бик якында гына, ахры, безнең Яшелтау артында, сарыклар белән бүреләр бер көтүдә йөри. Резин галошлы, бәрхет түбәтәйле, кызыл ыштанлы, зәңгәр сатин күлмәкле малай шул көтүне көтеп йөри. Әле бүреләр, әле сарыклар килеп аның кулын ялап китә...

Минем әнә шулай онытылып хыялга бата торган гадәтем бар. Менә әле дә... Кемдер минем бөеремә төртте. Мин дерт итеп киттем. Минем янымда, авызын ерып, Ибрай басып тора.

— Ишетәсеңме, әнә Хәмитҗан нәрсә ди сиңа? — дип ысылдый Ибрай.

— Ишетмим.

— «Кендек», «Кендек», «Кендек»...— ди ул сиңа.

Мин кабынып китәм. Хәмитҗан аркылы башын чайкый:

— Юк, әйтмәдем, билләһи, әйтмәдем,— ди.

Ибрай инде Хәмитҗанга килеп пышылдый:

— Күрәсеңме, әнә тегенең ирене кыймылдый. Ни ди ул? «Аркылы баш», «Аркылы баш», «Аркылы баш», ди...

Мин елардай булып танам:

— Якты кояш, икмәк өсте! Әйтмәдем, — дим.— Хәмитҗан бит ятим, ятим кешене корбан бәйрәмендә рәнҗетергә ярамый,— дим.

— Һы, ул бер дә корбан дип тормый. Әнә күзен чылт-чылт йома: «Кендек», «Кендек», «Кендек» диюе шул аның. Эченнән кабатлый...

Хәмитҗанның күзе, чынлап та, чылт-чылт килеп тора иде. Токтымалга түгел бу. Эченнән генә миңа исем атавы бик ихтимал. Ух, юаш имеш... Салынкы колаклы ул аркылы башта әллә нинди астыртын уй бардыр әле. Ачу төене минем тамагыма тыгыла. Ты-

ным кысыла. Тел очыма Хәмитҗанның кушаматы килеп асылына. Ул, үлән кыягыннан менә-менә тамарга торган тамчы сымак, хәзер өзелеп төшәчәк. Тыя алмадым, ычкынды:

— Күзеңне печпелдәтмә, Аркылы баш,— дидем.

— Минем күздә эшең булмасын, кендегеңне өйрәт,— дип җаваплады теге. Мин бу кадәресен үк көтмәгән идем.

— Кара аны, аркылы башыңны буй итәрмен!

— Кендегеңә төртеп, эчеңне тишәрмен!

— Куркытма, Аркылы баш!

— Өркетмә, Кендек!

— Аркылы баш, Аркылы баш!

— Кендек, Кендек, Кендек!

Бу вакыт малайлар, икебезне түгәрәк эчендә калдырып, безне уратып алган иде инде.

— Давай, давай! Сездән куәт, миннән көч! — дип Ибрай өсләтергә кереште.

Хәзер без икебез дә өсләтүгә мохтаҗ түгел идек инде! Йодрыклар күптән төйнәлгән, тешләр кысылган. Беренче булып, мин Хәмитҗанга очып кундым. Ул бераз артка чигенде дә: «Бәйрәм ашы — кара каршы»,— дип минем эчемә типте. Мин бөгелеп төштем. Шунда ук һушымны җыеп дошманның танавына китереп тондырдым. Аннан пырхылдап кан бәреп чыкты. Кан күргәч, мин коелып төштем, Хәмитҗан бөтенләй илереп китте.

— Канга — кан! — дип минем күлмәк якамнан эләктереп алды. Мин кинәт тартылдым. Күлмәк умырылып чыкты. Хәзер инде мин, акны-караны күрмәстәй булып, шаштым. Без, бер-беребезгә ябышып, я көрмәкләшеп китәбез, я ычкынып, аяусыз йодрыклар яудырырга керешәбез. Мин авырту да сизмим, ачу да татымыйм. Бары чәм [1] генә — сугыш чәме генә калды миндә. Ма-

---

[1] Чәм — ярсу, үч кайнау.

лайлар, каккан казык төсле, кымшанмый да басып торалар. Катнашучы да, аралаучы да юк. Тик Ибрай гына безнең тирәдә сикергәләп йөри:

— Бирешмә, бирешмә! — ди ул, кайсыбызгадыр көч бирә.— Сездән йодрык, миннән тел! — Мин аның тавышын ерактан, урман артыннан ишеткән кебекмен... Нәкъ шул вакыт Хәмитҗанның йодрыгы минем күз төбенә килеп тиде. «Күздән утлар чәчелде» дигән нәрсәне мин тәү тапкыр әнә шунда, сигез яшемдә, татыдым. (Аннан соң дөнья байтак ут күрсәтте.) Әйе, башта очкыннар чәчелде, аннан соң күз алдымда кара түгәрәкләр тәгәрәргә кереште, ләкин мин бирешмәдем. Шунда ук исемә килеп, Хәмитҗанның салынкы колагына ябыштым. Ул тартылмады, киресенчә, миңа таба тайчанды да, җан ачуын җыеп, башы белән минем чигәмә төкеде...

Моннан ары алыш күпме һәм ничек баргандыр, ачык кына хәтерләмим. Әмма шуннан соң да бер-бере безне байтак дөмбәсләдек бугай. Минем хәлем тизрәк бетте. Хәмитҗан миңа караганда яшькә дә олырак, гәүдәгә дә базыграк иде. Ахырда, хәлем мөшкелләнгәнне чамалап, ул мине, ыштан бөрмәмнән алып, өерелдереп-өерелдереп йөртте дә сыртым белән җиргә сукты. Калак сөягем астына каты, очлы нәрсә килеп төртелде. Күрәсең кырлы таш булды. Минем сыным катты. Котыру чигенә җиткән Хәмитҗан минем күкрәгемә менеп тубыкланды. Авыз читемнән нindider җылы нәрсә тәгәрәп чыгып, битем буйлап йөгерде. Мин кайдадыр батып барам, батып барам. «Аралагыз безне, коткарыгыз мине!» — дип кычкырмакчы итәм. Кычкырырлык хәлем юк. Безне әйләндереп баскан малайлар инде эреле-ваклы каккан казыкларга әйләнгән. Кычкырсам да ишетмәсләр. Бары күзләре генә елтырый. Алар да чын күз түгел, ботак тишекләре икән.

...Кырык дүрт ел үткәч, моңа охшаган хәл гомеремдә тагы бер тапкыр кабатланды. Мине куралмаучы

берәү ул чак учлап-учлап минем өстемә пычрак ыргытты. Минем эшемне, шәхесемне, мәхәббәтемне кимсетте, йөрәгемне менеп таптады, җанымнан кара кан бөркелеп чыкты. Ул көнне дә безне кешеләр тезмәсе уратып алган иде. Пычрак сибүче кеше — табигате белән юаш, бары минем аркада гына чыгырынан чыккан бала, ә битараф карап торучылар бергә уйнап йөргән гамьсез, аңгыра малайлар түгел иде. Бергә хезмәт иткән, кайгы-шатлык бүлешкән, язмыш уртаклашкан олы кешеләр иде. Якламаслармы дип өмет иттем. Эндәшмәделәр. Ә бит алар мине ихтирам итә, кайберләре хәтта ярата кебек иде. Курыктылармы? Әллә: «Безгә эләгә тора бит, аңа да эләксен әле»,— диделәрме икән? Бәлки, алар үзләренчә хаклы да булгандыр...

...Моңа кадәр малайлар кушаматымны әйтеп үчекләүдән тыш, мине җирле юкка кыерсытмады. Дәүрәкләр канат астына ала килде. Хәзер нәрсә булды соң? Нигә минем өстән берәү дә Хәмитҗанны тартып төшерми? Баягы күзле казыклар, бер-берсен куып, түгәрәк тирәләп әйләнә башлый. Әйләнгән җирнең үзәге сымак, уртада минем Олы инәем басып тора.

Дөнья яңадан үз урынына утыра. Инде мин үзем, акрын гына тирбәлеп, кайдадыр әллә очып, әллә йөзеп барам. Яңагымда йомшак, җылы нәрсә сизәм. Бу Олы инәемнең уч төбе — мин аны шунда ук таныдым.

Шушы кулның җылысы һәм кодрәте моннан ары да мине бөтен гомерем буе саклаячак һәм яклаячак. Минем тынгысыз һәм дуамал башым өчен ул иң ышанычлы, иң мәрхәмәтле төяк [1] булачак. Соңгы сулышымны алган мәлемдә мин, мөгаен, бик аз нәрсәләрне хәтергә төшерергә, бик аз затлар белән хушлашырга өлгерермен. Ләкин шунысын ачык беләм: әллә кайчан дөнья куйган Олы инәемнең йомшак кулын искә алырга,

[1] Төяк — «туган туфрак» мәгънәсендә.

аның җылысы белән хушлашырга вакыт табармын. Башкача мөмкин түгел.

Сәер тынлык эчендә әллә очып, әллә йөзеп барам. Башым Олы инәемнең уч төбендә рәхәтләнеп ята. Кояш нурлары, әйтерсең, керфекләремнән тартып, минем күзләремне ача. Мин башта биек зәңгәр күкне, аннан соң Олы инәемнең хәсрәтле йөзен күрәм. Ул мине күтәреп бара. Мөгаен, өйгә кайтып киләбездер...

Мине урам як өйгә — кунак өенә салдылар. Башка вакытта монда кереп йөрү дә сирәк эләгә безгә. Хәзер түр башында йомшак түшәк өстендә җәелеп ятам, әйтерсең лә, бер түрә... Артык җәелеп тә булмый шул әле. Тын алган саен калакбаш сөяген нәрсәдер яндырып үтеп җибәрә. Тамак кырыр әмәл юк, укмашкан кан пырхылдап килеп чыга. Ул канны сөртеп торырга минем кырыйга кызыл башлы озын тастымал салдылар.

Мине кызганып, чеңләүче дә, Хәмитҗанны каргап, сөрәнләүче дә булмады. Бер тапкыр яныма этием кереп чыкты. Ул миңа текәлеп карап торды да көрсенә биреп куйды:

— Ярар, ныграк булырсың...— диде, бөтен юатуы шул булды.

Абыйларым эндәшми генә күз салып чыктылар. Бәләкәчләрне, ахры, минем янга кертмиләр. Әле күзгә күренгәннәре юк. Кече инәем иелеп минем маңгаема иреннәрен тидерде. Шул чак битемә аның берничә бөрчек эре-эре күз яше тамды. Шул җылы дым, гүя, миңа хәл кертте, рухымны иркәләде. Күңелемдә кинәт рәхмәт тойгылары уянды. Иң кирәкле сүзләрне генә әйтеп, аның үзен юатасым килде:

— Елама, Кече инәем, елама, мин сине дә яратам бит,— дидем.

— Әйе, яратасың, мине дә яратасың,— диде Кече инәем,— мин бит ул хакта еламыйм. Мин бөтенләй еламыйм... Кайсы җирең авырта, балам?

— Инде бер җирем дә авыртмый,— дидем мин. Дөресен әйтеп, Кече инәемне кайгыртып булмый бит инде.— Корбан бәйрәме бетмәдеме әле?

— Юк, бетмәде. Әнә, күрәсеңме, алдыңда никадәр бәйрәм сые, хәтта ширбәт тә бар. Тамагыңа кабар идең.

Минем яныма поднос тотырып тәмле-томлы ашлар куелган. Аларны күргәч тә, күңелем болганып китте.

— Тәмле нәрсәләрне җыеп, Әсгатькә илтеп бир, Кече инәем, зинһар,— дип ялварам,— аның колагын ат тешләп өзде. Алар умач уып кына торалар.— Менә-менә укшып җибәрәм дип куркып, күзләремне йомам. «Ярар, балам»,— дип Кече инәем подносны алып чыгып китә.

Аш өеннән чыгарып, Олы инәем чәйнек борыныннан миңа нindидер ачы су эчерә. Әрем суы булырга тиеш. Менә сиңа бәйрәм сые! Авызны бөреп бара, ә үзен уртлаган саен уртлыйсы килә.

— Талак-бавырыңа шифа булыр, эч, балам, эч,— ди. Бераздан күңел өсте җиңеләеп китте.

...Хәтта миңа рәхәт тә. Мин инде Яшелтау битләвендә искиткеч ямьле, аяз көндә көтү көтәм. Ап-ак бөдрә бәрәннәр соры бүре балалары белән куышып, сикерешеп уйнап йөри. Тегеләр юри генә бер-берсенең колагыннан тешләгән була. Аларның инәләре белән аталары — олы сарыклар белән олы бүреләр — бәбиләренең татулыгына сокланып, читтән генә карап тора. Куанычларыннан тәмам ашаудан язганнар. Менә бер аңгыра бүре баласы исәр бәрәннең койрыгыннан тартты. Теге, мәэлдәп, бәла салырга керәште, үзе шунда ук, чигенә биреп, иптәшенең кабыргасына килеп төкеде. Моны күргән бөтен сарыклар, үчләшеп, бүреләргә ташланды һәм күз ачып йомганчы тегеләрне берьюлы буып, кырып салды. Сарыклар каядыр китеп югалды, тау битләвендә бары бүре үләксәләре генә ятып калды...

Инде ут белән су маҗарасы башланды. Тәүдә алар икесе янәшә килә. Су борылып-борылып ага, ә ут, кызыл ялларын тузгытып, яр буйлап йөгерә. Елга шундый шат, бәхетле, аның өстенә утның тылсымлы шәүләсе төшә. Мең төрле нур уйный су өстендә. Үз матурлыгына үзе таң калып, каядыр ашыга бахыр елга. Бәйрәмгәме? Туйгамы? Шатлыгына чыдый алмый сикергән бер тамчы ялгыш утка тамды. Тәкәббер ут моңа гарьләнде, ысылдап, шунда ук суга ябырылды. Тегесе рәхим сорап сүз әйтергә дә өлгерә алмады, томанга әйләнде, җиһанга таралды. Үз тинтәклеге аркасында судан аерылган ут, ачуыннанмы, үкенүеннәнме — белмим, нидәндер, йомгак булып йомарланып, офык читенә табан тәгәрәде. Әнә әле булса, зәһәрен чәчә-чәчә, тәгәрәп бара... Җирдә тамчы су калмаган.

— Су!

— Мә, балам,— Олы инәем минем иренемә баягы чәйнек борынын китереп тери.— Шундый әйбәт, тыныч йокладың,— ди ул.— Хәзер инде иртәнчәк.

Урам тәрәзәсеннән минем битемә кояш төшә. Мин җай гына кояшка табан борылам. Шул чак тәрәзә каршысында акрын гына Хәмитҗанның аркылы такыр башы калкып чыга. Мин тәүдә аның как түбәсен, аннан ялбыр колакларын, боек кара күзләрен шәйләдем. Мине күргәч, ул әллә еларга, әллә елмаерга итте — өске ирене калтыранып куйды. Шуннан ул, яссы маңгаен сак кына тәрәзә пыяласына терәп, катып калды. Мин дә аңа сүз кушмадым. Юк, ачудан түгел, хәлем мөшкеллектән эндәшә алмадым. Хәмитҗанны Олы инәем дә күрде, әмма аның да теле сүз әйтмәде, кулы ишарә ясамады. Без Хәмитҗан белән бик озак шулай йөзгә-йөз килеп тордык. Аның күзләрендәге кайгыны күреп чыдый алмый, мин башымны икенче якка бордым.

«...Менә сиңа бәйрәм!» — дип уйлап ятам мин. Нигә шулай икән ул — бәйрәм чорында адәмнәр бер-берсен

шөйлә рәнҗетә. Былтыр сабан туенда Каран-Елга гармунчысын шәһәрдән килгән бер зимагур хәнҗәр белән чәнечте. Теге гармунчы чатан булып калды. Яз көне ташу каршылау җомгасында Кызлар тавында үзебезнең авыл егетләре, урамга-урам каршы килеп, канга тузып сугышты. Әле кышын гына Ябалак урамында туй чорында адәм үтерделәр. Хәтта тула өмәсендә дә тәпәләшеп алырга җай табалар. Ызгыш-кырылыш чыгарыр өчен, кешеләр, әйтерсең, бәйрәмне генә көтеп торалар. Ел буена бөтәйтеп кигән иң матур киемнәрен, бер-берсенә ташланып, өзгәлиләр, пычраталар, канга манчыйлар. Яман сүзләр әйтешәләр, чибәр йөзләренә җәрәхәтләр салалар. Бәйрәм-туй чоры җиттеме, безнең бөтен өй эчебез буйга җиткән Мортаза абыем өчен дер калтырап тора. Ул да, минем кебек, үтә гарьчел. Торганы белән бер сугыш чукмары. Кәләш алып бирсәк, акылга утырмасмы дип өмет итәбез дә... Ничек булып чыгар инде. Ифрат үзсүзле ул. Әле кичә дә, корбан бәйрәмен санга да санамый, таң белән ике атны җигеп, басуга сабан сөрергә китте. Әтиемне дә, Олы инәемне дә тыңламады. Имеш, алар, егет-җилән бергәләп, сүз куешканнар, янәсе, аларның «корбан бәйрәменә катнашы юк». Әтием дә артык үҗәтләнмәде. «Мин элек тусам, бәлки, син белеп тугансыңдыр»,— дип, ризалашуын да белдергәндәй итте. Сәер ул минем Мортаза абыем. Куанып бәйрәм итәр урында җир сөреп йөргән адәм ниндирәк тискәре булырга тиеш — үзегез уйлап карагыз.

Мин тагы да тәрәзә ягына әйләнәм. Бу юлы инде минем күз алдымда Хәмитҗанның чокыр җилкәсе тора. Ул, урамга карап, безнең нигез ташында утыра, ахрысы. Үзе кымшанмый да...

Икенче көнне дә, өченче көнне дә нәкъ шул урында мин Хәмитҗанның я йөзен, я җилкәсен, я яңагын күрдем. Иртән дә, көндез дә, кич тә ул үз урынында калды. Безнекеләрдән аны берәү дә кумады, берәү дә аңа

ачуланмады, күрәсең. Тик мин тәү башлап урамга чыккач кына, мине күреп, артына да әйләнеп карамыйча, торып йөгерде. «Хәмитҗан!» — дип кычкырдым мин. Ул ишетмәде.

Моннан соң да дөнья үз җаен җайлап бара бирде. Малайлар белән ызгыштык та, ярәштык та. Барысы да, Олы инәем әйтмешли, эт тәнендәге җәрәхәт кебек, җөйсез төзәлә килде. Тик бер Хәмитҗан гына бүтәнчә миңа бервакытта да кул күтәрмәде. Әмма «Кендек»не миңа барыбер ябыштырдылар, куптармаслык итеп ябыштырдылар.

Тап унбиш ел үткәч, мин җәйге иртәдә яу кырында ялгыз имән төбенә килеп авачакмын. Күкрәгемне шунда тишеп кергән тимер ярчыгы соңрак, минем үпкәмне өңеп [1], үзенә оя ясаячак. Янә дүрт елдан шул оядан кан саркый башлаячак.

...Менә мин Мәскәү янында үпкә авыруларын дәвалый торган больницада ятам. Түбәләрдән апрель тамчылары тама. Яз — безнең өчен иң хәтәр чак. Нишләптер нәкъ шушы мәлдә, җир, уянып, өр-яңадан яши башлаган бер мизгелдә, минем кебекләрнең дөнья белән алыш-бирешләре ешрак өзелә. Бу яз үтеп китсә, ихтимал, дибез, үләнгә дә аяк терәрбез. О, ул ихтимал! Безгә олы өмет, олы иман хәзер.

— Мотоцикл белән ниндидер милиционер килгән, сезне сорый. Керсенме? — дип килеп әйттеләр миңа.

— Кем? Милиционер?.. Бар гөнаһларым өчен берьюлы җавап алырга килгәндер,— дип шаярган булдым мин.— Керсен әйдә.

Закон кешесен яткан көе каршылау килешмәс. Торып утырдым. Көтәм.

— Мөмкинме? — диде керүче. Аның иелгән башы ишек кашагасына чак-чак кына тими калды. Кергәч тә

[1] Өңеп — өн ясап.

ул, әйтерсең, үзенең галәмәт зур гәүдәсен кайда куеп бетерергә белми, аптырап торды. Фуражкасын салды. Аның яссы маңгае буйлап уң кашыннан өстәрәк сырлы-сырлы тирән җөй сузылган. Мин иң элек әнә шул җөйне күрдем. Янә шуны шәйләдем: миңа үтә таныш моңсу күзләр карый, тилмереп, ялварып карый.

— Хәмитҗан! — дидем мин. Ул ишетмәде. Бәлки, минем тавышым чыкмагандыр. Шундыен пәһлеван кинәт кенә бөршәеп, бәп-бәләкәй булып калды да минем түшәгем янына килеп тубыкланды. Хас теге чак тәрәзә пыяласына капланган шикелле, маңгаен минем койка тимеренә терәде.

— Кендек! — диде.— Сине күрер көн дә бар икән! — Ул буылып еларга кереште.

— Я, я, Аркылы баш, куй, синең кебек баһадирга елау килешми,— дип мин аның чәчен сыйпадым.

— Күз яшьләрем бугазымнан бугач, нәрсә эшлим, Кендек?

— Җитәр, җитәр, Хәмитҗан. Тор, утыр.

— Тыйма мине, елыйсын елап бетерим,— диде ул, тынычлана төшеп. Бераздан бөтенләй тынып калды. Кулъяулыгын алып, йөзен сөртте. Шуннан гына башын күтәрде. Ләкин, күпме инәлсәм дә, урыныннан кузгалмады.

Байтак ара күзгә-күз карашып торгач:

— Саумы? — дип мин кулымны суздым. Күрештек. Уң кулында аның ике бармагы юк иде.

— Сине күрер көн дә бар икән,— дип кабатлады ул.— Таба алмамдыр дип өмет тә өзә башлаган идем инде. Таптым шулай да...

Хәмитҗан түкми-чәчми үзенең маҗараларын сөйләп бирде:

— Синең үпкә чире белән авырып китүең хакында авылдан яздылар. Мәскәүдә ята, диделәр. Мин моннан алтмыш-җитмеш километр җирдә генә хезмәт итәм. Бер ай буе инде хезмәттән буш арада мотоциклга

атланам да һәр көн Мәскәүгә җилдерәм. Башта үпкә чирлеләр яткан бөтен больницаларны кыдырып чыктым. Юксың. Янә бер әйләндем. Шуннан соң мондый больницаларга берәм-берәм тиеп уздым. Юксың. Барлык санаторийларны әйләнеп кайттым. Юксың. Якын-тирәдәге район, хәтта авыл больницаларына да сугылдым, юксың, юксың... Синең өчен хафалана, ныгытып хафалана башладым. Соңга табан «больница» дип язылган йорт күрсәм, дертләп китә торган булдым. Ул сүзгә карата бер төрле нәфрәт туды... Ахмак мин! Адресыңны сорап, авылга телеграмма бирергә баш җитмәгән. Әле монда килгәч төшендем шуны. Ә сине табуым «бирәсе килгән колына — чыгарып куяр юлына» дигән мәкаль буенча булды. Әле бая гына фартка кул селтәп, Мәскәүдән чыгып килгәндә, бер бичәкәй, «утырт әле» дип, кул күтәрде. Ичмасам, берәүгә игелегем тисен дип, утырттым. Сөйләшә торгач, аның шушында сестра булып эшләвен аңладым. Синең хакта сораштым. Белми. Байтак урау булса да, тезгенне бу якка тарттым. Менә, насыйп булгач, күрештек.— Хәмитҗан бөтенләй тынычланды булырга тиеш. Аның тавышы да хәзер талгын агыла. Ләкин бу тышкы тынычлык күпкә бармады. Баягыча ук хәсрәт һәм хәвеф тулы күзләрен миңа төбәде дә:

— Кендек! — диде ул үзәк өзгеч әрнүле тавыш белән.— Синең чиреңнең сәбәпчесе мин бит! — Теге чак күкрәгеңне менеп таптамасам, син бу көнгә төшмәс идең... Мин, мин гаепле! Гафу ит дип әйтә алмыйм. Мине гафу итүдән генә сиңа җиңел булмаячак. Анысын беләм. Миңа гафу кирәкми дә. Тиеш тә түгел! Тик син шуны гына күр, шуны гына бел: синең белән бергә җәфаланам, бергә өмет итәм, бергә ышанам. Әгәр мөмкин булса, бер үпкәмне кисеп, ярты җанымны ярып бирер идем. Мин сине эзләгәндә, шуны тәвәккәлләдем: бәлки, докторлар минем бер үпкәне сиңа күчереп куя

алырлар. Ә, Кендек? Хәзер бу эшне башкара алалар, диләр бит. Әйтеп карыйк докторларга...

— Исәр син, Аркылы баш,— дип юатмакчы иттем мин аны.— Беренчедән, докторлар хәзергә иске үпкәне генә кисеп ташлый беләләр, яңасын куя алмыйлар; икенчедән, минем үпкәне бит фашист тимере тишеп үтте. Бәланең башы шунда. «Не виноват военкомат, виноват гитлеризм», дигән җырны ишеткәнең бардыр бит. Шуның шикелле, синең катнашың юк монда.

— Беләм. Немец тимере хакында да, «кем виноват» хакында да беләм. Әгәр теге чак имгәнеп калмаган булсаң, шул бармак очыдай юньсез тимер ярчыгына гына бирешер идемени синең үпкә? Затың андый түгел синең. Сезнең затны юкка гына «имән үзәкле» дип йөртмиләр бит. Аһ, сабый чак, сантый чак!— дип көрсенде ул.

Хәмитҗанны үгет белән түгел, ачу белән генә җиңеп була торган иде.

— Нәрсә син, Аркылы баш, минем баш очында чеңләргә тотындың әле? — дип җикерендем булдыра алганча.— Мин бит үләргә җыенмыйм. Син баядан бирле күзеңнән дә, авызыңнан да селәгәй агызасың.

— Үлмәячәксең дә!— дип раслады Хәмитҗан. Ә син минем күз яшьләремне, минем вөҗдан газапларымны кимсетмә. Монысы сиңа килешми.

Хәмитҗан миңа җәл булып китте. Ул янадан каккаланып-суккаланып үскән ятим малайга әйләнгәндәй тоелды. Каты бәрелүемә үкенеп куйдым.

— Син үлмәячәксең,— дип тыныч кына кабатлады ул,— сиңа бер тапкыр җеназа укылган иде инде. Хәзергә сабыр итеп торсыннар. Югыйсә ешракка туры килер.

— Кайчан? Ничек?

— Нигә, белмисеңмени?

— Ю-ю-к! — Мин аптырап калдым.

— 1943 елда. Берәү дә сөйләмәдемени сиңа?

— Сөйләмәде.

— Алайса мин сөйлимме?

— Сөйлә. Үз җеназаң турында әңгәмә тыңлау мәзәктер ул...

Хәмитҗан минем өчен, янәсе, имин беткән, башка берәүләр өчен үтә һәлакәтле тәмамланган, күңелемә гомерлек яра салган тарихны сөйләп китте. Ул китте. Соңыннан баш очымдагы тумбочка өстендә газета кәгазенә төрелгән төенчеккә күзем төште. Сак кына чишеп карадым. Анда бөршәеп беткән саргылт яшел ике алма иде. Ул китте. Шул безнең соңгы күрешүебез, соңгы аерылышуыбыз булды. Күп тә үтми, аның хакында коточкыч кара хәбәр килде. Исерек бандитлардан яшь кенә бер кызны яклаганда, аның йөрәгенә пычак кадаганнар. Имеш-мимешкә караганда, бу көн ул хәтта хезмәттә дә булмаган. Хәбәр миңа вакытында килеп юлыкмады. Шунлыктан мин аны җирләргә дә бара алмадым. Әле яңарак кына миңа бер үпкәсен, ярты җанын ярып бирергә дип килгән Хәмитҗан, шулай итеп, бөтен гомерен берьюлы бүтән бер гомерне саклау өчен биргән.

Бу хәбәрдән соң минем рухымны өзлексез ике хәсрәт таларга тотынды. Бердән, гаҗәеп кордашымның фаҗигале үлеме әрнетсә, икенчедән, үз язмышым тынгы бирми. Хәмитҗан сөйләгән нәрсәләрдән соң мин үземне кем исәбенәдер гомер сөргәндәй, бурычка яшәгәндәй хис итә башладым. Шушы уй торсам да, ятсам да миемне иги: бурычка, бурычка, бурычка...

Ул исә бу тарихны мине юату, өметемә куәт өстәү нияте белән, миңа озын гомер юрап сөйләде. Баксаң, бөтенләй башкача килеп чыкты. Бер башыма урын таба алмыйм. Врачларны да хәвефкә төшердем. Менә ул фаҗига. Мәрхүм ничек әңгәмә иткән булса, аны сүзмә-сүз кабатлап чыгам. Эчемдә сакларга башкача чыдамлыгым җитми.

«Калды газиз башым яшь көйгә»

...Менә шушы җирдән маңгай сөяген немец пулясы бораулап үткәч, мин байтак заман исәңгерәп йөрдем. Атна-ун көн чамасы авылда да булып киттем. Мин кайткан көнне шулай клубта — халыкның йончу күңелен аз-маз күтәрмәкче булыптыр инде — укытучылар концерт куйды. Биеделәр, җырладылар, шигырь сөйләделәр.

Ахырда сәхнәгә синең хатының Рауза чыкты. Кинәт халык арасында ниндидер шомлы чыш-пыш үтте. Үтте дә тынды. Бу көн, ак күбәләк кебек саф, чибәр Раузаң үзеннән дә сафрак, үзеннән дә чибәррәк иде. Шундый мәлләр була, әйтик, көтмәгәндә синең алда офык чигенә, баш өстеңдә күкләр күтәрелә, ап-ачык итеп искән җилне күрәсең. Рауза килеп баскач, минем өчен дөньяда чикләр югалды. Әйтерсең, җир йөзендәге туп тавышлары берьюлы тынды, тәннәрдәге сызлаулар басылды, яралар уңалды, шикләр таралды. Чын нәрсәләрдән бөтен җиһанда бары ул гына — бер Рауза гына торып калды. Аның йөзендә әллә сагышлы тантана, әллә тантаналы сагыш чагыла иде. Бәлки, ул да бөтенләй үк чын түгелдер — бер җыр җырлар өчен генә күктән төшкән сихри заттыр... Кыскасы, үзеннән дә илаһирак иде ул.

«Ашказар»ны җырлады ул. Тәүдә, җырның беренче яртысын җырлаганда, баш өстендә ниндидер куркыныч тынлык асылынып торды. Менә-менә ул авып төшәр дә адәмнәрне басып үтерер сымак иде.

Чәшкеләргә китеп вафат булды,
Калды газиз башым яшь көйгә.

Җырның икенче яртысын ул бигрәк тә җан тетрәткеч итеп башкарды. Ләкин нишләптер, ду килеп кул чапмадылар. Бер-ике җирдә чәбәкәй иткән булдылар. Анысы да кыяр-кыймас кына...

Кинәт арткы рәттәге бер хатын сыктап елап җибәрде. Аңа күршесе кушылды... Минем яндагы кыз бала да кулы белән йөзен каплады. Әле тегендә, әле монда яше-карты буылып еларга кереште. Бераздан бөтен зал үксергә тотынды. Рауза каушап калды. Җыры белән ул кешеләрнең ачык җәрәхәтләренә кагылды, ахры. Аның йөзенә борчылу чыкты. Әйе, күпме «газиз башлар калды яшь көйгә». Хәер, алай дисәң, инде өченче ел сугыш бара. Кешеләр күп нәрсәгә күнектеләр, җырның да моңлысы, фаҗигалесе ныграк күңелгә ятучан булып китте бит.

Кешеләр туктала алмый һаман үкси. Берәүне берәү юатмый да, тыймый да. Бер минем күземдә яшь юк. Шундый ук таш бәгырьгә әйләндем микәнни?

— Клубта гел шулай җырлап елашасызмы? — дип сорадым мин, әлеге кызга иелеп. Ул тынып калган иде инде.

— Юк,— диде.— Бу юлы чыдап булырлык түгел шул.

— Нигә алай?

— Бер атна әүвәл инде Кендек турында кара кәгазь килде. Бөтен авыл белә. Раузага әйтергә телебез бармый. Күтәрә алмас дип куркабыз, бигрәк ярата иде.

Мин акрын гына җир астына батып, кире калыктым. Алдагы биек урында әле булса Рауза басып тора. Ул шундый нечкә, аз гына җил тисә дә, чайкалып, авып китәр төсле. Кечкенә генә шушы хатынның бахыр иңнәренә менә никадәр хәсрәт йөге ауды. Сабырлыклар бирсен үзенә! Аягүрә басып, авылдашларга кычкырасым килде: «Ни эшегез бу? Нигә гөнаһсыз шушы җан иясен кумәкләп җәзалыйбыз соң әле? Аны, кызганып, һәлак итәбез түгелме? Иртәгә соң, иртәгә ничек аның күзенә күренербез? Ничек йөзенә карарбыз?» Кычкырмадым. Ихтимал, мин түгел, авылдашлар хаклыдыр. Бәлки, алар рухы имгәнгәнче бу хатын тагы бер тап-

кыр җырлап калсын, дигәннәрдер. Бәхетсезлекнең бер төнгә соңлап калуы, бәхетнең бер төнгә китми торуы кеше өчен үзе зур бүләк түгелмени? Хатын өчен ире, димәк, үз гомереннән тыш, әле булса яшәп ята.

Иртән, Рауза мәктәпкә киткәч, сезгә бардым. Әтиеңнәр бу хәлне белә иде. Алар да, бөтен хәсрәтне үз күкрәкләренә алып, Раузаны саклыйлар икән. Язмышны алдап булмаячак, һаман да яшерү бары алда торган һәлакәтне генә арттырачак дип, без шушы хәйләсез хәйләгә чик куярга булдык. Чамадан тыш авыр бу вазифаны мин үз өстемә алдым. Бәллүдә тыныч йоклап яткан улыңа карадым. Котым очып китте. Шушы баланы менә-менә атасыз калдырачакмын сымак тоелды.

Миңа ул вазифаны үтәргә туры килмәде. Күрәсең, бөтен авылны басып торган кайгы буасы башка җирдән ерылгандыр. Таш булып каткан Раузаны ике иптәше җитәкләп өйгә алып кайтты. Аны чишендереп сандык өстенә утырттылар.

— Кендекне үтергәннәр,— диде ул байтак торгач,— хәбәре килгән. Менә,— таушалып беткән кәгазь кисәген ул үрелеп өстәлгә куйды.

— Кәгазь әле әҗәл түгел,— диде Кече инәең.— Без аңа ышанмадык. Бала минем күкрәгемдә яши. Аның урыны менә монда суынмаган әле, димәк, аны кабер алмаган. Сабыр бул, кызым.

Раузага беребез дә якын килмәдек, юатмадык. Кичкә кадәр диярлек шулай сүзсез утырдык.

— Язмыштан узмыш юк,— дип көрсенде әтиең,— ни кылсак та, акрынлап күнегергә туры килер. Шәмгә ут ал, әнкәсе. Якты күңелле егет иде, караңгыда озатмыйк үзен.

Шул кичне без сине, һәркем үзенчә җеназа укып, җир куенына тапшырдык.

Ни арададыр, ис итмәстән үрелеп, мин өстәлдәге теге язуны алдым. Кат-кат укып чыктым. Әйе, исеме, фамилиясе, атасының исеме — бөтенесе дә синекенә

туры килә. Адресы да сезнеке. Туган елы гына байтакка туры килми. Анысын писарь бутаган булырга тиеш. Тукта! Нәрсә эшләп соң әле монда «рядовой» дип язылган?

— Званиесе кем иде? — дип сорадым, «иде» дигәнемә үземнең тәннәрем чемердәп китте.

Җавапны этиең кайтарды:

— Анда баргач, бөтенесе дә бер дәрәҗәгә күчә. Званиегә карап түгел, кылган яхшылыкка карап кабул итәчәкләр.

— Монда «рядовой» дип язылган. Ул бит командир. Шулай түгелмени?

— Мин язуны укый алмадым, — диде Рауза. Аңа җан кергәндәй булды. Кинәт калкынып куйды. Ләкин шунда ук яңадан бөршәйде.

— Командир, безнеке командир, — дип пышылдады Кече инәең, — командирны «рядовой» дип язмаслар ла...

Күңелләрдә зәгыйфь кенә өмет кузы җемелдәгәндәй булды. Язмыштан узарга тырышып, язуның башка хуҗасын эзләргә тотындык. Без башта сезнең фамилияне йөрткән кешеләрне, аннан синең адашларны, урамнан урамга күчеп, барлап чыктык. Берәү дә туры килми. Әтиең исеме исә, ул бөтен авылга бердәнбер... Бара торгач, Акманай утарына төшеп киттек. Ул да бит безнең авылга карый. Урамның аргы башыннан бер-ике өйгә кагылуыбыз булды, Кече инәең әрнеп кычкырып та җибәрде:

— Кияү! Акманай кияү!! Ой, бахыр Кәфия сеңелем! Ой, бичара! Киявеңне бигрәк яратам, апа, улыңа шуның исемен куша күрче дип, инәлде бит, бәхетсез җан!

— Әйе, кияүнең атасы белән без адашлар идек. Бик күптән дөнья куйды. Һәйбәт кеше иде, мәрхүмең, — дип раслады этиең.

Җизнәңнең исеме дә, атасының исеме дә, фамилиясе дә синекенә туры килә. Ләкин әле шик таралмады. Куанмадык та. Күзгә озын төндә шулай тып-тын утырып чыктык. Йоклап китсәк, бу ачы өметебез төшкә әйләнер дә, таралып, юк булыр дип курыктык. Мөгаен, шулай иттек.

Иртәнчәк теге кәгазьне тотып, мин авыл Советына киттем. Анда эшләүче читтән килгән секретарь кыз авылда синең өлкәнрәк сыңарың барлыгын башына да китермәгән. Барлык төп кенәгәләрне актарып чыкканнан соң, язу синең җизнәң хакында булырга тиеш дигән фикергә килдек. Әҗәлне аның өлешенә чыгардык.

Иң авыры икенче көнне булды. Елый-елый шешенеп беткән Кәфия апаң килеп керде сезгә. Кулында шул ук язу. Аны Кече инәеңә сузды:

— Апа, нигә шулай иттегез инде? Бу кәгазь бит сезгә килгән. Аны сезгә биргәннәр. Ни өчен аны миңа аткардыгыз? Шушы гаделлек буламы? Апа, мә ал, кире ал бу каһәрле кәгазьне! — Кече инәең аны җитәкләп сәкегә утыртты. Кәфия инде, күзләрен мөлдерәтеп, Раузага карады:

— Килен! Киленкәем! Синең балаң нибары берәү генә, минекеләр итәк тулы! Берәү ятим калыр урында бишәү ятим калсынмыни инде? Берәү тилмерер урында, бишәү тилмерсенмени? Үзем дә ятим үстем, тамагым — аш, өстем кием күрмәде... Уф аллакаем!

Ул бераз үксеп алды да яңадан Кече инәеңә эндәште:

— Нәрсә дип кенә, апа, теге чакта киявеңнең исемен улыңа куштың икән? Бүтән исем беткәнмени сиңа? Шуны кушмаган булсаң, бәлки, бу кайгыларга да төшмәс идек.

Кече инәең кайгысыннан алмашыну чигенә җиткән сеңелесенең бер сүзен дә кире какмады:

— Алдырыр көн яздырыр, ди шул. Болай булырларын белсәм, бер дә генә кушмас идем дә бит,— дип Кәфиянең башыннан сыйпады.

— Ниләр генә кылыйм инде, ниләр генә кылыйм? Кемгә барып күз төбәрләр минем балаларым? — дип Кәфия яңадан бөгелеп төште.

Гаепле кеше кебек, моңача башын иеп утырган әтиең сүзгә кушылды:

— Исән-сау чакта ташламабыз, балдыз. Кулдан килгән ярдәмнән мәхрүм итмәбез балаларыңны. Хәсрәтеңне җиңеләйтерлек бүтән сүз таба алмыйм — үпкәләмә. Әйткән вәгъдәм — иман. Син мине беләсең, балдыз.

Нәкъ кичәге урында сандык өстендә бөршәеп утырган Рауза кинәт атылып торды да Кәфиянең муенына килеп сарылды. Тегенең кулбашына башын салып, тыела алмый еларга кереште. Кәфия дә аңа сыенды. Бер-берсенең кочагына сеңеп, ике хатын бик озак яшь түкте. Әйе, аларның арасында бер әҗәл тора иде. Кем әҗәле? Анысы безгә барыбер бөтенләй үк анык түгел иде әле...

...Миңа бер үпкәсен, ярты җанын бүлеп бирергә дип килгән Хәмитҗан менә шуларны сөйләп китте. Китте дә икенче берәүнең гомерен саклау өчен бөтене белән үк гомерен бирде.

Кече инәемнең ике туган сеңелесе Кәфия апам моннан ары гел мине әзәрли торган булды. Аның хәйләсез зур кара күзләре, я үпкәләп, я тилмереп, гел миңа карый. Әйтерсең, мин үземә тәгаенләнгән немец пулясын җизнәмә аткарганмын, шуңа күрә безгә дигән кара кәгазьне апама җибәргәннәр. Беләм, минем беркем алдында да гаебем юк. Үз өлешемә төшкән җәфалар да җитәрлек булды. Һәм аларны үзем күтәрәм. Өй түбәләреннән апрель тамчылары түгел, минем санаулы көннәрем тама. Бәлки, соңгы тамчы минем соңгы сулышыма туры килер. Ә шулай да мин хәзергә теремен.

Тере кешегә үкенү дә, шикләнү дә, газаплану да ят нәрсә түгел. Хәтта өмет тә бөтенләйгә ташлап китмәде хәзергә. Ихтимал, әнә ул тамчылардан гомерлерәкмендер әле?!

Шушы хәвефле кичерешләр вакытында мин бер гади хакыйкатьне төшендем: башкаларның үлемендә минем дә өлешем булган кебек, минем яшәвемдә мәрхүмнәрнең дә дәхеле бар. Хәмитҗан юкка гына юата мине. Мин әле үзем өчен үзем ныгытып бер тапкыр да үлмәдем. Бәлки, бүтәннәр минем өчен дә һәлак булгандыр — бурычка миңа гомер калдырып?..

...Бервакыт мин, әле үсмер чагымда, кояш батып барганда Чагылтау башында йөргәндә чакматаш өеменә тап булдым. Кемдер мунча ташына дип җыйгандыр күрәсең аларны. Нишләптер, иелеп, өемдәге бер йомры ташны алдым. Ул җып-җылы иде. Мин моңа гаҗәпләндем. Икенчеләрен дә тотып карадым. Алары да җылы иде. Читтәрәк таралып яткан берничә ташны өемгә алып салыйм дип кул суздым. Болары сап-салкын иде. Димәк, күмәк булганда ташлар да, кояштан алган җылыны үзара бүлешеп, озак заман суынмыйлар икән.

Ә кешеләр? Күпме адәмнең җылысын, яктысын, дәрманын йөртәм икән мин үземдә? Мин гомер бакый алар белән аралашып, укмашып яшәдем. Үз тиңнәремнән миңа үз җылысын бүлеп биргән беренче кеше Әсгать булды. Ул һәрвакыт миннән ике яшькә олы йөрде. Миңа сигез чакта, аңа ун, миңа унсигез чакта, аңа егерме иде. Тора-бара мин Әсгатькә караганда ике тапкыр, хәтта аннан да артык өлкәнрәк булып киттем. Ул гомернең башында торып калды. Ә мин әле булса барам да барам. Арырак киткән саен, артыма ешрак әйләнеп күз ташлыйм. Еракта адашып калган моңнарга һәм өннәргә колак салам. Алар миңа еш кына намус авазы булып ишетелә. Гаҗәп.

Искәндәр Әсгате

Әсгатьләр урамын «Губернатор урамы» дип йөртәләр... «Монда губернатор үзе яшәгән имеш...» — дип уйламагыз тагы. Кайчандыр, әллә йөз ел әүвәл шушы урам шәрәмәтеннән, тройкада җилдереп, губернатор узып киткән, имеш, диләр. Шулкадәр зур түрәнең көймәсе туздырып узган тузанда коенып, рәхәтлектән, горурлыкның чигенә җиткән бәндәләр шунда ук үз урамнарына яңа исем кушканнар — «Губернатор урамы». Әйтергә кирәк, биш кенә йорттан торган бу тыкрыкның «Кәҗәләр төбәге» дигән элекке исеме дә тиз генә онытылмаган. Губернаторлар, байлар, түрәләр, күздән төшеп, түрдән тәгәрәгәч, «Кәҗәләр төбәге»н яңадан ябыштырырга маташучылар да булган бугай. Ләкин «губернаторлар», һәр йортның нигез буенда кәҗәләр күшәп ятуга карамастан, бу мәсхәрәне кабул итмәгәннәр, бердәм кире какканнар. «Губернатор урамы» авылдагы «Туң морҗа», «Өч этәч», «Ябалак», «Черчә» исемнәрен йөрткән башка төбәкләргә ишмени? Тегеләрнең һәрберсеннән мескенлек, наданлык, томаналык аңкып тора.

Бу урам үзе асылда ике нәрсә белән — фәкыйрьлек һәм тәкәбберлек белән аерыла. Биш йортның дүртесендә кәҗә белән тавыктан башка мал заты юк. Тик Әсгатьләрнең генә сыңар күзле биясе, бер сыеры белән яшь үгезе бар. Ярлылык ата-бабадан мирас булып калган, аның кадерен беләләр монда. Ә кукыраерга дигәндә — бала-чагасына кадәр кикриген катырырга тора. Әйтерсең, аларның һәрберсе, ким дигәндә, чын губернатор нәселе. Җитмәсә, торып килеп мактанчыклар. Һәр «губернаторның», төптән уйлап карасаң, башкаларда юк бер хикмәте килеп чыга. Алар суккан бүре башмак чаклы, алар тоткан җәен бүрәнә буе, алар аткан үрдәк торна чаклы була. Тик нишләптер үзләре

бер дә генә котаймыйлар, һич кенә дә кәпәренер урыны булмаган чатан Шәрәй дә хәтта мактанып җибәрә. «Чатан күп йөрер, дип, минем турыда әйткәннәр ул. Менә шушы ярман сугышыннан алып кайткан агач аяктан уңдым бит: талмый да, сызламый да, өшеми дә, тирләми дә. Бүтәннәр бер кием чабата туздырганда, миңа бер сыңары җитә»,— дип шапырына.

Бәләкәй чакта губернатор урамы минем өчен чит бер дөнья, андагы кешеләр тоташ бер сер иде. Ул һавалы фәкыйрьләрнең сәер кылыкларын мин соңрак, олыгая төшкәчрәк кенә төшендем. Тәкәбберлек аларның коралы, калканы, таяныр терәге булган икән. Башкаларның мөлкәтенә, дәрәҗәсенә, көченә нәрсәдер каршы куярга кирәк бит. Алар шул коры мин-минлекне китереп бастырганнар. Бахыр, горур, әкәмәт «губернаторлар»! Мин сезнең бөтенегезне дә сагынып искә алам — тереләрне дә, мәрхүмнәрне дә...

Шул «губернаторларның» берсе Әсгать иде.

...Мин губернатор урамыннан Тау артына бозау эзләргә китеп барам, үзләренең капка төбендә, хас та җитен төсле ап-ак чәчле Әсгать басып тора. Күзләре дә җитен чәчәгенә охшаган — зәп-зәңгәрләр. Мин аны беләм. Тик әлегәчә бер тапкыр да бергә уйнаганыбыз юк. Бу миңа я таш ыргытыр, я телен чыгарып үчекләр, я «Кендек»тән салдырып исем атар дип, үземчә җавап кайтарырга әзерләнеп киләм.

— Әй, малай, уңайла болай! — дип боерды теге, такмаклап.

— Үзең уңайла. Мин бозау эзләргә барам,— дип чәйнәштем мин.

— Шүрләмә, сиңа булмас һичнәрсә, мин кешегә тимим,— диде Әсгать. Мин туктадым. Үзем, хаҗәте килеп чыкмагае дип, уң йодрыкны йомарлап, артка яшереп куйдым. Ике күзеннән зәңгәр нурлар чәчә-чәчә, «җитен баш» үзе миңа табан уңайлады. Килеп җиткәч тә учын җәеп минем танау астына китереп терәде.

— Нәрсә исе килә?

Мин, авызны йомып, аптырап калдым. Әгәр яман ният белән булса, ул уч төбен түгел, йодрыгын иснәтер иде. Сугыш чыгарырга чамалаган малайлар шулай йодрык иснәтәләр.

— Я әйт инде, нәрсә исе килә? — дип кабатлады.

— Эт исе,— дип, авызын капларга уйлаган идем дә, тегенең хәйләсез елмаюы тыеп калды.

— Юкчы, бер ис тә килми,— дип баш чайкадым.

— Син яхшылабрак иснә,— дип үҗәтләнде теге,— танавыңны җыерыбрак...

Ярылып беткән пычрак уч төбен мин, бара торгач, чынлап иснәргә тотындым. Әмма аерып кына әйтерлек ис таба алмадым.

— Их, син,— дип кимсетмәкче итте мине Әсгать,— шуны да белмисең... Күмәч исе, май күмәче. Әле генә күмәч ашап чыктым.

Монысы да мине шаккатырды — тапкан мактаныр нәрсә! Аның күмәч ашавы миңа бик хаҗәт ди әнә. Харап икән!

— Ашасаң ни... Мин бозау эзләргә барам.

— Мин дә синә бозау эзләшимме?

— Эзләшсәң ни...

Сай чокыр дигән җиргә җиткәндә, без Әсгать белән җитәкләшеп китеп бара идек инде. Шул арада ул мине арбап, кулга ияләштереп алды.

— Әй, тукта әле, ыштан кесәңдә синең нәрсә кабарып тора ул?!

— Икмәк катысы.

— Булмас, я таштыр әле.

— Менә, ышанмасаң,— дип мин кесәдәге зур гына икмәк катысын чыгарып күрсәттем,— бозау алдатырга. Менә...

— Бозауны ни аны болай гына, алдатмый гына куып кайтырбыз. Әйдә икмәкне утырып ашыйк.

— Үзең әле генә, май күмәче ашадым дип, мактандың...

— Күмәч кенә тамакны туйдырмый шул, аны икмәккә кушып ашарга кирәк.

— Ә нигә соң кушып ашамадың?

— Икмәк булмагач...

Әкәмәт бу дөнья. Берәүләрдә гел генә күмәч, икмәк юк, икенчеләрдә икмәк бар, күмәч юк. Бездә, әйтик, күмәч бары җомга көнне генә була. Әсгать минем кулдагы икмәк кисәгенә йотылып карады да иреннәрен ялап, авызын чапылдатып куйды.

— Мә, аша,— дип сыныкны аңа тоттырдым. Кисәкне ул сак кына уртага сындырып яртысын миңа сузды. Мин баш чайкадым.

— Икмәктән туйган адәм дә булыр икән,— дип, арык ботларын сузып, үлән өстенә утырды. Күлмәк итәген тез башларына әйбәтләп япты да ашыкмый гына ашарга керешге. Итәгенә төшкән валчыкларны шунда ук алып каба барды.

— Икмәкне басып ашарга ярамый,— дип аңлатты миңа.— Басып ашасаң, тукландырмый ул. Әгәр бер валчыгын җиргә төшерсәң, язык була. Язык булгач, тәмугта яндыралар үлгәч.— Ул соңгы кабымын чәйнәп йотты. Тик урыныннан торырга ашыкмады. Туенып, күңеле хушланып алгач, ул гыйбрәтле бер әңгәмә сөйләп ташлады.

— Әтием әйтә, борын-борын заманда бер патша дала буйлап сыбай[1] китеп бара икән, ди. Бара торгач, моның корсагы ачкан. Куендагы икмәген алып, атыннан төшми генә ашарга керешкән бу. Вакыты кыстау булган, ди, патшаның. Актык кабымны каптым дигәндә генә, бер валчыгы җиргә тәгәрәп төшкән. Патша шунда ук ияреннән сикергән дә әлеге валчыкны эзләргә тотынган. Әй эзләгән, әй эзләгән. Өч көн, өч төн

[1] Сыбай — ат өстендә.

буе, мүкәйләп, бөтен тирә-якны кыдырып чыккан. Тәки таба алмаган. Дүртенче көнне өенә кайтса, бөтен сарайны кара кайгы баскан, ди. Моннан нәкъ өч көн элек патшаның иң яраткан улы суга төшеп үлгән икән. Ходай каһәренең тагы да яманрагы төшүдән куркып, патша әлеге икмәк валчыгы төшкән урынга куш манаралы мәчет салдырган, ди. Моннан соң аны ходай ярлыкагандырмы, юктырмы — анысы безгә мәгълүм түгел...

Әнә нинди нәрсәләр белә бу сәер малай!

Шыкыр-шыкыр шыкырдап баш өстеннән түбәннән генә бер төркем саескан очып үтте. Монысын мин дә беләм: инә саескан балаларын очарга өйрәтә. Үткән атнада гына сыерчыклар белән карлыгачлар бала очырган иде. Бүген — саесканнар. Мин җәһәт кенә бер таш табып, саесканнарга төбәп ыргыттым:

— Саескан, саескан, күкәй эчкән, май эчкән!

— Тидерсәң соң! — дип сикереп торды Әсгать.

— Тисә, тия бирсен, сандугач балалары түгел әле.

— Саенсканга да үз баласы газиз. Аның да эчендә җаны бар. Бөтен нәрсәләрнең дә җаннары бар — агачларның да, ташларның да, үләннәрнең дә... Җаннары булмаса, яшәрләр идемени алар? Безнең бармак киселсә, кызыл кан ага, агач ботагын кырыксалар, ак кан ага. Тимергә тимерне суксаң, чыңлый бит, әйеме. Шул — тимернең елавы була инде.

Белмәгәне юк бу Әсгатьнең. Адәм затыннанмы икән бу? Аның җитен чәче, зәп-зәңгәр күзләре, сары керфекләре мине бераз шомландырып та куя. Бөтен төбәктә бердәнбер ак малай ул — кара тавык оясында үскән ак үрдәк баласы төсле. Бишектә чакта аны пәри алыштырмадымы икән? Пәри шулай үзенең баласын калдыра да кеше баласын алып китә, ди бит. Булмас ла! Калган тагы пәри баласына шундый акыллы, шундый әйбәт булырга!

Без Сай чокырны да, Тирән чокырны да бер итеп,

бөтен Тау артын әйләнеп чыктык. Юкәле кул урманына барып җиттек, Мөкеш чишмәсенә төшеп су эчтек. Әллә ничә бозау очраттык, ә безнең Акмаңгайның эзе дә юк. Арып-талып өйгә әйләнеп кайттык. Кайтсак, безнең койма күләгәсендә Акмаңгай сузылып ята. Тиз генә капканы ачып, бозауны курага куаладык.

Алачык тирәсендә нәрсәдер мәшәкатьләнеп йөргән Олы инәем мине мактап каршы алды.

— Менә рәхмәт, улым, зур үстең инде, кул арасына керәсең.

— Мин түгел, Олы инәй, бозау зур үскән...

— Алайса икегез дә зур үскән.

— Олы инәем, бу Әсгать исемле малай. Ул миңа бозау эзләште.

— Аңа да рәхмәт. Болай булгач, өчегез дә зур үскән. Барыгыз әнә, баздан алып, кунагың белән салкын катык эчегез.

— Икмәкләпме?

— Икмәге дә шунда алачыкта.

— Ярар, мин кайтыйм инде,— дигән булды Әсгать,— өйдә я йомырка пешергәннәрдер.

Моны ишетеп калган Олы инәем, хәйләкәр елмаеп Әсгатьне кыстарга ук тотынды.

— Аш — ашка, урыны башка. Йомыркага да урын табылыр. Катык савытларыгызга берәр кашык каймак та салып бута.— Монысын ул миңа әйтте.

Әсгать башкача инәлтмәде... Алачык эченә җиләскә утырып, без тиз үк кашыкларны биетергә керештек. Үз савытын ялап куйгач, кунагым миңа яңа хәбәр салды:

— Күмәч турында бая мин шыттырдым. Ачлыкны адаштырыр өчен генә әйтелгән алдакчы сүз ул. Йомыркасы да шулай. Без икенче атна инде көненә бер тапкыр умач уып кына торабыз. Әти мәчеттән кайтмый, олы абыем калага китеп олакты. Дөньяны без Ибрай белән икәү генә алып барган булабыз.— Хәзер инде тавышында баягы тәкәббер гамьсезлекнең әсәре дә юк.

Минем каршыда бәләкәч кенә бабай утырган да үзенең аһ-зарын сөйли.— Безнең тәндә хәзер бер тамчы да май калмады. Кичә Ибрай белән икәү, корсакларны ачып, әллә ничаклы кояшта кыздырып карадык. Бөрчек тә май чыкмады. Шуннан мин агаемны үчекләп, җыр чыгардым. Кешегә сөйләмәс булсаң, сиңа да әйтәм.

— Икмәк өсте, ант! — дидем мин.

— Болай да, ант итмәсәң дә ышанам.

Ибырашка-дурашка
Артын ачкан кояшка.
Ике кадак мае чыккан
Күчтәнәчкә күмәчкә.

Кызыкмы җыры?

— Кызык, Ибрай нәрсә диде соң?

— Чабата калыбы белән башка тондырды. Менә орысы әле дә бүлтәеп тора. Бетәр әле, мәңгегә бармас. Ә төртмә җыр калыр. Аңа калып белән сугып булмый.

Әсгать беркатлы малай булып чыкты. Аның эчендәге тышында икән. Сер артыннан серен чишә генә бирде.

— Минем кушаматым «Сары черки»,— диде.— Төсемә карата да, телемә карата да кушылган ул. Телем әче минем. Тартай теленнән таба дигәндәй, шул телем аркасында эләгеп кенә тора миңа. Ә кушаматтан мин гарьләнмим. Исем атаудан бер җир дә кимеми. Харап икән — «Сары черки» имеш...

— Минем дә кушамат бар ла ул,— дигән булдым мин, аннан калышмаска тырышып.— Тик, әйтсәләр, гарьләндерә.

— И-и-и-и-һи,— дип күтәреп алды Әсгать,— синең кушамат бер дигән — Кендек! Дөньяда иң кирәкле әйбер — кендек ул. Арт арбаны ал арба белән нәрсә тоташтыра? Кендек! Иң гайрәтле ир узаманына нәрсә диләр? «Дөнья кендеге» диләр. Аның өстәвенә, син авылда бәби туган саен, өйдән өйгә, сыйдан сыйга йөреп, күпме игелек күрәсең — шул кендек аркасында!

— Кара аны, тагы бер исем атасаң, сугышам,— дип искәрттем мин.

— Исәр син, синең кушамат миңа эләксә, мин мактаныр гына идем.

— Бик мактанасым килеп тормый әле,— дип кырт кистем мин. Ул да сүзне ары сузмады.

Шулай да «Кендек»не Әсгать авызыннан ишеткәндә мин чыгырдан чыгып гарьләнмәдем, аны тыюым да ачудан түгел, ә «кунак булсаң, тыйнак бул» дигәнне аңлатуым гына иде. Ә бүтәннәр әйтсә, я әйтергә уйласа, җенем кузгала. Шуннан соң күп тә үтми без Хәмитҗан белән, көзге әтәчләр сыман, канга батып сугыштык бит инде. Ләкин «Кендек» бара торгач миңа нык ябышты, теш белән умырып та, тырнак белән куптарып та алырлык түгел. Ул мине җиңде, мин җиңүче алдында баш идем...

Бер көн эчендә Әсгать мине бөтенләй сихерләде. Ул кайтып киткәч тә үзен сагына башладым. Моннан ары без ташлашмас дуслар булдык.

Әсгать бәхетле затлардан түгел. Гомер буе аның башы бәладән чыкмады. Корбан бәйрәме алдыннан гына аңа бер-бер артлы ике җәфа килде.

Көтү кайткач та, бакча артыннан гына чыгып, Әсгатьләргә бардым. Болар агасы Ибрай белән икәүләп арткы абзарга мал ябып йөри. Үгезләре абзарга күндәм генә керә, ә сыерлары карыша. Үгетләп тә, чыбыклап та карыйлар — тыңламый. Ахрысы, сыерлары үз абзарыннан бизгән. Аптырагач, Ибрай сыерны атланып та әйдәп карады. Барып чыкмады. Теге кинәт бер якка тайчанды да пешмәгән сыбайлыны тирес өстенә атып бәрде. Аңа шул таман да. Үзе ул кешедән көләргә, адәм котыртырга бик әвәс.

Энесе шунда ук такмаклап та алды:

Атың арык, Ибырай,
Артың ярык, Ибырай!
Ат дигәнең пар мөгезле,
Тоз ялый да су сорай.

Ибрай акаеп Әсгатькә килә башлаган иде, энесе елт кына сүзне икенчегә борды:

— Үгез көчлеме, сыер көчлеме? — диде ул.

— Үгез!! — дидек без Ибрай белән берьюлы, чөнки ир затының көчлерәк икәнен бот буе малай да белә.

— Әйдәгез, алайса сыерны тарттырып кертәбез.

— Ничек?!

— Койрыгын үгез койрыгына бәйлибез дә! — Ибрайның баш юка аның. Мондый җәпле фикер аның уена бервакытта да киләчәк түгел, ләкин абый кеше алны бирмәгән булды:

— Тинтәк, юньсез! Агаең башында яралган акылны әйтеп ычкындырырга кем кушты сиңа?

— Әллә инде.

— Агаең исән чакта ким-хур булмассың, энем, баш түгел бездә — хәзинә,— китте, китте бу «губернатор» кукыраеп. Бу сүзләрен ул бигрәк тә минем колакка төбәп әйтте бугай.— Бар, китер монда үгезне!

Әсгать юаш ала үгезне сыер янына куалап китерде. Ибрай үз куллары белән койрыкны койрыкка ныгытып бәйләде. Әсгать, үгезнең мөгезеннән тотып, җай гына эчке абзар ягына уңайлады. Сыер киресенчә, дүрт аягын да терәп, җиргә ябышты. Үгез дә буй бирмәде, егетлеген итте, бар куәтен җыеп алга омтылды. Ике хайванның да койрыклары, сузылып, нечкәргәннән-нечкәрә барды. Дәрманга дәрт өстәп, Ибрай озын чыбык белән үгезнең сырт буена сыдырды. Ала мәхлук, үрә сикереп, алга омтылды. Нәрсәдер шырт итте. Баксаң, үгез койрыгы булган урында бер карыш чамасы гына йонтәч кыркынды серәеп тора иде. Кыркындыдан атылып кан килеп чыкты. Үгез яман итеп үкереп җибәрде дә, бөтен кураны бер итеп, үрсәләнеп чабарга кереште. Өй кырындагы утыртма читәнгә килеп бәрелде, читән авып төште. Шашып котырган бичара хайван Тау артына чыгып качты.

Без өчәүләп үгез артыннан торып йөгердек. Тик

эңгер төшүгә генә аны кире алып кайттык. Ул шул чаклы чабудан, сызланудан тәмам йончыган иде. Башын да күтәрә алмый. Авызыннан туктаусыз селәгәй ага.

Чалмасын киеп, мәчеткә ястү намазына барырга дип чыккан Искәндәр агай безне капка төбендә каршы алды. Бу үгез маҗарасын Әсгатьнең апасы күреп торган иде. Эшнең асылын атасына җиткергәндер, күрәсең. Шуңа да Искәндәр агай бәйнә-бәйнә сорашып тормады:

— Қайсыгызның этлеге бу? — дип кулындагы үгез койрыгын селтәп куйды.

— Әсгатең уйлап чыгарды,— диде Ибрай.— Башка да кергән нәрсә түгел иде, эти.

— Әлеге син! Атаң яхшы, инәң яхшы, эттән туган эт баласы! — Мәчет карты оятсыз, әшәке сүзләр әйтеп, кече улының колагыннан эләктереп алды. Икенче кулындагы үгез койрыгының канлы юан башы белән Әсгатьнең аркасын каезлый-каезлый, абзар эченә алып кереп китте. Ястү намазы урынына карт үзенең кече улын — тәнендә бер тамчы да май әсәре калмаган Әсгатьне — хәлдән тайганчы ярды. Ибрай шунда ук каядыр шылды. Әсгатьнең ыһ дигән тавышы ишетелмәде, тик үгез койрыгы гына чыелдады. Бөтенләй күз бәйләнә башлады. Абзар эченнән Искәндәрнең ак чалмасы килеп чыкты.

— Сиңа нәрсә калган монда? Бар өеңә кайт! — дип җикеренде миңа. Әмма тукталып тормады, ары китте. Ишек төбендәге комганны тибеп очырды да өйгә керде.

Мин посып кына Әсгать янына кердем. Ул тирес өеме өстендә капланып яткан. Ара-тирә сулкылдап куя. Аңа әйтер бер сүз дә таба алмадым. Баш очына тезләнеп утырдым. Ул, акрын гына кулын сузып, минем тез башымны капшады. Шул чак якында гына Олы инәемнең мине чакырган тавышы ишетелде.

— Мин монда, Олы инәем!

— Кайда?

— Абзар эчендә. Искәндәр агайлар абзарында! — Үзем тавыш бирәм, торып китәргә үземнең әллә хәлем, әллә зиһенем җитми.

Олы инәем абзар авызына килеп туктады.

— Нәрсә эшләп утырасың монда, кеше абзарында, эңгер төшеп беткәч?

— Әсгатьне атасы үтергәнче тукмады. Үгез койрыгы өчен. Ул тора алмый хәзер.

«Нинди үгез, нинди койрык?» — дип төпченеп тормады ул. Ыңгырашып яткан Әсгатьне караңгыда капшанып килеп тапты да җай гына кулыннан тартып торгызды.

— Әйдә, улым, өйгә керик.

— Әл-лә аркам! — дип кычкырып җибәрде Әсгать. Олы инәем, җитәкләп, аны өйгә алып керде.

Искәндәрләрнең түр ягында сукыр лампа яна. Йорттагы барлык җан иясе чаршау эчендә, ахрысы. Шылт иткән тавыш юк. Бу якта бер Искәндәр генә — сәке өстендә тезләнеп дисбе тартып утыра.

— Дисбеңне куеп тор әле, Искәндәр! — диде Олы инәем, тавышын күтәрә төшеп. Теге тыңламады. — Сиңа әйтәмче! — дип кабатлады.

Карт дисбесен куймады, шулай да тартудан туктады. Алга сузылган ике кулының бармаклары, төймә тоткан көе бөгәрләнеп, катып калды.

— Әйдүк, җиңги. Хуш... — диде, тешен кысып кына. — Түрдән уз.

— Иманың бармы синең? — Ул Әсгатьнең буй-буй булып кан сауган аркасын ачып күрсәтте. — Ерткыч син. Алай дисәң, ерткыч та үз баласын бу кадәр үк изеп, имгәтеп ташламас. Син аннан да кансызрак. Ходайдан курыкмасаң, әдәмнән оялыр идең. Болай булгач, синең мәчеттән чыкмый намаз укуың корысын!

— Ходა гамәленә тел тидермә, җиңги. Тәңре каргышы төшә күрмәсен...

— Ә син адәм баласын рәнҗетмә. Адәм каргышы төшсә, гүреңдә дә урын таба алмассың.

Олы инәемнең болай ачуланганын мин бер тапкыр да күргәнем юк иде. Әйтерсең, ул, бәбкәләрен яклап, тилгәнгә ташланган ана каз. Бәбкәсе дә үзенеке түгел бит әле. Үзенеке түгел димен дә... Мөгаен, Олы инәем Әсгатьнең дә кендек әбиедер әле.

— Кара аны, — дип кисәтте картны, — бармак белән чиертәсе булма балага. Аның күңеленә хәзер ачу чәчсәң, соңрак нәфрәт урырсың. Иң ямаң каза — ата белән бала дошманлыгы.

Искәндәр карт бүтәнчә әрепләшмәде. Башка кеше аңа шулайрак тел тидерсә, карт пыр тузар иде. Минем Олы инәемә каршы әйтә алмый шул. Авылда аңа берәү дә каршы әйтми.

— Әй, кем бар анда чаршау эчендә? — дип кычкырды Искәндәр. — Кунак килгәнен ишетмисезмени? Самовар куегыз!

Теге якта нәрсәдер кыштырдады, нәрсәдер шалтырады, ләкин җавап булмады. Олы инәем, Әсгатьне кулыннан тотып, сәкегә утыртты да без кайтып киттек.

— Өзелгән үгез койрыгы төзәләме, Олы инәем? — дип сорадым мин кайтып барышлый.

— Төзәлә. Бөтенесе дә төзәлә. Тик өзелгән өмет белән калган хәтер генә төзәлми. — Аның бу соңгы сүзләрен мин, әлбәттә, аңлап бетермәдем.

Икенче бәла Әсгатькә иртәгә гает дигәндә килде. Бәйрәм көнне төштән соң урамдагы бөтен малайлар Акманай суына ат йөздерергә барабыз дип, алдан сөйләшеп куйдык. Мортаза абыем миңа да күк алашаны биреп торырга вәгъдә итте. Акманайда ат йөздерү үзе бер тамаша ул. Анда барганчы һәр малай үз атын кыргычлап тазарта, ялларын тигәнәкләрдән әрчи, хәтта, кызлар чәчесымак, толым-толым итеп үреп тә куя. Купшыраклары әлеге толымнарга төрле-төрле тасмалар да тагып җибәрә. Безнекеләр алай кыландырганны ярат-

мыйлар. Мин күк алашаны буем җиткәнчә җирдән, буем җитмәгән урыннарын өстенә менеп кыргычладым. Сыладым-сыйпадым да Әсгатьләргә киттем. Әсгатьнең инде аркасындагы кутырлары кубып төшә башлады, йөзендәге кара янган урыннар да саргылт зәңгәргә әйләнде. «Нишләдең?» — дип сораганнарга ул: «Үгез сөзде», — дип җавап кайтарды. Миңа да шулай әйтергә кушты. Бахыр үгез өстенә юк гаепне ташлап, нигә алдашабыз икән без? Монысын мин аңлап җиткермим әле.

Кура уртасында, кияү куеныга керергә әзерләнгән кәләшсыман, бизәлгән сыңар күзле кара бия гамьсез басып тора. Бия түгел, торганы белән кәртинкә. Ике колагына чигелгән чуклы кулъяулыклар бәйләнгән, ялына аллы-зәңгәрле тасмалар кушып үрелгән, хәтта алгы бәкәлләренә ак чүпрәкләр уралган, койрыгына эреле-ваклы тәңкәләр тагылган. Үзе, кара сөлек төсле, елкылдап тора. Тик күз генә берәү. Анысы да, гамәлгә калгандай, чылт-чылт йомылып, эрен агыза, каһәрең. Бу кадәр бай җиһаз кара биягә каян килде икән, дисезме? Чамалавы кыен түгел: малайлар ике апасының да бирнә сандыгына ярыйсы гына тирән чумып чыккан булырга тиеш. Я алай да түгелдер. Я апалары үзләре биреп торгандыр. Әсгать хәл эчендә калганнан соң, алар бөтенесе дә йомшара төште.

Шундый итеп бизәнеп-төзәнеп, купшылыкның чиген узган кыска муенлы күпкәк кара биянең юкә нуктасын ике яктан Ибрай белән Әсгать тотып алган. Алар, такмак әйтеп, бер урында сикергәләп биеп тора:

Һайт, кара юрга! Һайт, кара юрга!
Аккош муен, нечкә бил,
Җилне узып җил дә җил,
Һайт, кара юрга!
Тавис койрык, шәм колак,
Бер адымы биш булыр.
Аны менгән узаман
Хан кызына иш булыр.
Һайт, кара юрга! Һайт, кара юрга!

Алтын тояк, ефәк ял!
Бер мөлаем караш сал!
Сал! Сал! Сал!

Шушы кадәр олы мактауны кара бия азагына чаклы баш та какмый, койрык та кыймылдатмый, үтә тыныч, үтә сабыр тыңлап торды. «Бер мөлаем караш сал! Сал! Сал!» — дигән ялвару сүзләрен ишеткәч кенә, дертләп киткәндәй итте. Шулай да җырның күрәләтә ярамсак булуы ошамады бугай биягә. Әсгать ягына кинәт башын борып, тегенең сул колагын төбеннән үк умырып та алды, ә иртәгә гает иде...

Быелгы бәйрәмнең кызыгы булмады. Мин кан төкереп үткәрдем, дустым гомерлеккә сыңар колаклы булып калды.

Күп тә үтми Өч әтәч урамында Кадергол картның җиде ел буе бәби китерми йөргән яшь бичәсе малай тапты. Мин соңгы тапкыр, рәхәт чигеп, бәби сыйларында сыйландым, сукрана-сукрана бәби мунчасы кердем. Кадергол бабай хәлле тора, туган-тумачасы да калын. Күчтәнәчне мул китерделәр, әмма коймаклары майда йөзсә дә, хуҗаларның күңелләре шатлыкта йөзмәде. Боек каршы алдылар малайны. Олы инәем белән бер әбинең аш өендә пыш-пыш сөйләшүе дә миңа сәер тоелды.

— Томшыгына кара чак кына, торганы белән козгын заты бит, — диде теге карчык.

— Кемнән туса да, дөньяга килгән, ахирәт, — диде Олы инәем. — Ул үз теләге белән килмәгән, бүтәннәр теләгеннән килгән, әмма ул барыбер үзе өчен туган, үз язмышы белән. Рәхим итеп, ачык чырай күрсәтеп кабул кылыгыз. Шик-шөбһә таратсагыз, бөтен ыруыгыз мәсхәрәгә калыр. Кагып-сугып рәнҗетмәгез — язык төшәр. Белеп булмый, бәлки, ул бер изге рухлы бәндә булып китәр. Хәтта пәйгамбәрләрнең дә кайберләре шулай чит җил кагылудан яралган, дип сөйлиләр.

Мин баш ватам: нишләп ул козгын затыннан икән? Нинди «чит җил»? Әллә бу малайны берәр кош оясыннан алып кайттылармы икән дисәм... Юк инде! Имеш, «бәбине коедан алалар» яки «торна оясыннан барып табалар» дигән әкиятләргә ышана торган заманнар үтте инде. Кешенең ничек туганын да, нәрсәдән туганын да беләбез хәзер. Шуңа күрә «козгын заты» дигәне акылга сыймый да. Шушы акылга сыймас нәрсәнең серенә берничә ел үткәч тә төшендем. Баксаң, бөтенесе дә гап-гади генә икән...

Кадергол картның бәрәңге бакчасына Козгын кушаматлы Исмәгыйльнең бакчасы килеп тоташа, диярлек. Ике арада ерганак кына, ерганак төбендә чылтырап агып яткан елгачык кына бар. Күрәсең, ерганагы артык тирән, елгачыгы артык киң түгелдер. Кадергол карт калага он сатарга киткән төннәр чамасыз караңгы да, чамасыз якты да булмагандыр. Адашмый күрешерлек кенә, аулакта ышыкланырлык кына, ягъни тап-таман гына, булгандыр ул төннәр. Әй, нәрсә эшләп имеш-мимеш сөйләп торам әле мин монда! Ничек булганын мин күргәнме дә мин күзәткәнме? Куй, кеше сүзе кеше үтерер, ди...

Ишморза исемле малай ай үсәсен көн үсте. Үскән саен Кадергол күңелен яулый барды, иң яраткан улына әйләнде. Ишморза тәү тапкыр атка атлангач, Кадергол карт үзенең кордашларына шундый әңгәмә сөйләгән, имеш. «Ишморзаның әнкәсе килен булып төшкән язда, — дигән ул, — минем бәрәңге бакчасында бер алмагач сабагы баш төртеп чыкты. Утырткан, чәчкән нәрсәм түгел. Орлыгын ходайның рәхмәте белән, күрәсең, кайдандыр җил китереп ташлагандыр. Күпме кырау, күпме боз-яңгыр күрде шушы зәгыйфь кенә сабак. Эссе җилләр көйдерде, салкын җилләр өшетте. Әнә теге кыштагы зәһәр суыкларда оды алмагачлар туңып корыды. Бу торып калды. Барча михнәтләр белән алты ел алышты да, җиденче язны чәчәк атып, җәен җимеш

бирде. Шушы җәйдә тәңре миңа кече улымны бүләк итте. Бөтенесе дә күктәгеләр ихтыярында, бөтенесе дә җил иркендә».

— Һай-һай, — дип баш чайкый дөнья күргән кешеләр, — алмагач хикәятен карт үз теле белән үзе сөйләмәс, аның теле белән бүтәннәр лыкылдыйдыр, мөгаен.

Шулай булуы да ихтимал. Бер табында утырып Кадергол авызыннан үзем ишеткән сүз түгел. Әмма Ишморза михнәт-җәфа күрми үсә бирде...

...Әнә шул Ишморза сыеннан мин Әсгатькә дә байтак өлеш чыгардым. Соңгы баруда ике кесә тутырып баллы чәкчәк алып кайттым. Бер кесәсен сеңелем белән энемә бүлеп бирдем, икенчесенә тимәдем. Кичкә табан күк алашаны Тау артына чыгарып тышаулыйм дип барганда, Губернатор урамына кереп, Әсгатькә сугылдым. Ул да кара биягә атланып чыкты. Тирән чокыр аръягына илтеп атларны тышаулагач, без үлән өстенә утырдык. Мин дустыма дигән күчтәнәчне алмакчы булып кесәмә тыгылдым, ләкин баллы чәкчәк тоташы белән укмашып киндергә ябышкан иде. Кесәне бөтенләй әйләндергәч кенә без аны куптарып ала алдык. Күчтәнәчнең яртысын бүлеп, Әсгать миңа сузды.

— Бугазыма җиткәнче тыгындым, менә! — дип авызны ачып күрсәттем.

Ул һәрвакыттагыча, ашыкмый гына, кадерләп кенә ашарга кереште.

— Миңа бүген тагы эләкте, — дип хәбәр салды дустым, колаксыз яңагын сыйпап.

— Нәрсә өчен?

— Җыр өчен. Иртән торганда әтием башы-күзе белән каз мамыгына баткан иде. Төнлә аның мендәр тышы ертылган икән. Мин шунда ук әйтеп куйдым:

Әтиемнең мендәре —
Пыр-пыр итә йоннары,
Әти үзе пыр туза
Мендәреннән элгәре.

— «Һи, авызыңа шайтан төкергере!» — дип кыптыр ката белән җибәрде. Җан җиргә килеп тиде. Бөгелдем дә төштем. Үзем дә исәр инде, бер телемне тыя алмыйм.

Минем каршыда утырган җитен чәчле, сыңар колаклы Әсгать кинәт караганда бер тоткасы төшкән самоварга охшап китә. Батып барган кояш нурлары да, самовар җизендә чагылып уйнаган шикелле, аның чәч арасында җемелди. Тау астында, түбәндә күзгә күренер-күренмәс кенә сыек зәңгәрлек төшә.

— Әнә ул зәңгәрлек, — ди Әсгать, — күктән коела. Көн буе күк йөзе кыза да кичкә табан, аннан кубып, шулай зәңгәр тузан сибелә.

Әлбәттә, дөресен әйтә ул. Югыйсә, каян чыксын ул зәңгәрлек? Җирдән күтәрелсә, бары бу күтәрелер иде. Җир йөзендә ниндидер моңсу тынлык ята. Югарыда болыт та, түбәндә җил дә юк. Шул тынлыкны ярып, моннан ерак түгел тугай юлы буйлап кемдер, үтә моңлы, үтә зарлы итеп җыр җырлап үтте. Сыбай бара булырга тиеш ул. Җәяүле кеше болай ук иркен, болай ук ямансу җырлый алмас иде. Мин үзем дә, атка атлансам, я шашып дәртләнәм, я яман моңаям.

Без җырның бары соңгы сүзләрен генә ачык итеп ишетә алдык:

Чуртан үрли суның үренә,
Кеше керми кеше гүренә...

— Шәйхи малае Рамазан бу. — Әсгать җырчының тавышын шунда ук танып алды. — Атасы мәрхүм турында зар елый ул.

Бөтенесен дә белә бу Әсгать...

Моннан бер атна гына әүвәл бар авылны тетрәткән шундый хәл булды. Кашафетдин белән Шәйхулла исемле агалы-энеле ике кеше Лекаревка дигән рус авылы янында Дим аша күпер салып ята икән. Күпер менә-менә бетте дигәндә, Кашафетдин, ялгыш басып, суга

егылып төшкән. Йөзә белмәгән агасын коткармакчы булып, Шәйхулла Димгә сикергән... Шул чумудан башкача калыкмаган. Кашафетдин, алай-болай итеп, ярга килеп сугылган. Ә Шәйхулла гаеп булган. Өч көн үткәч кенә аның гәүдәсе кайдадыр Дим түбәнендә килеп чыккан. Ул башы белән елга төбендәге иске баганага очына барып сугылган булган. Шуннан һушы китеп, батып үлгән.

Рамазанның тавышы күптән тынды, ә сүзе белән моңы күңелдә торып калды.

Кеше керми кеше гүренә...

— Әсгать, ә Әсгать,— димен мин оеп утырган дусыма,— ә бит уйлап карасаң, Шәйхи үз гүренә түгел, агасының гүренә кергән. Үләргә Кашафетдин агай тиеш булган.

— Әллә инде,— Әсгать баш чайкады,— монысын мин белмим. Олы инәеңнән сорарга кирәк. Кеше тууы турында ул бөтенесен дә белә, үлем турында да, мөгаен, беләдер.

Ләкин бу турыда мин Олы инәемнән сорамадым. Үлем турында төпченгәнне яратмый ул.

Байтак сүзсез утыргач, Әсгатьниндидер серле дә, шомлы да тавыш белән сөйләргә тотынды.

— Мин бит монда үзем өчен яшәмим, бүтән бер малай өчен яшим. Әгәр саклардан булсаң, ике серемне сөйлим сиңа. Антмы?

— Икмәк өсте.

— Син бит урге очтагы чем-кара чәчле, чем-кара күзле Фәридә исемле ятим кызны беләсең. Аларның йорты биек...

— Беләм.

— Шул Фәридәне үги әнисе көн саен я тирги, я тукмый. Минем шикелле бәхетсез ул. Без ятим Фәридә белән икәү бер ишбез. Миңа ул хакта әнә теге Әүлия чишмәсе янындагы яшен суккан куш каенның берсе әйтте.

Дөньяда минем иң кызганган кешем — әнә шул кыз. Үземне дә бу кадәр үк жәлләмим. Аның хакында мин җыр да чыгардым.

Биек-биек ызбада
Яшьләр түгә кыз бала.
Яшьләр түккән кыз баланы
Күңелләрем кызгана.

Шушы җырны җырлыйм да үзем елыйм.

— Синең елавыңнан аңа ни файда?

— Әлегә файда юк. Үсеп буйга җиткәч, мин аңа гашыйк булачакмын. Шуннан беркөнне, җәйге кояш яңа гына чыгып килгән бермәлдә, мин аны җитәкләп алачакмын да кояшка карап китәчәкмен. Без үргә, гел үргә менәчәкбез. Баш очыбызда өзлексез кошлар сайрап торачак, алдыбызда пырылдап ак күбәләкләр очып, безгә юл күрсәтеп барачак. Безнең куанычны күреп, чәчәкләр баш иячәк, еланнар ояларына, бүреләр өннәренә качачак. Без дөньяның иң биек түбәсенә — Кызлар тавыннан да биегрәк тау башына менәчәкбез, хәтта күк үзе түбәндә торып калачак. Моннан бөтен җиһанның бөтен авыллары, бөтен калалары күренеп торачак. Тау башын куе озын үлән каплаган булыр. Чак кына иелсәк, ул безне бөтенләй күмәчәк. Әнә шул үлән арасында, посып кына, аның сул битен үбеп алачакмын. Сул битендә аның матур миңе бар...

— Фу! Тапкансың һөнәр...— Әсгатьнең үбешүе миңа ошамады. Куе үлән арасына яшеренеп, үзең үптереп торган Фәридәсен әйтер идем...

— Гашыйклар үбешергә тиеш. Үбешмичә булмый ул. Мин бит әле түгел, ускәч... Фәридә әгәр ятим булмаса, үги әнисе аны җәберләмәсә, бәлки, мин аңа гашыйк та булмас идем... Бәхетле кешегә минем дә кирәгем бер тиен. Теге куш каенның берсе миңа янә шуны әйтте: «Берәүгә берәү кирәк, кыешка терәү кирәк»,— диде.

Фәридә белән минемише кыешлар бер-берсенә тераү булырга тиеш. Тик бу хакта кешегә сөйләмә инде.

— Ант!— дидем,— антка ышанмыйсыңмыни?

— Ышанам ла.

Әсгатьнең бу «сере», нигәдер, миңа ошап җитмәде. Беләм, ул теләсә, Фәридәне иң биек тауга да алып менәр, кояш нурларына да чорнар, сайрар кошлар да тотып бирер аңа, чишмәләрдән отып алган җырларын да җырлар. Күк түбәндә, алар югарыда булыр. Кодрәте чикләнмәгән аның.

Әмма ул Фәридәне мин дә беләм. Алар йорты турыннан узганда түбәтәемне төзәтебрәк, купшырак итеп киям, танауны да сирәгрәк тартырга тырышам... Юкка ачты Әсгать бу «серен». Димәк, мин чем-кара чәчле, чем-кара күзле, сул битендә кара миңе балкып торган ятим кызга тиң түгел, чөнки мин җәфа чикми яшим.

Ниләр генә күрергә язмасын, дустымның серен барыбер чишәчәк түгелмен. Ай күрде, кояш алды...

Минем күңелемә иләс-миләс уйлар кагылып үткәнне дустым сизмәде. Аның үз сагышы үзенә җиткән иде.

— Әгәр кошлар булсак, хәзер үк очып китәр идек,— ди Әсгать, һаман үзенекен сөйли.— Мин аны ничек тә күндерер идем.

— Ә син нинди кош булырга теләр идең — шоңкармы, аккошмы, әллә сыерчыкмы?— димен мин. Ул байтак уйланып тора. Шуннан гына җавап кайтара:

— Юк, мин барыбер кош булмас идем. Кошка әйләнсәм, минем арттан килгән өермә, мине тапмый, кире китәр.

— Нинди өермә ул?

— Икенче серем әнә шул өермә инде. Антыңны кабатла!

— Икмәк өсте!

Әсгатьнең арык йөзенә карадым. Аның зәңгәр күзләре шундый уйчаннар.

— Мин монда түгел, башка илдә — ефәк үләннәр үскән, татлы җимешләр пешкән сәхрә җирдә туганмын. Бер заман каты өермә чыккан да, мине күтәреп, биек таулар, чиксез дәрьялар, кара урманнар аша шушында китереп ташлаган. Минем урынга моннан икенче малайны очыртып алып киткән. Тегеңә рәхәт, миңа михнәт татыту өчен шулай иткән ул. Вакыты җиткәч, безне яңадан алмаштырачаклар. Әгәр дә мин ят җирләрдән килмәгән булсам, мине чит ояның чебеше урынына шулчаклы кыерсытырлар идемени? Беләм мин, бер кыенның бер ансаты булачак. Әнә тегеннән, Каенлыкул ягыннан гына өерелеп килер дә ул өермә мине алып та китәр. Гарәсәт купкан саен мин, абзар башына менеп, көтеп торам. Тик әлегә вакыты җитмәгән. Монда әчәсе суым эчелеп, йотасы утым йотылып бетмәгән.

Минем йөрәгем жу итеп китте:

— Алайса сине пәри алыштырган булып чыга... Алайса син пәри баласы...

— Юк, пәри баласы ак булмый, кара була. Әйтәм бит, мине монда бүтән дөньядан, бәхетлеләр иленнән китереп ташлаганнар. Мине юллап табачаклар барыбер...

Моннан соң бик күп давыллар булды, өермәләр узды, әмма алар минем дустыма тимәделәр. Әсгать үзе дә кабатламады бу хакта — бервакытта да. Мин дә хәтерләтмәдем.

Язмыш белән бәхәсләшеп, без үсә бардык. Буйга җиттек. Әсгать уйчан табигатьле, сабыр холыклы егет булып китте. Бәләкәй чакта аны атасы: «Шайтан сабагына йөрмә!» — дип мәктәпкә барудан тыйды, соңыннан үзе күңел салмады. Ул хәреф таныр-танымас көе калды. Үзе бөтен авылда, чәчән телле сүз остасы, җыр, такмак чыгаручы булып дан алды. Шул әче теле, тапкыр сүзе аркасында аңа ара-тирә тукмак та төшкәли торды. «Язгына күрә җәзасы»,— дип ул телен дә тыймады, җәбер-җәбырга да исе китмәде.

Бер заман бөтен ил өстенә көрән өермә ябырылды.

Ул, өерелдереп-өерелдереп, җиләк кебек егетләрне ерак якларга алып китте. Бәхет иленнән түгел, бәхетсезлек иленнән килгән иде бу гарәсәт. Ул, киресенчә, безне рәхәтлек дөньясыннан хәвеф дөньясына олактырды. Әсгать тә инде ефәк үләнле газиз туфракның үз аягы астында икәнен күптән аңлаган иде. Шул өермә каккалап-суккалап безне ир итте. Кайсыларыбызга әҗәлдән, кайсыларыбызга даннан өлеш чыкты. Әмма, бөтенесеннән дә югарырак күтәрелеп, туган туфракның изге нуры тереләрнең рухын, үлеләрнең гүрен яктыртты.

Бик күпләребезне утлы өермә кире әйләнеп кайтмас җирләргә алып китте. Әсгать тә хәбәрсез гаеп булды. Юк, моңа ышанып булмый. Ул хәбәрсез югала торганнардан түгел иде. Күрәсең, аның күзләренең зәңгәрлеге кайдадыр күкләрнең зәңгәрлеге белән барып тоташкандыр. Үлгәндә ул җирдә ятып, тартышып, чәбәләнеп, чырай сытып үлмәгәндер; я атта җилеп барганда ияр өстеннән атылып төшкәндер, я самолетта очып килгәндә һавада дөрләп янгандыр. Ул яхшы күңелле, матур кеше иде. Чибәр түгел, матур иде. Яхшы күңелле матур кешенең ямьсез үлүе мөмкин түгел. Ул шагыйрь иде. Шагыйрьнең ямьсез үлүе мөмкин түгел.

Әсгатьне заман чоңгылына бөтенләй батты дисәм дә, байтак еллар узгач, аның турында, күзгә күренмәс җилсыман, колак ишетмәс нурсыман, бер хәбәр ил өстеннән сак кына тирбәлеп үтте. Аны галәм төпкеленә юл ярган азамат ирләрнең берсе китергән, диделәр. Имеш, баягы галәм азаматы ерак галактикаларның ерагында планетадан планетага сикереп атлап барган җитен чәчле, зәңгәр күзле, сыңар колаклы яшь егетне шәйләп калган. Кулында аның сүнмәс чырагы бар икән. Шул чырагы белән егет җиһандагы сүнгән йолдызларны берәм-берәм яңадан кабызып, сүнә барганнарына ут өстәп йөри икән. Монысына ышанырга була. Чөнки ул шагыйрь иде. Димәк, шагыйрь үзенең төп эшенә тотынган...

Мәсхәрә ителгән кала

Өй артында тыңкыш Вәлетдин утын кисә. Бер чаба да күккә карап ялвара:

— И һава! Я мине ал, я шушы карт инәемне ал! Тота да утын кисәргә куша, тота да утын кисәргә куша...

Ул түмәрдәге коры каен агачына кизәнер-кизәнмәс кенә янә чаба. Агач бирешми, бары сикереп кенә куя.

— Агачы каты, балтасы үтмәс,— дип зарлана ул,— нигә бөтенесе дә бер миңа гына шулай тискәре килә икән?

Вәлетдин каешланып беткән түбәтәен башыннан алып җиргә атты. Түбәтәй төшкән урында, нигез буенда пырхылдап тузан күтәрелде. Ул тагы да зәп-зәңгәр күккә төбәлде. Әллә кая еракка китеп адашкан күзләреннән кинәт мөлдерәп яшьләр ага башлады.

— И һава, бер ятимеңне генә — минем үземне генә ал син. Карт инәем монда торып калсын. Бер ялгызы гына рәхәт чигеп яшәсен әйдә — бөтен мал-туарга баш булып! Ишетәсеңме, һава?

Вәлетдин мәлҗерәп беткән карт инәсе Гыйзелниса карчык белән икәү генә тора. Атасы аның герман сугышыннан кайтмаган, әнисе Күчем авылына кияүгә чыгып киткән. «Мал-туар» дигәннәре сыңар мөгезле сары кәҗә. Әмма кәҗәсе кәҗә ише генә түгел инде, торганы белән бер болан. Бөтен авылның көтүен ияртеп йөртә. Шуның белән Вәлетдин мактанып туя алмый: «Безнең сары кәҗә бөтен көтүнең патшасы ул, кайда тели, шунда алып бара сезнең күпкәк, надан сыерларыгызны, томана сарыкларыгызны...— ди.— Сөте чамалы булса да, тоткан дәрәҗәсе, кылган кыланышлары дан аның»,— ди.

«Кыланышлары дан аның...»— ди. Дан укмы икән? Юккамы теге көнне Кече инәем хатыннар собраниесеннән соңлабрак кайткач, этием, мыскыллый биреп, әйтеп куйды: «Болай эш ташлап, собраниеләргә еш йөри баш-

лагач, бичәкәй, Гыйзелниса кәҗәсенә әйләнеп куймасаң ярар да...» Кече инәем «һе» дип көлеп куйган булды, бик үк көләсе килмәсә дә...

Мин Гыйзелниса әбиләрнең өй почмагына сөялеп торам. Вәлетдин нишләптер мине һаман күрми. Ул балтасын ташлады да лып итеп түмәргә утырды. Әмма ике яңагы буйлап күз яшьләре туктаусыз ага бирде. Байтак шымып торгач, ул башын тагы да югарыга чөйде:

— И һава,— диде,— баягы сүзләремне мин кире алам. Калдыр безнең икебезне дә шунда. Югыйсә карт инәемә минсез үтә кыен булыр. Ике ятим бер үксез булып яшәрбез әле шунда...

Мин чыдый алмадым, Гыйзелниса әби белән Вәлетдинне жәлләп елап җибәрдем. Шул чак Вәлетдин дертләп китте, минем якка әйләнеп карады. Башта ул әллә хәвефкә төште, әллә ачуы кабынды — атылып урыныннан торды. Чит затның бары «мин генә» икәнен күргәч, тынычлана бирде:

— Кем тиде? — ди ул йомшак кына.

— Тимәде.

— Ә нигә балавыз сыгасың?

— Син елаганга... Сүзеңне кире алып яхшы иттең. Нәрсә калган сиңа анда бозлы һавада?

Минем, кешегә кушылып, кеше өчен әрнеп елавым, бәлки, гомеремдә беренче тапкыр шушы булгандыр. Ә кешегә кушылып, тәү тапкыр кайчан җырлаганмындыр, анысын хәтерләмим. Соңрак, күп заманнар соңрак, булгандыр монысы...

— Мин дә еламадым, син дә еламадың. Төшендеңме? — диде Вәлетдин.— Яшь агызып тору ир-ат эше түгел.

— Төшендем, — дип баш каккан булдым, төшенеп үк җитмәсәм дә... Ул чакта да, соңыннан да төшенмәдем мин моны. Имәндәй ирләрнең әрнеп елаганын күргәндә мин һич тә гаҗәпләнмәдем, аларны гаеп итмәдем. Таш-

тан сытылып су тамчысы чыкса, мин әйтер идем: күрәсең, шулай тиештер, димәк, башкача мөмкин түгелдер...

— Шушы агачны өч чабуда кисеп чыгармасаммы — исемем Вәлетдин булмасын! — дип ул өч тапкыр учына төкерде. Балтасын алды да гайрәтләнеп, селтәп җибәрде. Киселгән утын агачы түмәрдән очып та төште. Моннан ары Вәлетдин чаба торды, чапкан саен бер утын агачы читкә тәгәри торды. Ни хикмәт бу? Шул арада әллә агач йомшарды, әллә балта үткерләнә төште.

Гыйзелниса әби ишек алдына чыгып басты. Оныгына карап, сокланып бетә алмый:

— Менә нинди ул минем уңганым, минем күндәмем! Эшләгәндә йөрәккәйләре җилкенеп тора бит аның! Таянычым, алтын баганам минем... Хәтта түбәтәйләрен салып ташлаган. Кискән утыныңны инде кертеп тә бирсәң...

— Мин үзем! — дип шунда ук утын агачларын кочагыма төйи дә башладым.

— Затың игелек күрсен, балам, итагатьле икәнсең,— дип әби мине дә мактап алды.— Кылган эшең — кешегә, килгән савабы — үзеңә!— Шуны әйтте дә кире өйгә уңайлады.

— Ә дигәнче ике кочак утынны кертеп тә ташладым.

Вәлетдиннәрнең иңе-буе бер колач кына өйләре безнең төп төягебез ул. Үрге оч малайлары җәен-кышын шунда. Монда иркен. Тыючы, орышучы юк. Шуңа күрә Гыйзелниса әбинең бәләкәч кенә йомышын да зур итеп башкарырга әзер торабыз. Дөресен генә әйткәндә, аның чебек кенә «алтын баганасы» болай ук кычкырып мактарлык түгел — эш ягыннан. Холкына килсә, йомыш тыңлый, холкына килмәсә, хет үтер син аны, кыл да кыймылдатмый. Тискәрелек аңа төеп, дыңгычлап тутырылган.

Без бер җыела башласак, мал суйган җиргә ябырылган карабаш тургайларсыман, хәзер тупланып алабыз. Миннән соң Хәмитҗан, аның артыннан ук Шәйхат-

тар, Ибраһим белән Әсгать, Хөсәен Мөхәррәме, Ак Йомагол Әнвәре, тагы бүтәннәр килде. Иң соңыннан башлык үзе күренде.

Төшкә чаклы без төрлебез төрле җирдә я кулдан килгәнчә эш эшлибез, я вак-төяк уен белән мавыгабыз. Ә кичке якта бөтенебез бергә җыелабыз да, ике төркемгә бүленеп, «Герман сугышы» дигән иң зур, иң тамаша уенны уйныйбыз. Мин куәтле «Рукавказ» булыр сәгатемне көтеп ала алмыйм. Тик шунысы алама: мине төркемнән төркемгә күчереп йөртәләр — берчә «Рәсәй» кул астына, берчә «Германия» кул астына килеп эләгәм. Кая эләксәм дә, чәмләнеп аяусыз сугышам мәгәр: танау канамый, күз-баш күгәрми калган чак сирәк була. Яка төймәләрен әйтеп тә торасы юк — кырыла гына. Олы инәем тагып өлгертә алмый.

«Герман сугышы» башланыр алдыннан гына, тыны бетеп, Котлы кул Насыйп килеп җитте. Мәзәк ул Насыйп. Нинди генә нәрсәгә тотынмыйк: «Малайлар, мин кул башлыйм әле, минем кулым котлы»,— дип инәлә. Балыкка барсак, тәүдә ул кармак салырга ашыга: «Минем кулым котлы, балык бөтенебезгә дә илереп кабачак»,— ди ул. Калкавычы чәп итеп күл өстенә килеп тә төшә. Төшә дә шунда ук йокыга тала. Бүтән калкавычлар да кымшанмый утыра. «Хәзер... хәзер...— дип пышылдый Насыйп.— Безнең сабырлыкны сыный ул балык. Сабыр иткән — морадына җиткән...» Сабыр итәбез, әмма морадка җитеп булмый. Урманга какыга барсак, әлеге Насыйп алга чыга: «Беренче какыны мин өзим инде, малайлар, минем кулым котлы, сезгә дә игелеге тияр»,— ди. Әмма төрлечә туры килә — я тия игелеге, я тими. Ә былтыр арыш урагына төшкәндә, бу: «Әти, тәүге учманы мин урыйм әле, минем кулым котлы бит, эш ырамлы булыр»,— дигән дә... тәү урак салуы булган, сул кулының чәнчә бармагын сөягенә җиткәнче кисеп тә чыгарган. Ниләр генә күрми ул Насыйпның котлы куллары! Ук чүкесә, чүкеч төшә, тауда таш өеменнән

кош йомыркасы эзләгәндә таш баса, хәтта, ишек ачып япканда, ишеккә кысыла. Ләкин ул кулларының котына ихлас ышана. Насыйпның гел шулай тыгылып баруы минем эчемне пошыра. «Үзен күрсәтергә ничегрәк тырыша...» — дип ачуым килә. Тик байтак заманнар үткәч кенә Насыйпның шушы кыланышы аның үзенә түгел, бүтәннәргә кот теләве икәнен аңлаячакмын. Кулларының чынлап та котлы булуын ул берчак гомерлеккә исбат итәчәк...

«Герман сугышы» кабынырга торганда гына, Котлы кул, тотлыга-тотлыга, шундый хәбәр салды:

— Малайлар! Әле генә Йомры Талип белән әтием сөйләшеп торды. Йомры Талип әйтә, калада урысларның калач бәйрәме икән, ди, шул бәйрәмдә бөтен кешегә дә бушка калач өлешәләр икән, ди. Менә шундый күпереләп торган ап-ак калач.— Ул, куллары белән чамалап, калачның биеклеген күрсәтте. Ким дигәндә, тегермән ташы калынлыгы булыр иде.

Хәбәр чынлап та шаккатарлык иде. Малайларның күзләре түбәгә менде. Бөтенебез дә берьюлы телдән яздык.

— Я алдыйдыр әле! — Моны бөтен нәрсәдән дә гел файда гына чыгара торган Шәйхаттар әйтте. Ул Шәйхаттарның тимераягы бар. Кыш көне шуларны тагып Ак Йомагол тыкрыгыннан ике тапкыр шуып төштеңме, бер тиенеңне түлә. Алты төшсәң, өч тиен. Артыгына казна такыр. Кышка керсәм, мин шуның аркасында бөлеп бетәм.

— Алдаса, әтием ышаныр идемени? Алдаганга тамчы да ышанмый ул.

— Йомры Талипның шыттыра торган гадәте барын бар да ул,— диде Шаһидулла, сүзгә яңа кушылып,— әмма калада калач бәйрәме булу да бик ихтимал.

— Кәнишнә, ихтимал,— дип раслады башлыкның яраны Вәлетдин.

— Ни өчен дигәндә?..— Безнең алга башлык шундый сорау куйды.

Без бөтенебез дә аның юка гына иренле авызына төбәлдек. Оясыннан чыккан сыерчыксыман, менә-менә шул авыздан «ни өчен?»нең җавабы очып чыгачак. Җавап чыкмады, безнең алга яңа сорау килеп басты:

— Калач кайдан килеп чыккан?

— Кайдан булсын, мичтән инде,— дип Ибрай тапкыр җавап белән безнең исне китәрмәкче булды.

— Син үзең мичтән чыккан, тик ашыгыбрак чыгарганнар — пешеп җитмәс борын...— Безнең башлыкның теле кайчак әремнән дә әче була.

— Аны ап-ак оннан пешерәләр,— дип аныклады Ак Йомагол Әнвәре. Шаһидулла аның сүзенә колак та салмады. Үзенекен сөйли бирде:

— «Калач» сүзе ул, егетләр, «кала» сүзеннән килеп чыккан. Ягъни дә «калача икмәк», «кала ашы» дигәнне аңлата.

Оһо, ниләр генә белми минем нәсел Шаһидулла агаем!

— Булса тагы, безгә аннан ни файда? — дип баягы Шәйхаттар кысылды.— Әйдәгез, лутчы «Түбәтәй яшереш» уйныйк.

— Кайчан ди соң ул калач бәйрәме?

— Әллә инде... Йомры Талип этиемә үз авызы белән калач ашаганын сөйләде инде.

— Кайчан ашаган ул — кичәме, былтырмы, бүгенме? — Шаһидулла кызып-кызып төпченергә тотынды. Насыйп каушап төште.

— Бүген сөйләгәч, бүген ашагандыр инде... Я кичә ашагандыр,— дип мыгырдады Насыйп.— Ул бит безгә каладан кайтышлый сугылган иде.

— Йомры Талип, җәренгә атачак куянын «быел аттым» дип сөйләсә сөйләр, тик былтыр атканны быел аттым димәс.— Арабызда иң басынкы Мөхәррәм, бара торгач, сүзгә кушылды. Яшькә ул Шаһидулла белән Вә-

летдин чамасы. Буйга да ару гына. Башлыкның әмер-әмерләренә дә ыжлап бирми. Бәхәскә дә, уенга да сирәк катнаша.

— Ә куяны бөтенләй булмаса? — дип шик белдерде Шәйхаттар.

— Юкны бар димәс ул. Аның сүзендә һәрчак бер хикмәт була...

— Иң дөресен үзем әйтимме? — дип хәбәр салды Вәлетдин.

— Әйт!

— Мин урысларның гадәтен белеп бетергәнмен. Алар бәйрәм итә башласа, бер атнасыз туктамый. Якшәмбедән якшәмбегәчә зык кубалар.

Вәлетдин монысын белеп сөйли. Әнисе кияүгә киткәч, эле бәләкәйрәк чакта, ул өч аймы, дүрт аймы рус авылында приютта торган. Шуннан инде дуңгыз булып мыркылдарга да өйрәнеп кайткан. Хәйран килештереп мыркылдый, карт инәсенең котын алып бетерә. Тик русча сөйләшергә генә өйрәнә алмаган.

— Бүген ни көн? — дигән сорау куйды башлык.

— Җомга. Әтиләр бая өйлә намазын мәчеттә укыды,— дип раслады Әсгать.

— Рас шулай булгач, калач бәйрәме әле бетмәгән,— дигән нәтиҗә чыгарды Шаһидулла. Аның йөзендә ниндидер тантаналы балкыш чагылып узды.— Кем дә кем туйганчы калач ашарга тели, шулар минем уң якка бассын!

Шәйхаттар белән Мөхәррәмнән башкаларыбыз, елгага төшеп барган үрдәк бәбкәләресыман, башлыкның уң ягына тезелдек.

— Ә сез, бугазыгызга җиткәнче калач тыгынып, маемладыгызмыни? — диде Шаһидулла тегеләргә.

— Бармамдыр шәт. Бер калач ашаудан мал явамы? — дип Шәйхаттар кулбашларын җыерды.

— Бүген кич әтием белән Өршәк тегермәненә арыш

тарттырырга китәбез,— диде икенчесе.— Арыш икмәгеннән аермасын ходай.

...Бер тапкыр калач ашау өмете белән без егерме биш чакрым җиргә җәяү барырга әзербез. Тамакайлыкмы, комсызлыкмы, исәрлекме бу? Әллә башка берәр нәрсәме? Мин хәзер үткән гомернең чал түбәсеннән артка карыйм да шундый фикергә киләм: хикмәт бөтенләе белән калачта булмаган, хикмәт бездә, безнең рухта булган. Ун михнәтнең арасында бер рәхәтнең кадерен, йөз ачының эчендә бер татлының тәмен белеп үскәнбез без. Шуңа күрә дә соңрак, башка аң, йөрәккә дәрт кергәч тә, без әниләребезнең бер фатихасы хакына мең сынау үтәргә әзер булдык, сөйгәннәребезнең күзләренә тик бер генә тапкыр тутырып карау өчен, күкрәкләрдә ачык яраларыбызны учларыбыз белән кысып, меңәр чакрымлык араларны арага санамый, сугыш кырыннан бер генә көнгә, бер генә сәгатькә туган төякләребезгә омтылдык. Һәм, азак килеп, Туган илнең бер генә уч туфрагы, бер генә тамчы суы, бер генә сулам һавасы өчен, Ватан кабул иткән чакта, бөп-бөтен көе гомерләребезне бирдек...

— Шаһидулла! Әллә тозлы су сипкәннәр инде шул Гыйзелниса тупсасына? Ничә карама шундалар. Әтиең бәлтерәп кайтты, әнә, атны тугар! Берсе исерек, икенчесе исәр, өченчесе бырамат — ни кылыйм инде шулар белән? Шаһидулла, дим!..— Башлыкның әнкәсе Минлекәй җиңги урамның теге ягында шулай такмаклап сөйли. Аның тавышы бөтен авылга ишетелеп тора. Шуның аркасында аларның өендә һичвакытта да сер ятмый.

— «Герман сугышы» булмаячак,— дип белдерде башлык.— Иртәгә көтү куганда кала капкасы янындагы ком базына җыелабыз, калач мичтән чыгуга калага барып җитәргә кирәк... Карагыз аны, артык-портык кеше белмәсен.— Ул нигәдер Шәйхаттар белән Мөхәррәмгә сөзә биреп карап куйды.

Бездә дә уен кайгысы калмады. Берәм-берәм өйләргә таралыштык.

Менә озак-озак көттереп төн дә килде. Мин йоклап китәргә куркып ятам. Уяулыгымны Олы инәем сизмәсен дип, тын да чыгармыйм. Ул авыз эченнән генә дога укый. Аның пышылдавы ниндидер шом тудыра миндә: әйтерсең лә, Олы инәем төнге рухлар белән сөйләшә. Тик тәрәзә төбенә төшкән ай яктысы гына бераз шикләремне тарата. Энем белән сеңелем күптән инде чәбәләнә-чәбәләнә йоклый.

— Нигә шулай постың, синнай? Нигә йокламыйсың? — диде Олы инәем. (Бәләкәй чакта аның синнай дигән сүзен аңламый идем. Баксаң, ул русның «ценный» — «кыйммәтле» дигәне булып чыкты.)

Мин эндәшмим. Эндәшсәм, бөтенесен дә сөйләп бирермен дип куркам. Бүтәннәр алдында хәрамләшкәнем дә, хәйләләшкәнем дә, алдашканым да бар. Олы инәем алдында шуларның берсен дә кыла алмыйм.

— Иртәгә нiләр кыйратмакчы булып ятасың?

Йөрәгем жу итеп китте:

— Син аны каян беләсең?

— Беләм инде.

...Олы инәемнең зирәклегенә менә әле хәзер килеп гаҗәпләнәм, хәзер килеп сокланам. «Кичә ярамаган нинди эш кылдың, шулай йокыларың качарлык?» — дип сорамады ул. Чөнки кечкенә бала узганны кат-кат хәтерләү белән мавыкмас, тик алдагыңа гына алгысыр, үткән белән түгел, көткән белән яшәр ул...

— Дөрес беләсең, Олы инәем. Без иртәгә бөтен малайлар — Шәһидулла агаем да — калага, урысларның калач бәйрәменә барабыз. Бушлай калач ашарга.

— Аларның калач бәйрәме яз көне, ерганаклар ерылганда була, балам.

— Юк, әле була, иртәгә була. Йомры Талип әйткән...

— Һе, Йомры Талип әйткәч ни... растыр.— Күрмә-

сәм дә сизеп торам: ул елмаеп куйды.— Барыгыз. Йөгергәннән бурзайның табаны тузмас... Хәзер йокла инде.

— Йоклап калсам соң? Без бит таң белән үк китәбез.

— Калмассың, үзем уятырмын.

Олы инәем мине сары таңнан ук уятты. Кызыл чүпрәккә төреп, зур гына бер икмәк тоттырды.

— Кирәкми, Олы инәем, без бит анда корсак тулганчы калач ашарга барабыз,— дип карыштым.

— Мә, ал әле, бик авыр булса, ярты юлга җиткәч, берәр әрем төбенә куеп китәрсең, куяннар ашар. Әмма ярты юлга чаклы ташлама, чыда. Чүпрәген алып кайт.

Алсам да, Олы инәемнең сүзен екмас өчен генә алдым инде ул икмәкне.

— Чүпрәкне инде, Олы инәем, буш көе китермәм, калач төреп китерермен! — дип куандырдым аны.

Мин барып җитүгә, ком базы тулы кеше иде. Миннән соң, гел төшеп йөри торган ыштанын күтәрә-күтәрә, Ак Йомагол Әнвәре генә килеп өлгерде. Ул Йомаголлар бөтен өй эчләре белән шапшаклар. Әнвәрен әйттем инде. Аның агасы Мозафар әле булса танавын сөртә белми, апасы Ямлегөлнең гел генә чабата киндерәсе чишелгән булыр. Беркөнне Әсгать, янәсе, Әнвәрнең әнисенә охшатып, шундый такмак такмаклады:

Әнвәрбәк тә Мозаффар! —
Утын кисәсем дә бар,
Суга барасым да бар,
Камыр басасым да бар,
Казан асасым да бар,
Өй артына егет килгән
Шуңа багасым да бар...
Әй лә бетмәс кырык эш!
Юкны бушка тутырам,
Сагыз чәйнәп утырам...

— Нәрсә ул? — дип Шаһидулла агай минем төенчеккә төртеп күрсәтте.

— Икмәк,— дидем мин пышылдап кына.
Вәлетдин кеткелдәп көлеп җибәрде:
— Арыш икмәгеме? Юк инде. Безгә, малайлар, корсак сакларга кирәк. Мин хәтта кичә кич тә ашамадым.
— Бая мин дә шуны әйттем, тик Олы инәем генә аңламады.
Икмәк хакында башкача сүз булмады.
— Ибрай кайда? — дип сорады башлык.
— Агаемның бүсере кузгалды,— дип җаваплады Әсгать.
Башлык бөтенебезне барлап алды. Җыйнавыбыз җиде җан булып чыктык. Иң тәүдә үзе, аннан ары бүтәннәр: Вәлетдин, Насыйп, Хәмитҗан, Әнвәр, Әсгать. Иң ахырда мин.
— Кара аны, Кендек, арып бәла салмас булсаң гынаияр! — дип кисәтте Шаһидулла. Мин күкрәкне киерә биребрәк куйдым. Эндәшмәдем. Башлыкка хәтерем калса да, белгертмәдем. Үзләре бөтен өй эчләре белән адым саен, йомыш сорап, безгә киләләр, ә үзе мине буш сыйдан да мәхрүм итәргә тора.
Җавапны минем өчен Хәмитҗан кайтарды:
— Бирешмәс. Икмәген мин күтәреп барырмын. Бир, «Рукавказ»! — Шунда ук минем төенчекне үзенә алды. Теге елгы хәлдән соң Хәмитҗан миңа карата ифрат та әйбәтләнде. Ах итеп тора.
— Ә син калада да ыштаныңны шулай тотып йөрерсеңме, Әнвәрбәк?
— Тотмасаң, төшә бит.
— Юк, Әнвәр ыштаны белән бу көе юлга чыгып булмый,— дип пошынды башлык.— Мәсхәрәгә калырсың.
Бармак озынлыгы ике чөй табып, Вәлетдин белән Насыйп Әнвәрнең ыштан бавын алдан да, арттан да боргычлап җибәрде. Куанычыннан Әнвәр, кәҗә бәрәненә охшатып, бер сикереп тә куйды. Боргычлар ышанычлы иде.
Әле кояш чыкмаган. Артта, авыл өстендә, сыер мөг-

рәгән, этәч кычкырган тавышлар ишетелә. Аста, чишмә буенда, сыек кына томан йөзеп бара. Без, тузанлы кала юлында ялан тәпи баскан эреле-ваклы җиде эз калдырып, алга омтылдык. Кузгалыр алдыннан гына Әсгать борылып карады да:

Без илләрдән киткән чакта,
Күтәрелде томаннар.
Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар! —

дип җыр көйләп алды. Киттек. Дәртме, шатлыкмы — нәрсәдер эчне кытыклап рәхәтләндерә. Аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә тора.

Иманлек үренә чаклы артык әңгәмәләшми, атлыййөгерә генә бардык. Кояш инде байтак күтәрелде. Иманлек үреннән аяз көнне ак тау башындагы ак кала ялт итеп ялтырап күренеп тора. Шушы җирдә — безнең авыл басуының чиге. Уракка куна килгәндә, төннәрен карасаң, кала утлары, җем-җем итеп, болай табан килгәнсыман тоела. Каланың кайдалыгын беләбез, аның юлын таныйбыз, ә җидебездән беребез әле анда булганыбыз юк. Көмеш кыялар өстендә алтын түбәләре нур чәчеп тора бит әнә! Күзгә күренгәч, кала бигрәк тә ачык чырайлы, юмарт, кунакчыл булып тоелды. Юмарт булмаса, шулай чакырып торыр идемени? Әйтерсең, без калага китеп бармыйбыз, ә ул үзе, бөтен хәзинәләрен төяп, безгә каршы йөзеп килә.

— Калада безнең нәсел дә бар,— дип хәбәр салды Әнвәр,— иң биек пожар каланчасында тора, ул торган төштән йөз чакрымдагы җирләр күренә, ди. Патшасыман, башына алтын кәпәч киеп утыра, ди.

— Күчемдәге безнең якын гына коданың кодасы куш манаралы таш мәчеттә мич яга,— дип мактанды Вәлетдин.— Барсам, күтәреп алачак. Күр дә тор менә.

Тегеләрнең нәсел-нәсәбен белмим. Әллә бар, әллә юк. Ә менә Әсгатьнең иң өлкән агасы Исмәгыйль чын-

лап та Уфада эшли. Нигә Әсгать эндәшми икән? Хәтта теге чакта бер тактаны бүрәнә өстенә аркылы салып, икебез ике башка басып, таган атынганда, ул тамак та чыгарды бит:

Син дә бастың тактага,
Мин дә бастым тактага,
Безнең брат хезмәт итә
Универсальный лавкада.

Әсгать урынында булсам, тегеләрнең мин әллә кайчан авызын каплар идем.

— Нигә агаеңны әйтмисең? — дип пышылдадым мин, дустым кырыена килеп.

— Куй,— дип кул селтәде,— аны белмәссең: бер калада, бер салада. Ташкент ягына чыгып киткән ул хәзер.

Иманлек үрен үтеп, байтак киткәч, кала тагы да күздән югалды. Безнең дәрт тә нигәдер сүрелә төште. Кызыл чүпрәккә төрелгән икмәк бара-бара Хәмитҗаннан Насыйпка, Насыйптан Вәлетдингә күчте. Азак килеп, ул башлыкның култык астына кереп сыенды.

— Әле ярты юлга җитәбезме, Шаһидулла агай? — дип сорадым мин.

— Нигә, хәл беттеме әллә? Әйттем бит мин сиңа...

— Юк, бетмәде.

— Алайса нигә төпченәсең?

— Авыр булса, икмәкне, ярты юлга җиткәч, әрем төбенә куеп китәргә кушты Олы инәем.

— Бушны сөйләмә, Олы инәең алай димәс.

— Әйтте шул. Әйтте!

— Исәр, ул бит «авыр булса» дигән. Менә кара, кош кебек лә,— ул икмәкне күккә чөеп, ике кулы белән эләктереп алды.

— Куй, Шаһидулла, икмәкне уйнатма, валчыгы төшәр дә үзеңә язык булыр,— диде Әсгать.

Без бөтенебез дә языктан үлеп куркабыз. Хәтта башлык үзе дә. Шуңа күрә ул, гафу итүне сорагандай, икмәкне күкрәгенә кысты.

Яхшы-яхшы атлар җигелгән әллә ничә тарантас, тузан туздырып, безне узып китте. Каршыга да олаулар очрады. Җәяүлеләрдән олы юлда бары без генә.

— Кала әле еракмы? — дип сорады Вәлетдин арык атлы бер бабайдан.

— Унбиштән ким булыр, уннан артык булыр. Җәһәтрәк атлагыз. Анда сезне көтәләр.

Көткән җиргә ашыгырга кирәк. Моннан соң без бер тын йөгереп тә алдык. Йөгерсәк тә, артык алдырып булмый хәзер. Миннән олылар да әллә кая китә алмый. Әнвәрнең штаны янә бушады. Насыйп арттагы боргычны тагы бер кат борып куйды. Бүтәннәрнең ничектер, минем корсакның калач кайгысы китеп бара. Кара икмәккә дә бик риза булыр иде. Ничек инде башлап сер бирим, бер имгәк кебек?

Өч-дүрт йортлы бер рус авылын үткәч, басу уртасындагы сирәк кенә каенлыкка тукталдык. Күләгәгә килеп кергәч, тыннар иркенәеп китте.

— Утырыгыз,— дип боерды башлык. Үзе тезләнеп утырды да алдына кызыл төенчекне куйды.— Корбан мулла нәрсә ди, шуны кем белә?

— Син беләсең,— диде Вәлетдин, нәрсәдер сизенеп алды, ахры, тыңкыш.

— Корбан мулла әйтә: «Аш — ашка, урыны башка»,— ди.

— Мулла белеп сөйли инде ул,— бу юлы сүзгә Әсгать куәт бирде.

— Менә бу икмәктән авыз итсәк, калачка урын калырмы эчтә? — дип сорады Шаһидулла бездән.

— Калыр! Калыр! — диештек без.

— Мә, Вәлетдин,— дип башлык кесәсеннән алып пәке сузды.— Җиде өлешкә гадел итеп бүл шушы ризыкны.

Вәлетдин өтәләнеп үк китте. «Ә» дигәнче ул кызыл чүпрәк өстенә бер чама тигез генә бүленгән җиде кисәк икмәкне тезеп тә куйды. Әлбәттә, өлеше белән өлеше тип-тигез түгел иде. Нигәдер, башлык иң зур кисәккә — үз өлешенә кул сузмый тора. Аннан узып без дә үрелә алмыйбыз.

— Юлда ризыкны гадел өләшергә кирәк,— диде ул,— «монысы кемгә»не әйтеп.

— Малайлар! Мин әйтеп торыйм әле. Минем телем котлы — һәркемгә үз өлеше чыгар.— Насыйп сикереп үк торды. Каршы килүче булмады.

Насыйп артына әйләнде. Вәлетдин бер кисәкне ала да сорый:

— Монысы кемгә?

— Хәмитҗанга!

— Монысы кемгә?

— Шаһидуллага!

— Монысы кемгә?

— Кендеккә...

Җидебезгә дә өлеш чыкты. Әмма гадел үк булмады. Иң зур кисәк миңа, иң бәләкәе башлыкка эләкте. Шулай да теге сер бирмәде. Тик мин сизеп торам: бу икмәк минем эчемә аш булып бармаячак. Дөрес килеп чыкмады. Шаһидулла миннән биш яшькә өлкән. Дәү кешегә өлешнең дә зуррагы булырга тиеш. Алмашырга кирәк... Шулай дип уйланып торганда, теге үз кисәген умырып тешләп алды. Бүтәннәрнең дә авызлары чәпелди башлады. Бу яман гаделсезлекне ничек кенә төзәтергә соң?

Мин үз сыныгымны озак кына ашап маташкан булдым. Өч-дүрт кабымлык икмәгем калгач, аны Шаһидуллага суздым:

— Мә, агай, ашап бетер.

— Үзең аша.

— Мин туйдым инде, валлаһи...

— Ант итмә. Бирсәң, болай гына бир. Югыйсә антың башыңа төшәр.

Корсакка азык кергәч, аякка куәт кайтты. Мин еш кына шундый уйга калам: йодрык чаклы гына икмәк кисәгендә күпме тылсым бар, ачыкканда шуны ашадыңмы, дөнья ямьләнә дә китә. Менә әле дә... якында гына бер кош сайрап җибәрде, яңарак баш кыскан бодай өстеннән күгелҗем шаян җил йөгереп үтте, каен яфраклары да дәртлерәк, ихласрак җилфердәргә кереште. Кояш та ул кадәр өтеп бармый хәзер. Бөтенесе дә әнә шул бер сынык икмәктән.

Без кузгалып киткәч тә:

— Әйдәгез, малайлар, Әмин биясе кебек, юргалап барабыз,— диде Насыйп. Үзе, алдан төшеп, юргалый да башлады. Ләкин башлык белән Вәлетдин аны шунда ук узып китте. Мин иң арттан лерт-лерт кенә юртып барам.

Түбән урамда уттай эш өстендә урманга җимеш-җиләк җыярга йөри торган Әмин бар. Майланмаган кабык арбасына эреле-ваклы бала-чагасын төяп, иртәнчәк ул акрын гына югары очка күтәрелә. Әллә кайчаннан дегет әсәре күрмәгән тәгәрмәчләр, бөтен авылны бер итеп, сузып-сузып сөрән салып бара. Бер көн Әсгать миннән сорый: «Нәрсә ди Әмин арбасы?» «Нәрсә дисен, сөрән сала». «Юк,— ди Әсгать,— ул Әмингә инәлә: бар-мы-ыйк ла... бар-мы-ыйк ла... бар-мы-ыйк ла... ди». Юньләбрәк тыңласаң, Әсгать сүзе дөрескә чыга. Арба нәкъ шулай кычкыра. Ә инде кич кайтканда ала бия тау түбәненә юргаларга керешә, ул чак арбаның дүрт тәгәрмәче алмаш-тилмәш мактанырга тотына. Аларның нәрсә дип мактанганын да белә Әсгать. «Сыдырып салдык! Сыдырып салдык!!!» — ди алар. Хәзер инде, Әсгать төшендереп биргәч, Әмин арбасының телен бөтен авыл аңлый.

— Каладан кайтканда, без дә, Әмин арбасы кебек, җырлап кайтырбыз әле:

дә тәм ягыннан да, ямь ягыннан да баягыга караганда

Ак калада ак калачны
Сыдырып салдык, сыдырып салдык.
Капкачына чаклы тулды
Кызыл сандык, кызыл сандык...

Әсгатьнең башлап әйтүе булды, Вәлетдин белән Насыйп элеп тә алды:

Ак калачны сыдырып салдык, сыдырып салдык...

Хәзер инде малайлар юргаламый; бөтенебез дә, самокатта килгән шикелле, тубыкларны югары чөеп, ыргый-сикерә йөгереп барабыз. Күңелгә үтә ятышлы әлеге сүзләрне көйли биреп, беравыздан кабатлыйбыз:

Ак калада ак калачны
Сыдырып салдык, сыдырып салдык...

Кызыл сандык турындагы сүзләре шәп килеп чыкмады, ахрысы, алары шунда ук онытылды. Ә боларын әйткән саен әйтәсе килеп тора.

«Ак калачны сыдырып сала-сала», без биек таш юлга килеп чыктык. Юлның ике ягына юан-юан тирәкләр үскән. Юлга түшәлгән таш, мунча ташы кебек, шопшома. Үзе яссы түгел, кабарынкы.

— Бу юлдан әүвәл заман патша үзе генә йөргән. Хәзер, Совет власте булгач, теләсә кем йөри ала,— дип аңлатты башлык.— Слабуда хәзер. Хөррият!

Бер борылманы узгач та, алдыбызга янә ак тау башындагы кала килеп басты. Әнә генә ул — үрел дә тот! Кала хәзер безнеке, әллә кая китә алмас.

— Әссәламәгаләйкем, кала! — диде Вәлетдин.— Менә без сиңа килеп тә җиттек!

— Кала безне каршы ала, корсакларга калач сала, рәхмәт укый җиде бала,— дип тезеп китте Әсгать.

Без бары кабатладык кына:

— Рәхмәт укый җиде бала!

Кая күз ташлама, завод торбалары тырпаеп тора, мәчет манаралары, чиркәү гөмбәзләре ялтырый. Без

мәчетне чиркәүдән аера беләбез. Боголюбларның чиркәвен көн дә күреп торабыз. Мин бары шуңа гына аптырыйм — нәрсә эшләп ул чиркәүләрне әле булса җир йотмый икән? Бар галәм белә: бөтен чиркәүләр хәрам, алар зил-зәбәр киләчәк; бөтен каферләр языклы, үлгәч алар тәмугта яначак. Чиркәүләре әйдә чукынып китсен, ә менә каферләрен кызганам. Ул кызгану менә нәрсәдән башланды.

Былтыр яз Лекаревкадан безнең знаком Тимофей минем чаклы гына малае Егорка белән безгә кунакка килде. Әтиләр ашап-эчәргә утырды, без Егорка белән берәр күмәч тотып, курага чыктык. Ул сап-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, шалкан төсле ап-ак йөзле малай. Сөйләшә белмибез. Мин кая барсам, ул шунда бара, мин нәрсә эшләсәм, ул шуны кабатлый. Бакчага кереп әйләндек, лапас башына менеп төштек, шуннан килеп келәт янына өелгән бүрәнә өстенә менеп утырдык. Мин аякларымны селкетсәм, Егорка да кушыла. Мин көрсенеп куйсам, ул да көрсенә.

Әтиләр, ахрысы, тиз үк кызып та алды. Минем әтием Тимофей алдында гел генә русча җырлаган була. Ә тегесе безнеңчә сукалап маташа. Башта Тимофейның дәрте тышка бәреп чыкты:

Әйдә, зиңги, урманга,
Курай зиләк зыярга...
Курай зиләк бал кебек,
Безнең зиңги зан ке-бе-ек...

Белеп торам. Бу җырны ул табын карап йөргән Олы инәемә ярамсакланыбрак сыздырды. Хәзер көт тә тор — әтиемнең калын тавышы яңгыраячак. Аның русча бары бер генә җыры бар. Әнә, әйттереп тә җибәрде:

Базар большой,
Народ много,
Русский барышня идет,
Дай ему дорога.

Егорка белән без бер-беребезгә карашып алдык. Аның шундый зәңгәр, шундый моңсу күзләре мине кинәт шомга салды. Тамагыма ниндидер төер килеп тыгылды. Шул чаклы саф, шул чаклы ягымлы, шул чаклы гөнаһсыз күзләрнең хуҗасы мәңге-мәңге тәмугта яначак. Дөрләп-дөрләп яначак. Шушы кадәр газаплардан аны ничек кенә итеп коткарырга соң? Ничек кенә?

— Егорка! — дип ирексездән аны кочаклап алдым. Ул башта куркып китте, аннан соң үзе дә мине нык итеп күкрәгенә кысты. Бу чак мин аны коточкыч һәлакәттән коткарамсымак тоелды. Ихтимал, мондый кылыгым өчен үземә дә шул ук җәза килер. Хәзер соң инде — кафер баласы минем кочагымда. Ни күрсәк тә, бергә күрербез. Әтиләр инде бер-берсенә кушылып җырлый башлады. Безне алар бар дип тә белми. Бәлки, нәкъ шушы мәлдә берсе сары чәчле, берсе кара чәчле ике малай мәңге тәмугта янарга хөкем ителгәндер — сезнең балаларыгыз. Их, әтиләр! Йөрәгем ярылырдай булып гөп-гөп тибә. Үземне дә, Егорканы да кызганам.

...Нәрсә эшләп мин Егорканы хәтерләдем соң әле? Ә... чиркәү күргәч.

Барабыз. Йөрәгем леп-леп тибә. Барабыз, барабыз, кала һаман бер җирдә тора. Хәтта азрак артка да чигенәсымак. Ташка басып та булмый, аякны көйдереп ала. Тезелешеп юл читеннән киләбез. Адымнар нык ук сүлпәнәйде. Үлеп эчәсе килә. Баягы такмаклар, әйтерсең, бөтенләй онытылды. Алдан Насыйп атлый, аның артыннан Хәмитҗан, Хәмитҗаннан соң — Вәлетдин... Шаһидулла юлның икенче ягыннан берүзе бара. Минем алдан гына, аю табаннары белән аркылы басып, Әнвәр сөйрәлә. Аның ике үкчәсендә дә камыш калынлыгы ярыклар. Бу аякларның кышын киез итек, язынкөзен күн итек күргәне юк. Сирәк-саяк чабата тисә тия шунда. Алтын такыялы нәселе турында ул дөресен әйтте микән, әллә шыттырдымы? Булыр да. Без бөтенебез дә күпертергә, купаерга әвәсбез.

— Их, сусын кайтканчы су эчсәң иде! — диде Насыйп.

— Мин бер уртлауга да риза булыр идем әле, валлаһи! — дип ант итәргә кереште Вәлетдин.— Уртка сыйганчы уртлатсалар.

— Син, бирән, бала-чага котыртып, шыңшыма! — дип кырт кисте Шаһидулла.

Башкача сүз куертучы булмады.

Бер катлы агач йортлар тезелеп киткән урам буйлап байтак баргач, Агыйдел күперенә килеп җиттек. Кайсыбыз түбәтәе, кайсыбыз киез эшләпәсе белән сосып алып, туйганчы су эчтек. Суы җылымса, төче иде. Шулай да безгә җан кереп китте. Калач бәйрәме, әлбәттә, күпер аръягында, тау өстендә, булырга тиеш. Бәйрәм ул гел калку җирдә уза бит. Бу тирәдә әле аның ишарәсе дә юк. Күпер аша чыккач та әллә ни тамаша күренмәде. Йортлары болай биек кенә, капкалары да гел урыс капка, урамнары безнекеннән таррак. Урам тулы я атлы, я җәяүле кешеләр ары-бире узып тора. Бер-берсенә сәлам дә бирмиләр.

— Әһә, малайлар, ана «Калачлар» дип язылган. Калач лавкасы! — Моны арада иң шәп укый торганыбыз Вәлетдин хәбәр итте. Мин әле кушып укый белмим, бары хәреф кенә төсмерлим.

Урамның теге ягындагы сары йортның ишек төбенә килеп туктадык.

— Егетләр, ишек тоткасына тәүдә мин тотыныйм, минем кулым...— шулай дип әйтүе булды, эчтән ишекнең ачылып китүе булды, алга сөзелеп барган Котлы кулның башына шап итеп килеп тиюе булды. Күп тә үтми тегенең маңгаенда саргылт-күгелҗем оры да бүлтәеп чыкты.

— Әссәламәгаләйкүм! — дигән булды ул ишектән чыккан кешегә.

— Күм, күм,— дип үчекләде дә теге кеше китеп барды.

Ишек ябылмас борын без эчкә агылдык. Кердек тә, сәлам бирергә дә онытып, катып калдык. Шүрлекләрдә күперелеп торган калачлар тезелгән, чөйләргә бөят-бөят итеп бәйләнгән төрле-төрле крендельләр эленгән, әрҗәләрдә кызыл билле прәннекләр мыжгып ята. Тагы әллә нинди хәлвәләр дә әлбәләр авызга керергә тора. Менә кайда ул сыйның оясы!

Безгә карап, лавкачының күзе дүрт булды. Без дә эндәшмибез, ул да сүз кушмый. Тәүдә бездән шөрләде, ахрысы. Үлчәү табагында яткан зур гына гер ташын үрелеп алды. Без, әдәп саклап, ишек төбендә генә торабыз. Нишләптер ул кузгалмый, чырае да сытык күренә. Кайсы җиребезнедер килештермәде бугай. Алай адәм ошатмас җиребез юк кебек тә...

Әллә күпме шулай торгач, калын елтыр иреннәрен чак кына кыймылдатып, теге бездән сорар булды:

— Нәрсә кирәк сезгә, йолкышлар?

— Без йолкышлар түгел, иптәш, без авылдан килдек! — диде Шәһидулла, үзебезнең абруйны югары тотып.

— Патша сараеннан килмәгәнегезне күреп торам, иптәш йолкышлар,— ул тамак төбе белән кых-кых көләргә кереште, аның җәенке итләч битенә пешкән чөгендер төсе керде.— Шулай да ни дип безнең тарафларга рәхим иттегез? — Учындагы герне сикертеп алды.

— Без ни, калач бәйрәме кайда була икән дип, сорамакчы идек, тик...— Вәлетдиннең әйтеп бетерүен көтми, башлык аның җиңеннән тартты.

— Калач бәйрәме? Ә... калач бәйрәмеме? — Чөгендер бит тагы җәелеп китте.— Калач бәйрәме ул кесәдә була, менә монда.— Ул, кулын кесәсенә тыгып, көмеш акча чылтыратты.

Без дә, сүз куешкандай, бөтенебез берьюлы кесәләребезгә тыгылдык. Анда бәйрәмнең әсәре дә юк иде... Киштәләрдә тезелеп торган калачлар да, чөйдәге крендельләр дә, әрҗәләрдәге прәннекләр дә, әлвә-хәлвәләр

күп кайтыш тоелды миңа. Исәнләшми кергән идек бу йортка, хушлашмый чыгып та киттек. Ләкин моңа карап кына без әле өметебезне өзмәдек. Ары киттек.

— Без дә инде — җыен исәр! — диде Насыйп.— Калач бәйрәме бит ул урысныкы, ә без мөселманга килеп каптык.

— Үз мөселманыбыз, ә ничегрәк мыскыл итә, йолкыштан гына салдыра! — дип чәпчеде Вәлетдин.

— Мөселманның каруны аның кафердән дә яман була. Шуның өчен әнә теге карун бәете чыккан да,— дип төшендерде Әсгать.

> Карун мәлгунь бар иде,
> Ахырда аны җир йотты...

Моны да йотар әле берчак.

Без һаман кала өстенә, югарыга, күтәрелдек. Калач лавкалары каршына килеп, озак-озак басып тордык, урыс капкалы биек-биек йортлар турында туктадып, тәрәзәләргә карап каттык, яңа пешкән икмәк исе килгән өйләр тирәсендә уралдык, әмма безне берәү дә исәпкә алмады, берәү дә чакырмады. Калач өләшә торган урыслар кая икән? Бардыр бит инде алар. Булмавы мөмкин түгел. Монысы башка сыймый: шул тиклем җирдән кил дә, селәгәй агызып йөри-йөри, бушлай кайтып кит, имеш?!

Минем нәрсә уйлаганны сизгәндәй, Хәмитҗан әйтеп салды:

— Я без эзли белмибездер әле... Кешедән сорашырга кирәк.

— Бәйрәм сиңа адашкан бозаумыни — эзләп табарга? Бәйрәм ул үзе: «Мин монда!» — дип, нур чәчеп, ерактан күренеп, чакырып торырга тиеш. Болай булгач, туйдан соң дөмберенә генә килгәнбез, бәйрәм беткән. Вәссәлам! — дип мөһер сукты башлык.

Шулай дип әйтүе булды, минем бөтен буыннарым

таралды да төште. Ачлык та, сусын да — икесе берьюлы буып алды мине. Җитмәсә кояш, күлмәк аша үтеп, тирене генә түгел, сөякне өтеп бара. Бүтәннәрнең дә хәл шәптән түгел иде.

Тәрәзә капкачлары ябык бер өйнең болдырына тезелешеп утырдык.

— Давай минем нәселне табабыз,— диде Әнвәр,— пожар каланчасы кайда икәнен беләбез дә... Бер самовар чәен жәлләмәс әле.

Пожар каланчасын тиз сорашып таптык. Тик аның түбәсендә башына алтын таҗ киеп утырган адәм генә күзгә чалынмый. Муеннарны сузып, әллә ничаклы карап тордык, Әнвәрнең нәселе тәки күренмәде.

— Әллә егылып төшеп имгәндеме икән? — дип аптырый Әнвәр.— Һи-һи, Янбирде агай, син кайда?

— Янбирдегә юнь бирер, безгә җимне кем бирер? — дип Әсгать шаяртмак булды. Тик бездә мәзәк сүз кайгысы юк иде. Берәү дә көлмәде.

— Янбирде агай! Бу — мин, Әнвәр! Авылдан килдем! — дип кабатлады теге.

— Ярылырдай булып, нигә сөрән саласың? Марш! Марш моннан — җыен эшлексез!! — Зур кызыл капкадан килеп чыккан мыеклы бер агай шулай дип безне куып җибәрде. Нинди эре чиерттерә, җиз элмәкле киң каеш будым дигәч тә.

Нәсел-нәсәп эзләү шуның белән тәмам дигәндә, Вәлетдин михылдады:

— Бер уңмасак, бер уңарбыз, малайлар, әйдәгез куш манаралы таш мәчеттә мич ягып торучы минем кодага барабыз. Күчем коданың якын гына кодасы ул.

— Шундый челләдә мич ягалармыни? Ул кодаң әллә кайчан авылына кайтып киткәндер инде,— дип күңелгә шик салды Насыйп.

— Кала мәчетен җәен-кышын ягалар! — дип күзгә терәп алдашты Вәлетдин.

— Алдыйсың, бирән!

— Билләһи! Мич якмасаң, анда чиркәү пәриләре иләшә,— дип безне шунда ук сыртка әйләндереп салды Вәлетдин.— Әнә, кая карама, чиркәү бит.

Ҡаланы байтак кыдырып йөргәч, куш манаралы таш мәчет янына да килеп чыктык. Тик мәчетнең капкасы бикле иде. Шулай да янәшәдәге капкасыз ихата эчендә төптә үк торган бәләкәч кенә тәбәнәк өйгә сугылырга булдык. Урам яктагы зур йортка кагылырга йөрәк җитмәде.

Өйгә тәүдә Вәлетдин белән мине кертеп җибәрделәр. Кергәч тә күзгә чалынган нәрсәләр шул булды: көнгә караган тар гына ике тәрәзәдән ике буй булып, тузан агыла (гаҗәп, ничек пыяла аша үтеп керә икән ул?); как идәндә бер бала мүкәйләп йөри, икенчесе түшендә шуа; сәке өстендә олы гына апа яманып утыра, ишек төбендәге караңгы почмакта ир кеше йоклап ята.

— Исәнмесез! — дидек без бер-бер артлы. Теге апа күтәрелеп карамый гына:

— Арубыз әле,— дигән булды. Шуннан ул акрын гына башын безгә борды.— Әлеге өяз хәерчеләре! Иртә димиләр, кич димиләр, җәй димиләр, кыш димиләр — киләләр дә керәләр, киләләр дә керәләр!— дип кабынып китте ул.— Теңкәгә тиделәр бит инде! Тапканнар юлаучы йорты!

— Без хәерче түгел, апа, без...— дидем дә мин тотлыгып калдым.

— Хәерче булмасагыз да барыбер... хәерче инде. Бае аның безгә фатир төшәмени? — дип кул селтәде ул.

— Безнең Кучем коданың якын гына кодасы шушы мәчеттә ел әйләнәсенә мич яга...— диде Вәлетдин этенә-төртенә. Апа азрак җанланып китте.

— Кучемнекеме әллә сез? Исән-аманмы, кучемнәр?

— Юк, без Келәшнекеләр. Без шушында мич ягучы коданың Кучемдәге кодасының якын гына кодасы булабыз. Гыйзелниса карт инәйнең оныгы мин.

— Әллә тагы,— дип сүрелде апа,— андый кодагыйны бер дә генә белмим ләсә. Әй, Ишбирде, әнә кодаларың килгән! — «Ишбирде» дигәне почмакта яткан теге кеше булып чыкты.

— Ә? Кодалар? Хуш килдегез, кодалар! — дип теге сикереп үк торды. Йокысы да чыгып бетмәгән күзләрен уа-уа кабатлады.— Хуш килдегез, түрдән узыгыз, кодалар! Бик вакытлы йөрисез, ай, афарин!

Ул тәмам уянып бетте, карашы белән өйне байкап чыкты.

— Кодалар кая? Фу, янә саташтым, ахры. Мичәп-мичәп яхшы атлар җиккән кодалар, дөньяны дер селкетеп, авылны бер итеп, кыңгыраулар кыңгыратып киләләр, имеш, димен. Күрше-күлән көнләшүдән авызын ачкан да читәнгә сөялеп каткан, имеш, димен. Их, кодалар, кая булдыгыз?

— Әнә бит кодаларың,— дип апа безгә ымлап күрсәтте.

— Сезмени кодалар?! — дип аптырады Ишбирде.

— Без... Мин... Мин үзем синең Күчемдәге якын гына коданның кодасы булам,— диде Вәлетдин, тыцкышлыгын белдермәскә тырышып.— Минем карт инәем, Гыйзелниса кодагыең, сезнең бөтен өй эчегезгә күптин-күп, чуктин-чук сәлам җибәрде...

— О, минем Гыйзелниса кодагыем дан бичә ул! Баскан җирендә очкын уйната, ул җыр-биюгә дисеңме — хәйран тамаша, тәңкәләренең бер чылтыравы йөрәкләрне җилкетә,— дип Ишбирде шаштырып кемнедер мактап алды.— Рәхмәт кодагыйга! Сәламнәрен кабул кылдык.

«Нинди Гыйзелнисаны сөйли икән бу?» — дип аптырап торганда, ул миңа төбәп эндәште:

— Син дә кодамы?

— Мин дә кода,— дидем, кинәт каушап киттем, әмма җебеп төшмәдем.— Тышта тагы биш кодаң калды әле, керергә кыймыйча...

Какча яңаклы, озын буйлы, такыр башлы, нечкә генә мыеклы бу агай, ишеккә килеп, аны шар ачып җибәрде.

— Һай, һай, һай, кодалар! Өйгә рәхим итегез! Тартынмагыз! — диде ул.

Малайлар кыяр-кыймас кына өйгә керделәр. Апа идәндәге балаларны сәкегә алып утыртты.

— Хуш! Искә төшереп, санга сугып, килеп чыгуыгыз бик хуп, бик мәслихәт, кодалар,— диде Ишбирде.— Әнкәй, самоварыңны куй, чәеңне әзерлә!

Шулай дип әйтүе булды, эчтән ниндидер бер рәхәт җылы агым узып та китте.

— Самоварын куяр да идем, улым, чәе дә, шикәре дә юк. Икмәген дә килен кичен генә алып кайтачак. Кунаклар алдында оятка калдык инде болай булгач.

— Оның булса, көлчә пешер, ярмаң булса, өйрә бүрттер.

Бу юлы апа бөтенләй җавап бирмәде.

— Нәрсәң бар соң, әнкәй?

— Бүрттерергә куйган борчак кына бар...

— Борчак! — дип куанды Ишбирде.— Бүрткән борчак ни ул — нәгызь кодалар сые инде. Дан аш ул! Ризыкны кабул кылырсыздыр бит!

— Кылырбыз! Кылырбыз! — диештек без. Абруй саклыйм дип, аш талымлап торыр заман түгел иде.

Идән уртасына апа катып беткән сары ашъяулык җәйде, шуның уртасына зур гына коштабак бүрткән борчак утыртты. Борчагы ап-ак, эре иде. Чынлап та, мондый эре борчак теләсә кайчан эләкми ул.

— Әйдә утырышыгыз, җитешегез! Барыбер бөтенегезгә дә кашык чыкмас, кул белән генә согыныгыз! — дип кыстарга кереште хуҗа. Без, коштабакны тирәли тубыкланып утырдык та, ашыкмый гына учлап, борчакны авызларга ташырга керештек. Кабаланмасак та, эш җитез бара. Шундый тәмле борчакны гомердә дә

ашаган юк иде. Менә нинди була икән ул «кодалар сые» — телеңне йотарсың!

Коштабакның төбен ялтыратып куюга, алдыбызга бер бидрә салкын су да килеп утырды. Читенә зур гына чүмеч тә эленгән.

— Сыйлаганда су эч, дигәннәр борынгылар,— дип аңлатты Ишбирде,— алар белми әйтмәс.

Суны да төбендә генә калдырдык.

— Я, хәзер дога кылыйк,— дип, үзе табынга утырмаса да, битен сыйпап куйды хуҗа. Без дә йоланы башкардык.

— Кала күрергә килдегезме, кодалар? — дип сорашырга башлады Ишбирде, табын соңындагы әңгәмә гадәтен саклап.

— Әйе, агай, кода...— дип ихлассыз гына җаваплады Шаһидулла.

— Ошадымы соң?

— Әллә инде... Йортлары матур, коймалары биек,— диде шул ук башлык,— тик кешеләре үтә кабаланып йөри.

— Ярар, килеп әйбәт иткәнсез, дөнья күреп үсәргә кирәк шулай. Калада да бөтен адәм гел калач кына ашап тормый. Икмәге дә юк чак була, гаеп итеп китмәгез... каланы.

Бу өйдә Вәлетдин, сүзгә кушылып бармаса да, безгә караганда үзен иркенрәк тотты. Урыннан да ул беренче булып кузгалды. Ни дисәң дә — төп кода.

— Сый-хөрмәтегез, якты чыраегыз өчен рәхмәт, кода, рәхмәт, кодагый,— диде ул, өлкәннәргә охшатып,— гаепләп калмагыз. Без авылга уңайлыйк инде.— Бөтенебез дә пыр итеп урыннан тордык.

— Ярар инде алай булгач. Кайткач, кодагыйга сәлам тапшыр бездән, үзе кунак булып килсен,— диде Ишбирденең инәсе.— Ну, шул фәкыйрьлек! Биреп җибәрергә күчтәнәчем дә юк, ичмасам...

— Яхшы сүз үзе күчтәнәч ул, әнкәй,— дип юатты улы.

Без ишек төбенә килеп өйкәлештек.

— Кайтыр юлыгызны онытмадыгызмы? — дип сорады Ишбирде кода.

— Онытмадык,— диде Әсгать. Ул эт кебек. Әллә нинди кара урманда булмыйк, бер үткән җиреннән, һич тә адашмый, кире әйләнеп кайта белә. Үз эзенең исен тоя ул. Ә мин әрем арасында да адашам. Шундый аңгыра мин.

Кат-кат рәхмәтләр әйтеп, без бу сәер, кунакчыл өйдән чыгып киттек. Кемгә кемнең кодасы булып чыкты соң әле теге Ишбирде? Кодамы икән әле?

— Үтә бай тормасалар да, кодаң юмарт икән, малай,— диде, тышка чыккач, Шаһидулла Вәлетдингә.— Җанын ярып бирергә әзер тора.

— Чәйләре булса, чәй дә эчерер иде әле, валлаһи... Күтәреп үк алыр дидемме мин сезгә...— Масаюдан Вәлетдиннең тыңкышлыгы кими төште хәтта. Масаерга хакы да бар шул: кем кодасы дисең, аның кодасы сыйлады безне.

Бу шыксыз каладан без ярыйсы ук бизеп кайтып киттек. Кайтыр юл тагы да озынрак, тагы да йончыткычрак булды. Әмма берәү дә сукранмады, берәү дә бәла салмады. Каладан алып кайтып килгән бердәнбер табышыбыз — Насыйпның маңгаендагы оры иде. Янә Хәмитҗанның култык астында баягы икмәкне төргән тастымал бар.

Күз бәйләнгәндә генә без Имәнлек үренә килеп җиттек. Иркен тын алып, артка әйләнеп карадык. Анда, сыек эңгергә баткан ерак офык читендә, каланың утлары балкый. Алар, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, шундый еш җемелди — хәйран калырсың!

— Беләсезме, малайлар, ул утлар нәрсә ди? — Бу сорауны, әлбәттә, Әсгать бирде, җавабын да үзе кай-

тарды.— «Семәйттекме[1]?», «Семәйттекме?» — дип безне үчекли алар.

— Мәсхәрә иттең безне, ну, кала! — дип Насыйп йодрык күрсәтте. Аның артыннан, «менә сиңа», «менә сиңа» дип, без дә кукиш суздык тегенең тәкәббер утларына. Ләкин моның белән генә ачу кайтмады, үч алынмады. Тагы нәрсәдер кылырга кирәк иде әле.

— Әйдәгез, малайлар, каланы ныгытып мәсхәрә итәбез! — диде бу хәерсез сәяхәтнең бөтен оятын күтәреп килгән башлыгыбыз.

— Ничек итеп?

— Менә ничек итеп...— диде ул, ыштанын тезенә хәтле төшереп, калага артын әйләнде. Без дә шулай иттек.

— Қала, мә яла! Мәсхәрә сиңа! Мәсхәрә сиңа! Мәсхәрә сиңа! — диде ул. Без аның сүзләрен тагы да кычкырыбрак кабатладык:

— Мәсхәрә сиңа! Мәсхәрә сиңа!! Мәсхәрә сиңа!!!

Қайсыбыздыр берәү шартлатып, баягы борчак белән атып та җибәрде.

Үч тәмам алынды. Хәзер инде каланың утлары җемҗем итеп янмый, былт-былт итеп тона, сүнә бара иде. Чөнки бу чак кала баштанаяк мәсхәрәгә баткан иде. Шул кирәк тә аңа!

Үч алынып, ачу басылгач, без калган юлны тизрәк, җиңелрәк, күңеллерәк үттек...

...Нибары җиде ел узгач, шушы калага китәрмен дә бөтенләйгә олагырмын дип, шул чак я кем уйлаган инде? Әйе, киттем дә баттым. Гомерлеккә. Башта тәнем калада булса да, җаным авылым кырларында адашып йөрде. Бара торгач, ул таш диварлар эчендә төяк тапты. Кешенең күңеле кайда соңгы төяген таба, шул җир — аның рухи Ватаны. Уфа минем җанымның оясы, рухымның Ватаны булды.

---

[1] Семәйтү — мәхрүм итү.

Йомры Талип

— Теге кәҗә тиреләрен Талипка аткарасы иде. Үзе, нишләптер, күренми,— дигән булды әтием, иртәнге чәйне эчкәндә. Үзе, ат җигеп, каядыр чыгып китте. Агайларым белән Кече инәем ерак басуда куныш тары ура. Шулай булгач, ул кәҗә тиреләрен кем илтсен? Үзләре бармаслар да инде алар. Әтиемнең шундый мәзәк гадәте бар: ул йомышны атап кына кушмас. «Тегене тегеләй итәргә иде, моны болай итәргә иде»,— дигән булыр да сөйләнер. Таяк башы кемгә тигәнен үзең төшен шуннан. Беркөнне кичке аштан соң, агаемнарга төбәп, әтием шундый хикәят сөйләде.

...Имеш, борын-борын заманда, бер бабай буйга җиткән улына кәләш әйттермәк булган икән. Әзмәвердәй улын беркөнне кызлар суга йөри торган сукмакка алып чыккан, ди, бу. Бер төркем кызлар якынлашып килүен күреп калган да карт әлеге егетне камчы белән кыйнарга керешкән, ди. Кызларның берсе сорый икән:

— Улыңны ни өчен тукмыйсың, бабай?

— Әйткәч тә, белә, кушкач та, эшли. Шуның өчен тукмыйм,— дигән бабай. Кызлар шаркылдашып көлешкәннәр дә:

— Һи, исәр карт... Менә дигән улын тукмый,— дип узып киткәннәр.

Болардан байтак артта уйланып кына тагы бер кыз килә икән. Бабай янә улын тукмарга тотына.

— Ни өчен тукмыйсың улыңны, бабай? — дип сорый монысы да.

— Әйткәч тә, белә, кушкач та, эшли. Шуның өчен тукмыйм,— дигән карт.

— Әйдә, ныграк, үзегенә үтәрлек итебрәк яр, бабай. Улыңның инде әйтмичә дә белер, кушмыйча да эшләр чагы җиткән.— Шулай дигән дә кыз узып киткән. Шушы көнне үк бабай бу кызга яучылар җибәргән.

Әтием соңгы сүзен суза биребрәк әйтте дә тынып калды. Өлкән агаемның колаклары тырпаеп китте:

— Ә яучыларга нәрсә дигән ул кыз? — дип сорарга ашыкты.— Ризалык биргәнме?

Әтием юри генә тукталган икән. Шунда ук сүзен ялгап китте:

— Яучылар кайтып менә шундый хәбәр салганнар: «Кыз ниндидер килделе-киттеле булып чыкты. Сөйләгән сүзе, кылган кылыгы лөгатькә сыймый. Ыру-заты да шик-шөбһәлегә охшый. Без ниятебезне ниятләми кайтып килдек»,— дигәннәр. Шулай да әлеге карт иң өлкән яучыга ишеткән-күргәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирергә кушкан. «Без барып кергәндә, өйдә кыз ялгызы гына иде...» — дип алып киткән өлкән яучы.

— Әтиең кайда? — дип сорауга кыз: «Дустан дошман ясарга китте»,— дигән җавапны кайтарды.

— Әниең кайда? — дигәч: «Бер кешене ике итәргә китте»,— диде.

Әрле-бирле итүгә, чумарлы шулпа сосып, зур табак белән безнең алга утыртты.

Ашап-эчеп утыра торгач, өй бүрәнәләренә күзебез төште. Яман эре бүрәнәдән салынган икән өйләре.

— Бу тикле юан бүрәнәләрне урманнан ташуы кыен булгандыр инде,— диештек без.— Берьюлы ничәшәрне төйи идегез? «Атлар арык, хәлсез чакта өчәрне, хәтта дүртәрне сала идек, симерә биргәч, икешәрне генә сала башладык, тәмам симереп алгач, берәүсен дә ярты юлда төшереп калдыра торган булдылар»,— дип аңлатты аңгыра кыз. Менә шундый ни акыллы, ни тиле җаваплар алып кайттык,— дигән өлкән яучы,— калганына үзең хөкем чыгар.

— Их сез, пешмәгән башкодалар! — дигән моңа карт, баягы «әйткәч тә, белә» торган егетнең атасы.— Сүзнең сөяге була, сөяк эчендә җилеге була. Сез шуның сөяген генә ялап кайткансыз лабаса. Болай булгач, фәһемне биргән сезгә кыз!.. Атасы аның дусты

алып торган бурычны сорарга, әнкәсе туып килгән бәбине кабул итәргә киткән. Бүрәнә дигәне дә бөтенләй бүрәнә түгел, сез ашаган чумар ул. Ачрак чакта сез, тамакайланып, кашыкларыгызга, мөгаен, берьюлы өчәрдүртәр чумар соскансыздыр. Туя килгән саен, кимрәк эләктерә баргансыздыр. Азакка табан берне дә төшереп калдыргансыздыр. Шулай булдымы?

— Шулай булды,— диешкәннәр дә яучылар өйләренә кайтып киткәннәр.

Икенче көнне кыз өенә карт үзе барып, бөтенесен дә җайлап, вәгъдәләшеп кайткан. Менә Мортазага да шундыйрак кәләш кирәк иде. Ул да бит әйткәч тә, белә... Сәлихы да агасыннан калышмый, кушкач та, эшли...

Әтием әңгәмәсен шулай дип очлап куйды.

Агаемнар тын да алмый тыңлады бу хикәятне. Алар гына түгел, әтиемнең кинаясен мин дә аңладым. Безнең башка да чүбек тутырмаганнар...

...Кәҗә тиресен кем илтергә тиеш булып чыга? Олы инәем белән без икәү, әлбәттә.

Бәләкәч кенә буйлы, төптән юан Йомры Талип Ябалак урамында тора. Үзе ифрат җитез ул. Ел әйләнәсенә ул елтырап торган кара тышлы мескен бүрек киеп йөри. Көзен шул бүрегенә чүпрәктән колакчыннар тегеп куя, язын аларны сүтеп ташлый. Талипның кәпәч салганын күргән кеше юк. Хәтта мунча кергәндә дә кәпәч киеп керә, имеш, дип сөйлиләр. Нәрсә бар икән шул кәпәч астында? Хатынын ул кайдадыр байда торган җиреннән чуваш авылыннан алып кайткан. Имеш, кәләше: «Нигә син, Талипка, кәпәчеңне бер дә салмыйсың?» — дип сорагач: «Бездә, типтәрдә, йола шундый»,— дип җаваплаган икән, ди, бу. Шулай да кешеләрнең сиземләвенә караганда, Йомры Талип я мөгезле, я таз булырга тиеш.

Мин белә-белгәннән бирле ул, өйдән өйгә йөреп, вак-төяк мал, ыбыр-чыбыр җәнлек, эт-песи тиресе җыя. Ат-сыер, аю-бүре, болан-поши тиресе аңа тәтеми.

Алары туп-туры кәпирәтифкә китә. Малайлар белән язын йомран, әрлән, су комагы тотсак яки кышын капкынга ләтчә, ас эләктерсәк, тиресен сыдырабыз да Талипка йөгерәбез. Берничә бакыр, ара-тирә хәтта берәр көмеш тә эләктереп кайтабыз. Аның аты да, сыеры да, бүтән мал-туары да юк. Өй тулы бала-чагасы да шушы кәсебе генә бар.

Олы инәем ике кәҗә тиресен төреп култык астына кыстырды да, Йомры Талипларга киттек. Кече инәем белән икәү берәр җиргә бара башласак, барып җитә алмый иза чигәбез. Юлда очраган туган-тумача, кода-кодача белән сөйләшеп, аның сүзе бетми. Ә Олы инәем: «Исән генәме, карендәш? Һәйбәт кенәме, кодагый?» — ди дә, тукталып та тормый, атлый бирә. Хикмәт инде, аның белән барганда, авылның хәтта иң мыжык, иң бәйләнчек этләре дә өреп чыкмый.

Йомры Талип балчык алачык алдында, тезенә бәйләп, чабата кайтарып утыра иде. Безне күргәч тә ул үрә башлаган чабатасын чишеп ыргытты да сикереп торды:

— Һи-и-и, җиңги, әйдә, рәхим ит! — диде ул.— Өйгә уз дияр идем, өй тулы бала-чага, утырыр-басар урын юк. Шунда гына утырып дога кылыйк.— Алачык алдындагы түмәр өстенә, каяндыр китереп, иске палас кисәге җәйде. Утырышып дога кылдылар.

— Я, Талип, йорт-җир аманмы, күңел-хәтер иминме?

— Мал-туар юк — тыныч, бала-чага исән — шөкер. Күңел дигәнең инде, җиңги, төрлечә була. Сабый бала йокысындагы кебегрәк яшим бит мин: бер сәбәпсез көлеп алам, көтмәгәндә елап җибәрәм.

— Бәндә күңеле түгел, әнә тәңре күңеле күк тә гел үзгәреп тора,— диде дә Олы инәем ияген күккә чөеп куйды.

Талип, урыныннан торып, янә ары-бире сугылды. Үзе бертуктаусыз сөйләнә:

— Әле менә шуны уйлап утырдым, җиңги, атсыз кешенең ярты мөлкәте чабатага китә. Күпме чабата туз-

дыра җәяүле бахыр. Атлы кеше арбасына бер менеп утырдымы, бара бирә. Үтәр юлы үтелә, чабатасы бөп-бөтен. Әгәр мин җәяү йөргән араларны бергә кушсаң, биш тапкыр Мәккәгә барып кайткан булыр идем.

— Мәккәсенә дә барырсың әле, насыйп булса...

— Һи-и-и, җиңги, анда бит олы гөнаһ кылган кешеләр генә йөри. Мәккәгә үк барып, ярлыкаулар ялварырлык ни языкларым бар минем? Төптәнрәк уйлап карасаң, җиңги, мин оҗмахка туп-туры барып керер кешемен. Ни өчен дисәң, шуның өчен: мин бер кафирәне — үземнең бичәмне әйтәм — ислам диненә күндердем, өстәвенә, ул итәк тулы мөселман балалары тапты.

Олы инәем сәер генә елмаеп куйды.

— Аны мөслимә итүең дөрес, Талип,— диде ул.— Әмма син ул җан иясен үз иманыннан, үз алласыннан аергансың, монысы өчен языкк булмасмы? Һәр бәндә бары үз тәңренә генә табынырга тиеш...

— Бу кадәресенә үк минем баш җитми, җиңги,— диде Йомры Талип. Дөресен әйтә ул. Минем дә баш җитми моңа.

— Шушы тиреләрне алып калсаңчы, Талип,— дип Олы инәем йомышын йомышларга ашыкты.

— Минем кәсебемне санга санап, олы башыңны кече итеп йөрүеңә рәхмәт инде, җиңги, мәгәр бит әле сезгә элек түләп бетермәгән бурычым да бар иде,— язын алган теге өч пот тарыны әйтәм. Болары өчен дә чыгарып кына бирер капитал юк. Ни кылыйм соң: акча да юк, намус та бар...— дип көрсенде хуҗа.

— Булыр әле. Синдәге — илдәге, качмас, исән булсак, бәхилләшербез,— дип урыныннан кузгала башлады Олы инәем.

— Кара әле, җиңги, минем бик шәп самокат тәгәрмәче бар, мал-туарлы йортта, бәлки, берәр гамәлгә ярап куяр,— дип ул алачыктан сыңар самокат тәгәрмәче алып чыкты.— Менә тимерләре ничегрәк ялтырап тора. Кала юлыннан табып кайткан идем.

Олы инәем Талипның аркасыннан какты:

— Хафаланма, туганкаем, бурычлы булып калмассың, синең курага да бирәр заман кот керер әле.

— Һи-и, җиңги, мин череп байыйачакмын, тик көне бүген түгел! Шулай да, җиңги, хәзергесе авыр менә. Оныта язганмын ла: минем тагы бер затлы нәрсәм бар. Хәзрәтләр генә тәһарәт ала торган җиз комган ул. Безнең ишеләргә төс түгел андый зиннәтле әйбер, ал шуны.— Ул янә алачыкка омтылды. Олы инәем кул ишарәсе белән аны туктатты.

Ә самокат тәгәрмәче хәйран шәп иде. Мин аңа карадым да каттым. Аны урамның югары очыннан тәгәрәтеп җибәрсәң, Тәмәнәйгә кадәр туктамас иде, мөгаен. Тәмәнәй урамының малайлары шаккатыр иде. Тик резинкасы гына юк, күрәсең, кемдер куптарып алгандыр. Олы инәем, сыный биреп, миңа карап куйды.

— Синеңчә булсын, Талип, тәгәрмәчкә хуҗа чыкты. Тире өчен бәхилләштек дип исәплә,— ул тылсымлы тәгәрмәчне Талиптан алып миңа тоттырды.— Мә, аягың талу белмәсен.

Көтмәгәндә менә нинди хәзинә килеп эләкте минем кулга. Тире хакы гына торамыни ул? Талип бурычтан җиңел котылмады.

Олы инәем кайтырга дип урыныннан торды. Талип аның тирәсендә янә бөтерелә башлады.

— Көзге байлык булса да, чәй-шикәргә өзегрәк вакыт иде, җиңги, нәрсә кылыйм? Сый күрсәтми җибәреп, оятка калам инде. Хәерчелектән дә хурлыграк нәрсә юк!

— Куйчы, Талип, өзгәләнмә, эчмәгән чәй түгел лә,— дип юатты аны Олы инәем.— Булыр әле, чәе дә булыр, башкасы да булыр.

— Тукта әле, җиңги, болай коры гына җибәрмим әле. Такмак әйтеп үзеңә бер биеп бирим. Сыем шул булыр.

Кунак килгән курага,
Хуҗа нигә урала?
Такмак әйтеп бер биесә,
Бүтән сыйлар сорама.
Аты тартмый үренә,
Кунак узмый түренә.
Авызын ачса, хуҗасының
Үпкәләре күренә...

Боргаланып, юргалап ул үтә ихлас биеде. Бер-ике тапкыр чүгәли биреп тә куйды.

— Менә афарин! Сый-хөрмәтеңә рәхмәт,— диде Олы инәем, теге биеп туктагач.

Ләкин Йомры Талипның юмартлыгы, кунакчыллыгы моның белән генә бетмәде. Ул тагы да сый китереп чыгарды.

— Булгач булсын инде, җиңги, бер җырлап та хөрмәт итим. Менә тыңла:

Гүәрдиннәр сафка баскан,
Кылычлары ялтырый,
Гүәрдиннәр килеп чыкса,
Немец мәлгунь калтырый.

Бу — безнең җыр, гүәрдиннәр җыры. Мин бит патша гаскәрендә гүәрдиндә хезмәт иттем, үзем шулай гына булсам да. Калганнары бөтенесе дә өрлексыман егетләр иде. Бер мин — киле биеклеге. Кызык булды ул гүәрдингә эләгүем дә, һи-и! Зур бер яланга меңәрләгән гаскәрне китереп тезделәр дә, бер янарал гүәрдин сайларга керешге. Унбиш-егерме адым артка чигенә дә баягы янарал, йөгереп килеп, ис итмәгәндә солдатның тез астына китереп тибә. Әзмәвердәй ирләр бөгелә дә төшә. Йөздән берәү чыдыйдыр, чыдаса... Чыдаганнарын алга чыгарып бастыра. Бөтенесе дә гыйфрит кебекләр. Берчак минем тез астына китереп типте бу. Мин ыһ та итмәдем. Янаралның күзе шар булды.

Бер алдыма, бер артыма чыгып, мине күзе белән баштанаяк капшап карады. Шуннан соң, тагы да ераграк читенеп, миңа икенче тапкыр китереп типте. Мин кымшанмадым да. «Маладис, солдат! — диде янарал.— Сафның иң артында йөри торган минем иң ышанычлы, иң беренче гүәрдинем булырсың. Син артта чакта, берәү дә безнең тез астына суга алмас». Шулай дигән булды, бахырың. Күп тә үтмәде, үзенең тез астына китереп типтек. Тәүдә чүгәләп төште теге, соңыннан тәгәрәп үк китте. Патшаны бәреп төшереп, аның бөтен оясын туздырганда булды бу мажара.

Сөйләп беткәч, Талип, күзләрен мөлдерәтеп, Олы инәемә карады:

— Артыгын сөйләп, артыгын кыланган булсам, бигайбә инде, җиңги...

— Дөресен сөйлим дисәң, азрак арттырмый да булмыйдыр шул.

— Булмый шул, җиңги, булмый,— дип баш какты «гүәрдин».

Йомры Талип безне капка төбенә кадәр озата килде. Минем аякларым — җирдә, түбәм — күктә! Эшкә ашмаган ялбыр ике кәҗә тиресе өчен ничаклы байлык, хәзинә алып киттек: ике такмак, бер бию, бер җыр, янә менә дигән самокат тәгәрмәче. Тәгәрмәчнең тешләре кояшта нур чәчеп җемелдәп тора. Шундый матур-матур җыр-такмаклар әйткән Талипның ап-ак тешләре җем-җем итеп күз алдымда җемелдәп китә. Менә кем хәйләсез ул, ичмасам!

Мин артыма әйләнеп карадым. Сирәк кенә җирән сакаллы, неп-нечкә мыеклы, мескен бүреген батырып кигән Йомры Талип һаман капка төбендә тора. Байтак көннәр үткәч, бураннар бурап, урамнарны көрт баскач, шул мескен бүрек астында нинди баш йөргәнен бөтен авыл күрәчәк...

Ите сиңа, сөяге миңа

Ап-ак кырау төшкән иртәдә Олы инәем мине мәктәпкә алып китте. Мин аның катарыннан атламыйм, үлән өстенә сибелгән бәсне ярып, үземә юл салып барам.

«Балага укырга төшәргә вакыт, көтү кергәндә тугызы тула,— диде ул кичә Кече инәемә.— Укытучысына әллә үзең илтеп тапшырасыңмы? — Кече инәем минем күзләремә озак карап торды да: «Үзең генә илт инде, көндәшем, син сөйләшә дә беләсең...» — диде.

Мәктәп чокырның аргы ягында — Мәчет урамының түбән очында. Мин аны читтән генә күргәнем бар. Эченә кергәнем юк әле. Керергә, атлыгып та тормыйм. Ни калган миңа ул мәктәптә? «Укыган берәү мулла булмас, чукыган берәү карга булмас»,— диде беркөн Вәлетдин, малайлар сабак уку турында әңгәмә кузгаткач. Дөресен әйтә ул. Бөтен укыган адәм мулла булып бетсә, атка печән кем салыр соң? Анысы тагы бер хәл, печәне булса, салучысы табылыр. Иң яманы шул: мулладан бөтен адәм курка. Шулай, кеше өркетеп, яшә, имеш, албасты шикелле...

— Минем мулла буласым килми дә әле,— дидем мин үзем дә сизмәстән.

— Нигә алай дисең, сиңнай?

— Укый-укый мулла булып китәрмен дә аннан үкенермен...

— Язган булса, мулла итмәм мин сине. Мөгаллим булырсың, я землемер. Бер дә юк икән, иншалла, өй тулы дөм-сукыр арасында күзле бер кеше булырсың.— Олы инәем шунда ук төшендереп бирә.— Надан кеше бу заманда сукыр белән бәрабәр. Без бөтенебез дә наданнарбыз, улым. Шуңа күрә безне, кара халыкны, кара сарык дип йөртәләр.

— Әйдә бүген бармыйк ул мәктәпкә, иртәгә ба-

рыйк! — дидем мин, кинәт тукталып. Шул чак мәктәп тулы эреле-ваклы кара сарык килеп басты минем күз алдыма. Алар бер-берсен этәрәләр, кычкырышалар.

— Бүген күренеп, язылып кына кайтабыз. Сабакка бер атнадан төшәсез,— диде Олы инәем, үзе һаман юлында булды.

Олы инәем әйткәненнән кайтмый, юлыннан кире борылмый ул. Бездән алда гына мәктәпкә колга төсле нәзек озын улы Гыйльметдинне ияртеп тимерче Әгъләм кереп китте. Мин ул Гыйльметдинне беләм. Әллә үтә юаш, әллә акылга бер чамарак инде бичара: бәләкәч кенә малайлардан да курка.

Олы инәемне укытучы Мәхмүт аягүрә басып каршы алды:

— Әйдә, рәхим ит, әби! Менә монда утырып тор чак кына... Әгъләм агайның улын теркәп кенә куям да...

— Ярый, ярый, без ашыкмыйбыз,— диде Олы инәем.— Улың буйчан икән, Әгъләм, игелеген күрергә язсын.

Әгъләм аның белән кул биреп күреште дә Гыйльметдинне җитәкләп укытучы алдына китереп бастырды. Малайның чокыр җилкәле неп-нечкә муены менә-менә өзелеп китәр дә аның такыр как башы идәнгә тәгәрәп төшәр төсле. Шулай да ни могҗиза белән эленеп тора икән ул баш?

— Менә, Мәхмүт,— диде тимерче карлыккан тавыш белән,— өлкән улымны китердем; ите-мае сиңа, сөягетиресе миңа. Әрәм итмә, адәм ит.

Мин башта нинди «ит», нинди «май» икәнен аңламый тордым. Аңлагач, тәүдә чыдый алмый эч тырнап көләсем килде, азактан котым очты. Болай да күлмәк астында сөякләре шылтырап торган Гыйльметдинне әнә нинди җәфалар көтә икән. Әгәр Мәхмүт минем дә итем белән маемны суырып алып, тирем белән сөягемне генә калдырса?.. Минем хәзер үк торып качасым килде.

— Ярый, кулдан, акылдан килгәнчә, тырыштырырбыз, агай,— дип ышандырды укытучы.

Тегеләр чыгып китте. Укытучы үзенең калын кенәгәсенә мине дә язып куйды.

— Менә, мөгаллим, улымны синең карамакка ышанып тапшырам. Үзсүзле, кылтым холыклы, хөр табигатьле, әмма нечкә күңелле эчкерсез бала. Синең кул астында башыннан бер төк чәче төшсә дә, риза түгелмен, бәхиллегем юк. Гафу итмәм. Монысын алдан кисәтеп куям,— диде Олы инәем. Аның тавышы тыныч, ләкин җитди иде.

— Бу җәһәттән тыныч бул, әбкәй, вәгъдә — иман,— дип Мәхмүт янә урыныннан торды.— Синең кебек хөрмәтле әбинең улына тырнак та тимәс. Хафаланма, зинһар.

— Әйткәнне кабул итүеңә рәхмәт, мөгаллим! — диде Олы инәем.— Шулай башта ук аңлашып эш итү яхшы. Хуш булып тор.

Мәктәп мине артык хәйран калдырмады. Бүрәнәгә ябыштырылган төрле-төрле кәгазьләргә дә, кара тактага да, кара парталарга да исем китмәде. Укытучының да яшелле-зәңгәрле күзләре ошамады миңа. Аның «вәгъдә — иман» дигәне дә, нишләптер, күңелгә ятмады. Ярый әле кайтып киттек.

Укытучы барыбер сүзендә тормады. Дөрес, тырнак тидермәде тидерүен, бүтәнчәрәк эләктерде ул миңа. Укулар башланып, өч-дүрт көн үткәч тә, тәнәфес вакытында качыш-качыш уйнаганда мичкә кереп яшеренгәнем өчен ул минем колакны чак кына өзеп алмады. Аннан соң, пәке очы белән чокып, партага «Қ» хәрефен язганым өчен озын агач линейка кыры белән кул сыртыма сукты. Өченче тапкыр миңа кеше өлеше эләкте. Миннән арттагы рәттә әллә Хәмитҗан, әллә теге Гыйльметдин шаярып утырган. Қара тактага акбур белән язып торган укытучы, моны күреп, йодрык кадәр акбурны теге шаянга тондырмакчы иткән. Акбур чәп итеп минем

маңгайга килеп тиде. Хәтта күздән әллә нинди җемелдек дүңгәләкләр сибелеп китте. Укытучы үзе дә шөрләде: мине көйләргә, юатырга тотынды. Ә мин юри еламадым, тегеңә үч итеп.

Үземчә күптән ниятләп йөргән ниятемә ирешергә — мәктәпкә башкача килмәскә булдым мин шул көнне. Бу хәл, кар ятып, тауда выжлап чана шуар, Шәйхаттарның тимераягын бер тиенгә яллап, Ак Йомагыл тыкрыгыннан коштай очып төшәр чакка туры килде. Һичкемгә һичнәрсә әләкләп тормыйча, мин гыйлем алудан тынып торырга булдым. Ул тыну нәкъ ике ел дәвам итте.

Ике елдан соң сеңелем Сәлисә белән бергә мин янә беренче сыйныфка килдем. Мине иң артка, сеңелемне иң алга утырттылар. Безне яшь кенә укытучы апа укыта. Тәүге көннәрдә таяк сызарга өйрәтте ул. Минем сеңелем бер таякны сыза да, укытучыга әйләнеп тә карамый, миңа йөгереп килә. «Абыем, дөресме?» — дип сорый. Укытучы күрмәмешкә салыша, мин уңайсызланган булам.

Ике ел буш йөрүнең хакын бер кышта чыгардым мин. Язга табан мине теге ел сабакка бергә төшкән иптәшләремә китереп куштылар. Бөтенесе дә таныш, тик укытучы гына бүтән иде.

Ә теге кышның, мин иреккә чыккан беренче кышның, ап-ак кары өстенә күп тә үтми кып-кызыл кан тамды. Башта тамды, аннан акты...

Ике хөкем

Авылда үлем-җитем булса, сыбайлы ике малай урамның ике ягыннан, һәр өй турында туктала биреп, кычкырып уза: «Җеназага барыгыз! Җеназага барыгыз! Җеназага барыгыз!» Минем өчен иң куркыныч оран — шушы. Әйтерсең, ул малайлар тере кеше-

ләрне мәет озатырга түгел, кабергә чакыралар. Чынлабрак уйлап карасаң, шулай килеп чыга да. Вакыты житкәч, һәркемне шунда чакыралар, шунда озаталар.

Иртәнге эңгер таралып та бетмәс борын, урам буйлап оран салып, аллы-артлы ике малай сыбай чабып узды.

— Хөкемгә барыгыз! Хөкемгә барыгыз! Хөкемгә барыгыз!

— Әллә тагы үлем-җитем бар инде, ходаем? — дип борчылды чәй урыны җыештырып йөргән Кече инәем.

— Хөкемгә чакыралар, Кече инәй, кооператив башлыгы Сәмигулланы хөкем итәләр, мир акчасын ашаган, ди, бик күп. Җәмәгать суды була, ди. Кичә сельсовет Ташбулат яман ачулы иде,— дип этенә-төртенә хәбәр салды кече агаем Сәлих. Сүз сөйли башласа, ул әллә ничек каушап төшә.

— Каян килгән ул мирга шулкадәр акча? — диде Олы инәем.

Минем Мортаза агаем бөтенесен дә белә. Ул шунда ук төшендереп бирә:

— Бөтен җәмәгатькә ургычлар, суккычлар алырга дип көз көне капка башыннан акча җыйган иделәр бит. Бездән дә алдылар. Әнә шул акча инде.

— Һи, бахыр! Нәфсе аркасында нинди генә гөнаһларга төшми бәндә! — дип пошынды Олы инәем. Әтием нигәдер эндәшми әле. Уйлана ул. Йорт эчен шом басты. Баягы: «Хөкемгә барыгыз!» — дигән тавыш тәрәзәдән бәреп керде дә кире чыкмады, өйдә бүленеп калды, менә хәзер килеп-килеп һәркемнең колагына бәрелә.

— Сәмигулланың да акчага күзе кызгач инде, коммунистмын дип йөрүе корысын. Берәүгә дә ышаныч юк болай булгач! — дип үртәнде Мортаза агаем.— Һәркемнең бармагы үзенә табан кәкре...

— Пожар мәйданына икегезнең берегез аяк басасы булмагыз, ишетсен колагыгыз! Сезгә әле кеше хөкем итәргә иртәрәк,— диде әтием. Хәтта бармак янап куй-

ды. Аның абыемнарга болай каты эндәшкәне юк иде. Ул шунда ук йомшара төште.— Миңа күк алашаны җигеп куегыз, Тимофейларга барып кайтам. Сез, бер дә булмаса, куянга чыгып керегез, әнә кырпак кына кар да явып киткән.

Әтиемнең бармак янап сөйләшүенә абыемнар, берберсенә карашып, аптырап калдылар.

— Ярый, эти, куянга чыгарбыз,— диде Мортаза абыем, турсая биреп.

Олы ирләр һәрберсе үз юлына китте. Бераздан баягы малайлар янә сөрәнләп узды:

— Хөкемгә барыгыз — пожар мәйданына! Хөкемгә барыгыз — пожар мәйданына!

Күп тамаша күргәнем бар минем: ул томанный картинкә [1] дисеңме, ул кәмит дисеңме, ул бәйге дисеңме — күрмәгән нәрсәм юк. Ә менә «хөкем» дигәнен күргәнем юк. Карарга кирәк моны.

Пожар мәйданы Мәчет урамының иң калку җирендә. Мәйданга исәпсез-хисапсыз халык җыелган, күбесе сакаллы-мыеклы агайлар, бабайлар. Без, вак малайлар, урамның аргы ягындагы биек көрт башына менеп бастык. Безнең кебекләрне мәйданга кертмиләр, куып җибәреп торалар.

— Бала-чаганы ары куыгыз, эзләре булмасын! — дип чәрелдәде бер бабай.

— Карасыннар, күрсеннәр, фәһем булыр! — диде бүртенгән битле юан адәм.

— Гыйбрәт алсыннар! — дип өстәде икенчесе.

— Сабыйларны кайтарып җибәрегез, кәмит куймыйлар ла монда!

— Ниндирәк кәмит булыр да әле. Күр дә тор менә!

Торган саен халык ныграк кайнаша, мәйдан ныграк гөжли.

Шыгыр-шыгыр басып, Түбән очтан сельсовет Таш-

[1] Кино.

булат белән янә ике ят кеше килде. Ташбулат ул бәләкәч кенә буйлы. Озын кара тунының чабулары җиргә тиеп-тиеп кала. Агасыннан-фәләннән калган тундыр, күрәсең. Ул килеп җиткәч, халык тынып калды.

— Я, ни кылабыз, җәмәгать? — диде Ташбулат, беркемгә дә карамый, калкына биреп.— Қарак сезнең алда, хөкем сезнең кулда, ил агалары.

Халык алай-болай иткәләгәнче, сельсовет Ташбулат каршысына имәндәй таза Чибәр Мәрһим килеп басты. Бу кеше безнең урамда, Түбән очта тора. Атасы аны япь-яшь кенә көе Ильяс мәзиннең тол бичәсенә көчләп өйләндергән, дөресрәге, йортка керткән. Кичләрен өй алдына чыгып, Мәрһим гармунын тартып җибәрсә, бөтен авыл хәйран калып тыңлый. «Моңая, бичаракаең,— диде берчак Олы инәем,— ничәмә ел инде, ә күңеле һаман урынына утыра алмый, кемнедер эзләп адашып йөри. Заяга үтә җиләк кебек чаклары...»

«Чибәр кеше, моңлы кеше бәхетсез була» дигәннәре хактыр, ахрысы. Аның керфекләре шундый озын. Озын керфекле кеше, җитмәсә, кыска гомерле була, имеш. Шуңадыр инде, күрәсең, Чибәр Мәрһимне бөтен адәм кызгана, якын күрә. Менә әле дә ул уклау озынлыгы гына Ташбулат алдына килеп басты.

— Қордаш,— диде ул тыныч кына,— Сәмигулланың гаебе зур. Кая китсә дә ил мөлкәте аның кулыннан киткән. Тияр җәзасын алырга тиеш. Мәгәр аны гадел хөкем кулына, дәүләт кулына тапшырырга кирәк.

Ташбулат кинәт шашып китте, аның түп-түгәрәк күзләре халыкка төбәлде:

— Дәүләткә бирергә дәүләт малын урламаган ла ул! Сезнекен, җәмәгатьнекен урлаган. Сезнең хәләл малны ашаган! Җаны да, тәне дә аның сезнең кулда, җәмәгать! Дөрес әйтәмме?!

— Дөрес! Дөрес! — дип кабатлады ялпы [1].

[1] Ялпы — халык төркеме.

— Ашаганын костырырга кирәк убырның! — дип акырды баягы бүртенгән битле юан адәм.

— Җитмәсә, коммун булып, адәм котыртып йөрде, иблис! Тәмуг кисәве! Кая ул? Нәрсә көтәбез? — дип шашынды кемдер.

— Халык алдына чыгарыгыз! Җавап бирсен! — диде икенчесе.

Халык төркеме инде ярсуның чигеннән ашты. Шул чак Ташбулат әмер бирде:

— Әй, пүнәтәйләр, монда китерегез каракны!

Матур башын түбән иеп, Мәрәһим кайтып китте. Бераз баргач, ул әйләнеп карады, ләкин тукталмады.

Сәмигулланы каравыл өеннән алып чыктылар. Аның өстендә кыска кыптыр тун, аягында ап-ак тула оек белән ап-ак чабата. Нишләптер башында бүрке юк. Кара бөдрә чәче ялтылаш маңгаена төшеп тора. Йөзе көл кебек. Ике кулын артка тартып бәйләгәннәр, артып калган аркан очын бер кеше тотып алган. Ул карак белән янәшә атлый. Базарга сатарга илткән сыер малын нәкъ әнә шулай җитәкләп алалар.

— Менә монда биек урынга бастырыгыз, бөтен галәм күреп торсын! — дип боерды Ташбулат. Ул яртылаш кар астында калган арба күрсәтте. Сәмигулланы шунда мендерделәр. Мәйдан тып-тын булып калды, хәтта аяк астындагы кар да шыгырдаудан туктады. Һавада сирәк кенә җилбәзәк кар бөртекләре тирбәлә. Алар бүтән җиргә төшми дә кебек, бары тоткынның кара чәченә генә куна. Әгәр озак кына шулай торса, аның иелгән башы чалга әйләнәчәк. Сәмигулланың сул ягында, еракта, сельсовет кыегында җилфердәгән кызыл флаг күренә. Бер караганда, алар икесе янәшә торасыман. Кеше кымшанмый, флаг талпына, кайдадыр ашкына. Икесенең дә артында күгелҗем күк чите.

— Күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәл бу, җәмәгать! — дип чыелдады кинәт баягы чәрелдек тавышлы карт.— Илгә оят, җиргә оят, дингә оят — һәммәбезгә

оят китерде бу кара йөрәк! — Ул кулларын чәбәләндереп Сәмигулла ягына селтәде.

Аңа башка тавышлар кушылды:

— Сабыйларыбыз авызыннан ризык өзеп җыйган тиеннәребезне кайда типтереп, кайда исраф иттең, бәдбәхет! Җавап бир!

— Хәләл көчебезне сарыф итеп тапканнарыбыз бугазыңа тыгылсын, мәлгунь!

— Түләсен! Мирныкын мирга түләсен!

— Безнең тир хакын каны белән түләсен! Каны белән! — дип ярсыды берәү.

Карак акрын гына башын күтәрде. Мәйдан өстенә күз йөртеп чыкты. Тавышлар азлап кими, тына барды. Сәмигулла, башын югарыга чөеп, ике тапкыр йөткереп алды.

— Авылдашлар,— диде ул калтыраган тонык тавыш белән.— Сезнең алда гаебем зур. Җәмәгать мөлкәте минем кулда иде, минем кулдан юк булды, әмма мин сукыр бер тиененә дә тимәдем.

— Ничек инде тимәдең? Аякландымы икәнни ул акча?

— Урлаганнар. Кәнсәдәге тимер сандыкка ачкыч ятатып урлаганнар.

— Кайчан алганнар?

— Ачык кына белмим.

— Ялган! Алдаша!

— Теге дөньяда акланырсың!

— Каравылчы кая булган?

— Мин урлашмадым, агай-эне. Шулай да гаеп миндә. Гомер буе эшләп түләрмен.

— Бетең беләнме, зимагур?

— Моңа кадәр дөнья көтеп, бер корчаңгы таең дә булмаганны!..

— Каны белән түләсен! — дип кабатлады бая ук кансыраган тавыш.

Халык янә шашып китте:

— Самосуд ясарга кирәк! Самосуд! Бүтәннәргә сабак булсын!

— Аяк-кулын сугып сындырырга кирәк.

— Самосуд! Самосуд!

Инде акны-караны күрмәс чиккә җиткән кешеләр, кайсы йодрык йомарлап, кайсы таяк селтәп, кайсы күсәк күтәреп, арбага табан ябырылды. Шул чак Йомры Талип әллә кайдан килеп чыкты да, үтә җитез сикереп, арбага менеп басты.

— Җәмәгать! — дип кычкырды ул, бөтен мәйданны яңгыратып.— Мин бу кешене тумышыннан беләм. Ата-анасын, нәсел-ыруын беләм. Хәрамләшә торган заттан түгел ул. Күрә торып, кеше хакына кермәс. Хилаф эш эшлисез, аксакаллар, дуамал кылык кыласыз, яшь җилкенчәк! Әгәр сез йөз кеше бер булып шушы гаепсез, бер таянычсыз җан иясен һәлак итсәгез, һәркайсыгыз йөзәр кеше үтергән булып чыгачак, һәркайсыгызның өстенә йөзәр язык төшәчәк. Иман хакында уйлагыз, җәмәгать! Мин аны менә мондый чагыннан беләм. Күңелем сизә — гаепсез ул! Акылыгызны җуймагыз, җәмәгать! Ташбулат! Син ил башы кеше. Тый халыкны. Әйт халыкка. Тимәсеннәр Сәмигуллага. Аның алма кебек ике баласы бар, йөгереп кенә йөриләр. Ятим иттермә шул балаларны. Әйт, Ташбулат! Әйт ил агаларына!..

— Урлаганда миннән сорамаган. Үз җәзасын үзе күтәрсен! Җәмәгать, хөкем, әйткәнемчә, сезнең кулда...— диде дә Ташбулат, тун чабуына урала-урала, китеп барды.

«Җәмәгать» яман шаулашырга, кычкырышырга, гөжләргә тотынды. Талип янә нәрсәдер сөйләде бугай, аны бүтәнчә тыңламадылар, ләкин ул арбадан төшмәде, Сәмигуллага ныграк сыена бирде.

— Ялганчының гуаһы янында!

— Төш аннан, йолкыш!

— Урлаганны икәү бүлештегезмени?

— Сугым тирәсендә йөргән эт!

— Сиңа да тамдымыни?

Талип кинәт читкә тайчанды. Тузып беткән чикмәненең чабуларын әйләндереп, биленә кадәр күтәрде дә, ямау өстенә ямау салынган штанын күрсәтте.

— Менә тамды! Асыл заттан гына чуктай итеп киенеп алдым. Әнә аның аягында да өр-яңа чабата!

Талип чикмән чабуларын һаман төшерми. Сәмигулла бөтенләй битараф кыяфәттә баскан да каткан. Аның башын ап-ак чал каплаган; берәм-берәм генә төшкән кар бөртекләре ни арада аның кара бөдрәсен шулай сырып өлгерде икән?

Кинәт Талип, ике кулын алга сузып, яшь аралаш ялварырга тотынды.

— Адәмнән оялмасагыз, ходайдан куркыгыз, җәмәгать! Җәзаламагыз Сәмигулланы! Югыйсә бөтен авылыбызга каза килер. Алла сугар!

Кансызлыгы белән яманаты чыккан, котырган эт җыючы Ислай җенләнеп килде дә: «Алла менә шулай сугар!» — дип үкереп, юан гына имән казык белән Талипка кизәнеп сукты. Талип арбадан очып төште, аның чүпрәк колакчынлы мескен бүреге тәгәрәп китте. Күзгә кебек елтырап торган как баш килеп чыкты ул бүрек эченнән. Тазы да юк, мөгезе дә юк. Чәче генә коелган — нибары шул, Ислайның күсәге, ахры, аның чигәсенә туры килде. Сул яңагы буйлап кан агып төште дә кар өстенә тамды. Бер тамды, ике тамды, өч тамды... Талип башын күтәрде. Аннан акрын гына торып тезләнде. Адәм каны күргәч, Ислай отыры котырып китте. Ул, күсәген тагы да ныграк селтәп, Сәмигуллага ташланды. Шул вакыт бөтен «җәмәгать» арбаны сырып алды. Мин чытырдатып күзләремне йомдым. Тик колагым гына акылыннан шашкан «җәмәгать»нең үкерүен ишетә. Бераздан үкерү дә тынды...

Күзләремне ачтым. Арба буш иде. Аның турында еракта сельсовет түбәсендә байрак кына моңсу тирбәлә.

Кешеләр, мәйданнан чыгып, таралыша башлады. Арба янында Сәмигулланың бөкрәйгән гәүдәсе ята. Аның бөтен йөзен кан каплаган. Башы турында ак карны кызыл кан өнеп кергән. Сәмигулла янында кәпәчсез Талип тезләнеп утырган да аның кар сарган башын сыйпый. Ул сыйпый, ә кар төшми, аның саен чәчләренә ныграк ябыша бара. Нинди кар икән ул?

Мин гомеремдә беренче тапкыр ак кар өстендә кызыл кан — кеше каны күрдем. Башта тамды ул, аннан акты, акты да, карны көйдереп, җиргә үтте. Ул акрын гына туфракка сеңәчәк — мин монысын яхшы беләм. Олы инәем әйтә: «Төтен һавада эри, дым туфракка сеңә, җан күккә оча, тән гүргә керә»,— ди. Сәмигулланың да җаны бу сәгатьтә байтак юл алгандыр инде...

Әмма ул чакта мин чем-кара чәчнең күз ачып йомган арада чап-чалга әйләнүен белми идем әле.

— Тамаша бетте, бар, малай, өеңә кайт! — диде берәү. Мин башымны күтәрдем. Минем алда бер күзенә борчак хәтле ак төшкән, шөкәтсез, йонтач адәм басып тора иде. Аның кашлары да, танавы да, авызы да бер якка чалышайган. Аңа карагач, минем дә йөзем кыйшая башлагандай булды. Мин артка да әйләнеп карамый торып йөгердем. Төшеңә кермәсен бу нишана!

...Төшемә кермәде ул, мине кызганды, ләкин мин аны өнемдә тагы бер тапкыр күрдем. Күп учаклар янып сүнгәч, күп гомерләр күкрәп тынгач, очраштык без аның белән.

Авылга кайткан саен, мин тәүдә әтием белән Олы инәем каберен зыярат кылырга барам. Хәзер инде мин балалар атасы гына түгел, үзем карт әти кеше, әмма шунда килгәч, мин әҗәл турында да бөтенләй дип әйтерлек уйламыйм, чөнки ташларда исемнәре язылган кешеләр бу дөньядан китүләре белән түгел, шушы җиргә килүләре, җирдә яшәүләре, эшләгән эшләре, кылган кылыклары белән кызыклылар.

Кайбер кабер янында мин уйланып торам. Кайбер-

ләре янында ирексездән елмаеп куям, чөнки аларның хуҗалары җир өстендә шулкадәр күңелле, мәзәк, гыйбрәтле истәлекләр калдырып киткәннәр, шуларның хөр рух шаукымы, әйтерсең, каберләре өстендә әле булса балкып тора. Монда даһилар һәм диваналар, эше уңмаслар һәм хыялыйлар, ярсулар һәм сабырлар, батырлар һәм бичаралар җирләнгән. Монда явызлар да, куркаклар да, урта кул гына кешеләр дә юк. Булса да, мин аларны күрмим. Күзем шәйләсә, күңелем күрми, чөнки мин алардан калган дөньяда яшәмим. Әнә тегеләре калдырып киткән дөньяда дөнья көтәм мин. Мин тере булгач, димәк, алар да яши. Шуңа күрә дә һәр очрашкан саен: «Саумы, әтием!», «Саумы, Олы инәем!», «Саумы, Йомры Талип!» — дип эндәшәм. Дистәләгән кабер ташлары дәррәү дөбердәп миңа җавап кайтара: «Сау!..» Монда килеп шул дөреслекне аңладым: тере чакта бөтен кеше дә яши, дөнья куйгач, яхшылар гына исән кала.

Кара туфрак өстенә кызарып кына үләне шытып килгән кабергә карашым тукталды. Яңа баш төртеп чыккан очлы кыяклар минем фикеремне әллә кая еракка, мәңгелек төпкеленә алып китте. Кайчандыр кешеләр дә, ягъни аларның тәүге күзәнәкләре, менә шулай туфракны тишеп чыккандырсыман тоелды миңа. Бара-бара үләннән тере җан — кеше барлыкка килгән, ә хәзер кеше кабат үләнгә әйләнгән...

Кабернең баш очында бәләкәч генә бер хатын бөкрәеп утырган, үзе сулкылдап елый, аккан күз яшьләре, мөгаен, табанына барып чыгадыр. Буыла-буыла ул бер үк сүзләрне кабатлый:

— Түр гөлләрем сынды, бәйрәм шәмнәрем сүнде... Сынды түр гөлләрем, сүнде бәйрәм шәмнәрем...

Бу — сугышның тәүге елында ук хәбәрсез гаеп булган Корбангали хатыны Сабура иде. Әле теге вакытта ук, Сабура килен булып төшкәч тә, Әсгать аның хакында: «Сабура самовар биеклеге»,— дигән иде. Үзе

шундый гына булса да, кулында эш, теленд𝑒 ут уйнады, әмма алагаемга ләчтит сатып та йөрмәде ул.

Сугышның урталарында авылга зур гына бер төркем солдат килгән. Килгән дә, боерык булгач, кире киткән. Азмыдыр, күпмедер вакыт үткәч, үз вакыты җиткәч, Сабура кешелек дөньясына бер ир бала өстәгән. Күрше-күлән чыш-пыш иткән, туган-тумача кара орынган, бичә-чәчә сагыз урынына чәйнәгән аны. Сабура кылганны кылып та, аның көненә төшмәгән ахирәтләре дә моңа артын әйләнгән. Тик бер генә кеше, бичараның аркасыннан сөеп, болай дигән: «Көн биргәнгә җим бирер. Төкле аягы белән килсен бу дөньяга. Корбангалидән токымсыз калган идең. Бергәләп үстерербез әле». Шушы сүзләрне хәбәрсез югалган Корбангалинең әнкәсе, Сабураның каенанасы Гөлбәдәр, әйткән. Моңа кадәр каенана белән килен пычакка пычак ук килеп тормаса да, үтә тату да яшәмәгән. Еш кына каенана көрәк сораса, килен сәнәк тоттырган, килен кашык шылтыратса, каенана табак дөбердәткән.

Шушы Семен исемле малай (Сабура балага атасының исемен биргән, яраткандыр, күрәсең) тугач та, боларны, әйтерсең, ырымлаган да куйган. Гөлбәдәр белән Сабурага әйтеп аңлата алмаслык татулык, гомер буена җитәрлек дуслык килгән. Бала үскән саен килен каенанасына, каенанасы килененә гашыйк була барган. Гөлбәдәр, Семенны күтәреп, башта өй алдына чыккан, шуннан күршеләргә кергән, соңрак бөтен авылны бер итеп узган.

— Атасына нинди охшаган!..— дип мыскыл итәргә маташучыларны ул кырт кискән.

— Кемгә охшаса да адәм баласы. Явызлыктан тумаган, мәхәббәттән туган! Гөнаһсыз сабыйдан көлү — язык! — дигән ул.

Шушы Гөлбәдәрне каплаган кара туфрак өстендә хәзер сирәк кенә кызгылт үлән җилферди. Әллә җил

тирбәтә, әллә Сабураның күкрәгеннән бөркелеп чыккан хәсрәт сулышы тирбәтә аны.

Хатынның яралы күңеленә кагылмас өчен, мин, аңа күренми, чыгар якка киттем. Колагымда исә һаман аның зары яңгырый:

— Түр гөлләрем сынды, бәйрәм шәмнәрем сүнде...

Ничәнче кат инде таш зиратның тимер капкасы төбендә мин бер картны күрәм. Кеше килеп чыкса, ул башын читкә бора, күзләрен яшерә. Мин дә аның белән йөзгә-йөз очрашырга, туктап сүз кушарга, хәтта исәнләшергә дә базмыйм. Адәм күңеле — кара урман. Ни генә юк анда? Тик кара урманга сораусыз да кереп була, кеше күңеленә рөхсәтсез кагылу ярамый.

Бу юлы карт миннән тайчанмады. Сүнеп барган төссез күзләрен дә читкә алмады. Уң күзенә эре борчак зурлыгы ак салган. Анысында бөтенләй җан әсәре юк. Икенчесе миңа төбәлде. Нәрсә әйтергә тели ул күз? Юк, әйтми.

— Саумы, агай? Хәлләр имин генәме? — дигән булдым. Күңелемне кинәт шом басты.

— Мин сиңа агай түгел. Берәүгә дә агай да, ата да, бала да түгел мин. Мин үземә-үзем. Хәл сорашма миннән. Бөртөрле дә хәлем юк минем. Мин — албасты.

Мин китәргә кузгалдым. Ул лып итеп үлән өстенә утырды.

— Торып тор әле, сөйләшик! — диде карт.— Мин әллә кайчан инде шунда күченеп килергә тиеш идем.— Ул кулы белән зират эченә күрсәтте.

— Ә нигә күчмәдең соң?

— Сәмигулла кертми. «Кабереӊ якын булмасын!» — ди миңа, капкадан да җибәрми.

— Кайсы Сәмигулла?

— Әнә теге чакта мин үтергән Сәмигулла. Мин бит аны ике тапкыр үтердем: башта ил алдындагы намусын үтердем, соңыннан үзен...— Карт шундый тыныч, гамьсез әңгәмә кыла, гүя, ул миңа вак-төяк күргән-

белгәннәрен хәбәр итә. Котың очарлык! Аның тере күзендә зәгыйфь кенә бер очкын кабынгандай булды. Үзе чак кына калкынып та куйды.

— Мин — яманаты белән заманында тирә-якта дан тоткан карак — Ярулламын,— дип сөйләп китте ул шул ук зәгыйфь тавыш белән.— Мин рәнҗеткән адәм, мин түктергән күз яшьләре, минем өскә яуган каһәр бихисап. Усал гына түгел, хәйләкәр дә идем мин. Йөргән җиремдә итәк-чабуымны җыеп, эземне адаштырып йөрдем. Сәмигулла карамагындагы акчаны да, ишек каерып, сандык ватып алмадым, һәр йозакка ачкыч яраттым. Акчасын алгач, җиренә җиткереп, йозакларын кире бикләдем. Курку-өркүнең ни икәнен белми идем, бүре йөрәкле идем. Шулай да күңелемә беренче кат шик керде. Сәмигулла зирәк кеше иде, менә-менә сизенер, минем тамганы танырсыман тоелды, чөнки бу минем кулдан гына килерлек эш иде. Чыдамадым, Сәмигуллага самосуд башлангач, куеныма кистән тыгып, мәйданга килдем. Бүтәннәр таяк, чыбык, бау селтәп чәбәләнделәр, кистән белән башына бер генә суктым. Шунда ук, арбадан тәгәрәп, чалкан әйләнеп төште. Коралымны яшердем дә читкә чыктым. Мине исәпкә алучы да булмады. Тик барыбер тиз генә китә алмадым, халык таралганчы, мәет янында калдым. Мәетнең башы күземә ап-ак булып күренде. Бөтен тәнемне кинәт көзән җыерып алды, хәтта битләрем тартышты.

Мин инде зират капкасы төбендә түгел, әнә теге заманда пожар мәйданы янында көрт башында басып торам. Минем каршыма бер күзенә ак төшкән чалыш битле йонтач адәм килеп чыкты. Мин аннан тамчы да курыкмыйм. «Тамаша бетте, бар, юлыңда бул!» — дим мин аңа, ләкин тавышым чыкмый, тыным кысыла.

Акрын-акрын гына мин гомер юлының тагы бу очына, таш зират янына кайтам. Ярулла, арык тубыкларын чәнчеп, тын гына утыра. Башыма зиһен кергәч, мине күп тапкырлар борчыган нәрсә тагы исемә килеп төште.

Бу — сельсовет рәисе Ташбулатның шул көндәге кылыгы иде. Шул сорауны хәзер картның күзенә терәп бирдем:

— Ул акчаны сез Ташбулат белән бер булып урладыгызмыни?

— Юк. Ул белмәде дә. Акчаны кем урлавы, кая китүе аңа барыбер иде. Ташбулатның монда үз исәбе исәп иде — ничек кенә булса да Сәмигулладан котылу кирәк иде аңа. Шушы хәлләр килеп чыккач, теге кәрләнең бүресе улады. Самосудка бит ул халыкны өсләтте-өсләтте дә үзе шылды.

— Сәмигуллада аның ни үче бар иде соң?

— Ачык кына белмим. Гражданнар сугышы чорында Ташбулат урыс авыллары ягында ниндидер этлекме, явызлыкмы эшләгән, ахры. Сәмигуллага, күрәсең, шул мәгълүм булгандыр. Иллә-мәгәр Сәмигулланың күз карашыннан коелып төшә иде, ә мин курыкмый идем. Беркемнән дә курыкмый идем. Бары теге Сәмигулла гына күңелемә курку салып, тәвәккәллегемне алып китте. Мин куркакка әйләндем. Шул кичне үк кара айгырымны җиктем дә, өемне, хатынымны, балаларымны ташлап, билгесез якларга карап юл алдым. Кырык елдан соң туган төягемдә туфрак булырмын дип, өметләнеп кайттым. Өченче ел инде шунда йөрим. Сәмигулла якын да җибәрми. «Кылган җинаятьләрең өчен башта, хөкем үтеп, җәза кичер, шуннан кертермен»,— ди. Бик күп җинаятьләр кылдым, бихисап явызлыклар эшләдем, шуларның берсе өчен дә миңа үз вакытында кешеләр дә, тәңре дә җәза бирмәде. «Минем зур җинаятьләрем бар, шуларның һәрберсе өчен атап-атап җәза бирегез!» — дип хөкем ияләренә, закон хуҗаларына йөрдем. Кая барсам да тик бер генә җавап алдым: «Җинаятьләреңнең срогы чыккан, гөнаһларың искергән»,— диделәр. Юк, юк, срогы да чыкмаган, искермәгән дә! Мин анысын яхшы беләм — минем җинаятьләрем, минем гөнаһларым бит алар. Мин түктергән күз яшьләре, мин

койган каннар менә монда, күкрәк авызына килеп тыгылган.

Ул шунда ук җәһәт сикереп аягүрә басты. Тамак төбеннән гырылдап чыккан үзәк өзгеч тавыш минем колагымны ярып керде:

— Әй, бәндәләр! — дип шашып сөрәнләде карт.— Сез үз вакытында, хәтта вакытыннан да алда мөлкәт, мактау, бүләк алып калырга тырышасыз. Җаныгызны фида кыласыз, бахырлар, комсызлар, исәрләр! Ә сез олы гөнаһларыгыз өчен дә, кече гаепләрегез өчен дә үз вакытында җәза алып калырга тырышыгыз! Соңлап калмагыз, ашыгыгыз! Соңласагыз, менә бу тимер капка сезгә кирәк чакта ачылмаячак. Сәмигулла рөхсәт итмәячәк...— Ярулла карт нәкъ баягыча лып итеп җиргә утырды. Озын киң күлмәк җиңе белән маңгаен сыпырып алды. Башкача ул миңа игътибар итмәде. Мин үз юлыма киттем.

...Кышкы бураннар чорында беркөн Ярулла гаеп булган. Бөтен тирә-якны кыдырып эзләгәннәр, таба алмаганнар. Тик яз башында гына күрше авылның зират коймасы буенда кар астыннан картның кара көйгән гәүдәсе килеп чыккан. Аны шунда койма тышына гына күмеп тә куйганнар...

Мәзәк өчен генә

— Әллә Сәлихы да тәмәкегә салышты инде, Мортазасы җитмәгән...— дип сукранды Олы инәем кичкә каршы.— Өйдә бөтенләй шырпы тормас булды.

Ул шырпының кая киткәнен бер мин генә беләм. Янә Шәйхаттар белә. Аларның мунчасында кәрт уйнап, мин көненә икешәр, хәтта өчәр кап шырпы оттырам. Котым

юк минем. Шул аркада бөлеп беттем. Әмма өметне өзмим. Бер килмәсә фарт, бер килер. Ул чагында мин Шәйхаттарга оттырган бөтен мөлкәтемне кире кайтарып алачакмын. Җиде тиен бакыр акча, дүрт мылтык гильзасы, ике булавка, Мөхтәр җизнәм биргән сөяк саплы пәке, бихисап кап шырпы әлегесе көндә Шәйхаттарның комагай кесәсендә тоткынлыкта ята. Хәләл хәзинәмне коткарып кына калмый, тегенең үзен муеннан бурычка батырмасаммы! Безнең капкага да Сәмруг кош кунар әле. Күр дә тор менә. Инде төшемә дә керде, кәрткә салыр бүтән рәте калмагач, Шәйхаттар, берәм-берәм йолкып, башындагы һәммә чәчен миңа оттырып бетте, имеш. Йолкынган һәр төк чәч алтын кылга әйләнә бара — тот та бау иш. Тегенең елтыр башы, тургай йомыркасы төсле, сипкелле, имеш. Такыр башын сыйпап алды да Шәйхаттар елап җибәрде: «Чәчемне генә кайтарып бир! Моннан ары тамчы да хәрамләшмәм. Ышанмасаң, менә таш ашап, ант итәм»,— диде дә, шытыр-шытыр кимереп, мунча ташын ашарга кереште. Күп ашады, бетерә язды, бик эреләре генә торып калды. Мин дә ахмак түгел, егылып ук төшмәдем. «Өндә сөйләшербез...» — дип кенә җибәрдем. Ярар, ул да әзрәк газаплансын әле.

Бу төшемне мин үткән төндә күргән идем. Ә бүген ул өч каптырмамны, ике кармагымны, актыккы кап шырпымны отып алды. Хәерчелекнең инде чигенә җитеп кайтып керсәм, Олы инәем ак эт бәласен кара эткә сылап тора.

— Сәлих агаем тәмәке тартмый ул, Олы инәем,— дип тегенең арасына кердем. Ничек инде үз гаебемне күрәләтә кеше өстенә аударыйм.

— Көннең көнендә кая була соң шулчаклы шырпы?

— Әллә инде... Хәзер бит шырпыны бик алама чыгара башладылар. Өчне сызасың, берсе кабына. Шуңа күрә бәрәкәте юк,— дип мин кешедән ишеткән сүзне әйткән булдым. Олы инәем елмаеп куйды:

— Син әҗәлгә дә сәбәп табарсың ла ул, синнай... Бар, караңгы төшкәләгәнче лавкага барып кайт.

Бик ирендерсә дә, Олы инәемнең сүзен егып булмый. Мин бит аның иң төп таянычы. Әтием белән Кече инәем, бөтен вак балаларны төяп, Сайран авылына Гайникамал апамнарга кунакка китте. Агаемнар әле урман эшеннән кайтмаган. Өйдә ул да мин генә.

— Коба сыер бүген танда йөри. Төнен бозаулыйнитә калса, фонарь кабызып чыгарлык та шырпы юк. Көннәр әнә нинди зәһәр... Бозавын туңдырып куймасак инде...— Боларны Олы инәем минем өчен сөйли, мин башкарачак йомышның үтә зур икәнлеген төшендерә. Коба сыер дигәне — безнең абзарда минем иң яраткан малым. Юаш ул. Тыңлаучан, илгәзәк. Көтүдән адашып яки курадан китеп, һич браматта йөрмәс. Ике күзен мөлдерәтеп бер карася, коеласың да төшәсең. Сиңа әйтер әллә нинди акыллы сүзләре бар кебек аның. Кайчак мин аны Олы инәемә охшатып куям. «Тик теле генә юк»,— дим.

Олы инәем учыма өч тиен бакыр акча салды.

— Бияләең эчендә учлап кына бар. Тик теге Сәгыйдулла кебек булма,— диде.

Лавка бездән ерак. Аны кәпирәтиф дип тә йөртәләр. Кала урамы белән Өч әтәч урамы почмагында ул. Аңа барганда Сәлмәй чокыры аша үтәргә кирәк. Элегрәк шөрләтә иде дә, хәзер чокырына ис китми. Ул лавкада күркә Мәүлетбай белән Әтәч Сафуан агай сату итә. Кушаматлары үзләренә бик таман килеп тора. Икесе дә кәпрәергә, кешене мыскыл итәргә бик шәпләр.

Бакыр тәңкәне учлаган көе йөгерә бирәм. Үзем, теге Сәгыйдулла мәзәген уйлап, эчемнән көлеп барам. «Менә бер пешмәгән...»— димен. Безнең түбән күрше Сәгыйдулланың маҗарасы көлеп туймаслык шул. Югары очтагы Зөләйха җиңги Сәгыйдуллага бишмәт тегә икән. Әнисе моның учына өч төймә салган да:

— Мә, тиз үк җиңгәңә илтеп бир, көпеңә тагар,— дигән.

Сәгыйдулла учын йомып, йомышын йомышларга йөгергән. Юл уңаенда малайлар белән ат тизәге тибеп уйнаган бу, Гариф тавында чана шуган, аннан эт талаштырган җирдә торган, тик кичкә табан гына Зөләйха җиңгигә барып җиткән. Килеп кергәч тә, йодрыгын ачып, җиңгигә сузган.

— Җиңги! Менә сиңа өч төймә! — дип сөрәнләгән. Баксаң, учында бер төймә дә юк икән.

Сәгыйдулла хәзер җиткән егет инде. Аның малай чагында әйткән үтемле, тапкыр сүзен безнең авыл халкы әле булса онытмый. Эш көткәнчә барып чыкмаса яки нияткә ирешелмәсә, һаман кабатлый бирәләр: «Менә сиңа өч төймә!..» — диләр.

Лавкага йөрергә мин элек ярата идем. Әнә шул көннән соң биздем. Аның нигез буенда әле булса брәдәк Микәй укшып ятасыман... Бөтенесе дә шул бәхәс аркасында инде. Безнең типтәр үлеп бәхәс ярата. Яшекарты, бала-чагасы, бичә-чәчәсе, хәтта килен-киләмәсе, бәхәс дисәң, каплана да китә. Җирән мыек кодабыз Хисмәтулланы әйтеп торасы да юк. Аның әңгәмәсе әле алда булыр. Әнә, бездән дүрт өй аша Гайшә белән Гөлчирә исемле ике килендәш тора. Үткән атнада шулар бәхәсләшкән. Бер тавыктан. Гөлчирә әйтә икән: «Сакбай Миңзифа карчыкның кигән ыштанын салдырып алыйммы?»— ди икән. Гайшәсе өсләтә бирә, ди: «Булдыра алмыйсың!» Тегесе һаман: «Булдырам!» — ди. Монысы отыры котыртып: «Юк! Юк! Юк!» — ди икән. Икесе дә берәр тавык тотып, аягын бәйләп ташлаганнар.

Миңзифа карчык дигәнең — бәләкәч кенә алачыкта гомер итеп яткан ятим бер эби. Үзе фәкыйрь, үзе бик игелекле. Гөлчирә килгән дә эбигә болай дигән (Гайшәсе тәрәзәдән күзәтеп тора икән):

— Әбекәем, бөтен ышанычым синдә генә! Агаемнар Кара Якуптан, кунакка чакырып, пар ат җибәргән. Кешелеккә кияргә бер генә ыштаным да калмаган. Аруырак берәр ыштаныңны биреп торчы...

Миңзифа карчык шунда ук сандыгын актарырга керешкән. Ә Гөлчирәгә тегесе ошамый, монысы ярамый, имеш. Аптырагач, әби әйткән:

— Алайса, киленкәем, менә өстемдәгесен килештермәссеңме икән? Кичә генә кигән идем. Ямавы-фәләне дә юк.

Гөлчирә монысын, әлбәттә, ошаткан. Шул күлмәк-ыштаны белән генә ике катлы булган әби куана-куана салып биргән.

Юкка гына Гөлчирәне: «Елан аягын кискән»,— димиләр шул. Ифрат усал, хәйләкәр нәрсә.

Ә менә Микәй бөтенләй хәйләсез бер җан иясе. Аның каян килеп, кая киткәнен һичкем белми. Йөри шунда тирә-якны кыдырып. Безнең авылга ул базар көндә генә килеп чыга. Бирсәләр — ашый, кусалар — китә. Зыяны да, файдасы да юк. «Нәрсә берәр җирдә төпләнеп кенә эшләмисең, Микәй?» — дисәләр, ул болай җаваплый: «Эшләп карадым инде. Миңа эш чыдамый»,— ди. Тиле Габбәсне ирештергән шикелле, Микәйне бала-чага үчекләми, артыннан таш ыргытып та калмый. Кайвакыт аны сырып алып, авызы белән музикән уйнаттырабыз. Иреннәрен дерелдәтеп, шундый уйный ул музикәнне, гармунчы Мәрәһимең бер читтә торсын. Көе генә безнеңчә түгел, әллә марича, әллә керәшенчә. Шулай да моңлы. Эчләрне өздергеч. Микәй үзе дә адашып йөргән бер ят җыр шикелле. Үзе моңлы, үзе — безнеке түгел.

Үткән базар көн Кече инәем мине сабын алырга җибәрде. Лавкада халык байтак иде. Шагыр-шогыр басып, Микәй килеп керде. Туңып беткән. Сирәк кенә мыегына боз каткан.

— Ә, Микәй! Юл бирегез Микәйгә! — дип гылдырдады Күркә Мәүлетбай.— Товар кирәкме, бай абзый?

— Һи-и, Мәүлетбай, намусың түрдә, оятың гүрдә булгыры,— дип кеткелдәп куйды Микәй.

— Нидән шулай көләсең, Микәй? — дип бу юлы Әтәч Сафуан сүз катты.

— Үземнән. Миннән дә мәзәгрәк адәм бармыни? Аласы товарым алынган, сарайларым салынган, менә күрәсең, үзем керәшен, эчкәнем — кәрәчин.

Микәй тагы нәрсәләрдер тезмәкче иде, Мәүлетбай тиз үк эләктереп алды:

— Ә син, Микәй, чынлап та кәрәчин эчә аласыңмы?

— Минме? Кәрәчинме? Әллә, белмим...

Шушы мәлдә лавка эче гөж килде. Берсеннән-берсе уздырып, төрле тавышлар илерде:

— Булдыра алмый ул!

— Хәленнән килми!

— Нишләп хәленнән килмәсен, ди, ир асылының!

— Үзе шундый гына булса да, эче тулы гайрәт аның!

— Куегыз бушны! Микәй булдыра торган эш түгел бу!

— Булдырса, миннән егерме тиен көмеш! — дип Мәүлетбай тәңкә чөйде дә учы белән тотып алды.

— Миннән дә егерме тиен! — Сафуан көмеш акчаны бармак очлары белән чеметеп тотып, тегеләй-болай әйләндереп куйды.

Боларга бүтәннәр дә кушылды:

— Миннән ун тиен!

— Биш тиен!

— Өч тиен!

Кешегә ияреп мин дә: «Ике тиен!» — дип кычкыра яздым. Чак-чак кына тыелып калдым. Югыйсә, сабынның бер чите ару гына кителә иде.

Исәррәк булса да, Микәй акчаның нәрсә икәнен белә, ахрысы. Мул гына төшәчәк бит. Икеләнеброк ул тагы кабатлады:

— Минме? Кәрәчинме? Күпме эчәргә кирәк соң аны?

— Җәмәгать! Җыемны менә монда салыгыз,— дип берәү колакчының чиште. Танымыйм, чит авыл кешесе бугай.— Батыр өлеше шушы колакчында булыр!

— Әллә тәвәккәлләргәме икән? — диде Микәй үз-үзенә.— Күпмерәк эчәргә соң?

— Әнә бер кружка җиткән,— дип билгеләде Күркә Мәүлетбай. Мичкә өстендә тора ул калай кружка. Бер шешә сыешлы булыр.

Шушы мәл әлеге колакчынга көмеш катыш бакыр тәңкә чыңлап сикерешә башлады. Минем күңелемне кинәт ниндидер хәвеф басты. Әйтерсең, әле акча чылтырамый, ә Микәйнең башына, чыңлатып, бакыр табак белән сугалар. Мин беләм инде, кәрәчиннең бер тамчысын йотуы да әҗәл. Без аулак калсак, авызга кәрәчин уртлыйбыз да, аны янган шырпыга бөркеп, ялкын чыгарып уйныйбыз. Шул чак ялгыш йотып җибәрсәң, эчләрең актарылгандай була...

Колакчын хуҗасы, колакчының туктаусыз селкетеп, акча чылтырата. Башка шылт иткән нәрсә юк. Бары тәңкәләр генә чыңлый...

— Алай бик кыстагач ни... Акча өчен түгел, сүзегезне екмас өчен генә ходайга тапшырам. Эчемнән җаным чыгып качмас әле. Качса тагы... Коегыз!

Койдылар. Микәй күзен йомды да, тын алмый, бер кружка кәрәчинне эчеп бетерде. Нигә күзен йомды икән? Бу бәхәснең нәрсәсе кызык булуын мин шул чакта да, аннан соң да аңламадым. Тик исәр Микәйнең ни өчен күзләрен йомуын менә бара торгач төшендем. Ул, мөгаен, акыллы кешеләрнең ыржайган ахмак йөзләрен, әшәке кыяфәтләрен күрергә теләмәгәндер. Ни генә әйтмә, моннан ары да шул кешеләр арасында яшәргә кирәк бит... Менә шундый арзан, мәгънәсез кәеф-сафаларны вак акчага сатып алып, рәхәт чиккәннәрне бу гомердә байтак күрергә туры килде. Ә бит берәү дә (мин үзем дә!): «Туктагыз!» — дип дөнья ярып кычкырмады. Кычкырмый да. Акчасы түләнгән, янәсе...

— Афарин, Микәй, акчаны күрәп алдың,— дип әлеге агай колакчын төбендәге акчаларны тырнап учына җыйды да Микәйгә сузды. Теге баш чайкады. Берәүгә дә игътибар итми лавкадан чыгып ук китте.

— Вәт, әй, акчадан туйган адәм дә булыр икән,— дип аптырады Күркә Мәүлетбай.— Вәт, әй...

— Ачтан койрык чәнечсә, килеп алыр әле. Мә, Сафуан, синдә торып торсын.— Чит авыл кешесе иганәне лавкачыга тапшырды. Колакчынын каккалап башына киде. Янәсе, күрегез, сукыр бер тиене дә калмады, димәкче була.

Мин лавкада байтак юандым. Чират тими торды. Йомышымны йомышлап урамга чыкканда, Микәй нигез буенда кар өстендә капланып ята иде. Әллә үксеп елый, әллә укшый. Мин янында байтак басып тордым. «Микәй, Микәй агай!» — дип елардай булып чакырып карадым. Ул эндәшмәде. Ә бит, иреннәрен калтыратып, ничегрәк мүзикән уйный ул! Хәзер йөзтүбән ята. Әллә укшый, әллә ачынып елый. Кырык ямаулы чикмәне аркасына сыдырылып менгән. Ыштан төбе лычма юеш. Күрәсең, баягы кәрәчин юлны үзенә тиз тапкан.

— И, кафер, бугазына җиткәнче тыгынмаса тагы! Тфү! — дип бер әби төкеренеп үтте.— Дөнья корткычлар, шайтан коллары... Сиңа ни калган тагы?! — дип миңа да җикеренеп алды.— Эт косыгын иснәп торасың. Бар, өеңә кайт!

Микәйнең газаплары өчен мин өстемә үзем күтәрә алмастай гаеп йөкләп кайтып киттем. Бу үткән базар көн булды. Бүген тагы шул лавкага китеп барам. Сәлмәй чокырына җиткәндә, көн эңгергә авыша башлады. Кинәт шомланып куйдым. Шомланырсың да шул. Менә бу күпер астында бит җен-пәри мыжгып тора. Ярый юашлар әле. Берәүгә дә тигәннәре юк.

Мин лавкага килеп җиткәндә, Күркә Мәүлетбай белән Әтәч Сафуан ишеккә йозак салып тора иде. Таралдым да төштем. Бетте болай булгач...

— Агайлар! — дип ялвардым мин.— Зинһар өчен бикләми торыгыз! Олы инәем шырпы алып кайтырга кушкан иде... Агайлар...

— Бикләдек шул инде. Әнә, күрәсеңме? — Этәч Сафуан төнбоек яфрагы зурлыгы йозакка күрсәтте.

— Күрәм лә... Шырпы бик кирәк иде шул. Олы инәем кушты. Дөм-карангыда утырабыз югыйсә,— дип шаштырдым. Коба сыерны да кыстыра язган идем, әмма тыелдым. Көлкегә алулары бар. Бу икәүдә иман ягы чамалы.

Шулай да Мәүлетбай ишек яныннан китәргә ашыкмады.

— Син кем малае соң әле? — дигән булды, күрәләтә башын этлеккә салып.

— Беләсең дә инде... Нурсафа малае. Олы инәемнең улы...

— Әллә, Сафуан, бу егеткә шырпы бирәбезме, хакын әйбәт түләсә?

— Түләрмен. Әйбәт түләрмен. Менә акча! — Бияләемне селкеп куйдым.

— Акча гына җитми. Һөнәр дә күрсәтергә кирәк.

— Нинди һөнәр?

— Бар шундый тылсымлы бер һөнәр... Әнә теге мичкәгә басып, җилпенә-җилпенә, өч тапкыр «Торыйк! Торыйк! Торыйк!» дип кычкырсаң, лавка ишеге үзеннән-үзе ачыла да китә,— дип авыз ерды кызыл бүксәле Күркә. Аның ияге шулай миңа бүксә булып күренде.

Кинәт тыным кысылды. Минем «Кендек», «Рукавказ» дигән үз кушаматларымнан тыш «Торна» дигән ыру кушаматыбыз бар. Менә кая төзи Мәүлетбай үзенең агулы угын. «Кендеген» әйтсәләр дә, чикәгә чүкеч белән суккан кебек була, «Торна»сын ишетү — әҗәлдән дә яман. Тегесен атап үземне хур итсәләр, монысын атап, бөтен ыруымны мәсхәрәгә калдыралар.

— Юк! Әйтмим! Үтерсәгез дә әйтмим!

— Алайса, шырпы да юк! Утыра бир әйдә дөм-караңгыда.

Нәкъ шул мәл коба сыерның боек күзләре миңа төбәлде. «Бүген таңда китерәм,— ди ул, гүя,— бозавымны туңдырсак, нишләрбез».

— Агайлар! — дидем, үземне шартлатып сындырдым.— Минем үз кушаматым бар. Миңа «Кендек» дип исем атыйлар. Алайса, шуны гына әйтим дә... Теләсәгез, дүрт тапкыр...

Мәүлетбай якын да килми:

— «Кендек» тә булган икән кушамат! — Оятсыз нәрсә, хәтта минем кушаматымны кимсетә.— Син безгә чынын, ата-бабадан калганын давай! — ди.

Мин икеләнә башладым. Коба сыер хәзер миңа моңаеп карау гына түгел, ялварып мөгри дә, имеш. Тавышы җанымны өтә. Аның былтыргы бозавы, үзе төсле үк, хәйран сылу иде, алгы бәкәлләре ап-ак иде. Тик гомерсез булды. Ниндидер ярамаган үлән ашап, күбенеп үлде. Коба сыерыбыз шул хәсрәтеннән һаман айный алмый йөри. Бу бозавы, бәлки, юаныч китерер дип торабыз, имин генә котылса.

— Нәрсә, шырпы кирәкмәс булдымыни?

— Кирәк.— Мин бастырып куелган зур мичкә кырына килдем. Үзем генә менәрлек түгел. Биек.— Мендерегез! — дип боердым. Әтәч Сафуан мине мичкә өстенә бастырды. Менә хәзер шунда торган көе, ике кулыңны җилпеп, бер Мәүлетбайга, бер Сафуанга төбәп: «Голдыр-голдыр кикри-кү-үк! Голдыр-голдыр кикри-кү-үк!» дип йөз тапкыр, юк, мең тапкыр кычкырырга иде. Ниндидер мәлдә тел очымнан ычкына да язып калды. Тыйдым. Тирә-якка карап алдым. Үткән-сүткән күренми. Я ходай! Ни көннәргә төшәм мин! Тәүдә канатларымны җилпеп тордым. Бик озак җилпедем. Шуннан суза биреп, ачык итеп: «Торыйк! Торыйк! Тор-рыйк!» — дип кычкырдым. Торнага охшатып, җиренә җиткереп кычкырдым. Өч кенә түгел, биш тапкыр, ун тапкыр, егерме тапкыр

кабатладым. Үземә үч итеп кабатладым, янә тегеләргә үч итеп кабатладым. Торган саен чәмем, гарьлегем артты. Тәмам ярсыдым. Инде үземне тыя алмый кычкырам: «Торр-рыйк! Торр-рыйк!!» «Мәгез! Бугазыгыз тыгылсын!» — дип каһәрлим үзләрен эчемнән.

— Я, булды инде, булды. Җитәр, төш,— диде Мәүлетбай, нигәдер йомшарып. Мин бераз һавага муен сузып тордым да, канатларымны киң җәеп, җиргә сикердем. Торна булгач, ахырынача торна булып калырга,— хурлыкка бер баткач, муеннан батарга кирәк — гомергә онытылмаслык итеп...

Сафуан ишекнең биген ачты. Эчкә кергәч, Мәүлетбай шәм кабызды.

— Күпме кирәк? — дип сорады Күркә.

— Өч тиенгә. Беткәнче. Менә...— Мин бияләй эченнән кулымны китереп чыгардым. Учым буш иде. Икенче бияләемне дә салдым. Юк. Бияләйләремне селкеп тә карадым. Юк. Бердәнбер чалбар кесәмнең төбен әйләндереп чыгардым. Юк.— Шушы учымда гына иде. Өч тиен бакыр иде...

— Менә сиңа өч төймә! — дип кыткылдады Әтәч Сафуан. Мәүлетбай аның көлүенә кушылмады. Хәтта мине юаткандай итте.

— Мичкә тирәсендә төшкәндер, иртәгә табып алырбыз әле. Менә сиңа өч тиенлек шырпы,— дип миңа ничәдер кап сузды. Мин санап тормадым. Аларны чалбар кесәмә тутырдым. Үзем һаман тулыша киләм, тулыша киләм. Менә-менә шартлыйм бит инде. Ишеккә барып җитә алмадым, кычкырып елап җибәрдем.

— Елама, исәр, югалса, синеке түгел, безнеке югалды бит,— дип калды Мәүлетбай.

Чыгып йөгердем. «Их, сез!.. Сездә акча кайгысы, миндә намус кайгысы. Өч тиенлек шырпы өчен карт атамның, әтиемнең — бөтен ыруымның яманатын саттым мин. Намусны хәҗәткә алыштырдым. Шул аркада үзем бөлдем, юкка чыктым. Менә ни өчен елыйм мин...»

Кайтыр юлымда бу хурлыкка төшүемнең сәбәпләрен берәм-берәм барлап чыктым. Иң тәүдә, әлбәттә, Күркә Мәүлетбай белән Әтәч Сафуанга килеп төртелдем. Әшәке нәрсәләр! Аннары уенда хәрамчел Шәйхаттарга сугылдым. Хәрамләшкән өчен генә ота ул. Янә коба сыерны гаепләдем,— шушындый көндә бозауларга җыенмаса тагы... Олы инәем дә инде. Иртәгә чаклы күршедән генә берәр кап үтечкә алып торып булмыйдыр шул! Кич йөзендә мине җибәрмәсә... Өч тиен бакырын әйтер идем — куйган урынында тормый. Әгәр алтын булса, ниләр кыланыр иде икән?!

Бөтенесен дә әдәп хөкеменә тарттырдым. Ләкин бар бәланең башы да, азагы да булган үземә тел тидерү ул чак башыма да кермәде. Хәзер килеп үземнән җавап алам: ә син соң?

Намуска, әдәпкә көч китереп, шулай хаҗәт аткаручылар, мөгаен, үзләрен гаепле санамыйлардыр. Ул көнне бит мин хаҗәт башкардым...

Хәер, безне шаярттылар гына бит. Хәйләкәр Гөлчирә житмешне үткән Миңзифа карчыкның болай гына, кызык итеп кенә ыштанын салдыртты. Базар көнне бахыр Микәйне, кызык итеп кенә, үтерә язганчы интектерделәр. Минем мохтаҗымнан файдаланып, көлке чыгарыр өчен генә җанымны имгәттеләр. Уенның уймагы менә шулай килеп чыга. Бәлки, мин хаксызмындыр, уен күтәрми торган бер тинтәкмендер, бәлки. Ярый, шулай да булсын. Ләкин барыбер уен кешене эт итмәскә тиеш.

...Бик күп еллар үткәч, ерак Көнчыгыш илләренең берсендә мин борынгы цирк тамашасы карадым. Артистларның уеннары мавыктыргыч булды. Әмма бер нәрсә йөрәккә онытылмаслык әрнү салды. Аяк-куллары көтек, муены озын гарип ир аренада эт булып уйнады: ул сикерә, ауный, өрә, олы сөяк кабып йөгерә, ырылдый, багана янына килеп арткы аягын күтәрә, тагы әллә ниләр кылана. Шундый килештерә, чын этең ары торсын. Вак акча түләп тамаша күрергә килгән

кешеләр, моны хуплап, гөж килә, чәбәкәй итә, сызгыра; банан, әфлисун, кәнфит ыргыта. Мин үземне чамадан тыш нечкә күңеллемендер, дип уйламыйм. Шулай да цирк аренасында эт урынына өреп йөргән гарип миңа кече туганым булып күренде. Ул да кеше затыннан иде...

Ерак Көнчыгыш иле әле бик ерак иде. Мин, туң чабаталарым белән шыгыр-шыгыр карны шыгырдатып, өйгә кайтып барам. Тирә-якта һичнәрсә күрмим, һичнәрсә ишетмим. Тик аяк астымда кар гына шыңшый. Нигә шыңшыйсың, кар? Мин йомышымны йомышлап кайтып киләм бит...

Гарипләргә бәйрәм кирәкме

Минем ике апам бар: Сайран авылындагы Гайникамал апамның җитеп килгән кызлары алар. Берсе Гөльямал, икенчесе Өммикамал. Гөльямалы буйга сылу, төскә чибәр. Үзе хәйран уенчак. Аяк-кулың төгәл, буең-сының купшы булгач, шаярсаң да, көлсәң дә килешеп тора. Ә менә Өммикамал апамның хәле бүтәнчәрәк. Аның ярты сыны гарип. Ми чиреннән шулай булып калган. Йөргән чакта кыйшаеп-кыйшаеп китә. Ул да гарипмен дип, көн-төн елап утырмый. Адәм рәтенә эшли дә, сөйләшә дә, көлә дә. Тик кайвакыт, кычкырып көлгәндә, бер гаебе чыккан шикелле, кинәт туктап кала. Гариплеге исенә килеп төшә, ахрысы.

Сайрандагы җизнәмнең исеме Хәбибрахман. Ул мәчет карты. Эштән чыккан динчел нәрсә. Бөтен затны бары хәрам белән хәләлгә генә бүлә. Хәтта минем фуражка козырегын да хәрамгә чыгара. «Мөселман киеме түгел, шайтан мөгезе ул» ди. Шуңа күрә мин, алар йортына килеп кергәндә, фуражкамның алдын артка әйләндерәм,

«шайтан мөгезен» кире якка борам. Ишетүемә карaганда, җизнәм бик озак заманнар солдатта кафер арасында йөреп, иманын югалтып кайткан. Шуның аркасында, гөнаһларын йолмакчы булып, мәчеткә иялəшеп алган. Әллә шулай, әллә түгел,— анысын кем белсен. Әмма чит кеше алдында ул, песи төчкерсә дә, «Ярхамбикә, алла!» — дип кенә тора. Бәрәңге бакчасына күрше тавыгы килеп керсә, аны катлы-катлы сүгеп, куып чыгара. Оста сүгенә җизнәм. Аннан уздырса да безнең урамның көтүче Нуретдин гына уздырыр. Минем җизнәм куянчы. Бер чөйдә аның мылтыгы, икенче чөйдә камчысы эленеп тора. Өйдә малай заты булмагач, ул мине якын күрә. Эчем пошып китсә, йөгерәм дә Сайранга барам. Башыма берәр уй төшсә, әйтеп-нитеп тормый, кайтып та китәм. Уй дигәнең ул сәбәпсез генә килми инде. Һәрвакыт сәбәбе була. Берчак бакча артында печән чабып уйнаганда, ат атланган малай шундый җыр җырлап үтте:

Кыргын кузгалмый, диләр...
Ул кузгалса, дөньяларда
Хатын-кыз калмый, диләр.

Йөрәгем жу итеп китте. Әгәр ул кузгалган булса? Инде безнең авылга килеп җиткән булса? Минем ике инәемне дә үтереп ташлаган булса? Мин, арткы киртә арасыннан гына чыгып, үзебезнең авылга таба йөгердем. Үзем йөгерәм, үзем елыйм. «И Олы инәем! И Кече инәем!» — дим. Хәлдән таеп беттем. Авылга килеп керсәм, бөтенесе дә әүвәлгечә. Өйдә дә иминлек. Икенче бервакыт безнең авыл ягында төтен күренде: «Без янабыз икән...» — дип, тыным бетеп, авылга чаптым. Кайтсам, Казнагол басуында салам яндыралар икән. Шундый сантыймын мин. Куркуым белән узыша-узыша, биш чакрым араны сизми дә калам. Я бу яктан, я теге яктан мине артымнан эзләп киләләр. Табылгач, орышмыйлар

алай. Бәлки орышырлар да иде, Олы инәем тел тидертми. Хәбибрахман җизнәмнең дә миңа әйткән иң каты сүзе «Тинтәк!» Шуннан арттыра алмый. Алмас та шул! Бәрәңге бакчасында тибенеп йөргән күрше тавыгымыни мин аңа? Менә Өммикамал апамны ул ифрат кага. «Һи, са-ансыз!» — дип кенә тора. Әйтерсең, ул гариплеген үзе теләп алган. Чирдән шулай калмаса, Гөльямалдан да сылурак булыр иде әле — шушы буе белән!

Гарипләрне мин үлеп жәллим. Бигрәк тә бәйрәм чорында. Бәйрәм көндә аларның зәгыйфьлеге тагы да ныграк күренә төсле. Мәйданга чыкмасалар ни була икән? Былтыр сабан туйда Өч этәчнең көтүчесе бөкре Шәрәй ак күлмәкләр, кара итекләр, ак эшләпәләр киеп чыккан булган. Әйтерсең, сабан туй бер аның өчен генә ясалган. Бичаракай! Мин дусым Әсгатькә үземнең шигемне әйтәм:

—Гарипләргә бәйрәм нигә кирәк инде?

Әсгать аңламый тора:

— Кайсы гарипләргә?

— Теге бөкре Шәрәйгә, чалыш муен Хансага, тәяксез исәр Микәйгә...

Дусым аптырабрак торды:

— Гарипләргә бәйрәм бигрәк тә кирәк шул. Башка көнне аларны азмы кимсетәләр, бәйрәм көнне, ичмасам, бөтен адәм тиң... — дип Әсгать яфраксыз колагын сыйпап куйды.

— Тиң тагы... Шәрәйнең үркәче барыбер шиңми инде.

— Үркәче шиңмәсә, күңеле күтәрелә. Кулымнан килсә, мин гарипләр өчен бәйрәмне күбрәк ясар идем әле.

Әсгать нәрсә генә димәсен, бәйрәм мәлендә мин гарипләрне отыры кызганам. Кем табынындадыр азрак бал төшереп алган Шәрәй бию түгәрәгенә чыккан булды. Алай-болай сикергәләп, биегән рәвешле кыланды. «Һай, афарин, Шәрәй, оста басасың!» — дип, ихлас хуплаучылар да табылды. Ләкин бер явызы телен тыя ал-

мады: «Иплэп, иплэп, Шэрэй, аркандагы йөгең коелып бетмэсен...» — диде. Янында басып торган Хисмэтулла исемле безнең җирэн кодабыз теге эшэке телле нэрсэнең авызына чэп иттереп тондырды тондыруын. Эмма аннан ни файда? Елардай булып, Шэрэй түгэрэктэн чыгып китте.

Менэ сиңа тиңлек!

Бездэге шикелле, Сайранда да яз көне кичке уеннар була. Беркөнне апамнар елый язып инэлгэч, миңа ышандырып, җизнэм аларны кичке уенга җибэрде.

— Күз бэйлэнгэнче кайтып җитегез, мэтри аны! — дип кычкырып калды. Минем өскэ төшкэн бурычны аерата хэтерлэтте.— Апаңнарга күз-колак бул!

Бу инде аның миңа, күзэтче бул, шымчы бул, дию иде. Тапкан кешесен!

Уенны яшьлэр Бэрсүэн суы буенда ямь-яшел чирэмдэ корганнар. Кичке уеннарда кызыклы тамашалар да, узышлар да, көрэшлэр дэ, ярышлар да булмый. Яшь-җилкенчэк кара-каршы төшеп бии, эйлэн-бэйлэн йөреп җырлый, кулга-кул тотынышып, капкалы, чылбыр уены уйный. Кыңгыраулы, көзгеле эллэ ничэ гармун, күреклэре шартлардай булып, ярсып моң чэчэ. Язгы кичтэ шул гармун моңыннан да сихерлерэк нэрсэ юктыр...

Башта мин үзем кебек малайлар белэн шыгырдый уйнап туйдым да Өммикамал апам янына килдем. Ул, аякларын алга сузып, ялгызы бер читтэрэк үлэн өстендэ утыра иде. Йөзе моңсурак күренэ. Юк, аның күзлэрендэ көнлэшү дэ, кимсенү дэ чагылмый. Бүтэннэрнең уйнавына сокланып утыра ул. Мин аның янына тезлэндем. Апам мине муенымнан кочаклап алды.

Безнең Гөльямал апабыз исэ йөзэ генэ. Хэзер генэ, биеп, түгэрэк уртасында орчыктай эйлэнэ иде, баксаң, капкалы уенында иярпүче дэ булып алган. Җиз кыңгыраулы саратовский гамунын өзэрдэй булып сузган гармунчыга атап җыр да җырлап алды. Тегесе ерылган авызын яба да алмый. Бөдрэ чэчле баһадирны апамның

бер жыры жебетте дә куйды. Җебер дә шул. Җыры ни дә, күкрәгеннән чыккан моңы ни!

Үзең гармунчы егет,
Кулыңда көмеш йөзек.
Байкал күлләренә төшсәң,
Кереп алырмын йөзеп.

Ай-һай, шаштырыбрак җибәрде түгелме? Мин җырның ертыгын табам. Шушы чаклы әзмәверне, батса, алып чыгарсың. Үзеңне батырыр.

...Ул чакта мәхәббәтнең кодрәте, хатын-кыз рухының чиксез көче — минем өчен әле ачылмаган җиһан иде. Яши-яши генә аңлаячакмын мин: хатын-кыз мәхәббәте ир кешене океаннарда батырмый, галәм утларында яндырмый, өермәләрдә адаштырмый саклар икән. Үзенең батуын да, януын да, адашуын да уйламас икән. Тик сөйгәне генә котылсын. Менә ни хакта җырлаган Гөльямал апам теге җырны.

Гөльямал кичергән бәхетнең чиге юк. Нәрсә генә эшләсә дә, килешә, нәрсә генә әйтсә дә, урынлы. Үзенең ике бите ал янган. Бигрәк тә теге бөдрә гыйфрит күз салса, кабынып китә ул. Мин, әлбәттә, күзәтеп утырмыйм. Карагач, күренә инде. Ул йөгерә дә безнең янга килә.

— Сеңелем! Туганым! — дип инәлә безнең икебезгә,— чак кына чыдагыз инде. Тагы ә-әз генә торыйк та...— Үзе, безнең җавапны да көтми, кире йөгерә. Безгә нәрсә. Уйный бирсен. Мин, Өммикамал апамның җылы иңбашына башымны терәп, тик утырам. Өммикамал апам һәрчак тегене дәртләндереп кала. «Уйна, тансыгың кайтканчы уйна!» — дип пышылдый.

Гөльямал янә безгә сугылып узды.

— Ачуланмагыз инде! Тагы ча-а-к кына...— Икебезгә дә нечкә билле берәр кызыл прәннек тоттырып китте. Моның каян килгән сый икәнен хәтта мин дә беләм. Егет күчтәнәче. Димәк, Гөльямал апам бүген «тегеңә» чиккән кулъяулык биргән. Каршы бүләктән безгә дә

өлеш чыкты. Ярар, эчне тишмәс. Өммикамал үз өлешен дә миңа бирмәкче иткән иде, алмадым. Үзе ашасын.

Без кайтып кергәндә, шыгытып караңгы төшкән иде. Өйдә тып-тын. Өчле генә лампа яна. (Саранлыклары чиктән ашкан.) Күрүебез булды, Хәбибрахман жизни келт иттереп ишекнең келәсен элеп тә куйды. Чөйдәге камчыны алды. Тәүдә, чажлатып чөйдәге тире тунга сыдырды. Гөп итеп калды. Аннан? «Син аздырдың аларны!» — дип сәкедә утырган Гөльямал апама селтәп алды, ләкин сукмады.

— Шайтан кәмитчеләре! Газраил ялчылары! Эттән туган кәнтәйләр! — дип үкеренде.— Вакытлы кайтыгыз дип кемгә әйттем мин? Сиңа түгелмени? — Камчы минем баш өстендә әйләнеп алды.

— Тиеп кенә кара! Берәребезгә тиеп кара!!! Хәзер үк кайттым киттем булыр.

— Гөльямал тагы бер хәл. Сиңа ни калган сөйрәлеп йөрергә, са-а-ансыз! Адәм имгәге! — Бу юлы камчы Өммикамал апам аркасына төште. Апам «ыһ» та итмәде. Камчы тагы, тагы чажлады.

— Әти! Әти! Өммекәйгә тимә! Тимә, әтием!!

— Чиратыңны көт, мәлгунь! — Ул тагы да Өммикамалга кизәнде.

— Жизни! — дип ачыргаланып кычкырдым мин.— Үз мылтыгың белән үзеңне атып үтерәм хәзер! — Бутәнчә сүз әйтә алмый, шашып, мин чөйдәге мылтыкка ташландым.

Хәбибрахман жизнәм аптырап, каушап калды. Мин мылтыкны алмадым. Почмакка сөялдем дә каттым.

— Ярар, моннан ары сабак булсын,— дип жизнәм камчыны кабат чөйгә элде. Мин шул сөялгән килеш буылып еларга тотындым. Бер гаепсезгә тукмалган Өммикамал апамны жәлләдем. Бигрәк тә — бәйрәмне... Хәбибрахман жизнәм, камчы чыжлатып, үзенең гарип кызын гына түгел, бүген Бәрсүән буенда булган шундый күңелле язгы бәйрәмне дә аяусыз тукмап ташлады.

Янә килеп Югары оч Зыятдин исемә төште. Аның Әгъзәм исемле улы былтыр, атасына әйтми, бер алама гына тальянка алып кайткан иде. Зыятдин карт шундый адәм — гармун тавышы ишетсә, җенләнә дә китә. Егетҗилән алар турыннан гармун уйнап үтәр хәл юк, теге, күсәк күтәреп, куып йөртә. «Гармунны кафер ясый, аны кулга тоту хәрам»,— ди. Әгъзам үзенең тальянкасын читән буендагы кычыткан арасында яшереп тота икән. Тегене беркөн Зыятдин карт тапкан да, типкәләп, урамга алып чыккан. Шуннан, зур күсәк тотып, бөтен халык алдында тукмарга керешкән. Мүзикән, бахыр, суккан саен «гыр», «гыр» килә икән. «Әле гырылдыйсың? Әле һаман гырылдыйсыңмы?!» — дип ахырда тегене менеп таптаган. Әгъзәм утырып кына еламады. Менә шулай. Берсе моңны күсәк белән дөмбәсли, икенчесе бәйрәмне камчы белән яра. Куллары коргыры!

Шәфкатьсезлеккә төбәп мылтык ата алмасам да, теге кичтә аны елап куркыттым. Җизнәм башкача тузынмады. Димәк, явызлыкка каршы мылтык күтәрер форсатың булмаса, һич югында, аңа күз яшьләрең белән ат икән. Бәгырьсезлеккә каршы тәү тапкыр баш күтәрүем, бәлки, шушы булгандыр. Ә моннан соң төрлесе үтте. Ярсып, алыш мәйданына ташланган чаклар да, каушап битарафлык ышыгына поскан заманнар да булды. Төрлесе булды. Байтак булды...

...Ә хәтер, үткәннәрне үзенә уңайлаштырып, кат-кат сипләп, төзәтеп чыга, алардан юаныч һәм таяныч эзли. Инде җитмешкә җитеп барган Өммикамал апам теге чакларны, тәмләп-тәмләп, искә ала:

— Булган инде исәр, шук чаклар. Гөльямал мәрхүмә белән икебез тиң җиттек. Икебез дә ифрат дәртле булдык. Кичке уеннардан кайта алмый, төнгәчә олагып йөрер идек. Кайткач, этием мәрхүм, урыны җәннәттә булсын, әй орышыр иде, әй орышыр иде. Никадәр кызу канлы булмасын, кул күтәреп сукканын хәтерләмим алай. Әрләнү күбрәк миңа эләгер иде. Күрәсең баш-

баштаграк, шаталаграк булганмындыр. Тиярен алганмын да. Сагынып сөйләргә генә калды инде уенчак, гамьсез чакларны...

Кавказ патшасының варисы

Әсгать дустымны җәй иленнән давыл китереп ташлагандырмы, юктырмы — анысы безгә караңгы. Ә менә Чәнчәк Исабәкнең безгә чит тарафлардан килеп чыгуы рас. «Язмыш җиле мине монда ташлады», — ди ул. Әллә унбиш, әллә егерме ел әүвәл килеп чыккан ул безнең авылга. Өстендә билле кара җилән икән, җиләненең ике түшендәге буй-буй бөрмәләренә бармак буе ак чөйләр тыгылган икән, башында бөдрә йонлы түгәрәк кара бүрек икән, аягында үкчәсез кара итек икән. «Син кем буласың, ир-егет?» — дип сораучыларга: «Кавказ патшасының бахыр улымын мин»,— дип җавап кайтарган. Елгадай яшьләр түгә-түгә, хәлен сөйләп биргән. Тамган яшьләре туфракны көйдергән. Үтә дә аяныч, үтә дә яман булган икән моның хәлләре.

...Көннән беркөнне сары таң вакытында төрек патшасы Кавказ патшалыгына ябырылган да, сарайларын берьюлы көл иткән, патша муенына мәсхәрә бавы салган, кырык хатынын хур иткән, кырык кызын кол иткән, кырык улын җир иткән. Кырык беренче улы Исабәк, дөлдөленә атланып, тарлавыклар аша сикереп, төрекләрдән качып киткән. Иң соңгы тарлавык аша ыргыганда, менгән дөлдөле, хәле бетеп, упкынга мәтәлгән, ә сыбайлы, үз җиле белән очып, каршы ярга килеп төшкән. Менә шулай гына котылып калган Кавказ патшасының кырык беренче варисы.

Шушы әңгәмәне ишеткән кешеләр ул заман, Исабәккә кушылып, зар елаганнар. Еламаслыкмыни — Кавказ

патшалыгы шул хәлгә төшсен дә... Безнең типтәрләр патша кунакны, йола буенча өйдән өйгә йөртеп, хөрмәтләгәннәр, юатканнар, аның кайгысын уртаклашканнар. Йола тылсымының срогы чыгып, көче беткәч: «Нинди һөнәрең бар?» — дип сораганнар. «Сыбай чабам. Янә тимер чүки, калай тукый, кургаш коя беләм»,— дигән патша улы. «Атта без үзебез чабарбыз. Ә син чүке, тукы, кой,— дигәннәр безнекеләр.— Дан һөнәр». Әнә шуннан бирле чүки ул. Чәңчәк агай минем өчен серле дә, кызыклы да, хәвефле дә. Дустым Әсгать тә шундыйрак. Бүтән дөньядан килгән кешеләр миңа шулай гамь сала.

Калайчы Исабәк безгә урам аша тора. Үзенең балчык өендә ул көн буе чәң-чәк, чәң-чәк килеп, я бидрә төпли, я чүмеч саплый, я комган тоткасы ябыштыра. Шуңа күрә аңа Чәңчәк дигән кушамат тагылган. Күп вакыт исемен дә әйтеп тормыйлар. Чәңчәк дип кенә йөртәләр. Сабан сөрми, печән чапмый, урак урмый ул. Бар белгәне — шул калай чүкү. Хәтта Муса мулла җир сөрә, иген чәчә, ә ул чәчми. Чәңчәкнең үзеннән байтак яшь Әлифә исемле юан, ялкау хатыны бар. Хәтта өй кырындагы бәрәңгеләрен дә утамый. Көзгә чыккач, зарлана: «Котың булмагач ни... Шул бәрәңге дә игелек күрсәтми»,— ди. Кайчан карама, үзе бусага янындагы таш өстендә сагыз чәйнәп утыра. Я ямау ямаган була шунда. Әлифә үзебезнең авылныкы — Гафифә карчыкның кызы. Шулар инде балтырган җыеп йөргәндә, «кем зуррак» дип янәшә басып үлчәшкәннәр дә инәле-кызлы ызгышып киткәннәр. Инәсе: «Мин олы!» — ди икән. Кызы: «Мин зур!» — ди икән. «Инәй олы, мин зур»,— дигән сүз әнә шуннан килеп чыккан да инде.

Әлифә ике сүзнең берсендә зарлана: «Үтә бит яшь гомеркәйләрем заяга шушы Кавказ патшасының ак сакаллы йолкыш малае белән! Ун ел эчендә бер елак баладан башка нәрсә тергезде соң? Анысын да мин таптым бит әле». Иса юкта гына ул шулай сайрап кала. Ире алдында бик кычкырынып бармый. Ирне ир итә

белә. Кайчакта хәтта куштанланып та куя. «Калайны ничегрәк җырлатып биетә минем остам...» — дигән була. Ә инде бәйрәм көннәрендә Исабәк ике түшендәге буй-буй бөрмәләренә бармак буе ак чөйләр тыгылган билле кара җиләнен, бөдрә йонлы түгәрәк кара бүркен, үкчәсез кара итеген киеп, өй алдына чыгып басса, Әлифә сокланып туя алмый. «Ана, минем тау бөркетем нинди-рәк. Патша затыннан түгел дип кем әйтер? Бүтән кемдә шундый ир бар, мактанчыклар, юньсезләр, гыйбрәтләр? Сакалына да чал кермәгән, азрак көмеш кенә йөгертелгән...» Моны ул, күршесе Сәлимә ишетсен дип, юри кычкырып әйтә. Ачы телле, уңган Сәлимәнең ире Шаһиморат буйга бәләкәй, янәсе. Әлифә шуңа төрттерә. Чынлап та, бәйрәм чорында Исабәктән дә купшырак, килбәтлерәк, мәһабәтрәк ир күрмәссең авылда.

Иса белән Әлифәнең Нәсимә исемле имчәк балалары бар. Ул бишегендә я елап, я йоклап ята. Вәлетдиннәрдән кала минем икенче төягем — Чәнчәк өе. Җәйгә чыккач, көннең көнендә диярлек ук чүким мин шунда. Калай әзер, корал бар. Исабәк мине тиң күрә, серләрен сөйли. Нәрсәсенә тотынсам да ачуланмый. Ә хәзинәнең монда исәбе-хисабы юк. Бакыр заты дисеңме, тимере, җизе, чуены, кургашы дисеңме — җаныңа ни кирәк, бөтенесе дә бар. Теләсәң нәрсә яса. Әлифәнең бусага төбендә сагыз чәйнәп утырган чагында Нәсимә уянып китсә, мин аны тирбәтергә керешәм. Останың эшен бүлдертмим. Моңа аның күңеле була. Кайчак шартлап елаган Нәсимәне мин генә тыя алмыйм. Ул вакыт, эшен калдырып, бишек янына Чәнчәк үзе килә. Кайдандыр күкрәк төбеннән чыккан ягымлы тавыш белән татлы вәгъдәләр сөйләп, кызын юатырга тотына:

Әлли-бәлли, Нәсимә,
Баллы хөрмә мә сиңа,
Татлы йөзем мә сиңа,
Нурлы күзем Нәсимә.
Төрен ефәк йокыга,
Кер падишаһ йортына,

Тиен асыл бәхеткә,
Утыр алтын тәхеткә...
Әлли-бәлли, Нәсимә,
Ап-ак калач мә сиңа,
Майлы ботка мә сиңа,
Ай көндәше Нәсимә...

Ул шулай тезә дә тезә. Нәсимә сыйланмаган сыйлар, Нәсимә эчмәгән ширбәтләр, Нәсимә кимәгән киемнәр калмый. Хәтта минем дә авызыма сулар килә. Исабәк һаман туктамый. Байлыгының да, юмартлыгының да чиге юк аның. Туя белмәс Нәсимә генә һаман канәгать түгел. Акыра бирә.

Мине кинәт курку ала. Әгәр дә бәләкәй кызчык, бишегеннән сикереп торып, атасы вәгъдә иткән тәмлетатлы затларны таптыра башласа? Тик берсен генә таптырса да, харап булабыз бит. Мин беләм: бу өйнең шүрлекләре сый-хөрмәттән сыгылып тормый. Ярый әле Нәсимә болай гына, сүзсез генә елый. Бөтенләй тыяр әмәл калмагач, Исабәк елтырап торган кара арыш икмәген чәйни дә, чүпрәккә төреп, бала авызына тыга. Теге бер-ике тапкыр шыңшып ала да тына.

Баласын күтәреп, Әлифә браматка киткән чакларда, без сөйләшеп, серләшеп рәхәт чигәбез. Тик килгән-киткән генә сүзебезне бүлдергәли. Менә без әле икәүдән-икәү генәбез. Юк, әнә, кемдер килә. Ә, теге мосафир мулла икән ләбаса! Әнә, чапан чабуы киртәдәге ботакка эләкте. Исабәкнең капкасы юк. Капка урынында ботаклы-чатаклы бер киртә генә. Я аны аша атлап үтәргә, я астыннан чыгарга кирәк. Әле ботакка эләккән мулла узган атнакичтә дә бакыр комган калдырып киткән иде.

— Исабәк! — дигән иде ул.— Бер атнадан сугылырмын. Шушы комганны төпләп кенә куйчы. Ташларга кулым бармый. Әтием Исәнгол хаҗидан калган истәлек иде...

— Ярар, хәзрәт, башкарырмын,— дип алып калды

Исабәк. Комганны почмактагы калай-колай өеменә ташлады да азак үзе әйләнеп тә карамады.

— Исабәк агай! Теге мулла килә,— дип хәбәр салдым мин.

— Нинди мулла?

— Бакыр комган иясе.

Киртә төбендәге мосафир ботактан ычкынырга өлгермәде, Исабәк атылып урыныннан торды, почмактагы өемнән Исәнгол хаҗидан калган мирасны табып алды, янә үзенең бүкәненә утырды, тылсымлы коралы белән комганның төбен «ә» дигәнче каерып та ташлады. Нәкъ шушы мәл, тамак кыра-кыра, хәзрәт килеп керде:

— Әссәламәгаләйкүм, Исабәк оста!

— Вәгаләйкүм-сәлам, хәзрәт. Түрдән рәхим ит. Бик мактап йөрисең икән. Менә хәзер генә синең комганга тотынган идем. Әлегәчә кул тими торды, хәерсезең.

— Алай икән,— диде мосафир, түргә узмады.— Кайчан очына чыкмакчысың инде?

— Затлы нәрсә бит, хәзрәт, орды-бәрде эшләп булмый. Башта төпләргә, аннан кургашларга, аннан елтыратырга кирәк.

— Шулай да, Исабәк, күпмегәрәк сузылыр дисең?

— Иртәгә шушы вакытта коям да куям. Яңага алмаштыргысыз булыр.

— Көтә алмыйм. Иртәгә Чукраклы авылында бик зур җеназа. Ат җибәргәннәр.

— Алайса, иркеңдә, хәзрәт. Мә, комганыңны алып кит.

— Уеныңмы, чыныңмы бу, кем, Иса... Исабәк... Нишләп мин шундый дәрәҗәм белән төпсез комган күтәреп йөрим ди!

— Монысы да иркеңдә, хәзрәт...

— Иркеңдә... иркеңдә... имеш! Жулик, мошенник! Ярый, бер юлга каргамый торам, кулың коргыры, аягың тартышкыры нәрсә! — дип мосафир кинәт чәпчеп китте.— Мәлгунь! Килмешәк!

— Килмешәк дигәнең ни ул, хәзрәт, мәхәлләсез имам, төяксез брәдәк булып чыгадыр инде. Шөкер, минем атлап керер үз тупсам, баш терәр үз мендәрем бар.

— Тфү, бәдбәхет! — дип Исәнгол хаҗиның варисы, Кавказ патшасының варисына лач итеп төкереп, чыгып китте.

— Төкермә, төкермә, төкерегең үз битеңә чәчрәр, мулла шәрәмәте! — дип озатты мосафирны хуҗа. Ифрат кызу канлы ул Исабәк. Кабынып китсә, Әлифәнең йонын тетә. Тик тегесе генә әллә ни селкенми. «Я җитәр, чыж-пыж»,— ди иренеп кенә. «Чыж-пыж» диюе кызган безне суга тыгу булып чыга. Янәсе, уттай дөрләп торган Исабәк, бичәсенең салкын дәрьясына батып, «чыж-пыж»га әйләнә дә кала. Ә менә елак Нәсимә күпме генә теңкәсенә тимәсен, ачуланмый. Ачуы кабара башласа, Чәңчәкнең маңгай тиресе тартышырга тотына. Мосафир төкеренгәч тә, бер-ике тапкыр тартышып куйды. Имин. Җибәрде. Югыйсә ызгыш зурга китүе ихтимал иде.

Шулай да Исабәкнең дин әһеленә каты бәрелүе мине шомландырды. Әгәр дә ул каһәрли калса?.. Шул аркада Исабәк белән минем өскә җәза килсә?! Байтак заман без шымып утырдык.

— Изге кешегә тел тидергән өчен язык булмыймы ул? — дидем мин каушап.

Чәңчәк кулындагы җиз комганны әйләндергәләп карап утыра иде.

— Ярый, дуңгыздан бер кыл. Чын бакыр икән — гамәлгә ярар әле.

Мин һаман үземнекен талкыдым:

— Каргышы төшсә, нәрсә эшләрбез? Ул бит ходай юлында йөргән зат.

— Ул бичурага ходай юлы тагы! — дип мыскыллады Исабәк.— Әнә, ат карагы Исәнголның хаҗилыгы минем этиемнең патшалыгы белән бер инде ул...

Салды бу хәбәрне! Ничек йөрәге җитеп сөйли? Шушы

мәл Исабәк белән арабыз ераклашып киткәндәй булды. Соң, зиһен җитәрлекмени? Бер селтәүдә Исәнгол хаҗины да, мосафир мулланы да, үзенең патша атасын да сугып екты.

Ул торган саен аяусызрак ачышлар ясый барды.

— Монысы да анын Бохарада сәүдә итеп йөреп кенә мулла булып кайткан. Чапан киеп, чалма чалган, янәсе.

Безнең көннең көе китте. Мин, тешләремне кысып, ук чүкергә керештем. Исабәк, җиз комганны кире почмакка ыргытып, калай кисә торган кайчысын игәүләргә тотынды. Эш үрләми. Чүкеч белән бер тапкыр бармагыма да сугып алдым. Үзем һаман бер нәрсәне уйлыйм: нигә ул патша сынлы патша булган атасын ат карагына тиңли?

Чәнчәк эшеннән туктады. Көрсенеп куйды. Башын күтәреп, тәрәзә аша кайдадыр еракка карап торды. Мин дә шул якка төбәлдем. Күктә сыек болытлар ага иде. Әкрен генә тавыш белән Исабәк җырлап җибәрде. Элегрәк төн урталарында шуңа охшаш моң ишетелгәли торган иде. Кайдан килгәнен белми, өй эчебез белән хәйран кала идек. Менә кем җырлый икән ул.

Бер дә генә өер болыт каплый
Кавказ дигән тауның башкаен,
Туган илкәемне кайтып күрсәм,
Кочып елар идем ташкаен...

Менә сиңа Чәнчәк! Нindирәк җыр җырлый ул. Аны жәлләп, елап җибәрүдән чак тыелып торам. Шулай да хәленә кермәкче булам:

— Кавказ патшалыгыңны сагынып моңаясыңмыни, Исабәк агай? — дим.

Ул эндәшми. Мин аны һаман юатырга тырышам:

— Муенына мәсхәрә бавы тагылган патша этиеңне, хур ителгән кырык патша әниеңне, кол ителгән кырык патша апаңны, җир ителгән кырык патша агаңны мин

дә жәллим. Урыннары җәннәттә булсын! Ни кыласың, үлгән артыннан үлеп булмый. Һәркемнең үз гүре... Тереләр чыдарга тиеш...— Мин бөтен ишеткән-белгәнемне чәчеп салдым.

— Их, син, бәләкәч вәгазьче! — дип ул башымнан сыйпап куйды.

Исабәк яңадан минем якын кешемә әйләнде. Аның яшьле күзләренә карагач, күзләремнән мөлдерәп яшьләрем тәгәрәде. Бер тамчысы, «зың» итеп, алдымдагы ак калай кисәгенә тамды. Бәлки зыңламагандыр да. Тик миңа шулай ишетелде. Кавказ патшалыгының канлы кайгыларын уйлап, икәүләшеп, шулай яшь түгәбез.

— Минем турыда бүтәннәр теләсә нинди әкият сөйләсен, миңа барыбер. Ә менә синең гөнаһсыз күзләреңнән оялам. Бу күзләрне алдарга ярамый.

Исабәк әллә нинди сәер сүзләр сөйләргә кереште. Мине «гөнаһсыз» диме? Шәйхаттар белән кәрт сукканымны белсә икән...

— Патша малае түгел, качкын мин! — дип кырт кисте Чәнчәк. Бу сүзләр минем колагымны өтеп алды.

— Качып котылгач, качкын була инде,— дип төзәтеп аңларга тырыштым мин. Төзәтмәне ул кабул итмәде.

— Качкын! Йоласына, ыруына хыянәт иткән мөртәт мин! Гаделлек, шәфкатьлелек, аек акыл яклы бер изге затмын мин! Җаным шулай икегә бүленде. Гомер бакый ике ярты бер-берсен каргап яшәде. Бу дөньяда да, теге дөньяда да килешү, кавышу юк аларга. Чөнки аларның берсе балыкка, икенчесе кошка әверелде. Ә Кавказ патшалыгы исә — фаҗигале матур төш кенә. Ә ул төшне дә үзем түгел, минем өчен бүтән кешеләр күрде — теге заманнарда. Иртән торып сөйләделәр дә миңа юрадылар. Мин төшне кире какмадым. Бара торгач, хәтта үзем дә ышана башладым. Китте шуннан Кавказ патшалыгы турындагы коточкыч әкият!..

Менә сиңа өч төймә!

Эчемнән генә шулай дип әйтүем булды, Нәсимәне

акыртып, Әлифә кайтып та керде. Әңгәмә, Исабәк җаны кебек, бүленеп калды.

Өзелгән сүз тик биш-алты ел узгач кына ялганды.

Авылыбыз колхозга кучте. Кайсыдыр бер хәтерлесе Исабәкнең әллә егерме, әллә егерме биш ел әүвәл әйткән «атта чабам» дигән сүзен хәтергә төшергән. Колхоз елкысын көтәргә төнге көтүче тәгаенләгәндә, әлеге зиһенле адәм әйткән ди: «Җәмәгать! Безнең Исабәк сыбайлы бар бит! Намуслы, тугры кеше. Әйдәгез, бу эшне шуңа тапшырыйк! Кулы тигәндә, көндез үз кәсебе белән дә булыр! Көн иткән илгә ул һөнәре дә кирәк». Халык дәррәү ризалашкан. Халыктан болай Исабәк үзе риза булган.

Сакал-мыегына нык кына чал кергәч, Кавказ сыбайлысы яңадан ат менде. Тәүге көн ул, менәсе атын җитәкләп, өенә кайтты. Өйгә кереп, үзенең артыннан килгән теге купшы киемен баштанаяк киеп чыкты. Өзәңгегә сул аягын тыгып, җәһәт кенә ияргә сикерде. Онытмаган икән. Һәммә кыланышы килешеп тора. Көмеш кынлы озын хәнҗәр тотып, Әлифә дә килеп чыкты. Хәнҗәр! Монысы — Исабәк алачыгында күргән нәрсәбез түгел иде. Хәер, без күрмәгән нәрсә азмыни?

— Әй, атасы! Нәсимәнең атасы! — дип сөрәнли Әлифә, Сәлимәләр ягына карап.— Көмеш хәнҗәреңне тагарга оныткансың бит!

— Китер, бичәкәй, бик мәслихәт булыр...

Көмеш кынлы озын хәнҗәр сыбайлының биленә тагылып та алды. Мондый мәһабәт атлыны бүтәнчә күрсәң дә, картинкада гына күрергә мөмкин. Исабәге ат өстендә утырып, Әлифәсе җирдә торып рәхәт чигә. Нәсимәсе, бусага ташына басып, чәбәкәй итә. Менә кайчан ул Чәнчәк курасында куаныч тулып ташты. Ат башы чаклы алтын тапканнармыни. Гомер буе бөкрәеп калай чүкегән кеше ничегрәк тураеп китте. Моңа кадәр Исабәккә чак кына һаваланып, чак кына мыскыллап, чак кына кызганып караган күрше-тирә, сокланып, таң

калды. «Менә ниндирәк ул — безнең күрше!» — дип тел шартлатучылар да булды. Шушы сәгатьтән алып гомеренең ахырына кадәр ул иярдән төшмәде.

Соңрак ике җәй тоташ мин Исабәккә елкы көтештем. Иң күркәм заман Дим тугаенда печән җыелып беткәч килә. Әле кичләр салкын түгел. Ә чебен, черки, кигәвен заты инде интектерми. Яшел, йомшак курпы ат авызында үзе эреп тора. Дим суына көзге тәм кайта. Эчеп туйгысыз. Шундый кичләрдә без көтүне я Барлыбай утравына, я Капкалы эченә куып кертәбез дә Димнең ярында гына учак ягып җибәрәбез. Таганга чәйнек асабыз, көлгә бәрәңге күмәбез. Һәр урында безнең әзер таганыбыз бар. Эңгер төшкәләгәнче, Исабәк төрле җиргә таралышкан атларны яңадан барлап, һәркайсының диярлек хәл-әхвәлен сорашып чыга. «Йончыта төшкәннәр, ахрысы, үзеңне бүген, Җирәнкәй... Ә син, Бурыл, хәйләкәр, бирешмәгәнсең. Картлач Кашка бүген ял иткән икән...» — ди ул. Бу атларны көндез җигеп йөргән кешеләрне я мактый, я хурлый. Колынкайларны муеннарыннан кочаклап ала, йомшак ялларын сыйпый, сөя, һәр хайванның үзенә генә төбәп, яхшы сүз әйтә. Кызу канлы Чәңчәкнең шушы ике җәй эчендә бер елкыга, бер колынкайга ачуланып эндәшкәнен ишетмәдем. Гадәттәге көтүче коралы чыбыркыны ул кулына да алмады.

Һәр кич, шулай көтүнең кәефен, хәл-әхвәлен белеп чыккач, үзе айгыры Дәрман янына килеп, ирләрчә әңгәмә алып бара. Нәрсә сөйләшүләрен ишетеп булмый, бик шым сөйләшәләр. Соңыннан Дәрман, ризалык белдереп, баш кага. Күрәсең, килештеләр, мәслихәтләштеләр. Баш көтүче үзе башлыгына, димәк, төнге киңәшләрен бирде. Тегесе кабул итте.

Эңгер төшеп бетә. Чәй кайнап таша. Бәрәңге пешеп өлгерә. Баш көтүче шунда гына учак янына килә.

Ике җәй буе сөйләшмәгән сүз, җырланмаган җыр калмады. Исабәккә, бигрәк тә утка бакса, моң килә. Ләкин ул үзе-үзе болыт каплаган Кавказ тавы хакын-

дагы моңны да, Кавказ патшалыгы турындагы әңгәмәне дә кабатламады. Мин сорашырга кыймадым. Бер төнне ул, сүрелә башлаган учакка карап, кинәт көрсенеп куйды:

— Шушы учак янында без синең белән икәү генә утырабыз дисең инде. Юк, икәү генә түгелбез. Әнә, утның теге ягында минем егет чагым басып тора,— дип төнге бушлыкка ымлады.— Якында гына төсле. Ә ике арада көйрәп торган учак. Ике арада — узган гомер...

Мин инде аның кинаяле сөйләвенә күнегеп беткәнмен. Кысылырга ашыкмыйм. Үзе очын китереп чыгарыр әле.

— Бахыр егет чагым — батыр егет чагым... Әйе, корал күтәрер өчен генә түгел, күтәрелгән коралны тыяр өчен дә батырлык кирәк.

Монысы инде миңа бөтенләй аңлашылмый. Селтәнгәч — кылыч чабарга, төбәлгәч — мылтык атарга тиеш. Мин егет корына кереп барам. Батырлыкның нәрсә икәнен аңлыйм.

— Нигә килгән монда синең егет чагың? — дидем мин, Исабәкнең сүзенә җайлашып.

— Синең белән күрешергә, танышырга. Таныштырсам, кабул кыларсыңмы, әллә, каһәрләп, яныңнан куарсыңмы?

Мин, ни дип әйтергә дә белми, шымып калдым.

— Шулай да таныштырыйм әле...

...Унике яшем тулганда, карымтачы[1] минем агаемны үтерде. Өй эчендә ир затыннан иң өлкәне мин торып калдым. Әтием төрек сугышында гаеп булган иде. Үч алу минем өскә төшә. Карымтачының елга-ел, айга-ай, көнгә-көн миңа яшьтәш улы бар. Боташ исемле. Унжидебез тулган көнне, мин аны үтереп, үч кайтарырга тиешмен. Йола шулай куша. Әгәр карымтачының үзен юк итсәң, ул үлә дә котыла, ә менә улсыз калдырсаң,

---

[1] Карымтачы — кан дошманы.

гомер буе газап чигәчәк. Без газап чиккән шикелле. Ул мәлдә тау итәкләрен каплап өрек агачлары алсу-ак чәчәк аткан булыр, куаклар арасында, ярсып, кошлар сайрар, язгы моң чыгарып елгалар чылтырар, тәңре яраткан һәммә җан иясе, тереклек кылуына шөкер итеп, рәхәт чигәр. Нәкъ шушы мизгелдә караңгы бер төндә минем хәнҗәрем Боташ йөрәгенә кадалыр. Айдан-ай, көннән-көн мин аңа карата үземдә үч яндырдым, нәфрәт үрчеттем. Кыл ярырлык шушы хәнҗәремне биш кыш, биш җәй буе кайрадым. Очына чебен кунса, үтә тишеп чыга торган иде. Тәүдә елларны, аннан айларны, ахырда көннәрне саный башладым. Һәр көн Боташның әҗәлен якынайта. Тәкъдир сәгате сугар да, менә мин җан алырмын, Боташ җан бирер. Карымтачының каны җиргә сеңәр, алган үчем миңа гомерлек гайрәт китерер, рухыма көч өстәр.

Боташ арык кына малай иде. Җитмәсә, аксак. Бәләкәч чагында сакля түбәсеннән егылып имгәнгән. Шуңа карамастан, ачык йөзле, шаян табигатьле, хөр күңелле иде. Явыз, тискәре, ямьсез булса икән! Әмәлгә калгандай, андый түгел шул. Уен вакытында бөтен малайлардан болай аның шат тавышы яңгырый. Мин якыная башласам, ул кинәт тына, йөзе көл кебек була. Әҗәлен сизә. Буйга җиткәч, ул мәйданнарда оста бубен кагучы, уен, җыр башлаучы булып китте. Мәйданга мин килеп керсәм, ул, каушап, кеше артына поса, аннан, аксаклап, өе ягына юнәлә. Әҗәлен сизә.

Боташның атасы — минем карымтачым, кыр кәҗәсе аулаганда кыядан егылып, җәһәннәмгә китте. Аны, буркасына ураган көе, ияргә аркылы салып, авылга алып кайттылар. Боташ ат җитәкләп килә иде. Юлда мин тап булдым. Ул тәүдә башын түбән иде, аннан читкә борылып, узып китте. Бер мәет ат сыртында тирбәлеп бара, икенчесе, тезген тотып, сукмактан атлый. Аңа да атларга күп калмады инде... Боташның миннән тартынуы шулай да гайрәтемне кайтара, нәфрәтемне сүрелтә.

Әмма мин бирешмим. Әледән-әле билемдәге хәнҗәремне капшап куям. Үчем янә гөлт итеп кабынып китә.

Өрек чәчәк атты. Биш ел буе көтеп алган көн килде. Гөнаһ шомлыгына, төн мин көткәнчә караңгы булмады. Үтәдән-үтә күренеп торган айлы төн килде. Көндез Боташ Түбән Бигимгә базарга киткән иде. Әле кайтканы юк. Мин, авылдан чыгып, аның кайтыр юлында таш арасына постым. Айлы төн болай да минем зиһенемне ала. Әллә нинди ырымы бар аның. Дөнья телдән язган диярсең — шылт иткән нәрсә юк. Ә әнә тегендә тау киртләченә кыр кәҗәсенең баласы килеп чыкты. Инәсе күренми. Бичаракай, әллә адаштымы икән төн йөзендә? Ары карый, бире карый, тавыш бирер иде, бүредән курка. Бәлки, аны якында гына ата бүре сагалап ятадыр. Менә бер генә сикерер дә буып ташлар. Бар иде бу дөньяда матур кыр кәҗәсе, хәзер юк булачак... Шөкер, кәҗә баласы имин-исән көе үз юлына китте, бүре-фәләнгә хәзергә тап булмады. Ләкин ата бүре барыбер кайдадыр посып ята бит. Шушы бәрән, күңелемне кузгатып, шом салды. Мин кайсысы булып чыгам соң әле? Әнә теге гамьсез, исәр кыр кәҗәсе баласымы, әллә шуны сагалап яткан бүреме? Моңа мин тиз үк җавап бирергә тиешмен. Югыйсә, әнә, Боташның арбасы шыгыр-шыгыр-шыгыр килеп, болай табан үрмәли. Җавабымның кирәген, тапкырын суырып алмакчы булып, хәнҗәрем сабына кул сузам. Кулым тыңламый, тартыша. Арба һаман шыгыр-шыгыр минем өскә тәгәри, үгезләр мышный-мышный минем өскә килә. Боташ, арттан арбасын этәреп, арыган хайваннарга булыша. Аксак булгач аңа, мөгаен, кыендыр. Юлның бу текә җирендә мин үзем дә шулай үгезләремә ярдәмләшәм. Әле дә арба артындагы кеше Боташ түгел, мин үзем, имеш. Мин таза, көчле. Миңа берни дә түгел.

Башымда бөтен нәрсә берьюлы килеп буталды — гамьсез кыр кәҗәсе баласы, ата бүре, үгезләр, ай, аксак Боташ, үзем... Арба һаман шыгырдый. Боташ һайт-

лап малларын әйди. Тау түбәсендә акылдан шаштыргыч түгәрәк якты ай тора. Ай нурында өрек чәчәкләре җем-җем итә. Җан ала торган төнмени бу? Җан өләшә торган изге мәл бит!.. Мәрхүм агаемның коелган канын ярдәмгә чакырам. «Үч! Үч!! Үч!!!» — дип кабатлыйм. Колагымда ыруымның каһәре яңгырый, куркаклыгым, йола бозуым өчен ул мине каргый. Янә хәнҗәремә үреләм. Кулым бармый. Теге тау киртләченә баягы кәҗә баласы тагы килеп чыкты. Шыгыр-шыгыр итеп Боташ арбасы янымнан узып китте. Боташ үзе гыжнап төшкән, тынын чак ала...

Карымтачым авылга кереп китте, туган өемә минем юлым киселде. Чөнки мин йолабыз ярлыкамый торган хыянәт кылдым. Корбанымны йолып, кайтып керсәм, ыруым мине кабул итмәс иде. Ләгънәт укып, илдән сөрер иде. Ә мин үземне-үзем сөрдем.

Агаемның кайтарылмаган үчен намусыма алып, бик күп заманнар ил гиздем. Карт әтием һөнәре — калай белән чүкеч миңа ризык бирде. Байтак еллар оясыз-илсез йөргәч, шунда килеп төяк таптым. Оям башта салкын, котсыз иде. Күреп торасың, картлык көнемдә төягемә кот иңде, замана атка мендерде мине...

— Менә, энем, учакның теге ягында басып торган егет шушы инде,— дип Исабәк баягыча ук төнге бушлыкка ымлады. Миннән җавап көтте. Мин эндәшмәдем. Нәрсә дип сүз кушыйм соң?

...Мин авылдан киткәч тә, Исабәк атларын ташламады. Район газетасында хәтта аның исемен ташка басып чыгардылар. Эше белән беррәттән аның намусын мактадылар. Фронтта чагымда авылга хат язган саен, күрше-күләнгә аермыйча сәлам җибәргәндә, Исабәккә мин һәрчак атап сәлам күндердем. Ул да сәлам кайтара торды. Инде сугыш бетә дигән язда күршемнең сәламе урынына үле хәбәре килде. Теге кара хатта болай диелгән иде: «Бик зур кайгылы булып торабыз әле. Исабәк күршебез үз аягы белән дөньядан китеп барды.

Димдә боз кузгалган чакта Капкалы эчендә елкы көтеп йөргән җиреннән суга батты. Яр буенда гына сикергәләп уйнаган бер колынкай суга егылып төшкән икән дә, Исабәк күршебез, шуны коткарам дип, боз арасына ташланган, колынкайны барып тоткан, әмма ярга кире чыга алмаганнар. Кочаклашып боз астына кереп киткәннәр. Ул җирдә чоңгыллар күп шул. Белмәгәндер, күрәсең, мәрхүмең... Әйбәт кеше иде. Гәүдәсен таба алмадык. Үзе урынына теге артыннан килгән җиләнен, бүреген, итекләрен, хәнҗәрен, янә утырып йөргән иярен җирләдек. Җеназада халык бихисап булды. Әлифә тәгәрәп елады...»

Шулай итеп, Исабәк күршебез, Дим бозына ияреп, мәңгелек сәяхәтенә йөзеп киткән.

...Исабәк теге заман учак янында үзенең егет чагы белән мине очраштырыр алдыннан болай дигән иде: «Кабул кыларсыңмы, әллә югыйсә, каһәрләп, куарсыңмы?» Аның тарихын тыңлагач, мин җавап кайтармаган идем. Кешенең гомерлек кичерешләренә кысылырга әле минем хакым юк.

Кайтмаган үч... Сугышның тәүге елларында, илебез газапларыннан җан әрнегәндә, солдат киеме кигән һәрбер немецны биш тапкыр үтерерлек үч йөртә идек күңелдә. Үтерергә! Мылтык аткан чагындамы, йоклаган, ашаган, гыйбадәт кылган җирендәме — үтерергә! Ак чәчле картмы яки мыегы да чыкмаган селәгәй малаймы — үтерергә! Берне генә булса да — үтерергә! Бу нәфрәтне безнең күңелгә алар үзләре салды. Без тумыштан кансырау түгелбез. Канлы барымтаны [1] алар үзләре башлады. Бөтен нәсел-нәсәбе хәзер аяусыз карымта көтсен! Берсенә дә аяу юк.

Ә менә кояш чыгып килгәндә, бөтен өметләрен өзгән бер пар зәңгәр күз сиңа ялварып караса, шушы мәл ку-

[1] Барымта — талау явы.

куруз кыякларыннан, күз яшьләренә охшап, елтырап чык тамып торса, дөньядагы бөтен авазлар тынып калган булса, кеше маңгаена төзәп мыктык ату мөмкинме соң? Мөмкин түгел икән.

Минем белән нәкъ әнә шундый хәл булды.

Яссы — Кишинев сугышларында дошман гаскәрләре чамасыз кырылды. Яу барган көннәрдә шушы яланнар өстендә иртәдән кичкә кадәр тузан катыш төтен болытлары асылынып торды. Бер тәүлек әүвәл сугыш бу җирдән ычкынып, оча-җилә Прут ярларына табан юнәлде. Ялга чыккан ротаның командиры кояш баер алдыннан мине — фронт журналистын — кичә яу узган кырны күрсәтергә алып килде.

— Сугыш барганда аны күреп булмый, узып киткәч кенә нинди мәхшәр булганын аңлыйсың,— диде ул. Әйе, моны мин үзем дә беләм. Әнә, немец армиясенең, әйтерсең, ярты коралы шунда торып калган. Җимерек танклар, орудиеләр, минометлар, автомашиналар, тракторлар... Исәбе дә, саны да юк. Элекке көн атлы артиллерия дивизиясе дә кыйратылган иде. Әле менә я иярле, я камытлы атлар кукуруз басуын кыдырып йөри. Безне күргәч, кешни-кешни, арттан иярә башладылар. Дөмегеп өлгермәгән фашист имгәкләре дә шушы кукуруз арасында посып ятадыр әле. Тик чыгып иярмиләр генә.

Без шоферның үзен генә җибәреп, атларга менеп алдык. Миңа тимер күк бия эләкте. Безгә ияреп, авылга бер өер ат кайтып керде. Авыл читендәге бер өй каршысында ике-өч солдат, зур табактан кружкалар белән сосып, яшь вино эчеп утыра иде. Солдатлар янына килеп туктагач, минем биям, башы белән тегеләрне төрле якка этәреп, табактагы винованы чүмерергә кереште. Шунда гына без атларның эчәсе килгәнен аңладык. Сусаган елкы малы үзе шулай кешегә тартыла икән. Без өерне кечкенә генә елга буена ияртеп төштек. Атлар эчеп туй-

гач, шунда аерылыштык та. Миңа үзебезнең редакциянетиз үк куып җитәргә кирәк иде. Аның Белград дигән калада тукталачагын беләидем. Картага карыйм. Әгәр олы юлга кире чыгып, урап барсам, ике тәүлектә дә куып җитәчәк түгелмен. Кабат авылга кайтып, бер молдаван картыннан туры юл сораштым. Ул бик ихлас һәм ачык итеп аңлатты. Бабай өйрәткәнне карта белән чагыштырып алдым. Бөтенесе дә туры килә.

— Бу юл аулак булыр. Сак йөре,— дип теләп калды ул.— Насыйп булса, иртәгә кичләтеп барып та җитәрсең. Әмма юлда атыңа ял бир.

Эңгер төшкәндә, үземне язмышка тапшырып, сәфәр чыктым. Иксез-чиксез кукуруз урманы эченнән тар гына юл сузыла. Ай калыкканда, бер бәләкәч кенә утарны үттем. Аннан элекке еврей авылын уздым. Юлым бабай әйткәнчә килә. Дөнья тынганнан-тына бара. Ул тынган саен, эчтә шом арта. Сугыш мәлендә тынлык һәрвакыт хәвеф сала. Ай яктысы да әллә ничек күңелне әлсерәтә. Гомеремдә беренче тапкыр бөтен җиһанда ай белән икәүдән-икәү генә торып калдым. Аның ырымына бирелсәң, башны югалтырга мөмкин. Бу еллар эчендә сугыш кырында дуамал ярсу да, хурлыклы курку да кичерелгәндер. Ләкин бүген кичергән хәл бөтенләй башка. Тынлыктан шикләнү бизгәге эләктереп алды мине. Ярый, менгән биям акыллы, сизгер, шул ук вакытта сабыр булып чыкты. Һәр карачкыдан өркеп бармый. Хатын-кыз заты шул.

Таң алдыннан йокы баса башлады. Ничәмә еллардан соң беренче тапкыр өзәңгегә баскан аякларым да авырайганнан-авырая бара. Балтырларымны, очаларымны ияр кырды. Биям, киресенчә, җегәрләнеп китте. Аратирә юырткалап та куя. Әллә, Германиямә кайтып барам, ди инде? Мин йокы белән алышам. Бер ул өстен чыга, бер — мин. Ай яктысы, эреп, югала башлады, аны туып килгән көн яктысы кысрыклый. Ай яктысы үз уры-

нын болай гына бушатмый. Тартыш китә. Ике яктылык бер-берсен йотарга керешә. Яңадан эңгер төшә...

Башын кинәт артка чөеп, атым шып туктады. Мин сөрлегеп киттем. Алдымда гына зур түгәрәк кояш тора. Күрәсең, шуңа килеп төртелгәнбездер. Кояш ары тәгәрәп китте. Юлдан бер-ике адым эчтә, кукуруз арасында, нечкә генә муенга утыртылган кәпәчсез сарыбаш серәеп тора. Бүтән нәрсә шәйләмәдем. «Ә» дигәнче пистолетымны суырып алып, буй-буй кара тир юллары ергычлаган маңгайга төзәдем. Шул чакта гына маңгай астындагы бер пар зәңгәр күзне күрдем. Бу күзләрдән хәтта курку да качкан. Бары ялвару гына торып калган. Менә хәзер ул бераемләп әсир төшкән һәр немец солдаты әйтә торган дүрт сүзне кабатлар: «Сталин корош, Гитлер капут!» — дияр. Мөгаен, шулай дияр. Әгәр шулай дисә, валлаһи, курокны тартам. Җан саклар өчен әйтелгән шушы ялган тәүбә отыры чиркандыра, отыры нәфрәтне арттыра.

Бу һаман эндәшми. Хөкем көтә. Ул — илбасар. Мин — ил хуҗасы. Нинди хөкем чыгарсам да хакым бар. Һәм гадел дә булыр. Приговор минем пистолет көбәгендә.

— Миңа унсигез генә яшь...— диде ул. Тез буыннары сыгылып, чайкалып китте, ләкин аумады.

...Кинәт хәтеремә бер вакыйга килеп төште. Моннан ике ел әүвәл унсигез яшьлек механик-водительне, дезертирлыкта гаепләп, бөтен бригада алдында аткан иделәр. Дезертирлыгы шул иде: резервта торган чакта төнен танкка утырган да ун километр җирдәге авылга әнисен күрергә барган. Шуның өчен үлем җәзасы бирделәр. Ул көн унсигез яшьлек егеткә төбәлгән автоматлар безнең һәрберебезнең эчендә яткан гамьсезлекне, мәнсезлекне, җавапсызлыкны бер катардан атып үтерде. Үз кешебезгә карата булган аяусыз хөкемне мин шуның белән аңлаттым. Акламадым, аңлаттым. Асылда

механик-водитель бер зыян да итмәде. Тик әнисен генә күреп килде. Килгәч — аттылар.

Каршымда фашист гаскәренең киемен кигән, кичә генә минем ватандашларыма төзәп аткан дошман, минем кан дошманым басып тора. Шуның аталары, агалары бит инде Смоленщина авылларын тоташ утка үртәделәр, Донбасс шахталарында меңәрләгән кешеләрне тереләй күмделәр, елга-елга яшьләр түктереп, Украина кызларын Германиягә коллыкка олактырдылар, аналарның чал чәчләрен мәсхәрә иттеләр, сабый балаларны ялкынга ыргыттылар. Боларның бөтенесе өчен дә кемнән үч алырга соң? Зәңгәр күзле сары шайтан, ишетәсеңме? Кемнән үч алырга?

Минем уйларымны ул ишетми. Югыйсә күзләрендә өмет яралмас иде. Шул күзләрдәге өмет минем иңнәремне баса. Кукуруз кыякларыннан мөлдерәп чык тамчылары тама. Җир йөзе шундый тыныч, аяз, ваемсыз. Әйтерсең, аның үткәне юк, тик киләчәге генә бар. Мин дертләп киттем. Дөнья ничектер сәер җемелдәп куйгандай булды.

Пистолетымны җан ачуым белән кире кобурага тыктым.

— Әйдә, алдан атла! — дидем, юлга ымладым. Ул, аксый-аксый, алга чыкты. Башкача мин аңа сүз дә кушмадым, йөзенә дә карамадым.

Олы юлга чыкканчы без шулай килдек. Кояш инде байтак күтәрелде. Юлда очраганнар безгә аптырабрак карап уза. «Кошның асылыдыр, күрәсең, бу. Берүзенә бер сакчы...» — диләр, мөгаен. Бер күпер төбендә әсирләр колоннасына каршы очрадык. Конвой башлыгы сержантка «үземнең» әсирне тапшырдым. Тапшырганда, болай дип кисәттем: «Аксак дип, юлда алай-болай итмәгез». Нигә шулай әйткәнмендер, белмим. Бер котылгач, иленә кайтып җитсен, дигәнмендер, бәлки. Бәлки... Юк, әйтеп кенә аңлата торган нәрсә түгел бу.

Бояр балалары

Әүвәл-әүвәлдән безнең авылга, савым бияләре тоткан кешеләргә, кымыз эчеп, ит ашап ятарга төрле түрәләр килә торган булган. Әле дә шулай. Бичә-чәчәсе, бала-чагасы белән кыл да кыймылдатмый җәй буе рәхәтләнеп яши бирә тегеләр. Безнекеләр аларны «боярлар» дип йөртәләр. Бояр булмый, тагы кем булсын. Йокылары туйганчы йоклыйлар, эчләре күбенгәнчы кымыз эчеп, ит согыналар, аннан көтүләре белән я урманга, я тау ягына сәхрәгә чыгып китәләр. Хәтта сәхрәдә дә алар кыланып туймыйлар, үлән өстенә япма җәеп кенә утыралар; янәсе, безнең үлән аларның ниен... тәнен чәнчә, күлмәген пычрата. Бичәләре баш өстендә чатыр тотып йөргән була. Имеш, безнең кояш аларга килешеп җитми. Явым булса, тегеләр, өндәге йомраннар шикелле, капкадан баш тыгып карыйлар да кире курага чумалар. Бик таман аларга! Ул боярлар белән минем үземнең исәп-хисабым бар. Сәке өстендә ашап утырганда чак кына кырын ята биреп куйсам, әтием: «Туры гына утыр. Бояр булдыңмы әллә?» — ди. Иртән озаграк йокласам, Олы инәем: «Шулкадәр йокларга — каян килгән бу бояр?» — ди. Мортаза агаем йомыш кушканда, иренсәм: «Шундый сүлпән кузгала, әйтерсең, бер бояр». Бәләкәйрәк чагымда шул бояр белән битәрләп, бигрәк тә тәкатемә тияләр иде. Хәзер бер чама басыла төштеләр, бәлки, үземнең дә боярлыгым кимидер.

Байтак адәмнең ел да диярлек килеп йөри торган үз бояры бар. Безнең бервакытта да боярыбыз булмаган. Мөгаен, минем хөр рухлы әтиемнең үз ирке белән кемгәдер олтырак буласы килмәгәндер. Яки болай гына кеше көйләп, үзен бимазаларга теләмәгәндер. Бәлки, безнең өебез, без үзебез ул боярларга ошамагандыр. Кыскасы, үз боярыбыз юк безнең. Булмасын, бик әйбәт. Кеше боярының теңкәмә тигәне дә җиткән.

Муенга кызыл галстук тагып, бөтендөнья революциясе өчен җанны аямаска ант иткәч, без — малайларның әлеге боярларга ачуы отыры кабара төште. Без хәзер яхшы беләбез: төрле байгуралар, боярлар, түрәләр элек халык җилкәсен кимергән, кеше ризыгын ашаган, ә хәзер соң болары, кала боярлары, берни эшләми тыгынып ятмыймыни? Безгә шуларны Сәфәргали исемле малай төшендереп бирде.

Безнең хәзер башлыгыбыз икәү: урамда — Шаһидулла, пионерда — Сәфәргали. Шаһидулла аңа ара-тирә бәйләнмәкче дә итеп куя, ләкин теге, галстугының бер очын тота биреп: «Тиеп кара, башың ике булса...» — дип кенә җибәрә, ә Шаһидулланың башы чаясын чая, әмма икәү түгел, берәү генә.

Сәфәргали Губернатор урамында Әсгатьләргә каршы гына тора. Вәлетдиннекесыман, аның да атасы герман сугышыннан кайтмаган. Алар әнисе белән икәү генә көн итәләр. Пионерда башлык булганчы Сәфәргали гел сукрана, үзен жәлләтә торган иде. Ук атканда, угы сәпкә [1] тимәсә, ул: «Бәхетем юк шул минем, бәхетем булса, этием дә германда калмас иде»,— дип зарлана. Берәр уен башлар алдыннан шобага тотканда, ул аска калса: «Котым булса, мин Сәфәргали дә булмас идем»,— дип елар чиккә җитә. Былтыр яз Акманайда икәү балык каптырганда, моңа нишләптер адашып зур сыла килеп эләкте. Балыкны ул кабалана-кабалана ярга кадәр тартып китерде. Сыланың сырты судан яртылаш калкып чыкты. Балыгы дан иде. Колачка ук җитмәсә дә, беләк буе булыр. Сәфәргали күл гыйфритенең саңагыннан кулы белән җай гына эләктереп алырмы дисәм, ул кинәт, гөрс итеп, корсагы белән суга, сыланың өстенә сикерде. Сәфәргали белән бер катардан балык та сикерде. Сикерде дә, кармакны өзеп, күл төбенә чумды. Сә-

[1] Сәп *(башкортча)* — цель.

фәргали кулларын беләк төбенәчә суга тыгып, камыш арасында байтак бутанды. Азактан ярга чыгып утырды да елый-елый зарланырга кереште: «Әгәр дә минем бәхетем булса, немец ядрә коймас иде, герман сугыш ачмас иде, әтиемә төзәп атмас иде... Бөтенләй капмасаң, ыһ та итмәс идем, и сыла! Нигә шулай ымсындырып кына калдырдың мине?! Нигә шулай һич кенә дә кызганмыйсың мине? Син кызганыр булсаң, әтиемне патша да алмас иде, иңбашларына мылтык та салмас иде, башкайлары чит җирләрдә ятып та калмас иде...»

Вәлетдин белән Сәфәргали ике туган балалар. Аларның хәсрәт-зарлары да бертөсле — йөрәкне көйдереп, әрнетеп ала. Миндә дә балык кайгысы калмады.

— Әйдә Болау күленә, Сәфәргали, анда табан илереп каба,— дигән булдым мин.

— Безгә дигән кояш кайда да бер...— дип көрсенде ул.

Пионерда башлык булгач, шушы Сәфәргали үзгәрде дә китте. Адымын ашыкмый атлар, сүзен чамалап сөйләр булды. Үзе генә түгел, хәтта муены да озынайтөште аның. Без күрмәгән нәрсәләрне күрә, без белмәгән әллә нинди нәрсәләрне белә, без укымаган китапларны укый. Чит илләрдә бала-чага ничек кыен яшәгәнен, байлар ярлыларны ничек җәберләгәнен, үзе барып карагандай итеп, бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Әллә кайдагы, җир аягы җир башы җирдәге боярларга, байларга, буржуйларга безнең ачуыбыз көчле, үчебез чамасыз, ләкин үзебезнең боярларны да үч һәм нәфрәттән өлешсез калдырмыйбыз. Хәлдән килгәнчә, мазаларын алып, тәкатьләренә тиябез тегеләрнең. Караңгы төшкәч, алар йоклаган йортның бүрәнәсенә гөп-гөп таш бәрәбез. Урамда үтеп барсалар, юри эт өсләтәбез. Шулай да әлегә кадәр бояр балалары белән күкрәккә күкрәк килеп, алышка чыккан юк, ә алышасы килә. Күп тә үтми, дошманнан үч алу сәгате җитте.

Чокыр аръягы Миңнуллаларга ирле-хатынлы яңа

бояр килде. Янә минем чаклы бер малайлары, миннән кечерәк кызлары бар. Малае кыска балаклы зәңгәр чалбар, кызы тезенә дә җитмәс чәчкәле күлмәк киеп йөри. Малайны без «Салам сыйрак», кызын «Чикерткә» дип атадык. Малаеның сыйраклары чынлап та салам юанлыгы гына, тубыклары да салам буыны хәтле генә. Кызы торганы белән бер чикерткә: атлаганда да сикерә, йөгергәндә дә сикерә, тик торганда да сикерә.

Болар иртән иртүк дүртәүләп, кәрзинкәләр тотып, Губернатор урамыннан тау ягына чыгалар, кич кенә урап кайталар. Салам сыйрак белән Чикерткә аталарыннан тотам да калмый. Чикерткәсе бер хәл. Безгә аның Салам сыйрагы кирәк. Тәүге көннәрдә без, я Әсгатьләр, я Сәфәргалиләр өе артына посып, тегеләргә мәсхәрә яудырдык:

— Бояр, бояр — хәлдән таяр!

— Әй, бөлгән бояр, ыштан балагыңа ситсаң җитмәдемени?

— Әй, кибеп какланган боярлар, тау башында җил йотып симерәсезмени?

Безнең сыйнфый дошманнарыбызның дүртесе дә нишләптер үтә арык, үтә зәгыйфь иде.

— Кешеләрне күп рәнҗеткәннәр алар, шуңа күрә үзләренә ит кунмый,— дигән нәтиҗә чыгарды Әсгать бу җәһәттән.

— Синең дә маең ташып бармый,— диде Сәфәргали.

— Миңа ашау җитми... Боярлар кебек тыгынсам, корсагымнан май тамып торыр иде минем.

«Эт өрер, бүре йөрер» дигәндәй, без чәйнәшә тордык, алар безгә әйләнеп тә карамый йөри бирде. Аның саен безнең кул кычый, йодрык йомарлана барды.

Хәзер инде без — «без» дигәнем, Сәфәргали, Әсгать, мин — боларны Сай чокырдагы таш өемнәре арасында яшеренеп күзәтә башладык. Боярлар еш кына шул җирдән кайта. Бер капмасалар, бер килеп кабарлар... һәм каптылар да! Җир җиләге пешеп өлгергәндә булды бу.

Безнең Сай чокырда җиләк тәгәрәп пешә. Урыны-урыны белән кызыл чикмән җәйгән төсле тоташ кызарып ята. Бер килеп тап булсаң, баш та калкытып булмый.

Көн кичкә авышкач, әлеге кәрзинкәләрен күтәреп, Сай чокырга килеп чыкты болар. Бояры белән бичәсе сукмак буйлап бара бирде, малай белән кызый, читкә тайчанып, җиләк чүпләргә керешге. Тәүдә алар йөгерә-атлый гына өзгәләп узмакчы иттеләр. Узып кара син! Җиләкле урын бер эләктереп алса, тиз генә ычкындырмый ул. Менә Чикерткә барып чүгәләде, Салам сыйрагы сузылып ук ятты. Өлгерә алмастай булып, авызларына җиләк тутыра болар.

— Әй-һәй, балалар! Әйдәгез! — дип кычкырды аталары, байтак ара киткәч.

— Хәзер! — дип чытырдады Чикерткә, ләкин аларның тиз генә кузгалыр чамалары юк иде әле. Шулай сихерле ул пешкән җиләк.

Олы боярлар, сыртны узып, күздән югалды. Болары, миңгерәү бәрәннәрсымак, чокыр төбендә адашып калды. Көне килде, сәгате сукты! Без өчебез өч яктан чыгып, Салам сыйрак белән Чикерткәне искәрмәстән камап алдык. «Герман сугышы»нда алган сабак ярап калды.

— Әһә, килеп каптыгызмы, бояр калдыклары! — диде Сәфәргали. Шунда ук миңа әмер бирде.— Кендек! Син Чикерткәнең канатыннан эләктер, аталарына барып әләкләмәсен. Без монысының измәсен изәрбез.

Малай белән кыз, ак чүпрәктәй агарып, калтыранакалтырана безнең алда басып тора. Салам сыйракның моңсу соры күзләре мине шунда ук арбап алды. Юк, мин аңа кул күтәрергә базмаячакмын. Чикерткә, тыпырчына-тыпырчына, чыелдап еларга керешге. Аның шулай ачу китергеч ямьсез елавы миңа куәт бирде. Шунда ук кызыйның көпшә юанлыгы гына беләгеннән эләктереп алдым, әмма без ир намусының, егет әдәбенең нәрсә икәнен беләбез, кыз балага сугу түгел, тырнак

белән дә чиертмибез, хәтта бояр кызы булса да. Аның күз яшьләренә минем исем китми. Күзләре дә, песи күзе төсле, яшел. Кызганыр җире юк, ә менә малайның күзләре...

— Кеше каны эчкән боярмы син? — дип җикеренде Сәфәргали.— Бояр булсаң, мә! Җәзаңны ал! — Ул Салам сыйракның күкрәгенә төртте. Әсгать тә берне өстәде. Малай еламады, качарга да җыенмады, рәхим дә сорамады, тыныч кына акланырга тырышты:

— Без... мин бояр түгел, малайлар. Бөтенләй бояр түгел!

— Син булмасаң, әтиең бояр, әниең бояр, карт атаң бояр, карт инәң бояр! Ә син бояр эттән туган бояр көчеге! — дип кызмакчы булып маташты Сәфәргали. Тик малайның күзенә караган иде, җебеде дә төште.

— Әллә нинди бояр бу, һич кенә дә ачуны китерми,— дип аптырады Әсгать.

— Һәр селәгәй бояр, һәр үләт буржуй каршысында шулай коелып төшсәк, бездән нинди көрәшче чыксын?! Көрәшче ул дошманга карата аяусыз, кансыз булырга тиеш! Менә минем кебек!

Сәфәргали Салам сыйракка тагы бер сукты, аның җилкәсеннән ныгытып этеп җибәрде. Малай җиргә йөзтүбән капланып төште. Сәфәргали, сыный биреп, Әсгать белән миңа карап алды. Кешедән калышмыйм дигән булып, мин дә Чикерткәне җибәрми генә, җирдә йөзтүбән яткан Салам сыйракка бер тибеп килдем. Типтем дә, тәннәрем чымырдап китте.

...Бүтәннәргә ияреп, үзем теләмәгән ямьсез эшне эшләвем гомеремдә беренче тапкыр, бәлки, шушы булгандыр. Исемә төшсә, әле дә уң аягым тартышып куя, ләкин, кызганычка каршы, теге тибүем гомеремдә соңгысы да булмагандыр... Шулар аркасындадыр, ахры, юк-юк дисәң дә, йөрәк чәнчешеп ала...

Малайга без бүтәнчә кагылмадык. Ул җай гына башын күтәрде. Аның иягендәге ярадан кан ага иде.

Күрәсең, ул шул җире белән кырлы ташка килеп төшкәндер. Кулы белән ияген тотты. Учына шунда ук кан тулды. Кан күргәч тә ул үзгәрмәде, шул өнсез көе калды. Аяк өсте басып, чалбар балагындагы юк тузанны каккалаган булды. Яралы агасын кызганып, Чикерткә отыры чәбәләнеп еларга тотынды. Мин аны инде ычкындырып җибәрдем.

— Елама, туганым, тамчы да авыртмый. Су белән югач та бетә ул,— диде малай. Ул безнең беребезгә дә күтәрелеп карамады. Сеңелесен җитәкләп алды да ашыкмый гына китеп барды.

Без аптырап калдык. Тукмавын без тукмадык, ә кем җиңде соң әле? Кыз белән малай түбәгә күтәрелде, аннан, калкулыкның теге ягына китеп, бөтенләй күмелде. Күздән югалдылар алар, ә күңелдән китмәделәр.

...Бу боярлар безнең авылга башкача килмәде. Ел артыннан ел уза торды. Мин дә кала кешесе булып киттем. Чәч җибәреп, шигырьләр яза, аларны хәтта бастыра башладым. Тәүге китабымның кулъязмасы типографиягә киткәч, бер-ике көннән үк шунда йөгереп килдем. Көтәргә сабырлык җитми иде.

— Анавы агаең җыя синең китабыңны,— дип күрсәттеләр миңа.

Хәреф җыючының янына ук килеп бастым. Ул мине шәйләмәде. Муенымны сузып карап торам. Кулларына күзем иярми. Мин язган сүзләрне ул хәрефләп җыя. Бармаклары, әйтерсең, кургаш хәреф түгел, ә кыйммәтле асыл таш чүпли: шундый кадерләп ала аларны.

— Саумысез! — дип исәнләштем мин, байтак вакыт үткәч.

Ул миңа әйләнеп карады. Саргылт ак йөзенә елмаюга тартым нәрсә чыкты, ләкин зур моңсу күзләре миңа битараф калды. Ул баш какты. Мин шунда ук читкә борылдым. Әйе, бу адәм, һичшиксез, ул — Миңнулла бояры — Салам сыйрак белән Чикерткәнең атасы иде. Нәрсә эшләп ул монда килеп чыккан? Әллә бу сыйнфый

дошман эз яздырыр өчен шулай итте микән? Үткәннәрен яшерер өчен? Мин ерынып чыкмаслык шикләргә баттым... Ә соңрак шик урынына эчке әрнү, вөҗдан газабы килде.

«Миңнулла бояры» дигәнебез, бала чактан ул типографиядә эшләп, каты үпкә чире алган эшче-наборщик булып чыкты. Теге елны, хәле бик мөшкелләнгәч, шифасы булмасмы дип, ул безгә кымызга килгән икән. Менә кемнең балаларын җәберләгәнбез без! Ә ул, хәрефен хәрефкә китереп, шик-шөбһәсез минем яңа борын төртеп чыккан шигырьләремне җыя, ташка бастырып, аларны гомерле итәргә әзерли. Гүя, аның өчен дөньяда шуннан да кирәкле, шуннан да ашыгыч эш юк.

Мин аңа бер тапкыр да сүз куша алмадым. Кыймадым. Намусым тыйды.

...Дүрт елдан соң тагы бер очрашу булачак. Шундый ук уйчан зур соры күзләр миңа төбәләчәк. Мин өн белән төш, үлем белән яшәү арасында калачакмын... Еракта офыклар чайкала, мин яткан җир тирбәлә. Җир тирбәлми, мине, носилкага салып, каядыр алып баралар. Мин үзем тирбәләм. Манма тиргә баткан арык солдат мине көч-хәл белән күтәреп килә. Аның ияк өстендәге аркылы җөйдән күзләремне аерып ала алмыйм... Җөйгә кадәр һәрвакыт яра була, ярадан кан ага. Бу җәрәхәттән тамган кан бик еракта, Сай чокырдагы соры ташка йогып калган булырга тиеш. Йокканны яңгыр юган-дыр, кояш киптергәндер. Онытырга, тынычланырга мөмкин... Ә ул, еллар узгач, ут тамчысы булып, синең йөрәгеңә килеп тамса? Әйтик, турыдан-туры синең гаебең дә юк кебек. Аннан соң, аның гаебе бар идемени? Җиргә тамган һәр тамчы кан өчен кемдер гаепле, кемдер жаꞵаплы — ике якның берсе, әлбәттә. Ике як та берьюлы гаепле яки берьюлы гаепсез булмый.

Әйе, носилкада ятканда ук әле мин аны таныдым. Тән яраларымның сызлавы басылды хәтта...

Акйолдыз

Иртәгә сабан туе дигәндә, күршебезгә килен төште. Терәлеп торган ут күршегә түгел, арырагына — бер өй ашасына. Хәлле генә көн иткән Галләм карт уртанчы улын — йомык Хәмзәне шулай башлы-күзле ясады.

Безнең якта туйларны кышын кыз йортында үткәрәләр дә җәйнең иң ямьле көннәрендә, мичәп-мичәп җиккән атларга кыңгыраулар тагып, кәләшне кияү төягенә алып кайталар — килен төшерәләр. Кышкы туйдан соң килен төшерүгә кадәр кияү кеше һәр атнакич саен кыз йортына «кәләш кияүләргә» куна бара. Урам аша җирме, утыз-кырык чакрым арамы — барыбер ул, шартына китереп, юлга әзерләнә: атының койрык-ялын тарап үрә, аны тасма-тосма белән бизи, йөгән, ияр җизләрен ком белән ышкып ялтырата. Атын ул курадан ук атланып килми, урамга чыккач кына, купшы итеп ияргә сикерә. Анда да тиз үк һайтлап чабып китми, масая биреп, бераз туп-туры карап тора: күрмәгәннәр күреп калсыннар, янәсе...

Былтыр минем Мортаза агаем, аннан әүвәлге елны Корбангали Хәҗимулласы әнә шулай итә торган иде. Күрексез генә адәм дә, кияүгә әйләнгәч, купшылана да китә.

Ә менә Хәмзәнең «кәләш кияүләргә» йөрүе бөтенләй дип әйтерлек сизелмәде. Язгы сабан беткәч, бары бер тапкыр гына, агасына ияреп, барып әйләнде бугай. «Нигә яшь кәләшеңнең күңелен күрергә йөрмисең?» — дип интектергән яшьтәшләренә Хәмзә болай җавап бирә икән: «Ара ерак, юл өзек, юлда азган-тузганга тап булып куюым бар. Андый зат очраса, булыр бичәң тол калыр, туар балаң ятим үсәр. Тамгасы салынган, адашмас әле, тәгаенләнгән җиренә килер...»

Кичләрен нигез буенда тәмәке тарта-тарта әңгәмә

корып утырган агайлар бүтәнчәрәк тә сөйләп ташлый торган иде. Имеш, кәләш үзе шундый шарт куйган: арчилар килгәнче, күренеп йөрмәсен, дигән. «Нигә шулай дигәнен бер ходай гына белә, белеге җитсә»,— диде беркөнне көтүче Нуретдин.

Хәмзәнең сүзе дөрескә чыкты. Тамгасы салынгач, килен адашмады, кияү йортына туры килеп төште. Ерактан килде, диделәр киленне — бик ерактан — Дим үреннән. Килене килен генә түгел, күрер күзгә тамаша, сизгер күңелгә бер могҗиза иде. Безнең авылда да чибәр кызларны, сылу киленнәрне, куштан хатыннарны үләт кырмаган. Шөкер, исәннәр. Әнә безнең үрге күрше Мансур кызы Гөлбостан үзе генә дә ни тора. Буе-сыны коеп куйган шикелле. Йөргәндә дә, атлап йөрми, берчә оча, берчә йөзә ул. Аның биш төрле йөреше генә бар, диләр. Быел яз арткы бакчада бәрәңге утыртканда, Мансур карт, нәрсәгәдер ачуланып, кызына кычкырып җибәрде: «Шул «барыня» атлавыңны куй әле, Гөлбостан!» Күрәсең, теге эш вакытында ялгыш «барыня»ча атлап киткәндер.

Әле Мортаза агаема кәләш әйттергәнче, Гөлбостанга яучы җибәрергә дә ниятләп караган идек, әмма азактан кире сүрелдек. «Уңган хатын ир күрке, матур хатын ил күрке,— диештек,— үтә чибәр Гөлбостан йортка төс бирмәс»,— дип шикләндек. Агаема Тәмәнәй очыннан урта матур Бикә җиңгәчәмне алып бирдек. Үзенең дә күзе төшеп йөргән икән. Әти пешәр-пешмәс башкодалар җибәреп мәшәкатьләнмәде, кыз атасына туп-туры үзе барды. Барды да көе китебрәк кайтты. Кичке чәй табынында ул шулай дип салды:

— Булачак киленне күргәч тә ошаттым. Сөяге безгә тартым. Тик кодалар гына бераз күңелне китте. Саранга охшыйлар.

— Мал күп сорыйлармыни? — диде Олы инәем.

— Юк, күп сорамыйлар. Алар комсыз түгел, саран, артык сакчыл булырга охшый.

— Һи-и, бер күрүдә ул кадәресен үк каян белеп бетәсең, моңача аралашкан кешеләребез түгел бит,— дип каршы төшкән булды Олы инәем.

— Чирек йомарлам май куйдылар табынга, шикәрләре дә үтә вак ватылган иде, борчак чаклы гына...

Олы инәем бүтәнчә эндәшмәде.

Җиңгәчәй дан бичә булып чыкты. Куанып бетә алмыйбыз. Ә кодалар, чынлап та, саранның да сараны инде...

Гөлбостан кебекләрне меңләптер дип әйтә алмыйм, ә шулай да, тырышыбрак санасаң, байтак җыелыр. Бер дә юккамыни тирә-якның иң чая егетләре, бал тәпәненә ябырылган сагызаксымак, безнең тирәгә сарыла. Урала-сарыла да борынын салындырып кайтып китә. Кызларның сылулары үзебезнең егетләрдән дә артмый. Арту гына түгел, хәтта җитми дә кала әле. Шулай булмаса, әлеге Хәмзә, әллә кая Дим үренә барып, кәләш әйттереп йөрер идемени?

Чибәрләре белән дан тоткан авылга төшкән бу килен шулай да бозау көтүенә адашып килеп кергән болан баласына охшый иде. Төсе-башы, торышы-йөреше белән дә, күз карашы, хәтта тавышы белән дә безнең өчен ят, сәер, тылсымлы иде, гүя, ул бөтенләй башка туфракта, башка күк астында, башка һаваны сулап үскән. Эчкәне дә су түгел, мөгаен, ширбәт булгандыр. Югыйсә шундый ягымлы тавыш каян килсен ди ул? Әйткәнемчә, бер карауда ир-атны әсир ясап, мәҗнүн итәр хатыннар күп иде бездә, ә мондые әле юк иде. Исеме дә моңача колак ишетмәгән исем бит — Акйолдыз. Аның исемен тәүтапкыр ишеткәч тә, мин ирексездән күккә карадым, баш очымда көпә-көндез балкып янар йолдыз күрердәй булдым — күрмәдем, ләкин гомерем буе шул җиңгәбезнең исеме колагыма чалыну белән, аның сыңарын күрмәмме дип, күккә баш чөйдем. Алай иткән бер мин генәме икән әле?

— Мәгәр дә ниндирәк иде ул хәйран илаһи зат, тасвирлап бирсәңче,— диючеләр булыр, бәлки.

Мин бары шуны гына әйтә алам: кояшны, айны ничек тасвирлыйсың? Кояш һәркем өчен бер кояш, ай һәркем өчен бер ай инде. Акйолдыз да бары Акйолдыз гына, берәү генә иде.

Акйолдызның, кыз-кыркынга ияреп, су юлы башлап кайтуын бөтен урам, тамаша кылып, каршы алды. Киленнең ике чиләге дә мөлдерәмә тулы иде. Әмәл өчен бер тамчысы чайпалсын ла! Атлаганда, үкчәләре җиргә тими, тик аяк очлары гына кагылып кала. Үзе сизелер-сизелмәс кенә елмая. Нәрсә күреп елмая икән ул? Койма башында әсирләнеп утырган унике яшьлек мин бичараны шәйлиме икән? Шулай да кемгә елмая ул — үз-үзенәме, кешеләргәме, әллә бөтен дөньягамы? Бер карасаң, менә-менә, тыела алмый, елап җибәрер кебек...

...Моңа хас елмаюны миңа гомеремдә тагы ике тапкыр күрергә насыйп булачак: бер тапкыр үзем белән туфракташ, замандаш бик сылу хатын, бу дөньяга китәр өчен генә килгән Җир кызы, миңа карап, миңа атап, җан тетрәткеч шулай елмаячак, ә икенче тапкыр бөек Леонардо да Винчиның хыялыннан яралган үлемсез Джоконда — мәңгелек Мона Лиза елмаеп, рухымны берчә күккә ашырачак, берчә упкынга атачак...

Килен төшкән Галләмнәр йортында шау-шулы мәҗлес төн уртасына кадәр барды. Без Сәлих агаем белән ике буйдак лапас башында кунабыз. Күк тулы йолдыз. Мин шуларга карап ятам. Аларның берсе дә ак түгел, я зәңгәрсу, я яшькелт. Мөгаен, ак йолдыз берәү генәдер, үз вакыты җиткәч кенә калкадыр. Бәлки, ул хәзер бөтенләй күктә дә түгелдер, кыз сынына кереп, җиргә төшкәндер... Әсгать нәрсә әйтер иде икән бу хакта? Өйдә юк шул ул, күрше авылда көтү көтә.

Галләмнәр курасында да ыгы-зыгы тынды. Этләр дә өрүдән туктады. Инде тәүге әтәчләр дә хәбәрләшеп алды. Нәкъ шушы мәл Түбән очтан дулкын-дулкын бу-

лып гармун моңы агылып килде. Башта ул кемгәдер йомшак кына, ягымлы гына сузып эндәшкәндәй булды, аннан соң ярсып-ярсып эч серләрен сөйләргә кереште, бара торгач, нәрсәдер инәлергә, ялварырга, үтенергә тотынды, азак килеп, үкереп елап җибәрде; кинәт тынды да буылып-буылып үксеп алды. Юк, гармун үз яшеннән үзе чәчәмәде. Ул чак кына тын алды да, ашкынып-ашкынып сайрап, төнге галәмгә үзенең булачак шатлыкларын, өметләрен, күкрәгенә сыймас дәртләрен сибә башлады. Бу моң агышын мин инде ишетәм генә түгел, хәтта күрәм дә төсле. Ул агыш, нурлар чәчә-чәчә, Түбән очтан Югары очка сузыла.

— Мәрәһимнең тагы җене кузгалды, ахрысы,—диде Сәлих агаем йокы аралаш.

Их, агаем! Нигә шулай дидең инде? Җеннең ни кысылышы бар монда? Син шулай дидең дә хырылдап йоклап киттең, ә үзең шул бер авыз сүзең белән әле генә бөтен дөньяны сихерләп алган моңны, искиткеч якты балкышны сүндердең.

Олы инәем, мөгаен, алай итмәс иде. «Кемнедер эзләп чыкты янә бу бахыр Мәрәһимнең ялгыз җаны»,— дияр иде. Ул чакта әле мин җиде төн уртасындагы ялгызлыкның нәрсә икәнен танып та, татып та белми идем. Ялгызлыкның иң яманы — төн уртасындагы ялгызлык булуын бик күп заманнар үткәч кенә аңлаячакмын, шулай да әле мин барыбер җаным-тәнем белән Мәрәһим яклымын. Аның зары да, куанычы да төнге бушлыкка батып югалмый, минем күңелемә сеңә бара. Бу сәгатьтә бөтен җиһанда уяулардан без бары икәү генәбезсыман — ул да мин...

Янып сүнгән елларымның соры көлләре чәчләремә кунгач, шул хакыйкатькә ирештем мин: кешеләр барысына да күнегә — матурның матурлыгына, ямьсезнең ямьсезлегенә, яманның яманлыгына күнегә. Иләшә дә, гаҗәпләнми башлый. Шулай итеп, матурлар һәм яхшылар хәтта оттыра, ямьсезләр һәм яманнар ота, ә минә

Акйолдызга без ай үткәч тә, ел үткәч тә, гомер бакый да, аны гадәти итеп, күнегә алмадык. Ничектер, ул бөтенләйгә җиргә төшеп җитмәде, безнең арага кереп югалмады, чак кына югарырак җирдә, буй җитмәсрәк арада калды. Бу аның тәкәбберлегеннән, эрелегеннән түгел иде. Анда масаюның, һаваланунын әсәре дә булмады. Кешеләр үзләре аны шулай югары кабул итте һәм нинди хәлләрдә дә түбән төшермәде.

Безнең Черчә урамы башта Акйолдызның чибәрлегенә, сылулыгына сокланды, тора-бара аның уңганлыгына, булдыклылыгына, илгәзәклегенә хәйран калды. Галләм килене эрләгән җеп, суккан киндер ефәккә алыштыргысыз, кискән токмачы кылдан нечкә, кием тексә, коеп куя, дип сөйлиләр. Моңа кадәр дүрт аягын тышаулагач кына саудыра торган ала сыерлары, хәзер көтүдән кайткач та, килен артыннан үзе иярен йөри. Анысы хак. Көн дә үзебез күреп торабыз. Галләмнең чыгымчы җирән биясе дә ходай мәхлугына әйләнде. Бер тапкыр ире белән утынга барганда, Акйолдыз, дилбегәне үз кулына алып: «Әйдә, малкай, әйдә, акыллым, әйдә, күндәмем!» — дип кенә әйткән, имеш. Шушы сүзләрне ишеткән җирән бия әйләнеп караган да ике тапкыр баш каккан, янәсе, төшендем, моннан ары син әйткәнчә булырмын...

Акйолдыз печән җыйган, урак урган җирдән кешеләр гамьсез генә, битараф кына узып китә алмый, аның эшләгәнен бер тамаша карагансыман дөньяларын онытып, үз эшләрен калдырып карап торалар. Торалар, торалар да: «Эшең уң булсын!» — дип, теләк теләп китәләр. «Сезнеке дә шулай булсын!» — дип җаваплый килен, эндәшмәс иреннән узып булса да. Кәләш алгач та, Хәмзә шул йомык, шыксыз көе калды.

Учына кош кундырып сайратыр, тыны белән өреп чәчәк бөреләре ачтырыр хатыннар булуын мин әле белми идем. Алар бар икән. Әнә, шуларның берсе Акйол-

дыз булган икән. Ул узып киткән саен, Шаһидулланың әнкәсе Миңлекәй җиңги:

— Шушы Акйолдызның урамнарны ямьләтеп бер үтеп китүе үзе ни тора. Тфү, яман күзем тимәсен! — дип сокланып кала.

Галләмнәр күрше-күлән белән бик аралашып бармыйлар, бүленебрәк көн итәләр. Шуңа күрә алар йортыннан сер чыкмый, хәбәр таралмый. Миңлекәй җиңгинең бер өтәләгән азгын тавыгы бәрәңге бакчасына кереп тибенсә, бу хакта бөтен Черчә шунда ук тулы мәгълүмат ала, ә тегеләрнең аты егылып үлсә дә, тавыш-тын чыкмый. Ничек кенә яшидер ул өйдә Акйолдыз — монысы илгә билгесез.

Килен төшкәннән соң ашык-пошык җәй узды, саргаеп, моңаеп көз үтте, башланмаган озын бер кыш бетте, ерганаклардан янә кар сулары йөгерде. Менә күпме заман Мәрәһимнең гармуны бер генә тапкыр да тавыш чыгармады. Бөтенләй телдән язды. Баштарак кешеләр моңа бик аптырады, хәтта хәтерләре калды, күңелләре төште. Бер юанычтан мәхрүм булгандай тоелды аларга. Ничек инде ул? Айдан-ай, елдан-ел, көн саен булмаса да, атна саен Мәрәһимнең сагышлы көйләре бөтен авылны моңландырып яңгырасын да кинәт өзелеп калсын, имеш... Тиктәстән генә булмас бу хәл, диләр. Мин дә шулай уйлыйм. Күрәсең, бичара Мәрәһимнең җаны тәмам адашкандыр, эзләгәнен табудан өмет өзгәндер, шуңа күрә гармун телдән калгандыр, көйдән язгандыр. Мөгаен, шулайдыр.

Бәлки, алай да түгелдер...

...Кечкенә вакытта минем ифрат алама бер гадәтем бар иде. Кичтән юрган астына кереп чумам да, йоклаган булып, олыларның сөйләшкәнен тыңлап ятам. Җитмәсә, шартына китереп, ара-тирә мышнап та җибәрәм. Торганы белән бер шымчы. Тфү, шакшы! Хәтеремә төшсә, әле колакларым янып китә. Монысы минем икенче әшәкелегем, ә беренчесен аннан да әлегрәк — дүрт-биш

яшемдә кылдым. Икейөзлелек күрсәттем. Менә ничек булды ул.

Бездән кыйгачрак урам аша Каюп агайлар тора. Бер заман мин аларга бик нык ияләшеп алдым. Көн дә киләм. Аларның Зәйнәп белән Җәмилә исемле җитеп килгән ике кызы бар. Болар, берсе йорт болдырына, икенчесе келәт алдына утырып ала да әрләшә дә әрләшә. Беркөнне Зәйнәп мине, үз янына чакырып, берәр төймә-фәлән бирә дә Җәмиләгә атап төрле начар сүзләр әйттертә. Ул шым гына колагыма шыбырдый, мин ул әйткәнне кычкырып кабатлыйм:

— Сине чабатачы кәкре Хәбетдин кочаклап яткан! Кыеш авызлы тешсез селәгәй Ханса үпкән. Тәмле булдымы селәгәй Ханса үпкәч? Җитмәсә, син тиле Габбаска гыйшык хаты язгансың. Мәсхәрә! Хат язганчы, Габбаска ыштан тегеп кидер лутчы. Югыйсә әнә җаенкышын ыштансыз йөри.— Җәмиләгә тагы әллә нинди гаепләр тагып, тегене елатмый туктамыйбыз.

Икенче көнне, берәр буш шырпы кабы сузып, мине Җәмилә кулга төшереп ала. Мин инде келәт алдына күчәм. Хәзер шул ук тырышлык белән Җәмиләнең Зәйнәпкә төбәлгән сүзләрен сөрәнләп кабатлыйм:— Син бур! Сабын буры! Тарак буры! Син мөртәт! Качып ураза ачасың. Алдакчы син! Шуның өчен сине берәү дә яратмый. Дивана Габбас та сиңа әйләнеп карамый. Ыргак төсле кәкре танавыңа кияү эләктерә алырмын дип өмет тә итмә. Бичура! Албасты! Мунча пәрие!!

Сүз кәкре танауга барып җиткәч, Зәйнәп, йөгереп килеп, Җәмиләнең чәченә ябыша. Шушы җирдә инде минем бурычым үтәлеп, эшем тәмамлана.

Алдагы көннәрдә, тагы шулай кулдан кулга күчеп, әлеге исәрлегемне эшләдем. Шушы кылган кылыгымны мин гомер буе оныта алмадым. Исемә төшкән саен дертләп киттем. Яман төш күргәннән соң шулай дертләп уянасың бит: «Ярый әле төш кенә булган...» — дисең. Мин дә: «Ярый әле бу яманлыгым өнне төштән аермый

торган чагымда гына эшләнгән»,— дип үземне юаткан булам, ә онытып булмый. Димәк, гомер буе сабак алам. Танылган хаталарыбыз, хәтта гаепләребез тормышта безнең киңәшчеләребезгә, ярдәмчеләребезгә, шулай итеп, бара торгач, таләпчән дусларыбызга әйләнәләр, ә танылмаганнары яки яшереп килгәннәре дошманнарыбыз булып калалар. Катлаулы хәтәр хәлләргә тап булганда да, мин шуны онытмаска тырыштым. Беркөнне Зәйнәп тавышы, икенче көнне Җәмилә тавышы белән кычкырсаң, бөтенләй тавыштан язуың бар.

...Мин инде байтактан бирле юрган астында ятам. Өйдә бары ике инәем генә. Олы инәем нәрсәдер ямаып утыра. Кече инәем казан төбе кыра.

— Ишеттеңме әле, ил өстендә имеш-мимеш йөри бит,— диде Кече инәем,— Мәрәһим белән Акйолдыз хакында.

— Пыш-пыш йөргән һәр хәбәрне тыңлый калсаң, зиһенеңә көч килер. Куй, Вазифа! — дип кырт кисте Олы инәем. Бөтен ишеткәнен сөйләп бетерми туктарга тегесенең чамасы юк иде.

— Бик каты гыйшык тотышканнар, ди, Таһир белән Зөһрә кебек...

Олы инәем көрсенеп куйды. Бераздан тыныч кына әйтеп салды:

— Мәхәббәт язык түгел. Мәхәббәтсез уйнаш язык. Әгәр дә син безнекенә яратып килмәсәң, белмим, ничек икебез бер дөньяга сыеп яшәр идек... Мәхәббәт бөтенесен дә аклата, ярлыката...

— Языгын да, савабын да үзе өчен һәркем үзе күтәрә. Мин бит аларны гаепләп әйтмим,— дип акланды Кече инәем. Байтак эндәшми торгач, ул тагы тезеп алып китте.— Мәрәһим белән Акйолдыз, күрәсең, электән үк бер-берсен белгәннәр. Теге елны безнең авылныкылар Дим үренә барып уракка ялланганнар иде бит. Шунда күрешкәннәр, диләр. Имеш, Акйолдызның риза булып Хәмзәгә килүе дә шул Мәрәһим өчен генә икән.

«Мәрәһимне гомеремдә тагы бер күрер булсам, Хәмзәгә кияүгә чыгарга гына түгел, туп-туры җәһәннәмгә китәргә дә ризамын»,— дип әйткән диме, уйлаган диме.

— Шул кешеләр белгән чаклыны ходай белсә, дөнья нинди төзек, ипле булыр иде. Хәерсезгә, адәмнәр артыграгын белә, аннан да артыграгын сөйли.

— Мәрәһимнең яше дә утызга җитеп барадыр инде,— дигән булды Кече инәем, янәсе, сүзен очлап.

— Баягы гыйшык дигәнең мал санап та яшь сорап тормый шул. Монысын син үзең дә яхшы беләсең, Вазифа.

Кече инәем минем әтиемнән егерме яшькә яшьрәк. Олы инәем әнә шуңа ишарә ясады бугай. Юк, ачуланып түгел, болай гына, сүз уңаенда гына...

Менә нинди серләр ачылды миңа! Гыйшыкның нәрсә икәнен мин үзем дә татып беләм. Узган ел партада янәшә утырган кыз белән (исемен әйтмим) ярты кышка кадәр янып-көеп көн саен хат алыштык, һәр кич саен тегеңә озын-озын хатлар язам. Җырлар да кушып җибәрәм:

Бер кузгалса машиналар,
Бара да бара икән.
Гыйшык уты бер кабынса,
Яна да яна икән.

Безнекеләр куанып бетә алмый: «Озак укымый йөргәч, сабакны ничек тансыклаган Кендек. Иллә тырыш бала булып чыкты. Баш та күтәрми дәрес карый»,— диләр. Олы инәем, бүтәннәрдән тамак аерып, ара-тирә мине тәмле нәрсәләр белән сыйлап куя. «Сабак укыган кешегә тәм-том кирәк ул. Зиһенең артыр. Башың тагы да ныграк эшләр»,— дип битемнән сөя.

Әмма тиз үк кара көн килеп җитте.

Бер иртәдә (хатларны без иртә белән дәрес башланганчы алмашабыз), бер каһәрле иртәдә, теге кызый миңа хат урынына кәгазьгә төргән кара күмер валчыгы бирде. Гыйшкыбыз янып, көл-күмергә әйләнде

дигән сүз иде бу. Димәк, бөтенесе дә бетте! Ул башкача миңа әйләнеп тә карамас булды. Нинди генә гаепләремне тапты, нинди генә җиремне ошатмады икән? Уф! Гыйшык тотулары кыен иде, гыйшыксыз торып калулары бигрәк тә әрнүле, бигрәк тә газаплы икән. Үз башына төшмәгәннәр генә белмиләр моны.

Кич кайткач, Олы инәемнең җылы учына башымны салып, шым гына елап җибәрдем.

— Нигә елыйсың, синнай? — диде ул. Мин җавап кайтармадым. Ярый әле башымны куеп еларга аның йомшак куллары бар. Яңагымнан бер сыйпады да бөтен газапларымны алып ташлады. Моннан күп заманнар соңрак та сагышлардан бушамас тынгысыз бу башым сыеныр тәяккә күп тапкырлар мохтаҗ калачак, тик инде ул чак Олы инәем, шул тылсымлы куллары белән бу дөньяның ишеген үз артыннан ябып, мәңгегә киткән булачак...

Мәрһим белән Акйолдызның хәлен аңлыйм мин. Тик анавы имеш-мимеш һич кенә дә дөрескә охшамый. Әниемнәр сөйләшкән теге кичтән соң атна узды, ай узды, ә гашыйклар хакында урамда ләм-мим сүз юк. Безнең Югары оч халкы, гаеп табып, кеше чәйнәргә, мыскыл итеп көләргә ифрат әвәс — сылтавы гына табылсын. «Фәләннең бичәсе фәләннең иренә күз кыскан икән, фәлән кода фәлән кодачасын аздыра язган икән, фәлән агай фәлән тол бичәнең тәрәзәсен чиерткән икән...» кебек юк-бар хәбәрне хатыннар сөт аерткан җирдә, ирләр каравыл өенә җыелганда, кыз-кыркын суга барганда авыз тутырып сөйли. Әсгать кебек җор сүзлеләр әчкелтем-төчкелтем төртмә җыр да чыгара. Әнә теге пешмәгән кода турында кичке уенда бер егет, биергә төшкәч, болай дип такмаклады:

Кодачаның бармагы,
Бармагында балдагы.
Тал төбенә киләм, диде,
Килмәс булды, алдады.

Кодачаның шәле
Җиргә тияр әле,
Язган булса, иншалла,
Бер үбәрмен әле.

Олырак язык кылган яки яман шик астында калган кыз-кыркын, бичә-чәчә яшәгән йортның капкасына төн эчендә дегет буяп, атларының койрык-ялын тунап чыгу гадәте дә булган әүвәлрәк. Хәзер анысы сизелми. Мәгәр бер тапкыр, күздән төшеп, телгә эләккән адәм тиз генә ычкына алмый: тегермәндә тарттырып, иләктән илиләр аны.

Акйолдыз белән Мәрәһимгә җил-яңгыр кагылмый. Димәк, Кече инәемә кемдер бөтенләй буш хәбәр сөйләгән, сөйләгән дә тынган. Ярый, хәерлесе шулдыр. Онытыйк инде бу хакта...

Ләкин алар үзләре оныттырмады. «Адәм ышанмас сүзне дөрес булса да сөйләмә»,— диләр. Әйе, үзең күреп, үзең ишеткәнгә дә кайчак ышанып бетмисең. Расмы икән, дип икеләнәсең. Мин дә тәүдә күзем күреп, колагым ишеткәннәрнең хаклыгына шикләнеп, югалып калдым. Бу шаһитлыгыма сәбәпче безнең гел әллә кая югалып йөри торган кышлау үгезебез булды. Кич ул тагы көтүдән кайтмады. Шуны эзләп без, өйдәге ир-ат, көтү йөргән тугайның төрлебез төрле ягына таралыштык. Минем әлсерәп йөрүем бушка гына булды. Үгез табылмады. Әллә кайчан эңгер төшеп, төн тәмам куерып беткәндә, мин, арып-талып, Кызлар тавына килеп мендем. Көндез Мортаза агаемның кесәсеннән чәлдергән бер чеметем тәмәкене төреп тартмакчы булып, тау битләвендәге ялгыз имән төбенә утырдым. Кәгазен табып, тәмәкесен урадым, ә шырпысын таба алмадым. Күрәсең, каядыр төшереп калдырганмын. Ризыкка язмады бу хәрамнан килгән мал!

Инде кузгалып киттем дигәндә, күземә галәмәт зур сәер нәрсә чалынды. Адәм дисәң, адәм түгел, җанвар дисәң, җанвар түгел. Үзе шөкәтсез. Ул тау астыннан

акрын гына өскә, миңа табан, үрмәли. Минем җаным бармак очыма килеп җитте. Менә-менә атылып чыгып китәчәк ул. Мин сак кына имән артына сыенам. Йөрәгем дөп-дөп тибүдән имән селкенә. Теге гыйфритне инде ачыграк шәйлим. Аның аяклары да, башы да икешәр, куллары әллә дүрт, әллә алты. Санап бетерерлек түгел. Агач башына үрмәләсәм инде? Алай да котылып булмас шул. Ни күрсәм дә шунда күрермен, кымшанырга ярамый. Кышлау үгезне эзлим дип, әҗәлемне эзләп йөргәнмен икән. Тегесе табылмады, монысы үзе мине килеп тапты. Иртән торуга безнең бөтен өй эчебез, мине жәлләп, канлы яшьләр түгәчәк. Бәлки, мине санга санамас булган теге кызый да үкенер әле. Чытырдатып күзләремне йомдым, йомылган күз алдымнан безнең таш зират капкасы, мәчет ае, яңа гына казылган кабер чагылып үтте. Мин аларны, гүя, табутта яткан килеш күреп барам...

— Яратасыңмы? — диде гыйфритнең бер башы ирләр тавышы белән.

— Яратам... Яратам...— дип үтә ягымлы раслады хатын тавышлы баш.

— Бик, бикме? — дип төпченде тегесе.

— Бик-бик-бик булмаса, шушы бер чеметем бәхет өчен шул чаклы газап йөкләре йөкләп йөрер идеммени? Барыбер үкенмим. Синең кочагыңдагы мыскал гына бәхетемне алтын тауларга алыштырачагым юк.— Шул чак чут итеп кош сайрап куйды. Саташкан кош булды, ахрысы.

— Шул көе сине әнә теге ак йолдызга алып менимме? — диде ир тавышы.— Синең йолдызыңа...

Күк йөзендә байтак биектә бу чак, чынлап та, ак йолдыз балкып яна иде. Ул, талпына-талпына, җиргә табан омтылып куя. Менә-менә күктән ычкынып китәр дә Кызлар тавына килеп кунар төсле. Мин инде тынычлана төштем. Гыйфрит дигәнем миңа зыян китермәячәк. Аның кайгысы миндә түгел.

— Синең белән җирдә дә бик рәхәт миңа. Ул йолдызда нәрсә калган безгә. Мин үз исемемне болай да яратмыйм. Сине генә яратам — исемеңне дә, үзеңне дә...— Баягы саташкан кош йокы аралаш чут-чут итеп бу юлы, суза биреп, ике тапкыр сайрап алды.

— Күңелем гомер буе сине эзләде, сине зарыгып көтте...

— Эзләгән — тапкан, ташка кадак каккан,— дип такмаклады хатын.— Сабыр итеп көткән — сөйгән ярын үпкән...— Баягы кош тагы чут итеп алды.

— Син һич кенә дә боекмыйсың, Акйолдыз, ә мин гел сагыштамын,— дип зарланды ир.

— Әйттем бит, икебез бергә чакта, бу дөньяда минем өчен сагыш та, хәсрәт тә, хәвеф тә юк. Аларның урыны башка җирдә.

Ике кулын алга сузып, пәһлеван Мәрәһим, Акйолдызны, бәби тоткан шикелле күтәреп, минем яннан гына узып китте. Тау башына менеп китте. Мине күрмәделәр. Гашыйкларның күзе җирдәге бөҗәктә түгел, һавадагы бөркеттә икәнен мин шул төнне тәү тапкыр аңладым. Сөешкән кешеләрнең ни өчен биеккә, тау түбәләренә омтылуын шул көнне мин беренче тапкыр сизендем, ә ни өчен икәнен менә сүз белән әйтеп аңлатып булмый.

Күргәнемнән, әлбәттә, башта каушап төштем, аннан шаккаттым, ә тегеләрнең аяк тавышы ерагая баргач, тирә-ягым ничектер бушап, моңсуланып китте, дөнья яме кимегәндәй булып калды. Хәтта күңелемне үзләре белән алып китте алар. Матур тавышлары, сөйләгән сүзләре ошады миңа. Тик Мәрәһимнең Акйолдызны бәби урынына күтәреп йөртүе генә ошамады. Нygытып ошамады. Тапкан һөнәр! Атлап кына йөрергә аягы юктыр шул тегесенең дә?!

...Янә кырык өч елдан соң, Чехия тауларында кояш батып килгәндә, шундый ук күренешкә тап булдым. Мәрәһим сынлы бер яшь егет, сөйгәнен ике кул очында тотып, юлсыз-нисез текә үргә йөгереп менеп китте. Үзе

көлә. Миңа ошады бу, бик ошады. «Афарин, егет, афарин!» — дип калдым эчемнән. Бу чак без Рауза белән җитәкләшеп, бормалы сөзәк сукмактан сак кына түбән төшеп килә идек. «Афарин, егет!» — дип кабатладым мин, борылып карап. Үкенечкә каршы, берәүне дә шулай күтәреп тауга менә алмадым мин. Хәзер бик менәрдәй булам да — хәлдән килмәс. Хәлдән килсә, болай килешмәс, адәм көләр. Менәр тавыңа үз вакытында менеп калырга кирәк икән... Кырык өч елга артка әйләнеп карыйм да янә кабатлыйм: «Афарин, Мәрәһим, афарин!» — дим...

Мәрәһим белән Акйолдыз үтеп киткәч, төннең караңгы шомы таралгандай булды. Алар йөргән җирдә шик-шөбһәнең, куркынычның булуы мөмкин түгел кебек иде. Мин, тәмам һушыма килеп, кайтыр якка уңайладым. Бераз баргач, нишләптер, фуражкамны салдым. Нәрсәдер шылтырап җиргә төште. Шырпы кабы иде бу. Күрәсең, мин аны гадәтемчә башымдагы фуражка эченә яшергәнмен дә оныткانмын.

...Әле уйлыйм: әгәр шул шырпы кабы мин эзләгәндә табылган булса, саксыз сызылган бер шырпы ике кешенең нинди зур шатлыгын өркетер, нинди зур серне фашлап, хур итәр иде.

Ничек итеп кенә эчемә сыйдырыйм бу серемне? Бер көн чыдадым, ике көн чыдадым. Өченче көн чыдар әмәл калмады. Мәчет манарасына мен дә азан урынына кычкыр хет.

Аулак мәлне туры китереп, Олы инәемне алачыкка чакырып чыгардым.

— Нәрсә, каймак ашыйсың килдемени, синнай? — диде ул.

— Юк, Олы инәем. Минем сиңа әйтә торган серем бар.

— Алай каймактан да баш тартырлык булгач, хәтәр сердер, күрәсең.

— Хәтәр шул, Олы инәем. Акйолдыз белән Мәрәһим хакындагы теге сүз дөрес булып чыкты бит.

— Нинди сүз, кем сүзе?

— Нигә, теге кичне Кече инәем...— Минем телем, тешемә тиеп, абынып калды. Шымчылыгым чак-чак кына ачылмады.— Кеше сүзе инде, халык сүзе...— дип мыгырдадым.

— Куй, бушны сөйләмә.

— Буш түгел шул! Теге төнне үгез эзләп гаеп булганымда аларның икесен бергә Кызлар тавында күрдем.

— Тфү, тфү, балам, күзеңә күренгәндер. Кара төндә бәндә күзенә әллә нәрсәләр аймылышып күренә ул. Төн бик караңгы иде шул.

— Мин аларның сүзләрен дә ишеттем, Олы инәем. Валлаһи! Икмәктер, кояштыр! Мин алдакчымыни?

— Алдакчы түгел. Хата күргәнсең, ялгыш күргәнсең. Хаталану ул алдашуга керми.

— Күрдем дә, ишеттем дә.

— Адәмнең кайчак шулай күзе тиешсезне күрер, колагы тиешсезне ишетер була. Куй, балам, юк белән башыңны бутама.

Мин бөтенесен дә тезеп сөйләп бирмәкче идем дә, Олы инәем ышанырдай булмагач, сөйләмәдем.

— Адәм ышанмас сүзне сөйләмә моннан соң,— диде ул ахырда.— Гайбәтче яманаты күтәреп мәсхәрәгә калырсың.

Мәсхәрә калудан без бөтен өй эчебез белән куркабыз. «Менгән атың егылып үлсә үлсен, әйткән сүзең нахакка чыгып үлмәсен»,— ди әтием. Чынлап та, әллә бөтенесе дә күземә генә күрендеме икән? Олы инәем, шулай гына булгандыр, ди бит. Ә колагыма өзлексез чыңлап торган: «Яратасыңмы?», «Яратам»...— дигән авазларны ничек басарга соң миңа? Минем колагымда тынса да, ул авазлар Кызлар тавында барыбер калачак бит.

...Олы инәемнең сәер кылыгын — минем дөрес хәбә-

ремне көчләп-көчләп нахакка чыгарырга тырышуын мин бары әле килеп төшендем. Борынгы грекларда гашыйкларны яклаучы, аларны хәвеф-хәтәрдән саклаучы Афродита исемле илаһия булган. Минем Олы инәем, әлбәттә, ул илаһия турында ишетмәгән дә, белмәгән дә... Әмма үзе дә сизмәстән, ул Акйолдыз белән Мәрәһимнең мәхәббәтен саклаучы шул алла вазифасын үтәгән.

* * *

Теге кышлау үгезе табылды. Шул шатлыктан без быел арыш урагына өмә ясарга ниятләдек. Мич башында ике мичкә балыбыз үкереп әчеп утыра. Сугымга әлеге баш бирмәс брәдәк үгезне тәгаенләдек. Төшкелекне ашатыр өчен олы-олы өч тәпән баллы катык оетмакчы булдык. Күп итеп икмәк пешердек, калач салдык.

Урак өмәсе — үзе бер бәйрәм ул. Көн буе яныпп-пешеп эшлиләр дә кичен ихата тутырып табынга җыелалар. Ит согыналар, шулпа чүмерәләр. Олырак ир-ат, чаярак бичә-чәчә шау-шу килеп бал эчә. Егет-җилән белән кыз-кыркын табыны болай да, бал эчми дә, кызмача була. Чулак Кашфулла кебек берәр җырлаучы моңлы итеп сузып та җибәрә.

Өмәләрдә эчкән әче балның
Шифалары җитте тамырга.
Өмәләрдә күзем төшкән ярны
Форсат килде туйлап алырга.

Бу җырның хикмәте бар аның. Өмәдә уңганлыгы белән данга чыккан кызның базары тиз үк күтәрелеп китә. Аның йортына уң балагын чыгарып салган яучы карчыклар ешрак сугыла башлый.

Өмәгә сайлап кына, көндез кулыннан эш килер, кичен табын кадерен белер кешеләрне генә чакыралар. Анда эләгү мәртәбәгә санала. Дөрес, кайбер әрсезрәк адәмнәр чакырганны да көтеп тормый.

Дүрт-биш көн алдан ук без кичке чәй вакытында кемне-кемне чакырачагыбызны чамалап, барлап чыктык. Мин хисапчы эшен башкардым.

— Мәрәһимгә әйтәсездер бит? — диде Олы инәем.

— Бичәсе чирле икән,— диде Сәлих агаем ашыгапошыга.

— Үзе килер.

Мин каләм белән сыза барган кәгазьгә тагы бер таяк өстәлде.

— Күрше-күләннең һәммәсенә дә кагылдыгызмы? — дип белеште бу юлы әтием.

— Галләмнәргә генә сугылмадык. Йомык Хәмзә барыбер өненнән чыкмас, дидек,— дип җаваплады өлкән агаем.

— Килмәсә, чакыруыбыз калсын. Күрше хакы бар. Хәтер калыштан булмасын...

Мин тагы ике таяк өстәп куйдым. Шуның белән вәссәлам.

Кояш чыгуга, безнең капка төбендә мәхшәр кайный иде. Кулбашларына ураклары салып, бөтенесе дә килгәннәр. Мәрәһим дә, Хәмзә белән Акйолдыз да бар, хәтта бер-ике «туң аяк»та күренә. Кыш көне кунактөшем чорында чакырылмый гына өйдән өйгә йөреп, аяклары бозланып каткан әрсез бәндәне «туң аяк» дип атыйлар. Җәй көне андыйларның аягы туң булмаса да, кадерләре барыбер шул ук була.

Якынрак кардәш-ыру, алдан әйтеп куелганча, атын җигеп килгән. Быел арыш басуы ерак. Җәяүләп озак барырга кирәк булачак. Аннан да болай, өмә урагында җәяү йөрү үзе килешә торган эш түгел. Яме китә.

Минем күзем, билгеле, теге икәүдә. Алар бер-берсеннән качмый да, сарылып та бармый. Акйолдыз кызкыркын арасында. Алар шырык-шырык көлешәләр. Култык астына кыңгыраулы гармунын кыстырган Мәрәһим, Мортаза агаем белән сөйләшкән булып, ике генә адым арырак басып тора. Әйтерсең, алар Кызлар тавы-

на да менмәгән, чут-чут үбешмәгән дә... Болар бөтенләй икенче кешеләр. Теге төнне мин, димәк, бүтән ир белән бүтән хатынны күргәнмен булып чыга. Хәтер калып китте хәтта. Әмма аларга сыный биреп караучы бер мин генә түгел икән. Әле теге якта, әле бу якта шул икәүнең я монысына, я тегесенә юнәлгән күз карашы елт-елт итеп кала.

Күк алашаны җигеп, капкадан әтием чыкты.

— Я, өмәчеләр, хәерле сәгатьтә! Кузгалыйк,— диде.— Утырышыгыз арбаларга. Кызларның иң уңганнарын, иң чибәрләрен үз яныма алам. Арба минеке, җыр сезнеке...

Кинәт ыгы-зыгы купты. Кыз-кыркын белән киленкиштә, чыр-чу килеп, әле теге арбага, әле бу арбага барып сугылды. Берсе ахирәте, икенчесе кардәше, өченчесе күршесе янына эләгергә тырышты. Я кучер сайлаган булып кыландылар: янәсе, монысының чәче бөдрә түгел, тегесенең бичәсе көнчел, бусының танавы кыеш. Табыла инде, шаярырга дисәң. Байтак чуалышкач, кызлар утырышып бетте. Тиешле арбаларына, тиешле кешеләре кырына егетләр дә тавыш-тынсыз гына сыенып алды. Олырак хатыннар белән ир-ат тегеләрдән калган арбаларны тутырды.

— Миннән дә чибәре, миннән дә уңганы юктыр, күрәсең, агаем,— дип, әтием арбасына шапшаклыгы белән дан тоткан кара шадра Ниса апа менеп утырды. Мин аның безгә ничек кардәш икәнен дә белеп бетермим. Ярты авыл аның нәселе инде.

— Әйдә, әйдә, Ниса,— дип хуплады әтием,— шадра да йөрәк яндыра.

— Әтү! — Ул вак кына ак тешләрен күрсәтеп елмаеп җибәрде. Ниса апам елмайдымы, бетте — үзгәрә дә китә. Йөзенә карап туймассың. Ул әтиемә борылды.— Әйткәч, әйтеп үк бетер инде: «Ак хатынның эче боз, каракайның эче куз»,— диген.

Мин, нишләптер, шунда Акйолдызга борылып кара-

дым — акмы, карамы ул? Ак та түгел, кара да түгел икән.

Алдагы атлар кузгалып китте. Бары өч кеше генә нәрсәгәдер икеләнгән, аптыргансыман, өч яры һаман басып тора, әйтерсең, өч багана: Хәмзә, Акйолдыз, Мәрәһим. Менә Мәрәһим дә, җәһәт кенә борылып, Мортаза агаемның арбасына сикерде. Киттеләр.

— Чибәрләр көймәсенә безне дә алыгыз әле! — диде Акйолдыз уенчак тавыш белән. Әмма мондый уенчаклык аңа — «бер чеметем бәхет өчен шул чаклы газап йөкләре йөкләп йөргән» кешегә — килешми иде. Мин ошатмадым. Әтием эндәшми генә күк алашаны аның ягына табан борды. Акйолдызга тәгаенләнгән урындагы печәнне чыбыркы сабы белән тетеп күпертеп куйды. Хәмзә әллә моны күрмәде, әллә юри күрмәмешкә салышты: сикерә бирде дә лып итеп шул урынга утырды. Сөмсез нәрсәкәй! Акйолдыз арбаның икенче ягына чыкты. Ниса апа аңа кулын сузды.

— Әйдә, аккошым, үземнең яныма! — диде,— ике чибәр тап килик әле бер. Без аларга төс түгел. И-и, үшән! — Ул Хәмзәнең кабыргасына төртеп алды.

Акйолдыз иренә арка биреп, арбаның читенә генә, үрәчәсенә генә утырды. Күк алаша дертләп алга омтылды. Акйолдызның ап-ак оек белән ап-ак чабата кигән аяклары кинәт артка чайкалып китте. Ул, сөрлегеп, чак-чак егылып төшмәде. Әлдә үрәчәгә тотынып калды. Иң азактан гына арба артына ыргып үзем менеп бастым. Алдагы атлар юырта да башлады. Без сөйләшми генә барабыз. Телгә беткән Ниса апа да, җор сүзле этием дә шымып калды. «Алачыгы бикле» Хәмзәне әйтеп торасы да юк.

Авыл очына җитәр-җитмәс үк Мәрәһим гармунын тартып җибәрде. Мин елт итеп Акйолдыз ягына әйләндем. Күңелем сизеп тора: гармун моңы бер аның өчен генә шулай сибелә. Моны Акйолдыз үзе дә сизәдер, мөгаен. Аның яңагында гөлт итеп куе кызыллык балкыды.

Балкыды да сүнде. Гармун ашкынып-талпынып моң түгә, ләкин аңа кушылып җыр башлаучы юк. Ни өчен дигәндә, эшкә барганда авыз күтәреп җырлау гадәтен мактап бетермиләр безнең урамда. Кайтканда әнә теләсәң күпме җырла. Өч этәчләр генә ул вакытлы-вакытсыз тавык урынына кыткылдашалар, этәч урынына кычкыралар. Без чаманы чамалый, әдәпне саклый беләбез.

Сакладың!.. Әнә бер кыз, чәрелдеген чыгарып, җыр башлады. Аңа тагы ике-өч тавыш кушылды. Дәртләре иртә кузгалган боларның! Тегендә җыр көчәйгән саен, безнең арбада сагыш арта бара төсле. Акйолдызның йөзен ниндидер моңсу шәүлә каплый килә, каплый килә. Аның чынлап та аккош муенына тартым муены сыгылып, башын түбән идергән.

...Ул чакта Хәмзә белән Акйолдызның, аркага арка куешып, ике тораташ шикелле, сүз дә кушышмый кеше арбасына утырып баруы мине әллә нинди хәвефле уйларга төшергән иде. Йомык Хәмзәнең бар табигате шул булгач, нәрсә кыласың. Авызындагы сүзен кыскыч белән тартып аласыңмыни? Ярый әле алда моң, җыр бар. Без шуларга ияреп барабыз. Арыш басуына ул вакыт тиз барып җиттек. Юл әллә ни озын булмады. Ә менә әле хәзер, шушы икәүнең озын гомере турында уйлаганда, җанымны кинәт калтырау алды. Бөтен гомер юлын нәкъ шулай, кеше арбасында аяк салындырып, аркага арка биреп утырган көе үтмәс микән бу икәү дим. Алда чакырып торган моң булса, тагы бер хәл иде. Әгәр ул да булмаса, булып та, соңыннан тынып калса...

Безнең арыш җирләребез басуның төрле урынына таралган — тегендә бер дисәтинә, монда бер пирәез, тегендә бер ачминнек, монда бер түтәрәм. Шуңа күрә өмәчеләр, икегә бүленеп, берсе — Куянлы бүләк ягына, икенчесе Бәрсүән буена китте. Төшкә кадәр аерым-аерым урдылар да, төшлекне, бергә җыйналып, Бәрсү-

ән буенда ашадылар. Бәрсүән суы — ул безнең авыл биләмәләренең чиге. Аръягында чит җирләр китә.

Төшкелеккә баллы катык белән юача булды. Өмә ашы үзе бер тамаша ул. Һәр табынга зур-зур табаклар куелган, тау-тау итеп юача киселгән. Табак тирәли утырган өмәчеләр кашыкларны биетә генә. Оялып, юанып утырсаң, ач калуыңны көт тә тор. Аннан бигрәк «ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен» дигән фәһемле сүзне безнекеләр бик күптән төшенеп алганнар. Сүлпән күшәү — үшән эшләүдән дә мәсхәрәлерәк нәрсә. Монысын эштән чыккан ялкау да белә.

Туя биргәчрәк шаяру, көлешү дә башланды. Я берәүнең кулындагы кашыгын кинәт табакка бәреп төшерәләр, я икенчесенең кулыннан, инде каптым дигәндә, калачын тартып алалар. Теге ачык авызлардан бөтенесе дә гөж килеп көлә шуннан. Бу юлы кашыгын чеметеп кенә тоткан Өч әтәч кызы Сажидә белән сүлпән Хәмзә көлкегә калды. Кашыгыннан язган Сажидә турсаеп торып ук китте. Юачаны умырдым дип авызын ачкан Хәмзәнең хәтта тешләре шакылдап калды. Әмма моңа аның исе китмәде. Бары танавын гына тартып куйды. Шунда ук үрелеп икенче телемне алды, ә Акйолдызның баягыча ике яңагына берьюлы кызыллык йөгерде. Мин үз ихтыярымнан тыш шулай күзәтчегә әйләндем. Акйолдыз белән Мәрәһимнән күземне читкә алсам, күңелемне аерып ала алмыйм. Арбадылар бит болар мине!

Мин баллы катыкны зур гына тустаганга үземә аерым салып алдым. Мин аны салам белән суырырга яратам. Кашык белән соскан ише түгел, болай ширбәте тамакны ныграк рәхәтләндерә. Ир җитеп, дөнья гизә башлагач, зур калаларда салам аша төрле коктейльләр чүмерергә туры килгәндә, мин гел уйлый торган булдым: шундый хикмәтле һөнәрне, мөгаен, бездән күчереп алганнардыр әле бу тәмле тамаклар, дидем. Башлары җиткән. Өйрәнер өчен дә акыл кирәк бит...

— Әллә катык үтә баллы булып чыкты инде, Ниса-ның әнә ирене иренгә ябышкан,— диде әтием.— Бер дә тавышы чыкмый.

— Кичен майлы ит согынганда кубар әле, агаем,— дип, вак кына ак тешләрен ялтыратты Ниса.— Итең генә мул булсын.

Бөтен халык урыныннан торганда, иң читтәге табын-да бер Исхак кына утырып калды. Ул бөтен җиргә — туйга да, җеназага да, эчү мәҗлесенә дә, өмәгә дә — чакырганны көтеп тормый, үзе килә. Авылның беренче «туң аягы» ул. Исхакны кумыйлар да, түргә дә чакыр-мыйлар. Ул үз урынын, үз дәрәҗәсен белә. Аның уры-ны — иң түбәндә, иң читтә. Нәзек озын буйлы, уклау юанлыгы гына муенлы, бәләкәч башлы бу коры сөяк адәмнең әкәмәт кушаматы бар. Аны «патша казнасы» дип йөртәләр. «Казна» дигәне шуны аңлата: үзе бихи-сап убыр, үзенә чеметем дә ит кунмый, ягъни, туймый да, оялмый да. Кем, кайчан таккандыр аңа бу куша-матны, берәү дә белми. Әмма иллегә җитеп барган бу бахыр, кыерсытылган ялгыз кеше, патша төшкәннән соң да, «патша казнасы» булып яши бирә. Ул бичәләр мендәр тышы ясый торган эре чәчәкле ситсыдан тегел-гән күлмәк киеп йөри. Ни өчен дисәң — шул иң арзан товар. Тагы алга узып әйтим: хәзерге заманда Исхак иң модный киенгән ирләрдән исәпләнер иде — тот та үзен Бродвейга чыгар да җибәр!

Исхак табакны күтәреп эчте дә төбен ялап куйды.

— Я, туйдыңмы инде, Исхак? — диде әтием.

— Туймадым, агай, тулдым,— дип җаваплады теге, тире агып торган озын муенын сыйпап.

— Әй, Исхак! Бәхәс бар. Отсаң, билемдәге каешны чишеп бирәм,— диде безнең җирән мыеклы Хисмәтулла исемле кодабыз. Ул тирә-якта беренче бәхәсче. Кай-дадыр чуваш авылында бәхәсләшеп, атын оттырган ул бер заман. «Атның бит елыгып үлүе дә ихтимал иде»,— дип юаткан ул бичәсен. «Ярый әле оттыргансың гына

икән, исән калган, егылып үлсә, үтә кызганыч булыр иде, атыбыз ифрат дан иде»,— дип куанган беркатлы кодачабыз.

Исхак та тәү тапкыр гына бәхәскә керми. Дөресрәге, ул үзе түгел, аның корсагы алышка чыга. Әле дә ул тиз үк төшенеп алды.

— Күпмегә? — дип сорады.

— Чүмәкәй тулы ун тустаганга.

— Бәхәс бар! Бәхәс бар! — дип шаулашты өмәчеләр.— Исхак пәһлеван алышка чыга. Мәхрүм булып калмагыз!

Халык тиз үк бәхәсчеләр янына җыелып алды.

— Кая, каешыңны чишеп күрсәт,— диде Исхак. Тегесе шундук каешын чиште. Җирән коданың киң җиз прәшкәле сары каешы могҗиза иде. Исхак аны, кулына алып, әйләндереп-әйләндереп карады да:

— Ач чак булса, каешың унбиш тустаганга, хәтта егермегә дә торырлык. Хәзер биштән арттыра алмыйм, — диде.

— Тугыз! Тугызга ризалашыгыз! — дип кычкырды берәү.

— Алты, — дип тартышты Исхак.

Җирән кода тегенең кулыннан каешны тартып ук алды, ә каешы — хәзинә иде.

— Алты тустаганга әнә мин Кендек белән дә бәхәсләшмим! — Ул башы белән минем якка ымлады. Миңа кыен булып китте. Их, кода, кода! Миннән дә булдыксыз, миннән дә ким кеше юк инде синеңчә, ә? Уң кулым елт итеп башымдагы кәпәчкә үрелде. Үрелде дә кире сүрелде. Кәпәч ташлап бәхәскә чыгар идем, кешеләрдән генә оят. Ни дисәң дә, теге «җирән мыек» кода ишарәте бит.

— Тук Исхакның хәленә керик, агай-эне! Сигезне түнтәрсә, җиткән, — дип гөрселдәде Чокыр башы Тимербай. Аның тавышы сикәлтәле җирдән буш мичкә тәгәрәткән төсле дыңгырдап ишетелә. Тимербайга бүтәннәр дә кушылды:

— Сигезе бик җиткән. Шунысын сыйдырса да ярый...
— Исхакның да эче эчәксез түгелдер бит!
— Сигезне дә булдыра алмый ул! Хәленнән килми!
— Элекке Исхак түгел инде, рәте беткән хәзер!
Монысын күрәләтә тегене чәмләндерү өчен әйтәләр — беленеп тора.
Исхак гөп иттереп корсагына ике тапкыр сугып алды:
— Аллага тапшырдык. Ярылсаң, ярыл, мине хур итмә! — диде ул. — Китерегез катыкны. Сигезгә кадәресен төгәл санагыз. Калганын күз күрер.
Олы табак катык, коштабактан чак кына кечерәк тустаган китерделәр.
— Сос, Тимербай кордаш! Син гадел кеше, кулың җиңел булыр, — диде Исхак.
— Я, утырышыйк. Исхак, син дә утыр,— диде этием. Бөтен кеше баскан җирендә лап итеп җиргә утырды, ләкин Исхак аягүрә көе калды.
— Мин басып эчәр идем, рөхсәт булса... — Ул ялварып этиемә карады.
— Рөхсәт юк! — дип кырт кисте каеш иясе. — Ашка хөрмәт кирәк!
Мин сизеп торам: аш кадерен яклап әйтмәде ул моны. Баскан көе эчсәң, карынга күбрәк сыя. Менә нәрсәдән шөрли җирән шайтан.
— Ярый, синеңчә булсын,— дип ризалашты Исхак. Ул табак алдына килеп тубыкланды. Җәелеп утырмады, бары тубыкланды гына; аның бөтен кыяфәте менә-менә очып китәргә җыенган торнага хас иде.
Тимербай тәүге тустаганны сосып бирде. Исхак аны җай гына чүмерергә кереште. Шундый җай чүмерә, хәтта арык бугазы буйлап катыкның эчкә төшкәне дә сизелми. Икенче тустаганны да шулай ашыкмый эчте. Өченчесен чүмергәндә, халык сукрана башлады:
— Шушы кадәр сүлпән кылангач, знамо, отар.
— Кичкә чаклы сузмакчы бит бу!

— Кит, шул да булдымы бәхәс! — диде бер кыз. — Ятим бозау чүпрәк имгән шәйле, билләһи!

— Оетасың, Исхак!

Исхак боларга әйләнеп тә карамады. Шулай да дүртенче тустаганны тизрәк бетерде. Бишенчесе белән алтынчысын бер-бер артлы түнтәреп кенә куйды. Аның бүлтәеп чыккан бугаз төене, ияк асты белән үңәче арасында арлы-бирле йөгереп, киләп сарып торды. Бу чак өмәчеләр утырган җирдән акрын-акрын Исхакка табан шуышты. Бара торгач, аны бөтенләй камап алдылар. Җиденчесенә кул сузганда, ул тирән көрсенеп куйды. Маңгаеннан моңача тамчылап торган тир, юл-юл булып, чөбердәп агарга тотынды. Тустаганны авызына китергәч, бүлт-бүлт итеп, аңа эре тамчы тама башлады. Чәчкәле күлмәк астындагы корсагы, тыгыз тышлы мендәргә охшап, күбеп чыкты. «Мендәр» чак кына да тибрәлми. Тынын каян ала икән бу кеше? Җиденче тустаганны ул өчкә бүлеп эчте. Эчте дә кикереп җибәрде.

— Җимерелеп төште! — диде кемдер. — Урын бушады.

Урын шулай да күп бушамады, ахры. Соңгы тустаганны Исхак бик авыр, бик җәфаланып чүмерде. Урт-лаганы тамагына китми җәфалады. Һәр йотымы газапка әйләнде. Аның авызына карап торган кешеләр, муен-нарын сузып, үзләре тырышып-тырышып йотарга керешт-те. Янәсе, Исхакка булышалар. Тәүдә уртламлап, азакка табан тамчылап кимеде катык. Шулай да кимеде. Төбенә төшә башлагач, Исхак чүмерүдән туктады да, озын ак телен сузып, песисыман яларга керешті. Ялап бетергәч, буш тустаганны һавага чөйде дә тотып алды. Аннан тамчы да таммады. Җирән кода сүзсез-нисез генә аның муенына киң җиз прәшкәле сары каешны китереп элде. Каешы илдә бер иде. Шул мәлдә мин гомеремдә тәүге һәм соңгы тапкыр Казна Исхак йөзендә шаян, хәйләкәр елмаю күрдем.

— Әйдә, мыек,— диде ул,— бәхәсне дәвам итәбез.

— Шартыңны әйт! — дип янә кабынды безнең кода.

— Бөтен адәм алдында ыштан бавыңны суырып алып бирер булсаң, тагы икене түнтәрәм.

Янә шау-шу купты:

— Давай, давай, мыек!

— Ну маладис, Исхак, чая ир икән!

— Сигез сыйган җирдә ун да сыяр, бирешмә!

— Әйдә, тәвәккәлләә!

— Кит, оятсызлар! — дип чәрелдәде бер бичә. — Тапканнар тамаша, өмә яме китәреп.

— Мин риза! Сос, Тимербай! — дип этәчләнде җирән кода. — Оятка калсам, оялганнар карамас.

Ләкин бу арада җиңүче батыр, эчен тоткан көе йөгерә-атлый барып, зуратлар артына посты. Уракчылар арасында да, кичке мәҗлестә дә ул бүтәнчә күренмәде. Әмма шул көннән алып дөнья куйганга кадәр Исхак биленнән теге каеш төшмәде: әйтерсең, аның бер әгъзасына әйләнде. Җирләгәндә дә каешын будырып җирләгәннәр аны: әҗәле алдыннан бердәнбер васыяте итеп мәрхүм шуны әйткән, имеш. Бәлки, кешенең үз гомерендә алган иң зур бүләге шушы булгандыр...

Әмма бәхәснең катысы, ярышның хәтәре алда иде.

Төштән соң бу яктагы вак өлешләрне ике төркем бергә кушылып урды. Өмә вакытында, халык күп булгач, җирнең буена түгел, аркылысына төшеп уралар. Кояш төшкелектән байтак узгач, өмәчеләр бер-берсеннән өч-дүрт адым ара калдырып, соңгы ачминнекнең ызанына буйдан-буйга килеп тезелде. Ап-ак алъяпкычлы кызлар, яулыкларын артка чөеп бәйләгән киленнәр, ачык изүле егетләр, аркалары тозланып беткән агайлар, иңбашларына уракларын салып, беразга тынып калды. Алда агарып пешкән арыш җире, тыныч күлгә охшап, оеп утыра. Менә шушы кешеләр менә-менә ярдан сикерерләр дә, колач җәеп, йөзеп китәрләр төсле.

Ниса апа белән Хәмзә арасында торган Акйолдыз кинәт атылып алга чыкты. Чыкты да елт итеп артына борылды. Башта ул бала итәкле яшел сатин күлмәгенең

итәген ике яктан да кыстырып куйды, терсәгенә чаклы җиңнәрен сызганды, чулпылары чылтырап торган ике толымын, бер кат муенына урап, артка салып бәйләде. Шуннан гына, кыннан кылыч суырып алган шикелле, сул иңбашындагы кызыл саплы ай урагын уң кулы белән тартып алды. Аның күзендә моңача безгә таныш булмаган чая очкыннар сикерешеп уйнады. Башка чакта гел елмаерга гына торган матур иреннәре кинәт тараеп, катып калды.

Көтәләр. Акйолдыз да аякларын аера биреп баскан килеш әлегә кузгалмый. Бик озак вакыт үткәндәй булды. Ниндидер бер арада бу хәл миңа төштәгесыман тоелды, ләкин монысы өн иде. Ә соңрак әле арыш ызанында басып торган шушы чибәр җиңги я биек кыя түбәсендә, я куркыныч шарлавык кырында, я котырынган янгын алдында торган көе күп тапкырлар төшемә керәчәк. Уң кулындагы кызыл саплы елтыр ай урагын югарыга сузып, ул инде кыядан егылды, инде шарлавыкка атылды, инде ялкынга ташланды дигәндә генә, уянып китәчәкмен. Уянгач, куанычымның чиге булмаячак. Бәлки, төшләрем бөтенләй үк буш та булмагандыр; бәлки, Акйолдызның өннәре минем шушы төшләремә охшабрак үткәндер...

Үтә сабыр, үтә әдәпле бу киленнең кылыгыннан халык гаҗәпкә калды. Нәрсә булыр икән? Кымшанган да адәм юк. Бөтен күзләр бер Акйолдызга төбәлгән. Тик Хәмзә генә бу тамашага күзләре белән түгел, очлаеп ачылган авызы белән карап тора.

— Безнең якта ирләр ашта түгел, эштә ярыша! — диде Акйолдыз. Аның тавышы, элекке кебек үк, чылтырап чыңлап китте. Чәм дә, гамь дә юк кебек иде бу тавышта. — Йөрәге җиткән ир чыксын минем белән алышка! Кайсыгыз тәвәккәлрәк? Ягез.

Өмәчеләр, әле булса ни дияргә дә белми, аптырап тора. Акйолдыз, үчекли биреп, тагы эндәште:

— Ир заты юкмыни бу авылда?

Мин, үзем дә сизмәстән, күзләрем белән Мәрәһимне эзләп таптым. Ул ызанның арырак очында башын иеп тора. «Сиңа әйтә бит, сиңа! Нәрсә җебеп торасың анда?» — дип кычкырасым килде.

— Давай, Хәмзә, — диде безнең әлеге җирән кода, — бичәң белән ярышып, булмаса, үзең күрсәт әле ирлегеңне!

— Әйдә, Хәмзә, әйдә! — диештеләр бүтәннәр.

— Мыек дөрес әйтә — Хәмзә ярышсын!

— Кемнең базары күпме икәнен күрик әле!

— Күрмирәк торсаң да ярар, — дип мөңгерәде Хәмзә. — Мин үз бичәмне ярышсыз да әллә кайчан җиңгәнмен. Ярышып маташырга ничу.

Шау-шу беразга янә тынды.

— Авылыбыз белән мәсхәрәгә калабыз бит, агай-эне! — дип үрсәләнергә кереште безнең гарьчел кодабыз. — Үзем чыгар идем, урагым үтмәс, кулым — булдыксыз. Тел белән урып булмый шул. Миннән башка бер генә чая ир дә юкмыни?

Ызан буйлап салмак кына атлап, Акйолдыз каршысына Мәрәһим килеп басты. Аның мәһабәт гәүдәсе янында буйга-сынга кайтышрак, чебегрәк бүтән кеше гадәттә тагы да кечерәеп, мескенләнеп кала. Шуңа күрә кәрлә адәмнәр аның тирәсендә чуалмаска тырыша. Ә бу юлы бәрде балыгысыман нечкә генә Акйолдыз пәһлеван алдында бәләкәйләнеп, югалып калмады, ничектер үсеп, гайрәтләнеп киткәндәй булды. Менә бер могҗиза!

— Мин чыгам, — диде баһадир. — Өчәр адым үлчә, Мортаза.— Үзе бары шунда гына Акйолдызның йөзенә күтәрелеп карады. Тегесенең ике битендә әлеге кызыллык гөлт итеп балкыды да тиз үк сүнде.

— Бирнәсе шул булыр: җиңеп тә генә чыксаң, бер үбәрсең, егылып үлсәң, шәһит үтәрсең... — дип, җыр сүзләре белән әйтеп куйды каешын оттырган кодабыз.

— Ир намусы бил каешы түгел, берсен салдырып

алсалар, икенчесен буып булмый, — дип төрттереп алды тегенә кемдер.

— «Батыр үлеме бичәдән» дигәнне ишеткәнебез бар. — Мәрәһим кинәт батыраеп китте. — Ни булса да булыр, Акйолдыздан җиңелеп хурлыкка калуымны да бер мәртәбәгә, бер бүләккә санармын.

— Бик ук кыйммәтле бүләк өмет итмисең икән, Мәрәһим... — Акйолдызның матур иреннәрендә беленер-беленмәс кенә елмаю чагылып калды.

— Язганы шул булса ни... — дип тегесе дә көлемсерәгәндәй итте. Үзенең зәңгәр күзләре шундый боек иде. Ул иңбашындагы урагын алды. Күзләре кинәт җанланып китте. — Тәвәккәлләдек, Акйолдыз! Син янсаң, мин сүнмәм...

Нинди матур сүзләр әйтеп салды Мәрәһим! Мин ул сүзләрнең асылына яхшы төшенәм. Бүтәннәрнең, әлбәттә, моңа зиһене җитми.

Өмәчеләр, бер-берсен бүлдереп, шарт куярга тотындылар:

— Көлтәләрен үзләре бәйли барамы? — дип сорады Ниса апа.

— Үзләре, үзләре!

— Ура барсыннар, бәйли барсыннар!

— Юк, юк! Башта урып чыксыннар, азактан бәйләсеннәр!

— Әй, җәмәгать! Үзләренә ничек җайлы, шулай итсеннәр!

— Әйе, үзләре теләгәнчә кылсыннар, бәхәс барыбер соңгы көлтәгәчә барачак бит!

Бу арада Мортаза агаем ачминнекнең аркылысына, башта бирге ызаннан өчәр адым үлчәп, арыш сабакларын өч урында төйнәп, ике алым билгеләде: шуннан, каршы ызанга чыгып, шундый ук билгеләр ясады. Бүтәннәр дилбегәгә дилбегә, арканга аркан ялгап, һәрберсе ачминнекнең аркылысына җитәрлек өч озын бау әзерләде. Шул бауларны, кара-каршы әлеге билгеләргә

туры китереп, бер ызаннан икенчесенә тарттылар. Тип-тигез ике бүлем булды — гаделнең дә гаделе килеп чыкты.

Хәзер башланачак. Мин Акйолдыз өчен хафаланмыйм. Аның беренче уракчы икәне илгә мәгълүм. Мәрәһим өчен борчылам менә. Дөрес, ул да эшкә уңган ир, булдыклы, маһир кеше. Ул читән үрсә, кызлар бәйләгән челтәр шикелле купшы килеп чыга. Җибән салса, чиркәү гөмбәзе шикелле килбәтле була. Ул ясап буяган тәрәзә капкачлары әллә каян елмаеп тора. Хәтта урманнан утын алып кайтканда да йөген ничек итте алай өйми, аны ыспай итеп, картинка кебек итеп төйи. Гармунны ничегрәк уйнавын әйтеп тә тормыйм инде, уенын бөтен тирә-як үзе ишетеп тора, ә менә уракка ничегрәк икән — кулыннан килә микән? Акйолдыз җиңелсә, тагы бер хәл, ул бичә кеше. Мәрәһим җиңелсә, бөтен авылга мәсхәрә. Ай-һай, хәерлегә булсын. Баксаң, эчемдә утырган коткычы — бәләкәч кенә шайтан баласы — Акйолдызның җиңүен дә теләп куя. Нигә, бичә кеше җиңелергә генә дигәнмени?

— Я, башлагыз! Җиңелгән еламасын. — Әлегә кадәр бәхәскә катнашмый торган әтием ярышчыларга шулай дип фатихасын бирде.

Акйолдыз белән Мәрәһим уртадагы бауның икесе ике ягына килеп басты. Бу икәү бер-берсен шушы сары дәрьяга батырырмы, әллә, киресенчә, коткарып алып чыгармы? Икесе дә жәл миңа, чөнки алар минем кешеләрем. Мин аларның серен саклыйм. Хәзер инде бу серне бүтән кешегә чишәсем дә килми. Ул минеке генә, юк, Олы инәем белән икебезнеке генә... Ә нигә соң алар янәшә басканнар? Һәр уракчы үз өлешенең уң почмагында булырга тиеш бит. Уңнан сулга уралар лабаса. Мәзәк икән бу Мәрәһим — тискәре якта тора, уңны сулдан аермый. Көлкегә кала бит инде! Аның хатасын төзәтәсем килә минем, тик җөрьәт кенә итә алмыйм.

— Башлап кул сал, Акйолдыз, — диде Мәрәһим.

Акйолдызның кызыл саплы елтыр урагы беренче

кабымын кырт иттереп тешләп өзде. Икенчесен, өченчесен дә чеметте. Шуннан китте бу, әй китте! Уң кулындагы урагы елт-елт итеп кенә кала, сул кулындагы учмасы урак көенә, ничектер, әйләнә-әйләнә биеп бара. Учмасы тулгач, урагы белән башак яныннан тота биреп, аны артка әйләндереп сала. Сала да яңадан башлый. Кәкре башкисәр тагы уйнарга, һәр сикерүдә тыгызая барган учма тагы биергә керешә. Әле генә алымының уң ягында булган уракчы «ә» дигәнче сул ягына килеп чыга. Артка урап куйган толымындагы чулпылары гына аратирә чылтырап куя. Йөзен күреп булмый. Башын күтәрми. Ул торган саен җиргә ябыша бара, ябыша бара төсле. Инде арыш сабакларын ул үзе учламый, тегеләр үзләре, укмашып, аның учына килеп керә, тик учыңны бер ачып, бер ябып кына өлгер. Ә елтыр урак бөтенләй ярсыды, бөтенләй шашты. Азактан тыеп туктатып булса ярар иде... Урак уру түгел бу, торганы белән бер тамаша — бәйге! Күзне аерып алып булмый, ә шулай да аерырга кирәк. Чөнки янәшәдә икенчесе бар.

Яңа гына килеп төшендем: Мәрәһим сулагай икән. Ул, бәләкәйрәк җәя чаклы урагы белән учмаларны умыра-умыра, тискәре якка урып китте. Аның көрәк чаклы учына берьюлы, сантыйныкы, ярты көлтә сыядыр. Монысы салмак салдыра, ләкин бер селтәүдә әллә ничаклы ялмап ала. Ай-һай, Алпамшамыни?!

Ике арадагы чиктә алар сирәк тап килешәләр. Тап килешсәләр дә, шунда ук икесе ике якка аерылып китә. Әйе, бер-берсенә күтәрелеп тә карый алмыйча, кавышалар да аерылышалар, кавышалар да аерылышалар. Күзгә-күз килешмәү, бәлки, яхшыдыр да әле. Әнә Мәрәһимнең ак күлмәге аркасына ябышты. Тәүдә яфрак чаклы гына күренгән дымлы тап, җәелә-җәелә барып, биленә җитте. Акйолдызның аркасында әлегә дым әсәре күренми. Монысы әйбәт. Булмасын да. Шундый сылу бичәгә кара тиргә бату һич тә килешмәс иде. Бәйгедә ак күбеккә батып килгән байталны да җәллим мин.

Алымнарның яртысына җиткәнче, алар тип-тиң килделәр. Аръягында хәлләр үзгәреп китте: башта Акйолдыз Мәрәһимне бер адым, соңга табан ике адым чамасы артта калдырды.

Ярышны моңача тавыш-тынсыз гына күзәткән кешеләр, һәркем үзенчә, я куана, я борчыла башлады. Бирәүләр Акйолдызны дәртләндерде: «Һай, килене дә килене! Килен түгел, хәзинә!», «Бүресе улаган икән бу йомык Хәмзәнең...», «Кадерен бел, бурсык!». «Бурсык» дип Хәмзәгә яңа кушамат та чәпәп куйды берәү.

Икенчеләр Мәрәһимне әйдәде: «Әй, гармунчы, ешрак бас урагың телләренә!», «Җиңелсәң, гарьлегеннән ят та үл инде», «Ашыкмагыз әле, аю котырса, кыр кәҗәсен куып тотар, ди!..», «Кыр кәҗәсенең койрык кыска, тоттырырга чамасы юк!» Кайсыдыр оятсызы әдәпкә сыймасрак сүзләр дә ычкындырды. Кемнәрдер хахылдап көлеп җибәрде. Ниса апам чыдамады, ике кулын биеренә таянып, теге ерык авызлар алдына килеп басты.

— Тыйнаксызлар, мәнсезләр, хәсисләр! Монавы хозур тамашаны, мөнәҗәт тыңлаган төсле, тын да алмый карау тиешле.— Ул башы белән уракчыларга ымлады: — Ә сез авыз күтәреп кешнисез, карт алашалар. Күңел биребрәк карагыз, юньсезләр.— Аның тавышы кинәт йомшарып, йөзе яктырып китте.— Сөбханаллламашалла! Тфү, тфү, күз тимәсен. Матурлык белән Көч ярыша бит монда! Чибәрлек белән Гайрәт алыша. Шундый бәйрәмне гомердә бер генә тапкыр күрергә мөмкин, әгәр насыйп булса... Соклана белергә кирәк. Ә сез, имансызлар, көчек талаштырган ише, өслэтәсез.

Ниса апамның сүзләреннән соң бу ярыш бөтенләй бүтән сыйфатка кереп, бүтән мәгънә алгансыман булды. «Матурлык белән Көч ярыша бит монда!..» Кайсысы җиңәр икән боларның? Нәкъ мөнәҗәт тыңлагандагы шикелле, халык тынып калды.

«Кыр кәҗәсе» инде, ике кулы белән тылсымлы хәрәкәтләр ясый-ясый гына, үз алымының очына чыгып

бара. Ул үзенең сихри уены белән шундый мавыккан, әйтерсең, бөтен дөньяда шушы арыш басуы да ул гына. Мәрәһим дә зур-зур учмаларны, каракош канат җилпегәнсыман селтәп, артына ешрак әйләнеп сала башлады. Акйолдыз соңгы учмасын кулына тоткан көе орчык кебек бер бөтерелеп, әйләнеп куйды. Мәрәһимнең янә бер сажиндай урасы бар иде, ләкин әле бәхәс бетмәгән. Кем аңгы көлтәсен алдарак бәйләп ташлый, шул җиңә. Акйолдыз инде көлтә бәйләргә тотынды. Ни арада бавын ясый, ни арада учмаларын җыя, ни арада көлтәсен буып ташлый. Артында тәгәрәшеп кенә торалар. Көлтәләре дә көлтә генә түгел, тыгыз билле сары курчак сынлы: шундый ыспайлар, көлеп торалар.

Шулай да бу эштә Мәрәһим тагы да җитезрәк булып чыкты. Байтак соңлап тотынса да, ярты юлны үтүгә, ул Акйолдызны куып җитте. Дөрес, аның көлтәләре бераз эрерәк. Эре көлтәгә учма күбрәк керә, эш җәһәтрәк бара, ләкин барыбер ул, кулым зур, көчем бихисап дип, чамадан арттырмый. Ир әдәбен саклый. Җирнең очына чыкканчы диярлек алар бергә бардылар. Иң ахырда гына Мәрәһим бер-ике көлтәгә узып киткән иде дә, тегесе шунда ук куып җитте. Утыз-кырык пар күз алдында алар чак кына да хәрамлашмады, бер-берсенә аз гына да буй бирмәде. (Күп гомерләр үткәч, әле килеп, менә мин нәрсә аңладым: Акйолдыз бу ярышны, мөгаен, Мәрәһимне җиңеп хур итү я үзе җиңелеп мәсхәрәгә калу өчен башлагандыр. Күрәсең, шулай итеп, ул Мәрәһимнән суынырга һәм тегене үзеннән биздерергә теләгәндер. Бәлки, мин хаталанамдыр да... Хатыннар күңеле төпсез дәрья, төбендә ниләр ятканын каян беләсең?)

Менә Акйолдыз соңгы көлтәсен бәйләде дә, селти биреп, аны Мәрәһим ягына ыргытты. Актыккы көлтәсен кысып торган ирнең кулбашына килеп тиде ул. Әмма теге әйләнеп тә карамады. Җәһәт кенә эшен бетереп, әле бәйләгән галәмәт юан көлтәсенең ялбыр башыннан

тотып, хатын алдына китереп бастырды. Үзе, башын ия биреп, тынып калды. Акйолдызның иреннәре буйлап әлеге арбаучан елмаю йөгерде. Ул тәүдә толымнарын чишеп артка ташлады, кыстырылган итәкләрен тартып төшерде. Шуннан гына Мәрәһимнең зәңгәр күзләренә туп-туры карап:

— Ир икәнсең, Мәрәһим... — диде.

«Мөнәҗәт тыңлау» тынлыгы шартлап ярылды. Кешеләр, үзләре җиңеп чыккан шикелле, бөтенесе берьюлы иркен тын алды. Рәхәт итеп тын алды.

— Шаукымлы бит әй болар! Җенле! — дип сокланды безнең җирән мыеклы кодабыз.

— Менә, ичмасам, болар бер-берсенә торырлык — пар килгәннәр! — дип мөһер сукты Ниса апа.

Ике уракчы арасына әтием килеп басты. Ниндидер бик кирәкле сүз әйтергә уйлый, ахры. Төбеннән үк сакалын учлап тотты. Иң акыллы сүзен шулай сакалыннан сыгып чыгара ул.

— Сез икегез дә җиңдегез, — диде ул. — Матур итеп җиңдегез. Мондый җиңүчеләргә затлы бүләкләр тиеш тә бит, затлы малларым юк. Сез яшьсез, уңгансыз, матурсыз. Һәркайсыгыз — үз-үзенә бүләк... Минем өмәмне олыладыгыз, күтәрдегез, ямьләдегез. Сагынып сөйләрлек тамаша ясадыгыз. Рәхмәт сиңа, килен! Мәрәһим, сиңа рәхмәт!..

Ничек кызык сөйләп ташлады әтием. Нәрсә бу — рәхмәтме, хуплаумы, сокланумы? Ә миңа калса, әтиемнең сүзләре фатихасымаграк булып ишетелде. Булмас ла! Нинди гадәт ул миндә — кеше күрмәгәнне күрәм, кеше ишетмәгәнне ишетәм? Әллә бер хыялыйга әйләнеп барам инде?

Моннан соң өмәчеләр яңадан җирнең буеннан-буена ызанга тезелде. Күз ачып йомганчы бер ачминнек арышны кырып та ташладылар. Шуның белән вәссәлам — безнең арыш урагы бетте. «Бәләкәй генә бөкре — бөтен

кырны бетерде» дигән табышмакның җавабы килеп тә чыкты менә...

Ихатаның төрле җиренә паласлар җәеп әзерләгән кичке табында Мәрһим белән Акйолдыз кара-каршы туры килде. Мин лапас башыннан бөтенесен дә күреп утырам. Мәрһим ашамады да, эчмәде дә, баштан ахырга кадәр бары гармун гына уйнады. Әй уйнады да соң! Бер чакта да бу кадәр үк ярсыганы юк иде аның. Минем күкрәгемне берчә күзгә күренмәс ниндидер җылы нурлар бәрелеп рәхәтләндерә, берчә утлы уклар өтеп тишкәли: йөрәгем берчә куанып талпына, берчә, әрнүенә чыдый алмый, күкрәк авызын дөмбәсләргә тотына. Кара моңнардан тыным кысыла. Менә беттем, буылып үлдем дигәндә, янә ак моңнар килеп, мине әҗәлемнән коткара. Мин яңадан һаваларга ашам.

Табындагы лампа пыскып кына янганга күрә, мин гармунчының йөзен шәйли алмыйм. Акйолдыз миңа бөтенләй арты белән утырган. Шулай да мин аларның бер-берсенә я өметле, я үтә моңсу караш ташлауларын сизәм. (Менә тагы — ни галәмәт — күзем күрмәгәнне үзем күреп утырам!) Бу кадәр ярсу, бу кадәр сагышлы моңнарга ничек түзә икән Акйолдыз, ничек дөрләп янып китми икән? Гармунчыга ара-тирә җырчылар кушылган була, ләкин алар бүген көйне генә бозалар. Сандугачка этәч ияргән төсле килеп чыга.

Бер арада Мәрһим безнең якта бөтенләй ишетелмәгән матур озын көй тартып җибәрде, уйнап чыкты да тагы башлады. Бөтен табынны хәйран калдырып, Акйолдызның йомшак моңлы тавышы яңгырады. Хәйран калуыбыз шуннан: елдан артык вакыт үтеп, аның җырлавын тәү тапкыр ишетәбез. Бездә халык җырга әвәс. Сүз сөйләргә тартынганы да җырларга тартынмый. Моңы бармы, юкмы — мөгери бирә.

Нинди матур, талгын җырлый Акйолдыз. Бүтән табыннарда да шау-шу тиз үк басылды. Моңа кадәр, күршесен дә тыңламый, тик үз сүзен генә сөйләп утыр-

ган кызмача ирләр дә тынып калды. Акйолдызның тавышы, төнге авыл өстеннән акрын гына агылып, әллә кая еракларга юл алды. Бәлки, чит җирләрдә адашып калган җыр үзенең туган төягенә, Дим үренә, табан киткәндер? Китсен. Бөтен дөньяда шылт иткән өн аңа комачауламый, аны тыймый. Юк, китеп олакмады, кире урап кайтты. Миңа моннан, югарыдан, бөтенесе дә күренеп тора.

Айкый да гына чайкый керләр юа,
Талмый микән аның беләккәйләре
чайкаганда.
Күршедә генә торып, күрә йөреп,
Янмый микән аның йөрәккәйләре
кич ятканда,—

дип җырлады безнең чибәр җиңгәчәбез. Аннан соң, башын түбән иеп, байтак заман кымшанмый да утырды. Шушы җыр — Акйолдызның безгә мәгълүм гомерендәге тәүге һәм соңгы җыры булды. Аның моңлы тавышын башкача мин дә, бүтәннәр дә ишетмәдек. Куанычларын да, хәсрәтләрен дә җырсыз уздырды ул.

Моннан ары табынның гайрәте кайтты. Бүтәнчә җыр көйгә килмәде, юлыннан язды. Халык таралыша башлады. Исергәнрәкләр, һәркем үзенчә кәмит күрсәтеп бераз утырды да, алар да кайтып китте. Бәйрәм сүнде...

Иртәгесен таң белән Мәрәһим башын алып чыгып китте. Куенына бер түтәрәм икмәк тыккан, култык астына гармунын кыстырган да шулай авылдан чыгып киткән. «Мине тиз арада көтмә, мин озак кәсепкә юл тоттым», — дигән ул хатынына. Күзләрен, кышларын читкә кәсепкә еш йөргән Мәрәһимнең хатыны моңа артык аптырамаган да. «Ярый, исән йөре, калган бар игенне үзем җыештырып куярмын. Тик шулай да чамасыз озаклама, буемда бар...» — дигән. Бу кадәресен читән аша теге Кара Йомагол бичәсе ишетеп торган. Мәрәһим урам капкасыннан түгел, ындыр артыннан чыгып киткән. Шуннан, Галләм картның бакча артына

килеп, бик озак басып торган. Торган, торган да, кинәт борылып, тугай ягына йөгергән. Имеш, башкача авылга әйләнеп тә карамаган. Боларны кем күзәтеп торгандыр, анысы безгә караңгы.

Атна үтте, ай үтте. Чыпчык белән ала каргадан башка кош калмады авылда, юньлерәкләре җылы якка уңайлады. Әбиләр чуагын ямьләп, үрмәкүч авының алтын җепләре оча. Ә Мәрһимнән хат та, хәбәр дә юк һаман. Халык шомлана башлады. Шулай да каз өмәләре чорында кош теледәй генә хат килеп төшкән бугай. Анда да исән-саулыгын гына сөйләгән дә йөкле калган бичәсенә үтенечен әйткән: «Ул туса, исемен үзең тап, кыз туса Акйолдыз дип куш», — дигән. Хатын иренең сүзеннән чыкмаган. Ыжгырып торган январь числосында дөнья күргән кыз балага атасы теләгән исемне бирде — Акйолдыз дип кушты. Мин белгән икенче бала үз исеме белән дөньяга килде. Тәүгесе — Кара Йомаголның игез сыңары Хәбибулла иде. Бәләкәй Акйолдызны, әлбәттә, минем Олы инәем кабул итте. Әмма мин инде хәзер андый эшләргә катнашмыйм.

Өлкән Акйолдызның суга барганын да, мал эчереп йөргәнен дә, курада утын кискәнен дә күреп торабыз. Ара-тирә ул, йомыш табып, минем Бикә җиңгәм янына да кереп чыга. Ул әүвәлгечә үк — үзе басынкы, үзе алчак, үзе итагатьле. Тик шул җанны җилкетә торган сихри елмаюы гына әллә кая китеп олакты. Иң-иң сердәше булган бер хатынга бик-бик каты сер итеп кенә Акйолдыз болай дигән, имеш: «Бөтенебезне дә газаптан коткарыйм дип киткәндер дә бит... Ул дигәнчә килеп чыкмады. Катырак әрнүләргә төштем, катырак сагышларга сабыштым, эч-бавырларыма кара каннар савып, яна-яна кара күмерләргә калды. Күкрәк эчемдә йөрәк түгел, көйрәп торган куз йөртәм. Тагы күпмегә чыдармын, белмим... Ә чыдарга кирәк. Эчтән үлсәң дә, тыштан яшәргә кирәк...» Бәлки, ул бу сүзләрне әйтмәгәндер дә. Аның өчен кешеләр үзләре сөйлиләрдер, ихтимал.

Әмма гаеп итеп түгел... Янә Акйолдыз болай да дигән икән: «Бер килеп, куркаклыкта гаепләп, үзен каһәрлим дә шунда ук каһәрләремне кире кайтарып алам. Каргышларым башына төшмәсен дип котларым оча. Сакла үзен, саклый гына күр дип, ходайга ялварам...» Менә нинди серләр бәреп чыккан сагышлы җиңгинең эченнән. Сернең канаты җитез. Бер ычкынса, илне тиз урап чыга ул. Бер кавырсыны безгә дә кагылып үтте. Әмма Акйолдыз исемен кыстырып, һичкем гайбәт тә, гыйбрәт тә сөйләмәде. Әүвәлгечә, хәтта әүвәлгедән дә болай һәркем аны «ах» итеп торыр булды.

Беркөнне Акйолдыз, безгә килеп, Бикә җиңгәм белән чаршау эчендә байтак сөйләшеп утырды. Бу юлы ул миңа боек күренде. Киткәндә, Бикә җиңгәм дә аңа ияреп чыкты. Өйдә без Олы инәем белән икәү генә калдык. Тегеләр киткәч, Олы инәем, эч-бавырына ут капкандай тирән көрсенеп, уфылдап куйды.

— Нигә уфылдыйсың, Олы инәем? — дидем мин.

Ул тәрәзә аша каядыр еракка карап, байтак заман эндәшми утырды. Шуннан борылып минем күзләремә туп-туры карады да сөйләп китте.

— Хәзер инде син үндүрт белән барасың. Егет корына керәп киләсең. Укуың да зур. Мин сөйләгәнне аңларсың шәт. Тыңла... Адәм балалары анадан яртышар гына булып туа. Аяк-куллары бөтен, башы-күзе төзек көе дөньяга кабул итәм мин кешене, ә үземнең эчләрем өзелә: «И, бахыркаем, — дим, — үз яртыңны табарсыңмы икән? Тапсаң гына ярар иде», — димен. Табышмасалар, күктәге бихисап йолдызлар кебек җемелдәшеп, гомер буе бер-берсен эзләп йөри бичара бәндәләр. Аларны кушарга, күрәсең, ходайның да кодрәтеннән килмидер. Кодрәтеннән килсә, җиһан буйлап адашып йөргәннәр шулкадәр күп булмас иде... Әнә Акйолдыз белән Мәрәһим ике яртыдан бер бөтен булырга тиеш җан ияләре дә бит... Үз вакытында табышмагач, зар-интизар булып, адашып йөриләр.

«Егет корына кереп килсәм дә», Олы инәем әйткәннәрнең төп мәгънәсен аңлап җитмәдем. Күңелемә сеңсә, акылыма сыймады. Ул сүзләрнең фаҗигале мәгънәсен төшенү миңа бик күп еллар узгач кына — йөзәрләгән кешеләрнең язмышы өчен янып, үз язмышымның карлы бураннарын, эссе җилләрен татып, гомер бакый үзем акылга утырырга тырышып та, акылга утырудан бар өметләрне өзгәч кенә — насыйп булачак. Бу коточкыч дөреслекне аңлау өчен әле үз җаныңның кырык тапкыр уртага бүленеп, кырык тапкыр кушылуы кирәк булачак...

Әмма мин Олы инәемнең тел төбен бөтенләй үк аңламыйм түгел, аңлыйм. Аның үз яртысы турында сорыйм дип авыз ачкач, тыелып калдым. Ярый тыелдым. Сорасам, ахмак була идем. Үзем күреп торам бит инде: әтием берәү, әнием икәү. Кайсысы ярты, кайсысы бөтен икәнен белеп бетерерлекме монда? Буталышып беткән. Балалары гына да өч төрле. Мортаза агаем Олы инәемнең төпчек улы, Сайран авылында торган аның өлкән кызы Гайниямал апам — Кече инәемнең ахирәте. Сәлих агаем Кече инәемнең артыннан килгән малае. Ул ярты ятим исәпләнә. Шуңа күрә аны тиз үк кагып-сугып бармыйлар. Калганнарыбыз өченче ояныкы. Мин боларны, әлбәттә, күптән түгел белдем.

Минем иреннәрем кыймылдаганны Олы инәем шунда ук сизеп алды:

— Я, сора. Уйлаганыңны әйт.

Байтактан инде чәч җибәрдем, үземә кызыл тарак сатып алдым, кышын муеныма зәңгәрле-яшелле ефәк шарф буам, резинкалы пима киям, кичләрен клубка да, тула баскан җиргә дә йөрим. Мине санга санамаган теге кыз үзе хәзер төрле ишарәләр ясый, мин генә сер бирмим. Мәхәббәттән күңелем кайтты. Аның каравы төрле җәмәгать эшләренә ихлас катнашам. Мәктәптәге җыелышларда кызып-кызып речьләр сөйлим, ә менә Олы инәем янына килдемме, сабый булам да куям.

— Юкчы, — дигән булдым, — болай гына.

— Хәйләләмә. Син бит минем яртым турында сорамакчы идең.

Минем чәч төпләрем чемердәп китте. Әллә күрәзә инде минем бу Олы инәем!

— Соравыңа менә җавап бирәм. Без, бәндәләр, бүтәннәрне җиңелрәк төшенәбез, аларга тизрәк бәя бирәбез, башкаларны сагалаган бәлаләрне үзләреннән алдарак күрәбез. Кеше тормышы кола-яланда, үз тормышың кара урманда үтә. Мин үз уйларымның, үз хәстәрләремнең очына бервакытта да чыга алмадым. Үз урманымда үзем адашып йөрдем... Әйе, этиең синең бик һәйбәт кеше, әмма мине ул үз яртысы итеп кабул кылмады. Ул гаепле түгел моңа. Мин үзем аңа туры килмәдем, аның ише булып чыкмадым. Мин утырып калган кыз идем. Ярлы булсак та, малга алданып, этием мине теләсә кемгә тотып бирмәде, үз иркемә куйды. Башта, күңелемә ошаганны көтеп, ни җиттегә ризалык бирмәдем, азактан яучылар безнең бусагага бөтенләй аяк басмас булды. Егерме дүрткә җиттем шулай. Тирә-якта миннән карт кыз юк иде — гарип-горәбәсеннән башка. Беркөн безнең өйгә какча гына бер карт белән сөлек кебек сылу егет килеп керде. Карты — синең карт атаң, егете — Бүз егетнең ише — унҗиде яшьлек синең этиең иде. Мин коелдым да төштем. Шунда ук җанымны әсир итте ул. «Шомлы язмышым менә кем икән!» — дип уйладым. Мине тиңсетмәячәген дә шунда ук сиздем мин — йөрәгемне әрнү өйкәп үтте. Шигем дөрескә чыкты. Тиңсенә алмады ул мине. Миннән болайрак үзе газапланды. Әле яшь чакта Имәнлек үрендә кунып урак урганда, төн уртасында торам да, бөтенесен дә ташлап китмәкче булып, үзебезнең авыл ягына карап йөгерәм. Йөгерәм-йөгерәм дә таң атуга кире урап кайтам. Йөрәгем басылгандай була. Өч-дүрт тапкыр шулай иттем. Бишектәге бала уянгач, этиең торып, кычкыракычкыра мине эзләп йөри икән. Мин урап килгәч, һични булмагандай: «Ят, азрак черем итеп ал»,— ди. «Күңелең

шулай бер дә генә тартмагач, нигә мине алдың соң? Нигә борылып кына кире чыгып китмәдең?» — дип буылып елыйм. Ул эндәшми. Бик күп еллар үткәч кенә минем әлеге соравыма болай дип җавап бирде: «Җәлләдем. Җәлләп алдым. Шул җәйне генә печән чапканда, искәрмәстән, бер бүдәнәнең ике аягын да чалгы белән чабып өзгән идем. Теге бичара канатларын бер-ике генә тапкыр каккан булды да кырын ятты. Башын күтәрә биреп, «Их кеше!» дигәндәй, шундый боегып карады миңа — йөрәгем жу итеп китте. Тәүге күрүемдә шул бүдәнәне искә төшердең син. Җәлләдем». Рәнҗетмәде дә, какмады да әтиең, әмма иш күрмәде. Без аның белән кушылып бербөтен була алмадык. Монда яшь аермасының да, холык төрлелегенең дә, акыл-фигыль дәрәҗәсенең дә катнашы, бәлки, аз булгандыр. Без төрле сыңарлар булып чыктык — бөтен хикмәт шунда... Һәр кешенең үз хакыйкате була, әмма бөтен адәм өчен уртак, һәркемнең гомерлек таянычы булган, бөтен хәвеф-хәтәрләрдән саклый торган тагы бер хакыйкать бар. Ул хакыйкатьнең исеме м ә х ә б б ә т. (Олы инәем әүвәлгечә минем битемнән сөеп куйды.) Син, тәү тапкыр колкынып, минем муеныма сарылгач, мин үземә болай дип әйттем: «Хәзер инде бу дөньяда яшәү куркыныч түгел миңа...»

Без сагынганны белгәндерме, үз сагышына түзә алмагандырмы — анысы безгә караңгы — язгы ерганаклар ерылганда, Мәрәһим авылга кире әйләнеп кайтты. Мин сагыну хакында җирле-юкка гына әйтмәдем. Кешене үз йортыннан читкә хыял яки әрнү алып китә, ә сагыш алып кайта. Соңыннан моны мин үзем дә күп тапкырлар татыдым.

Бу юлы Мәрәһим, тезенә җитеп торган кунычлы зур кара итекләре белән урам уртасыннан эре-эре атлап, Югары очтан Түбән очка көпә-көндез үтте. Кешеләр я тәрәзәгә капланып, я капка төбенә чыгып баскан көе карап калды аны. Очраган берәүгә ачык елмаеп, ихлас

сәлам бирде, ләкин, тукталып, берәүдән дә хәл-әхвәл сорашмады, атлавын белде. Аркасындагы йөге зур булмаса да, култык астындагы гармуны моңача без күреп, без ишеткән ише генә түгел иде. Кала кала шул. Мәчетләре дә, чиркәүләре дә, йортлары да, хәтта гармуннары да зур аның.

Кояш кыздырып, гөрләвекләр ага башлагач, бөтен адәм урам як киртә буендагы карны, көрәк белән ыргытып, читкә тарата. Без, егет-җилән, шушы эш белән булашканда кайтып төште Мәрәһим. Автомобиль узып киткәндәге шикелле, бөтенебез дә көрәкләребезгә таяндык та каттык. Галләмнәр турыннан узганда, ул башын уңга бора бирде. Шул чак — әллә аягы таеп китте инде — чак кына чайкалгандай булды. Күпме тилмереп карасаң да, Акйолдыз анда юк инде... Хәмзә башка чыкты. Атна эчендә генә чокыр аръягындагы Тукран урамына күчеп киттеләр. Аларның өе моннан, безнең капка төбеннән, күренеп тә тора.

Мәрәһим кайтуга бар галәм куанды. Аннан башка илнең яме, моңы ким иде. Ул кайтканчы авылда алмашынулар артык булмады. Тик сельсовет кына бүтән. Әүвәлге сельсовет Ташбулат үткән көздә тегермәннән кайтышлый, йоклап китеп, арбадан егылып имгәнде. Арт тәгәрмәч тегенең билен тапап узган икән. Исерек булган дисәң, авызына да ала торган зат түгел. Халык хәйран аптырады моңа. «Бәла аяк астында ята шул», — диештеләр кешеләр. Ташбулат хәзер, уртага бөкләнеп, арт санын сөйрәп йөри. Шулай да язга табан Сәмигулланың каберенә, үзе ясап, бик матур рәшәткә куйды. Кулы һөнәр белә икән.

Нәкъ Мәрәһим кайтып төшкән көннәрдә авылда галәмәт шау-шу күтәрелде, ыгы-зыгы купты. Берәүләр куана, икенчеләр борчыла, өченчеләр шикләнә. Кая барма — әңгәмә, кая карама — бәхәс. Клубта көн саен җыелыш. Кайчак таңда гына таралышалар. Тула өмәләре, бәби туйлары, аулак өйләр бөтенләй тукталды.

Колхозга язылу башланды.

Безнең өйдә тартыш зур булды. Колхозга керергә теш-тырнагы белән каршы торган Мортаза агаем, үзенә тияр малны алып, бүленеп чыкты. Ул тискәре нәрсәне Бикә җиңгинең күз яшьләре дә җиңә алмады. «Ялкау Дүсмәт белән Казна Исхак тиңе булып йөрер хәлем юк! — дип кәпәч сукты ул. — Минем кулымнан эш килә. Әгәр минем ишеләр сайланып кына бер колхоз булса, дүрт куллап ризамын. Төзесеннәр шундый колхоз!» (Минем Мортаза агаем өчен, әйтергә кирәк, ул елны да, аннан соң да махсус колхоз төзелмәде. Ике елга якын каңгырып йөрде дә, шактый бөлгәч, шул безгә яраган артельгә килеп керде. Күпмедер вакыттан хәтта бригадир булып китте.)

Өйдә нәкъ әлеге бәхәсләр куерган чакта, безнең Кәлимулла исемле кылыйрак күзле юаш кына бер нәселебез кереп елап чыкты. «Ата-бабаларым күрмәгән атка тиендем. Карап торган шушы мөлкәтемне ят кулларга ничек итеп тапшырыйм? Имеш, бичәләрне дә бергә җыялар икән. Чукынсын бичәләре! Атым газиз, атым... Ялындагы бер бөртек кылы өчен җаным фида!» — дип, ул йодрыгын кинәт югары чөйде дә матчага асылынган җиделе лампаны ялгыш бәреп төшерде. Кәлимулла баштанаяк кәрәчингә коенды.

— Шунда тукта, баҗа, ары кызма, — диде әтием, — югыйсә өстеңдәге кәрәчин гөлтләп янып китәр...

— Янса... — Ул, икенче кулын селтәп, сәкегә утырды.— Атым юк иде аранда, кайгым юк иде буранда. Ат дигәнем кайгы булып чыкты болай булгач...

— Менә атыңны илтеп тапшыр да кайгыңнан котыл, — дип киңәш бирде әтием. Кәлимулла җанланып китте.

— Чынлап та, әллә шулай итәргәме икән, баҗа? Әйткәнеңчә, гомер буе атсыз яшәдем, иншалла, үлмәдем, хәтта уфтанмадым да. Балдызың да нәфселе булмады мал җәһәтеннән... Аның каравы, шөкер, балаларга

бай булдык. Берсе артыннан икенчесе тупылдап кына торды.

— Дөньяңның җитешмәгән җире юк, хәйран... Ә үзең монда килеп елап утырасың, — дип төрттермәкче итте Мортаза агаем. Беркатлы Кәлимулла әче кинаяне аңламады.

— Шулай шул, Мортаза, зарланыр урыным юк. Бөтенебез дә сау-сәламәтбез, гарип-горәбә түгелбез.— Ипкә килүчән Кәлимулла авып та төште.— Инде, бажа, синең ише кара акылы белән дан тоткан адәмнән узып, мөгез чыгарып булмас. Тәвәккәлләрмен, шәт. Тик менә лампаны гына әрәм иттем. Дуамал...

Безнең нәселебезнең шушы күндәмлеге, тиз ышанып баручанлыгы турында төрле имеш-мимешләр йөри. Янәсе, безнең апабыз, әле яшь чакта, беркөн эңгер вакытында тыкрык читәне буенда мут кына бер ир белән сөйләшепме, серләшепме торган икән. Җизнәбез моны үз күзләре белән күреп калган. Бичәсе өйгә кайткач, бу бәйләнмәкче итә башлаган, ә тегесе шыр тана, ди.

— Соң бит, бичәкәй, үз күзләрем белән күрдем, ышан инде. Зинһар өчен, ышан,— дип инәлә икән бу елардай булып.

— Ышанма күзеңә, ышан сүземә! — дип боерган бичәсе.— Нәрсә эшләп әле син үзеңнең кылый күзеңне минем туры сүземнән өстен куясың? Каян килгән андый башбаштаклык?

Кәлимулла шым булган. Бичәсенең эреннән куркып түгел, үзенең хатасын танып, оялуыннан тынып калган ул.

— Эңгер куе иде бит...— дип акланган Кәлимулла.— Минем бичә тавышы белән кем болай сөйләшә икән дип, шикләнгән идем шикләнүен. Баксаң, шигем тәки дөрескә чыкты.

Ә Кәлимулланың ат алып кайтуы теге чак бөтен урам өчен бер мәзәк булды. Кыска торыклы йонтач

җирән алашаны хуҗа, алып кайткач та, абзарына япмады. Аны урам як киртәгә бәйләп куйды. Туйганчы күреп калсыннар әйдә! Качырга тартым бу хайван, олы башын киртәгә салып, кичкә кадәр тамашачылар кабул итте. Әмма теләсә кем алдында баш иеп, иелепсыгылып бармады. Дәрәҗәсен югары тотты. Ат янына халык иң күп җыелган мәлдә генә курага нииндидер бер сөмсез брәдәк эт килеп керде. Минем апам, озын чыбык тотып, этне куарга керешге. Эт тиз генә буйсынмады. Абзар ягына омтылды. Кәлимулланың киртәгә атланып утырган кече малае Заһидулла кинәт сөрәнләп җибәрде:

— Әни, әни, дим! Ат менеп ку этне! Ат менеп! Җәяү йөрү җитәр инде!!!

Безнең җизни тиешле кешебез менә шушы дан аргамакны үз куллары белән колхозга илтеп тапшырырга карар кылды һәм тапшырып да.

Минем әтием алга да омтылмый, артка да калмый — бер көе бара дөньяда. Шуңа күрә аны «урта хәлле» диләр. Әле дә шулай. Адәмнән узмый да, калмый да колхозга керде. Күк алашаны, бер келәтне, тимер сабан белән агач тырманы, арба белән чананы яздырып кайтты. Бу хакта кичке чәй вакытында алдан киңәшләшү булган иде. Киңәштә ике инәем дә, Сәлих агаем белән мин дә — ягъни олылардан бөтенебез дә катнаштык.

Колхозга язылган кешеләрнең исемлеген, һәр өй эчендәге һәммә җан иясен тезеп, авыл Советына элеп куйдылар. Анда Мәрәһимнәр җиденче, Акйолдызлар егерме дүртенче, без утызынчы урында торабыз. (Минем исемне ачык итеп, аеруча килештереп язганнар.) Тегеләрне мин ихтыярымнан тыш берчак үз карамагыма алдым да хәзер шуннан һич кенә дә котылып булмый. Нинди генә хәл килеп чыкса да, Акйолдыз белән Мәрәһимне янәшә куям. Минем аңымда алар әллә кайчан икесе бербөтенгә әйләнгән. Их, дим, дөнья-

да да алар, минем күңелемдәге шикелле, бүленми яшәсәләр иде! Ә Хәмзәне мин үз уем белән җитәкләп алам да Мәрәһимнәр йортына кертеп җибәрәм. Кайчандыр бозылган гаделлекне үземчә төзәтәм, һәркемне, янәсе, тиешле урынына куям. Исәрмен дә инде... Төптәнрәк уйлаганда, гаилә таратучы, оя туздыручы булып чыгам бит. Моның өчен мине бик каты орышырга, хөкем итәргә кирәк.

Тегеләрнең бер тезмәдә торуына күңелем үтә риза. Һәм, үзем исән вакытта, алар бер тезмәдә калдылар да. Тик соңрак берсен әҗәл генә җуеп ташлады. Ә аңа кадәр әле күпме сулар ташып кайтты, күпме кошлар сайрап тынды.

Акйолдыз белән Мәрәһимнең икесен бергә мин тагы ике генә тапкыр күрдем.

Кошлар сайрап торган бик матур көндә бөтен колхоз диярлек Усман төбәгенә печән эшенә чыкты. Арыш урагы кысып килгәнгә, печәнне дәррәү генә бетереп ташларга кирәк иде. Кыз-кыркын печән җыя, үсмер егетләр, атка атланып, сөйрәткеч белән чүмәлә тартты-ра, бичә-чәчә белән ир-ат, пар-пар булып, безгә чүмәлә төяп җибәрә, олы агайлар кибән коя. Төбәкнең иң ерак читендәге вак зireклек буенда «минем кешеләрем» чүмәлә озатып тора. Мәрәһим сәнәк белән төйи, Акйолдыз арттан тырматып тазарта бара. Хәмитҗан белән минем өлешкә шушы икәү төште, юырттырып, алмаш-тилмәш болар тирәсенә киләбез дә җитәбез. Мин бигрәк тә ашыгам. Аларны бергә күрү рәхәт миңа. Акйолдызның юка, матур иреннәреннән теге сихри елмаю көне буе диярлек китмәде. Бермәл чак кына сүнеп торды да тагы кабынды.

Мәрәһим сәнәге белән бер чәнечкәндә, арттыра димәгез, ярты чүмәләне китерә дә сала. Үзе, зәңгәр күзләреннән нур чәчеп, хахылдап көлә. Менә, ичмасам, кемдә гайрәт! Мин ат өстендә яртылаш борылган көе алардан күземне аерып та ала алмыйм. Моның әдәп-

сезлек икәнен дә аңлыйм, әмма һичнәрсә кылып булмый.

Бермәл, чүмәлә төялеп бетәр-бетмәстә генә, Мәрәһим Акйолдызны кинәт биленнән кысып алды да печән өстенә ыргытты. Минем өркәк атым, үрә ыргып, читкә тайчанды, мин очып төштем, ул торып чапты. Шунда ук минем өстемә Акйолдыз килеп төште. Ул, мөгаен, чүмәлә башыннан тәгәрәгәндер. Шул чак миңа, күкнең зәңгәр чаршавы ертылып, әллә кайда төптә яткан йолдызлар җемелдәп күренде. Берсе ап-ак иде. Мин, аңа табан карап, очып та киттем. Офык читендә тоташ елмаю балкый... Юньсез аттан егылып төшүем мине әнә нинди биеклекләргә ашырды. Акйолдыз шунда ук тезләнеп минем чәчемне сыйпарга тотынды.

— Берәр җирең авыртмадымы, бөдрә баш? — диде. Мин, рәхәтлекнең чигенә чыгудан исереп, эндәшә алмыйм. Ул хафага калды.— Ни җирең авырта? — дип кабатлады шундый ягымлы итеп. Күзләреннән сагыш бөркелеп чыкты. Кешене кызганганда аның күзләре үтә хәсрәтле була икән. Мин җирдән аермый гына башымны чайкадым.

— Уф! Коткайларым очты! — диде.

— Минем бер җирем дә авыртмады. Ат тәбәшәк, җир йомшак,— дигән булдым, торып утыргач. Шулай да сырт буе ару гына янып тора иде.

Бу арада Мәрәһим исәр атны тотып китерде. Күрәсең, ерак китмәгәндер. Хәтта чүмәләсе дә коелып бетмәгән.

— Менә бер дуамал,— дип шелтәләгән булды тегене Акйолдыз,— адәм имгәтүең бар бит. Ике адәмне берьюлы.— Ул янә минем чәчемнән сыйпап алды. Мин, сикереп, аягүрә бастым. Мәрәһимнең олы хатынны, бала урынына кул очына алып, йомшак печәнгә ыргытуын бу юлы гаепкә алмадым. Киресенчә, килешеп торгандай булды бу эш.

Шулай да Мәрәһим минем алда нишләп болай шук

кыланды икән? Мине исәнкә алмавымы, әллә үз итүеме бу? Әллә дәртенә, ашкынуына чыдый алмадымы икән? Ярый, яхшысына юрыйк. Җитеп килгән егетне санга санамаска хакы юк аның... Минем шундый тугрылык белән сер саклавымны алар сизенергә тиеш. Тугрылыкны адәм түгел, зирәгрәк ат та сизә.

Минем чүмәлә яңадан төялеп бетүгә, Хәмитҗан да юырттырып килеп җитте. Эш тагы да үз җаена салынды. Кичкә кадәр бу дөньяда без өчебез бер булып яшәдек — Акйолдыз, Мәрәһим, мин... Акйолдыз белән Мәрәһим икесе бергә бәхетнең җанлы сыны иде. Ә мин шушы бәхетнең шаһиты булдым. Азактан да мин кайта-кайта куаначакмын: бәхетнең шаһиты булу — үзе бәхет икән!

Моннан соң Усман төбәге минем хыялымда бәхетлеләр төбәгенә әйләнде. Шул тугайдан узган саен, теге зиреклек ягына борылып, озак-озак карап торам. Мәрәһим сәнәген, Акйолдыз тырмасын кулбашына салып, миңа каршы килеп чыгар төсле. Алар һаман яшьләр, һаман бәхетлеләр. Ә вак зиреклек бер күргәндә киртәлек, икенче күргәндә бүрәнәлек урманга әйләнде. Буйга җитеп беткәч кенә, аны кисеп ташладылар. Шул ук урында яңа курпылар үсеп чыкты, елдан-ел тамыры ныгыды, буйга үрләде. Менә күпме яфрак шаулап коелды! Ә теге икәүне тагы бер тапкыр янәшә күрүдән һаман өмет өзмим. И хыяллар! Йөздән берегез генә гамәлгә ашса икән!

Мин җан өшеткеч бәхетсезлекнең дә шаһиты булдым. 1941 елның егерме дүртенче июнендә алар аерылыштылар. Сугышка китүчеләрнең тәүге төркеме ул көн клуб алдына җыелды. Мәйдан тулы иярле ат, парлап-парлап җигелгән арбалар, бричкалар...

Сөйләнәсе сүзләр сөйләнеп, биреләсе үгетләр бирелеп, әйтеләчәк теләкләр әйтелеп бетте. Менә-менә юлга чыгарга тиешләр. Хушлашасы гына калды. Озатучыларның күпчелеге — хатын-кыз да яшь-җилкенчәк. Яуга китүчеләргә ата-аналар, борынгы йола буенча, йорт-

та гына фатиха биреп кала. Алар озата чыкмыйлар. Иярдәге яугирнең[1] өзәңгесенә тотынып, аның бичәсе генә бераз ияреп бара. Яуга озатканда сыктау-чеңләү гаеп санала, әдәпкә сыймый. Чыдамлык белән сабырлык — фатихага бәрабәр. Китәр юлга тамган күз яшьләре яугирнең күңелен боектыра, ихтыярын какшата.

Һәр китүченең кырында хатыны яки кәләше басып тора. Байтагы бәләкәй улын яки кызын күтәргән. Бүтәннәр читтәнрәк аларны уратып алган. Халык шулкадәр күп булуга карамастан, шау-шу да, ыгы-зыгы да юк. Хәтта имчәк балалары да еламый.

Без нишләптер Акйолдыз белән янәшә туры килдек. Бу юлы аның иренә чакыру килмәгән иде әле. Ул китми. Мин Сәлих агаемны озатам. Агаем аз гына кызмача. «Чоландагы әрҗәдә безнең тракторның ачкычлары ята,— дип шыбырдый ул җиңгәмнең колагына,— шуларны иртәгә үк Сәйфуллага илтеп тапшыр... Дөньяда иң кирәкле нәрсә — ачкыч ул. Ни өчен, дисәң, алтын ачкыч турында әкият чыгарганнар...» Җиңгәм эндәшми. Анда ачкыч кайгысы юк.

Өрлектәй Мәрәһим төркем эчендә аерылып тора. Бер ягына аның җыйнак кына тары көлтәсе төсле, төптән юантык, күрер күзгә мөлаем генә бичәсе, икенче ягына — чем-кара чәчле, атасыныкы шикелле зәпзәңгәр күзле кызы Акйолдыз баскан. Ун яшьләр чамасындагы бу бала нәрсәсе беләндер өлкән Акйолдызга тарткансыман. Ирексездән мин Акйолдызларның тәүдә зурысына, аннан бәләкәенә тагы бер кат сыный биреп күз ташлыйм. Охшашканнар шул! Менә бер могҗиза! Әллә үзем һаман юкны бар итеп күрәм инде?!

Алдындагы кызын Мәрәһим ике кулы белән сак кына биленнән алды да баш өстенә күтәрде:

— Хушлашыйк, вакыт,— диде. Аның көр тавышы мәйдан өстеннән күкрәп үтте. Ул озатучыларга күз йө-

---

[1] Яугир — сугышчы.

гертеп чыкты. Тавышын аз гына түбәнәйтеп, дәвам итте: — Авылдашлар! Акйолдыз белән ант итәм, ике кат ант итәм: ил йөзенә кызыллык китермәм. Әйтер сүзем шул.

«Җыйнак тары көлтәсе», гүя, сөрлегеп китеп, иренең уң кабыргасына сөялде. Сөялде дә, чайкалып, кире үз урынына утырды. Янымдагы Акйолдыз сизелер-сизелмәс кенә минем җиңемнәм тотып алды. Шунда ук кире җибәрде. Мәрәһим кызын җиргә бастырды. Тынкыш Вәлетдин, бичәсе кулыннан алып, кечкенә генә малаен һавага чөйде:

— Улым Җиһандар белән!..

— Туфрагыбыз белән...— дип өстәде Әсгать. Аның баласы түгел, әлегә хатыны да юк. Ә туфракның, шул туфрактагы бөтен ямьнең бәһасын да, кадерен дә белә ул.

Саубуллашу башланды. Хатыннары ирләренә, кәләшләре тиздән булачак кияүләренә сыенды. Әлбәттә, тиздән булачак... Дошманны җәһәт кенә җиңеп, сугышны бетереп кайтырлар да гөрләтеп туйлар ясарлар. Әлбәттә, ясарлар... Берәүләр кул бирешеп, икенчеләр кочаклашып, үтә чаялары үбешеп хушлаша. Мәрәһим туры каткан көе безнең якка карап тик тора. Сул култык астына кызының башын кыскан да бармаклары белән аның чәчен сыйпый. Уң ягындагы хатыны, кемгәдер урын биргәндәй, чигенеп, иренең артына басты. Шушы мәл Акйолдыз минем беләгемнән умырып тотты. Үзе каядыр омтыла, үзе мине җибәрми.

Хушлашып беткәч, тавыш куера төште. Берәүләр арбаларга, бричкаларга утырышты, икенчеләр атларына атланды. Мәрәһим өлешенә колхозның иң атаклы кара айгыры Козгын туры килгән. Арбалылар юлга чыгып тезелгәч кенә, Мәрәһим баганадан чишеп айгырын авызлыклады. Шуннан олы гәүдәсен, елт иттереп, ияр өстенә кундырды. Кузгалып киттеләр. Китүчеләр, аларны районга чаклы озата чыгучылар бөтенләй тынып

калган мәйданнан акрын гына ераклаша барды. Аның саен Акйолдызның бармаклары минем беләгемә тирәнрәк батты. Җир буе җир киткәч, Мәрәһим, атын туктатып, каерылып карады. Шул чак Акйолдыз, кыр кәҗәсесыман кинәт үрә сикереп, китүчеләр артыннан торып йөгерде. Мәрәһим, атының башын каерып кире борды да хатынга каршы җилдереп килде. Акйолдыз, өзәңгегә тотынып, янәшә атламакчы иде, тегесе ирек бирмәде, гайрәтле куллары белән эләктереп алды да үз алдына утыртты. Утыртты да, арбаларны, сыбайлыларны узып, чабып китте. Аларны Мөкеш үренә җиткәнче карап калдык. Аннан соң беразга күздән югалдылар. Хуплаучы да, хурлаучы да булмады. Хәтта Мәрәһимнең хатыны да чыдәды, буйга үзеннән чак кына кайтыш кызын җитәкләп, башкалар рәтендә кымшанмый да карап торды. Шушы мәл мин бу хатын алдында үземне ничектер гаеплесыман сиздем. Монысы да бит «минем кешем», ә үзем аны хәсрәтле иткән серләрне саклыйм... Бара торгач, бөтенләй буталдым, ахры. Бөтенесен дә кызганам...

Тегеләр тагы бер түбәне узгач, офык читенә кереп тәмам баттылар. Кабат калкырлармы икән?

Берсе калыкты, икенчесе батты.

Язмыш мине, күрәсездер, еш кына хәтәр вакыйгаларның, көтелмәгән фаҗигаләрнең, гадәттән тыш хәлләрнең гуаһы ясады.

Сугыш бетүгә ел тулып үткән иде инде. Авылга кайткач, ниндидер йомыш белән авыл Советына кердем.

— Җиңүдән соң күпме гомер үтте, ә кешеләр һаман һәлак булалар. Үзләре өчен әллә кайчан үлгәннәр, әле килеп безнең өчен икенче кат гүр иясе булалар,— дип зарланды председатель.— Әле берсе, әле икенчесе хакында «Пал смертью храбрых» кәгазе килеп тора.

Ул миңа таушалып беткән кәгазь кисәге сузды. Похоронная. Учымны өтеп алды. Мондый яман язуны мин

беренче кат кулыма тоттым. Кеше үлемен тегендә мин күп күрдем. Ә үлем хәбәрен үз күзләрем белән тәү тапкыр күрәм. Болай караганда, сыер сатарга бирелә торган рөхсәт кәгазеннән һич кенә дә аерылмый. Ә үзендә бөтен бер кешенең әҗәле ята. Бу язуны төзәтеп тә, үзгәртеп тә, яндырып та булмый. Ул — кешенең мәңгелек шәхси таныткмасы: «Батырларча һәлак булды...» Кем? Гвардия старшинасы Мәрәһим Зәбиров.

Председатель, минем кулдан кәгазьне кире алып, әйләндереп-әйләндереп карады. Әйтерсең, аннан хата эзли, шул хатаны табарга өмет итә.

— Мондый хәбәрне иясенә тапшыру хәзер бигрәк тә кыен, кайгы яңартып... Тордым-тордым да, нәрсә кыласың, Акйолдызга кеше җибәрдем инде. Сугышның соңгы айларында гына Хәмзә дә кайдадыр Венгриядә госпитальдә үлеп калды. Килгәч килә инде бәндәгә... Мәрәһимнең бичәсе кар астында калган агулы бодай ашап үлде теге җәйне. Бер ай эчендә бик күп халык кырылды ул чак. Ачлык бәласе инде. Мәрәһимнең бөтенләй үксез калган кызын Акйолдыз үзенә алып кайтты. Терәүгә таяныч булып яшәп яталар шулай. Кызы җитеп килә инде.

Берьюлы күпме кайгы-хәсрәт сөйләп ташлады уң кулын Сталинград янында күмеп кайткан бу кеше. Кулы турында ул күрешкәндә үк әйтте: «Сулы белән генә күрешергә туры килә инде. Уңын Мамай курганына күмеп калдырдым. Данлы курганга»,— диде.

Тыштан ук кычкырып-укыныпмы, карганыпмы — таяк таянган бер карчык килеп керде.

— Сөбханалла, машалла! Ходайның ачы каһәре суккыры! — диде ул, бусагага абынып. Җәһәт кенә атлап, председатель алдына килеп басты. Бу — Өч этәч урамын дер калтыратып торкан Майтап әби иде.

— Утырып сөйләшик, җиңги, менә түрдән уз,— дип председатель урын күрсәтте.

— Утырмыйм! — дип киреләнде карчык.— Баструк-

та черет анавы Әлмисакны, персидәтель булсаң. Минем хөкемем бетте ул ристанга. Кичә тагы кәҗәмне сауган. Тамагына агу булып баргыры! Көтүче түгел бу, бер бур булып чыкты бит. Көпә-көндез адәм талый! Бирән!

Майтап әби түр башындагы утыргычка узып утырды, кулындагы таяк очын ияк астына терәде. Таягын шунда ук кире читкә алды:

— Чыгар хөкемеңне! Югыйсә бүген сөтен сауса, иртәгә үзен суеп ашар кәҗәмне. Иманы юк аның!

— Ярый, чара күрербез.

— Чара кирәкми миңа, җәза кирәк. Әлмисакка каты җәза бир! Бүтәннәргә гыйбрәт булырлык итеп...

— Ярар, җәза да бирербез, әгәр гаебе исбат ителсә.

— Исбаты-ние бары да шунда — бер кәҗә җилендә! Элекке көн өч тустаган чыккан иде, кичә икегә торып калды. Ибраһим пәйгамбәр тотып иммәгәндер бит инде аны! — Карчыкның тавышы кинәт йомшарып, хәтта калтыранып китте.— Үзем өченмени ул сөт? Миңа үсәргә түгел, үләргә генә калган. Әнә ике ятим оныгым, кулларына тустаган тотып, көтү кайтканны көн саен тилмереп көтеп утыра. Шул ятим сабыйлар ризыгын ашый бит ул убыр.

Бер-ике минут эчендә Майтап әбинең зары мине кырыкка түнтәрде. Башта ул ачуымны китерде, аннан кызыкка әйләнде, азак килеп, йөрәгемне өтеп, бөтен рухымны куырып алды.

— Сүзең раска чыкса, Әлмисакка каты җәза бирермен,— дип вәгъдә итте председатель.— Бик каты җәза.

— Бир шул. Әмма баструкка яптырма. Аның да баласы итәк тулы. Яхшы көннән эшләмәгәндер бит бу эшне, бахырың. Син аңа тел җәзасы бир. Нык иттереп...

Безнең авылда әллә килделе-киттеле кешеләр күп, әллә тормыш үзе шулай килделе-киттеле инде. Бер карасаң, тегеләйбез, бер карасаң, болайбыз. Үзебез ут чәчәбез, үзебез су сибәбез. Ләкин бу безнең аумакай-

лыгыбыз түгел. Безнең кәефебез уйлаган уебызга, ишеткән сүзебезгә буйсына, бөтен хикмәт менә шунда.

Майтап әби таяк очына ияген янә куйды. Тагы ишек ачылды. Хәле барынча җыйнак, пөхтә киенгән Акйолдыз күренде. Аның аягында ап-ак оек, тирән резин галош. Төскә-башка артык үзгәрмәгән. Яулыгын ул әүвәлгечә үк артка чөеп бәйләгән. Чигәсендә берәм-сәрәм ак чәчләр күренә. Толымының очында шул ук чулпылар чылтырый. Ул елмайгандай итте, ләкин мин күреп өйрәнгән, мин сокланып туймаган балкышның әсәре дә юк иде. Ул куш куллап башта Майтап әби белән күреште, шуннан председатель белән миңа кул бирде. Минем кулны тиз генә ычкындырмады.

— Кунак бар ласа... Менә исән йөргәч, әйләнеп тә кайткансың. Бәхетле икәнсең. Бүтәннәрне дә бәхетле иткәнсең... Озын гомерле бул.— Кинәт аның матур иреннәрендә теге елмаю гөлт итеп кабынып китте.— Усман төбәгендә печән җыйганда син малай гына идең. Гомер буе исемдә булды шул төбәк... Матур булып төшләремә керә... Өмет өзмим әле...

Әйе, мин кайттым. Ләкин күпмегә кайтуым гына билгесез. Ике үпкәмне дә туберкулез кимерә. Шулай да кайтып күзгә күрендем, үзем дә күрдем.

— Чакырткансың икән,— ул, ике күзен мөлдерәтеп, председательгә карады.— Әллә Мәрһим җәһәтеннән бер-бер өметле хәбәр бармы?

— Утыр әле, Акйолдыз.

Ул шунда ук мич кырыендагы тимер тышлы сандык өстенә барып утырды. Ике кулын кушырып, тезләренә куйды. Бүлмәне таш тынлыгы басты. Мин тимер тышлы сандыкны таныдым. Ул күптән тора монда. Сәмигулла карамагындагы җәмәгать акчасы теге чак шушы сандыктан урланган иде. Ул миндә күргән саен шом уятты, каракка бирешкәне өчен ачуымны китерде. Менә әле дә. Юкка анда утырды Акйолдыз. Хәер, хәзер инде барыбер.

Председатель исән кулы белән маңгаен уып алды.

— Нәрсә дип кенә башлыйм икән?.. Өмет үтерү — адәм үтерү белән бер. Соңгы өметеңнән яздырам. Каһәрләмә, карендәш. Мә, үзең укы...— Председательнең калтыранган кулы баягы кәгазьне Акйолдызга сузды.

Алыйммы икән, юкмы икән дигәндәй, Акйолдыз икеләнеп торды. Шуннан, ике кулын сузып, яңа чыккан тавык чебешен тоткандай, язуны куш учына алды. Аның чибәр ак йөзе минем күз алдымда карая барды, карая барды. Ләкин аның аккош муеныдай нечкә муены сыгылып төшмәде, авыр хәсрәт тулы башы иелмәде. Ул таш сынга әйләнде. Тәне калды, җаны кайдадыр очып китте. Әмма күпкә түгел. Ул җан тагы үз тәненә урап кайтты:

— Ярабби! — дип, ачы кычкырып җибәрде ул.— Шушы кадәр мәхәббәт тә кешене үлемнән саклый алмагач инде! Нәрсәгә ышанырга, нәрсәгә таянырга кала соң? Ә мин шулкадәр ышанган идем... Мәхәббәтнең әҗәлдән өстен булуы турында күпме китап язганнар. Ул китапларны бит мин иман урынына күреп укыдым, һәрбер сүзен ятлап алдым. Бөтенесе дә ялган, бөтенесе дә уйдырма микәнни? — Үлем кәгазе яткан куш учын ул тагы алга сузды.— Шундый баһадирдан шушы гына торып калсын инде. Гаделлек кайда?!

Акйолдыз янә шымды. Майтап әби ияген таяк очыннан алды.

— Ә мин әйтәм, килен, шул мәхәббәт аркасында башын салган ул,— дип, аяусыз хөкем чыгарды карчык.— Гашыйк булдымы, ирнең асылы шаша да китә, күзенә ак-кара күренми аның, курку-өркүне оныта. Мәрәһим азамат та, янәсе, сиңа шәпле күренергә тырышып, алдын-артын карамый, гарасатның эченә кергәндер. Син күзәтеп торганны сизгәндер ул. Иң алга, яуның иң хәтәррәк җиренә ташлангандыр. Имеш, кара: менә мин нindirәк! Әнә шулай харап булгандыр аның

башкайлары.— Ул туктады да уфылдап өстәп куйды.— Әллә җыен җирле-юкны сөйләп ташладым инде?..

Карчыкның шәфкатьсез сүзләре Акйолдызга бертөрле дә тәэсир итмәде, ахры. Ул хәтта кузгалып та куймады. Ә минем гимнастеркамның ике кесәсендә йөргән ике хат тере күмер урынына күкрәгемне кинәт өтеп алды.

Берсе аның болай башлана...

Юк, ашыкмыйк әле. Хатка кадәр Акйолдыз турындагы әңгәмәне тәмамлыйк. Ул башкача эндәшмәде дә, бөртек яшь тә тамызмады. Майтап карчык чыгып китте. Без өчәү, белмим, күпме утырганбыздыр, башлап Акйолдыз кузгалды. Без аны, болдырга чыгып, озатып калдык. Хатын өенә табан юнәлмәде, теге елны Мәрәһим үз алдынаияргә утыртып чапкан Мөкеш үре ягына китте.

Чибәрлеген гомер ташламас бу җиңгәмне, байтак еллар узгач, тагы очраттым. Урамда тап булыштык. Йөзе аның яңадан яктырып киткән, ничектер тынычланып калган. Кыяфәтенә, төсенә әле булса картлык кагылмаган. Нинди ныклы токым, бирешмәс зат бу?! Ул дүрт-биш яшьлек малай җитәкләп алган. Баланы аз гына алга уздыра биреп, куанычын яшерми, әйтеп салды:

— Акйолдызның улы. Мәрәһим исемле.

Малай карт атасына шулкадәр охшаган — суйган да каплаган. Усман төбәгендәге яшь зирек үсентеләре дә шулай үзләренең төп аталарына охшыйлар. Мин белгәннән бирле генә өченче буын урман гомер сөрә.

Менә шулай. Күпме ташкыннар, әйләнмәләр, өермәләр үтеп, Акйолдыз үзенең ярына килеп чыкты. Әлбәттә, күңеле көткән теләге, яшьтән җаны омтылган яры шушы булмагандыр... Хәер, яшь чагында ул кая, кайсы тарафка баруы, нинди ярга килеп сугылуы турында, бәлки, уйламагандыр да. Теге вакытта аның

бары бүгенге көне һәм иртәгәне көтүе генә бар иде. Шуннан арысы томанда иде.

— Юанычым, таянычым шушы инде,— дип, малайны үзенә сыендырды ул. Тегесе, башын күтәреп, ике бөртек фирүзә ташы кебек күзләрен Акйолдызга төбәде. Мөгаен, бу малайны сөйгәндә дә аңа аңлашылып ук бетмәгән сүзләр әйтеләдер: «Мәрһим чаткысы — дөньямның яктысы». Бәлки, сүзләре бүтәнрәктер, ләкин асылы барыбер шулдыр.

Без хушлаштык, һәркем үз юлына китте.

...Түш кесәмдәге хатларның берсе болай башлана иде: «Минем хатынымның үлеменә сез сәбәпче булдыгыз».

Ике хат

Коточкыч хөкем. «Әйе, аны мәхәббәтегез белән сез һәлак иттегез. Үлем газабы кичергәндә ул гел сезнең исемне әйтеп саташты. Һушына килгән арада, хәле җиткәнчә, сөйләргә тырышты. Мендәр астыннан алып, сезнең хатларны күрсәтте. Мин аларны укыдым. Аздыручы иблис тозаклары иде алар. Хатынлы ир була торып, сезнең ир хатынын яратырга ни хакыгыз бар? Ничек җөрьәт иттегез? Кем бирде сезгә андый хокукны? Нинди моральгә, кем мораленә сыя бу?!

Мин аны дәваланырга җибәрдем, ә сез һәлак иттегез. Ишетәсезме? Мин сезгә ләгънәт яудырам. Мин сезнең хатны укып торганда Людмила әйтте: «Каһәрләмә аны,— диде.— Сез икегез дә миннән торып калачаксыз. Каһәрләмә. Киресенчә, минем үлемем сезне якынайтырга тиеш. Башыңны югалтма». Ул газаплангайда минем сездә кайгым юк иде әле. Мин аны акылымнан шашып ярата идем. Бөтен дөньяда бер ул гына иде. Людмиланы июльнең егерме тугызында җирләдек.

Җеназа беткәч, коеп яңгыр яуды. Яман яшен булды. Үземне яшен атуын теләдем. Атмады. Ул да теләсә ни вакытта атмый шул... Төнгә чаклы мин каберенең аяк очында утырдым. Нинди бөек, нинди илаһи җан иде! Хәер, андый булмаса, сезне дә шул кадәр үк яндырмас иде... Шайтан алгыры! Сезнең януыгызда минем ни эшем бар?! Онытырга, сезне бөтенләй онытырга теләдем. Булмады. Дәрья чаклы хәсрәтем сезгә булган нәфрәтне киметмәсме дип уйлаган идем баштарак. Кимемәде. Кайгыга нәфрәт килеп кушылды. Иң тәүдә сезнең хатларны өзгәләп җилгә очырдым... Ачу басылмады. Мин сезне күралмыйм. Мең кат каргыйм. Әгәр Людмиланы алып киткән чахотка сезне тиз арада буып ташламаса, мин сездән үч алачакмын. Әҗәлдән котылсагыз да, миннән котыла алмаячаксыз. Аклану да, ярлыкау да юк сезгә! Гомер буе баш очыгызда, үткер кылычсыман, минем нәфрәтем, минем янавым асылынып торачак. Өстегезгә нинди генә бәла килсә дә, минем җәзам булыр ул. Котылу юк сезгә! Юк!!!»

Хәсрәтләре, газаплары эченә сыймаган кеше менә шулай дип язган иде.

Ә миңа соң, миңа нинди җинаятьләрем өчен чыкты әле бу каты хөкем? Языкларым шулкадәр үк зур микәнни?

Менә бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм.

Әүвәл әйткәнемчә, сугыш беткәч, минем үпкәләремне туберкулез кимерә башлады. Башта байтак вакыт Румыниядә Предял дигән җирдә дәваланып яттым. Тау һавасы, карагай урманы, яз кояшы — бөтенесе дә минем карамакта иде. Ләкин шифасы тимәде. Җитмәсә, күрше палатада, кич булдымы, берәү йөрәк әрнеткеч итеп җырларга тотына:

Что стоишь, качаясь,
Тонкая рябина,
Головой касаясь,
До самого тына?..

Там через дорогу
За рекой широкой
Тоже одинокий
Дуб стоит высокий...
Но нельзя рябине
К дубу перебраться,
Видать, сиротине
Век одной качаться.

Мин үземне миләшнең сөйгән яры — елга аръягындагы бахыр имән хәлендә хис итәм. Ялгызлыктан, сагыштан минем яфракларым саргая, тамырым корый. Мин тәмам җирседем. Шуны күреп, врачлар мине туган илгә, Кырымга, күчерделәр.

Симферопольдән Ялтага без госпиталь автобусында бардык. Төрле поездларда төрле госпитальләргә килгән авыруларны башта, кычкырып, вокзал мәйданына бергә җыйдылар. Төш җитүгә генә кузгалып киттек. Борма-борма тау юлы, бөркү һава безне бик нык йончытты. Алда утырган яшь кенә бер хатын бигрәк тә газап чикте. Буылып-буылып ютәлли дә укшырга тотына. Алуштада тукталгач, аны күршеләре җитәкләп алып чыкты. Маңгае ап-ак, кан әсәре юк. Үзе дер-дер калтырый. Җитмәсә, уңайсызланып, башын түбән ия. Әйтерсең, ул гаепле.

— Тирән итеп, күкрәгеңне тутырып тын ал,— дип киңәш бирә бер майор.

— Тын алып булса икән ул... Болай интекмәс тә идем,— диде хатын, үзе тагы буылып ютәлләргә керешге.

— Кинәт климат үзгәртү шулай итә инде, күнегерсең әле,— дип юатты безне каршы алган сестра.

Алуштадан тиз үк китмәдек. Ару гына тын алдык. Теге хатынга да бераз хәл керде. Юлның икенче яртысында ул артык җәфаланмады. Хәтта ара-тирә оеп та киткәләде бугай. Мин иң артта утырам. Бөтенесен дә ачык кына күрә алмыйм. Шулай да шәйлим: урындык-

ның йомшак артына кырынрак куелган башы тыныч кына тирбәлеп бара. Монысы әйбәт.

Ялтада тау ягындагы бер урам тупигына килеп тукталу булды, автобустан халык шыбырдап коела да башлады. Яшел вещмешоклар аскан яки чит яклардан кайткан купшы саквояжлар тоткан хәрбиләр, катыргы чемодан күтәргән яки култыгына төенчек кыстырган хатын-кызлар төрле якка сибелде. Мин иң азактан чыктым. Безнең госпитальгә кадәр әле байтак күтәреләсе бар икән. «Байтак» дигәнем чирле кеше чамалаган чама инде ул. Булса, ике йөз адым булыр. Туктыйтуктый барам. Бераз үткәч, карасам, өй күләгәсендә баягы хатын чемоданы өстендә утыра. Мин, аның турына җиткәч, тагы туктадым.

— Миңа карамагыз, атлагыз. Мин үз җаем белән барып җитәрмен әле. Хәзер миңа хәл керде инде,— диде.

Мин тәү тапкыр аның йөзенә җентекләп карадым. Ул әйтерлек чибәр түгел иде, әмма озын керфекле ике кара күзенә бөтен җиһан кереп баткан дисәм, чак кына да арттыру булмас. Шушы кадәр үк төпсез, шушы кадәр үк сагышлы күзләрне минем моңа чаклы да, моннан соң да күргәнем булмады. Янә куллары. Озын бармаклы моңсу куллары игътибарымны тартты. Аларны мин азактан «акыллы куллар» дип атаячакмын.

— Барыгыз сез, бара торыгыз...

Сиңа әйтүе җиңел. Ә менә мин шулчаклы да газаплы күзләрдән аерылып китәрлек көчне кайдан алыйм?

— Мин булышыйм сезгә. Чемоданнарны алмаштилмәш илтим.

Ул көлемсерәп куйды:

— Сезнең дә нindirәк пәһлеван икәнегезне баядан бирле карап торам...

— Сезгә булышсам, бәлки, көчем артып китәр.

— Мин әле утырам. Миңа рәхәт. Әнә диңгез дә күренеп тора.

— Алайса мин дә...— дип, чемоданыма атланмакчы иттем.

— Утырмагыз, барыгыз, зинһар, китегез.

Гаҗәп. Кеше аңа ярдәм тәкъдим итә, ул яныннан куа. Минем аптыравыма җавап иткәндәй, әйтеп куйды:

— Хәтерегез калмасын. Мин сезне кумыйм. Үтенәм генә...

Чемоданымны күтәреп, мин китеп бардым. Күпмедер җир үтүем булды, ул тагы, тыны бетеп, ютәлләргә тотынды. Мин әйләнеп карарга базмадым.

Кабул итү бүлмәсендә дә байтак юандым. Теге хатын килеп җитмәсме дип көттем. Үз палатама озатырга килгән сестрага да: «Чак кына тын алыйм әле»,— дип, вакытны суздым. Ләкин ул килеп җитмәде. Күрәсең, бер-бер хәл булгандыр. «Их, син! — дип әрләдем үземне.— Шундый хәлдә ташлап киттең кешене...»

Атна чамасы әлсерәп яттым. Тәүге көннәрдә теге сагышлы ике күз юк-юк та минем күңелемне борчып куйды. Ләкин озакка бармады бу хәл. Онытылды.

Аякка басып, тышка чыктым. Күрше корпус кырыннан үтеп барганда, колагыма хатын-кыз тавышы килеп чагылды:

— Әй, капитан! Капитан!

Мин артык игътибар итмәдем. Юлымда булдым. Беткәнмени монда — хәрби госпитальдә — капитаннар.

— Капитан, мин сезгә эндәшәм бит! Юлдаш!

Карасам, әлеге төпсез ике күз. Хатын икенче катта тәрәзә төбендә утыра.

— Миңа җан кереп килә инде. Тик тышка гына чыгармыйлар. Дөнья әйбәтме анда?

— Әйбәт. Чыгармагач, урлап качыйммы соң сезне? — дигән булдым. Хәлсезлектән үземнең тез буыннарым калтырый.

— Күптән инде карак көтеп утырам. Урлагыз. Мин

риза,— дип, ике кулын алга сузды.— Башта әнә теге тау түбәсенә күтәреп мендерегез, аннан диңгез буена алып төшегез.— Аның иреннәре елмая, хәтта көлә. Ә күзләре тулы хәсрәт.

— Теге көнне мин сезне приемный покойда көттем, көттем дә... Ташлап китүем өчен соңыннан үкендем хәтта...— дип акландым мин.

— Нәрсә, сез мине, бу үзе сикереп төшәр, дип көтәсезме?

Мин аның янына күтәрелдем. Ул палатада ялгызы гына. Күршеләре чыгып таралышкан, ахры. Мин кергәләгәнче, ул, тәрәзә төбеннән төшеп, койкасына утырган. Йөзе тагы агарган.

— Башта танышыйк әле. Мин Людмила исемле. Ә сезне «Капитан» дип кенә йөртермен.— Ул күрешергә кулын сузды. Аның кулын кысуым булды, шунда ук йөрәгем аша тетрәү узды. Ниндидер бик мөһим, бик фаҗигале хәбәр салгандай булды шушы уч, шушы бармаклар. Моннан соң мин күп тапкырлар шәйләячәкмен: Людмиланың күзләре генә түгел, куллары да боеклар. Алар гел генә авыр уйга баткан төслеләр. Кеше кулларының уйлануын, хәсрәтләнүен, килеп-килеп шатлануын шушы язны мин үзем күреп белдем, үзем күреп аңладым. Шулкадәр дә зирәк, шулкадәр дә сизгер куллар булыр икән...

— Атыңны хәзергә бәйләп куй, батыр, хан кызының көе тагы китеп тора,— ул юрганын ачмый гына койкасына ятты.— Шушы температура теңкәгә тимәсә... Сез утырып торыгыз.

Ул бүтәнчә зарланмады да, сукранмады да. Безнең чир белән чирләүчеләрдән мин зар сүзләрен, гомумән, бик аз ишеттем. Авыртыну-сызлану булмагач, күрәсең, ихтыяр бирешми, өмет тиз үк какшап бармый. Озак вакытларга больница биналарына ябылганлыктан, безнең үз мохитыбыз, үз тормышыбыз, үз мәшәкатьләребез барлыкка килә. Бара торгач, безгә больница капка-

сыннан тыштагы тормыш түгел, үзебезнең яктагысы чын булып күренә башлый. Тегендәге ыгы-зыгы юрамалга әйләнә. Чөнки андагылар әле үз гомерләренең хәвефсез җирендә гамьсез адашып йөриләр, кичә бозганнарын бүген төзәтә алалар, бүген кылган языклары өчен иртәгә җәза кичерәләр, ә без инде гомер яланының читен, юлның ахырын төсмерлибез. Безне вак-төяк белән алдатып кына юата алмассың. Шулай да без ышанабыз — соңгы тамчының әле таммый торуына, соңгы яфракның әле өзелми калуына ышанабыз. Үлемгә дучар ителгән адәм, үз куәтен югалта барган саен, инерция көченә ныграк буйсына.

...1942 елның язында безнең бригада иртәгә һөҗүмгә күчә дигәндә, фаҗигале, яман шундый хәл булды: ревтрибунал хөкеме буенча бөтен гаскәр алдында бер дезертирны җәзаладылар. Башта аңа урман акланында тар гына елга янында кабер казыдылар. Приговор игълан ителгәч, җинаятьчене шушы кабер янына бастырып аттылар. Ул туп-туры үз гүренә авып төште. Бу гадел һәм шәфкатьсез вакыйгада мине иң тетрәткәне җәзалаучы залп түгел, ә залпка кадәр булган хәл иде. Яланаяк дезертирны елгачыкның аргы ягыннан алып килделәр. Конвойдагы солдатлар, итекләре белән суның күзенә басып, чәпелдәтеп атлап чыктылар. Ә тоткын, аягын чылатмас өчен, елгачыкны аша сикерде. Коры аяклары белән ул нибары унбиш-егерме адым гына атлады. Үз каберенә җиткәнче генә...

Менә шулай: соңгы адымына кадәр адәм аягын чылатудан курка.

— Магнолия чәчәк атса, бәлки, юнәеп тә китәр идем. Магнолия чәчәген ифрат яратам мин... Аны иснәп исергәнем дә бар, бәләкәй чагымда...— Ул беразга күзләрен йомып торды.— Әтием мине ул чак Гурзуфтагы апама кунакка алып килгән иде.

Людмила йончыды. Аны башкача ялкытмыйм дип, китәргә булдым.

— Иртәгә тагы килермен...— дидем, урынымнан торып.

— Бая тәрәзәгә менгәндә харап шәпле булыр кебек идем дә, кинәт рәт китте. Кичерегез инде.

— Мин сезне барыбер урламый куймам. Сак булыгыз.

— Мин әзер торырмын. Икенче юлы шушы тәрәзә төбеннән иярегезгә үзем генә сикереп төшәрмен. Монда кереп йөрсәгез, мәшәкать тагы озакка сузылыр.

Ул хушлашырга кулын бирде. Учыма кыскач та, әлеге бармаклар миңа ниндидер шомлы нәрсә әйтте. Тойдым, ләкин аңлап җиткермәдем.

Мин иртәгесен дә, атна буена да Людмила янына бара алмадым. Үпкәмнән бик күп кан китеп, түшәккә егылдым.

Инде мине чыгармыйлар. Бераз һушыма килгәч, янымда яткан лейтенанттан магнолия яфрагын өздереп, Людмилага сәлам хаты язып җибәрдем. Яфракка язылган хат бик купшы килеп чыкты. *«Хөрмәтле синьора!* — дип башладым хатны.— *Сезгә тәгаенләнгән сүзләрне мин, җансыз ак кәгазьгә төшереп, кимсетә алмыйм. Аларны сез яраткан агачның яшел яфрагына уеп язарга булдым. Бу яфрак сезнең йөрәгегезгә әйләнсә иде дә, минем сүзләрем шунда теркәлсә иде дип уйларга базмыйм. Чөнки сезнең йөрәгегезгә очлы тимер белән сызарга барыбер минем кулым бармас иде. Моннан да бигрәк, ул йөрәккә инде бүтән куллар бүтән сүзләрне язып өлгергәндер. Хөрмәтледән хөрмәтле синьора!! Сезең илаһи сыныгыз алдында үзем килеп тез чүгү бәхетенә ирешә алмавыма ифрат дәрәҗәдә үкенәм. Гаделлек һәм матурлык өчен көрәш юлында көтелмәгән вак-төяк бәлаләргә очрарга туры килде. Фон Туберкулез дигән корольнең әллә ничә миллион сөңге күтәргән гаскәре берүземә каршы яу ачты. Шушы яу белән алышканда, ике яктан да байтак кан коелды. Хәзерге мәлдә алда торган каты алышлар өчен яңа көч*

туплап ятам. Әмма, газиз синьора, сезнең кечкенә генә йомышыгызны да олы итеп башкару бәхетенә ирешергә минут саен әзермен. Ишарә генә ясагыз. Ишетәсезме, минем аргамагым, һава ярып, ничек кешни. Ишетәсезме синьора?!

«Боек йөзле Капитан...»

Төштән соң ук ышанычлы куллар аша җавап килеп төште.

«Батырлардан батыр, намус колы боек Капитан! Сезнең куш канатлы аргамагыгызның галәм ярып кешнәвен җиде төн урталарында ишетәмен. Минем йөрәк яфрагыма сызып язган сәлам хатыгызны алып укыдым. Борчылмагыз, Капитан, сез язганда минем йөрәгем чак кына да чәнчешмәде, киресенчә, рәхәтләнеп торды.

Мин һаман да шул биек-биек сарайның биек-биек манарасында бикле көе утырам. Менә минем батырым килер дә ун колачлы очлы сөңгесе белән тимер ишекләрне төртеп тишәр. Шул чак мин ап-ак күбәләккә әйләнермен дә һавага очып чыгармын, озын көн буена гамьсез уйнап йөрермен. Көне көн генә түгел, бөтен бер гомер, имеш... Минем гомерем, шулай итеп, Сезнең, кулда булып чыга, әчкерсез, чая Капитан. Сезгә кечкенә генә үтенечем шул: гомер бирегез миңа. Берне генә, бәләкәйне генә... Олы итеп башкарыгыз шушы кечкенә генә йомышымны. Әгәр сез шундый гайрәтле, шундый киң күңелле булмасагыз, мин сезне мондый вактөяк белән бимазаламас та идем. Вакыты җиткәч, мин Сезгә манарадан яулык болгармын. Ак яулык. Күзәтеп торыгыз.

Сезгә мәгълүм Людсения»

Нинди хәтәр шаяру! Бу хатын әллә бөтен өметләрен өзеп, бөтен куркуларын куркып беткән, әллә, киресенчә, аңа әҗәл шаукымы хәзергә кагылып өлгермәгән. Анын

хаты мине хәвефкә салды. Минем шаяруым, ахры, урынсыз булып чыкты. Кешене ул әнә нинди уйларга төшергән.

Әлеге магнолия яфрагына икенче көнне мин шундый ук моңсу-шаян хат яздым. Сарайның тимер ишекләрен тишәр өчен хәзерге мәлдә соңге очын кайрап утыруымны әйттем. Аның ак яулык түгел, аклы-кызыллы яулык болгавын үтендем. Кызыл төс минем дәртемне арттыруын аңлаттым. Көн аша аның җавабы килде.

«Боек йөзле шаян Капитан! Сезнең пар канатлы аргамагыгызның кешнәве көн саен ныграк ишетелә,— дип әүвәлгечә шаярып башлаган җавабын.— *Ул кешнәп җибәргәндә, мин бикләнгән сарайның диварлары калтырап ишелергә тотына. Менә кем ул тавышы белән таш яра! Болай булгач, тиздән ирекә чыгармын дип өмет итәм... Мине барабан кагып каршы алсалар иде. Мин барабан какканны яратам...»*

Шушы арада Беренче май бәйрәме килеп житте. Палатадагы минем күршеләрем бәйрәм күрергә калага китте. Алар ныгып киләләр иде. Аяк өстендәләр. Ачык тәрәзәдән, бөркелеп, хуш ис керә. Магнолия чәчәк ата башлады, диделәр, әле кичә үк. Торып тәрәзә янына барыр идем, хәл юк, башым әйләнә. Ятып торганда болай ару гынамын да бит...

Юк, шулай да ният итеп карарга кирәк. Пижама чалбары өстеннән ак күлмәк кидем, чәчемне тарадым, тумбочка өстендәге ярты стакан җимеш суын эчеп куйдым. Инде тәрәзә янына барып җитәрлек кенә дәрт тә, дәрман да бар кебек. Торып бер-ике адым атлавым булды, сак кына ишек кактылар. Мин тавыш бирдем. Ишек ачылды. Бер бөртек кызыл лалә тоткан кул күренде тәүдә, аннан Людмила керде.

— Бәйрәм котлы булсын, Капитан. Менә сезгә кызыл төс китердем. Дәртегез артсын.

Мин чайкалып куйдым бугай. Ул килеп минем билемнән тотты. Караваткa табан алып китмәкче итте.

— Юк, болай гына, сезне күргәч кенә каушап калдым мин,— дип аңлаттым хәлемне.— Әйдә, тәрәзә янына барабыз.

Без тәрәзә төбенә килеп таяндык.

— Шушы хәлендә шаян хатлар яза бит әле,— дип, миңа байтак карап торды. Шул чак мин теге төпсез ике караңгы күлгә берьюлы баттым да куйдым.

— Мин бирешеп бармыйм ла ул...— дип мыгырдадым бары.

Гайрәт һәм өмет алып, теге күлләрдән тиз үк калкып та чыктым. Шундый матур, яшь дөнья күрәм. Ап-ак чәчәкле магнолия ботаклары арасыннан зәп-зәңгәр диңгез күренә. Кайдадыр түбәндә җыр агыла. Монда тынлык. Нибары бер кош кына чыркылдый. Без әлегә үзебез яшәмәгән дөньяга читтән карап торабыз. Шулай да әйбәт.

— Минем сезгә бертөрле дә бәйрәм бүләгем юк бит әле,— дип пошындым мин.— Кичә егетләр миңа да бер шешә вино алып кайткан иделәр. Әйдәгез шуны эчәбез. Бәйрәм безнең өлешкә дә тиядер ич.

— Әйдәгез! — Людмила җанланып ук китте. Акыллы куллары белән хәтта чәбәкәй итеп куйды.

— Шуңа өстәп, мин сезгә бер шигырь дә укырмын...

— Алайса безнең табын патшалар мәҗлесенә бәрабәр булачак!

Мин чос кына шешәне ачтым. Солдат маһирлыгы онытылмаган икән әле. Людмила башта бер стаканга су салды да, теге кызыл лаләне алып, шуңа утыртты; аннан, тагы ике стакан табып, тумбочкага чәчәк янына куйды. Утырыштык. Мин вино койдым.

— Я, нәрсә өчен эчәбез? — димен мин.

— Бәйрәм өчен. Бәйрәм мәңгелек нәрсә ул.

— Мәңгелек нәрсә болай да яшәр...

— Ә мәңгелек булмаганы барыбер мәңге яшәми.

Бәйрәм өчен! — Ул елт иттереп стаканны алды. Без чәкештердек.

— Бәйрәм өчен! — дип кабатладым мин. Икебез дә эчеп бетердек.

Людмиланың йөзенә алсулык йөгерде. Төпсез моңсу күзләренең төбендә җанлы нурлар чагылып калды. Минем бөтен тәнемне талдырып рәхәтлек йөгерде. Күккә ашсам да, җиргә сеңсәм дә — барыбер миңа хәзер.

— Инде шигырь укыгыз.

— Юк әле, градусы җитмәгән,— дип кәпәрендем мин. Шунда ук шешәгә үрелдем. Людмиланың акыллы кулы сак кына минем йөгәнсез кулымны тотып алды.

— Җитәр, Капитан,— дип ялварды ул.— Кечкенә генә шатлыгыбызны өркетмәгез. Югыйсә безне ташлап китәр ул.

Әйе, бу мәлдә минем эчем тулы шатлык иде. Күптән онытылган хозурлык, кайдадыр адашып йөргән куанычларым кире әйләнеп кайтты. Мин үзем генә бәхетле түгел, теләсә кемне бәхетле итә алам хәзер. Минем кодрәтемнең чиге юк. Мин баш чайкаганда күкләр тирбәлеп китә.

— Алайса, рәхим итеп, тыңлагыз, мәрхәмәтле синьора!..

— Юк, кирәкми, бүген шаярмыйк, капитан. Бүген чынлап та күңелле, чынлап та рәхәт миңа.

Мин мәхәббәт шигыре укыдым. Кеше йөрәгендә шытып, дөньяга ямь биргән чәчәкләр, шул ук йөрәктә оя корып, җиһанга моң чәчкән кошлар турында әйтелгән иде анда. Чәчәкне мәхәббәт аттыра, кошны мәхәббәт сайрата.

Башын иеп, озак кына тынып торгач, Людмила миңа күтәрелеп карады.

— Сезнең яныгыздагы хатынга ышыктыр, җылыдыр... Мөгаен, ул бәхетледер... Бәхетле булыр...

Мин кинәт айнып киттем. «Бәхет» сүзе сәер дә, шомлы да булып ишетелде. Ул сүзнең инде миңа да,

моннан еракта мине сагынып көткән кешемә дә кагылышы юк кебек иде. Шул ук вакытта, яшермим, «Сезнең янда ышыктыр, җылыдыр» дигәне мине эретеп җибәрде. Андый сыйлы сүзләр ир затына сирәк эләгә ул. (Тагы байтак еллар үткәч, янымда атлап барган хатын шулай дип әйтәчәк: «Ә бит шушы кала тулы халык минем никадәр бәхетле икәнне белми. Белсәләр, болай ашыкмаслар иде, туктарлар да, сокланып, хәйран калып, миңа карап торырлар иде. Икәү урамнан узып кына барабыз, ә бәхетемнең чиге юк...» Менә нинди сүзләр ишетәчәкмен мин! Әйе, бәхетле итмиләр, бәхетле булалар гына. Бу хакыйкать безгә үтә соңлап килә.)

— Мине бигрәк зур үлчәү белән үлчәп ташладыгыз,— дидем мин, уңайсызланып.— Аны бәхетле итү хәлдән килерме соң? Гомерлек эш бит бу. Ә гомер дигәнең...

— Бәхет өчен гомер түгел, мизгел кирәк... Ә сез гомерле дә булачаксыз,— диде ул, әллә кайчан билгеле нәрсәне хәбәр иткәндәй, тыныч кына.— Сезнең керфекләрегез кыска. Күзегездә өметсезлекнең әсәре дә юк. Тәүдә кешенең күзләре дөньядан ваз кичә, аннан — үзе. Кая, бирегез әле кулыгызны.

Людмила минем сул кулымны учына алды.

— О-һо! Сезнең гомер юлының очы да, кырые да юк,— диде.— Өч упкын аша үтә, әмма өзелми. Кулыгыз бәләкәй, какча икән. Минем бу иремнең куллары зур, итләч. Ул бик көчле. Ә тегесе, үз ирем, сезгә тартымрак иде. Бөдрә чәче, маңгае, куллары, елмаюы... Сугышның тәүге елында ук һәлак булды.— Минем кулымны ныгытып кысып алды ул.— Ә сез яшәгез! Яшәгез! Зинһар, яши күрегез!

Кинәт безнең баш өстендә ак шәүлә калкып чыкты. Бу — дуамаллыгы белән яманаты чыккан, бөтен госпитальне айкап-байкап торган начмед Мария Аристраховна иде. Аны без «Страховна» дип кенә йөртәбез.

— Госпитальме бу, шайтан алгыры, әллә гашыйклар бакчасымы? Кая барма, парлы-парлы тәвисләр, койрыклары җилпәгечтәй,— безнең вино шешәсен күреп алгач, ул отыры шашып китте.— Вино? Болар бөтенләй шартына китергәннәр.— Ул Людмилага төбәп җикеренде.— Марш моннан! Хәзер үк чыгып китегез. Ире аны дәваланырга җибәргән, ә ул монда кызарып бүртенгәнче вино эчеп утыра. Болайга китсә, сезне дәвалаудан без баш тартачакбыз. Нигә сез урыныгыздан тормыйсыз? Аягүрә басарлык та юнегез калмадымыни?

— Миңа җикеренмәгез. Миннән баш тартсагыз. тартыгыз, ләкин җикеренмәгез,— диде Людмила, урыныннан тормый гына.— Мин инде өркүдән узганмын, Мария Аристраховна, монысы сезгә мәгълүм.

Көтелмәгән бу өермәдән мин каушап калдым. Авыз ачып сүз әйтергә зиһенемне җыя алмыйм. Шундый мәгънәсез кискен хәлләрдә оятсыз тупаслык алдында коелып төшү гадәтем гомер буена барды.

— Ни, Мария Аристраховна...— дип мыгырдадым.

— Сезнең белән соңыннан сөйләшербез. Марш постельгә! — Мин кузгалмадым. Ул яңадан Людмилага ташланды.

— Нәрсә сез, карета көтәсезме? Карета подана! Рәхим итегез! — Ул ишек ягына күрсәтте.

Людмила ашыкмый гына урыныннан торды. Мин аңа табан омтылдым:

— Людмила!

— Я, хуш булып тор. Мин тагы килермен,— ул начмедка әйләнеп тә карамый, чыгып китте. Шунда ук Мария Аристраховна да юк булды. Безнең бәйрәм очланды.

Ә мин соң, мин! Нинди мескен, нинди юньсез, нинди мәсхәрәле хәлдә калдым. Теге мәгънәсез, явыз хатын, авыз ачып тәүге сүзен әйткәч тә, мин:

— Вон моннан, Мария Аристраховна! Вон! Людмиланы да, үземне дә рәнҗетергә сезгә ирек бирмәм!

Марш! Марш моннан, медицина майоры Мария Аристраховна! — дип сөрәнләргә тиешле идем. Шап итеп өстәл сугарга, кырыемдагы тумбочканы тибеп очырырга, изүемне умырып ертырга тиеш идем мин. Соңгы чиктә Людмиланы ишек төбендә куып җитәргә дә кулыннан тотып, кире урынына утыртырга тиеш идем. Тиеш идем!.. Ә шуларның берсен дә эшләмәдем. Җебегән! Куркак җан! Мөртәт! Ә Людмила үзен нинди горур, нинди югары тотты. Менә шундый кешеләр дөньяга мәңгегә килергә тиеш тә бит...

Людмила иртәгәсен дә, аннан соң да килмәде. Хәбәр дә җибәрмәде. Күрәсең, миннән күңеле кайткандыр. Шулай тиеш тә. Ул мине аргамакка атланган чая егет дип күз алдына китерде, миннән азатлык көтте, бәләкәч кенә булса да гомер сорады. Ә мин ишәктән егылып төшкән юньсез бер бахыр булып чыктым. Янәсе, мин аны, әҗәлгә бирми, урлап качачакмын. Гамәлдә, бер череллек бичәдән аралап кала алмадым, битенә төкерттем. Хыянәтнең бер төре түгелмени шушы? Сабак булса ярый ла... Әйтергә кирәк, киләчәктә тормыш миннән бу бурычымны артыгы белән түләтте. Алышка — бирешь. Үпкә булмаска тиеш. Ә мин үпкәләп маташтым...

Чыгып йөри башлагач та, Людмила торган корпус ягына барып әйләнергә йөрәгем җитмәде. Гел тискәре якта уралдым. Беркөнне кичке аштан соң кечкенә генә записка килде. «Нигә тындыгыз, Капитан? Сезне тышта күргәннәр. Килә алсагыз, килегез!» Мин икеләнеп тормадым. Киттем.

Ишекләре ярым ачык иде. Шулай да шакыган булдым.

— Керегез!

Людмила, биек мендәргә сөялеп, койкасында ярым утырып тора. Аның йөзе ал янган. Күзләре тагы да моңсулана төшкән. Юрган астыннан чыгарып, күрешергә кул сузды. Кулы ут кебек иде.

— Мин сезне көттем. Күрәсез, үзем йөрерлек хәлдә түгелмен.

— Мин килергә оялдым. Шундый мәсхәрәдән соң...

— Онытыйк. Ул минутта сез түгел, бүтән кеше иде. Мин шулай хәл иттем. Ә монысы — сез үзегез. Урындык алып, кырыма утырыгыз.

Мин утыргач, ул, кулын күтәреп, озын бармаклары белән минем чәчемне тарап алды. Әйе, бармаклары минем чәчемне иркәли, ә мазасыз, ятим күңеле әллә кайларга китеп олага. Аның күзләреннән берничә бөртек эре яшь тамды.

— Гафу итегез. Мин үзем өчен түгел... Аның өчен... Сезнең өчен... Белмим, бүләкме бу, әллә җәзамы? — Ул минем чәчемне учлап алды да кинәт җибәрде. Кулы акрын гына юрган өстенә шуып төште.— Гафу итегез...

Әйе, бу минутта мин бүтән берәүне алмаштырам. Минем чәчләрем, кулларым, маңгаем, елмаюым үземнеке генә түгел. Мин аларны икенче кеше белән бүлешәм. Бәлки, киресенчә, ул үз өлешен дә миңа калдырып киткәндер. Бигрәк тә — елмаюын. Бәлки, мин аның өчен дә елмаямдыр?!

— Ичмасам, сез яшәсәгез иде. Озак итеп яшәсәгез иде...

— Сез дә, Людмила...

— Мин тияренъ яшәрмен. Хәтта аз гына артыгын да... Охшатуыма хәтерегез калмасын. Ул бик әйбәт кеше иде. Сез алама адәм белән охшаш түгелсез.

Ни дип әйтим? Иң хәерлесе — эндәшмәүдер.

— Рәнҗедегез, ахры, эндәшмәс булдыгыз.

— Мин үзем дә белмим, Людмила, яхшымы бу, әллә начармы? Яхшыга юрыйк.

— Шулай итик.

Яшь чылаткан ике битен ул кул сырты белән тик эле генә сөртеп куйды.

— Әйдәгез, күңелләрәк нәрсәләр турында сөйләшик,— диде ул.

— Әйдәгез, әгәр андый нәрсә табып булса.

— Андый нәрсә — бөтен дөнья! — дип, Людмила ачык тәрәзәгә күрсәтте. Ул кинәт юрганын ачып ташлады.— Читкә борылыгыз, мин хәзер киенәм.

— Нигә?

— Тышка чыгабыз.

— Ә температурагыз?..

— Температураны монда калдырып торырбыз. Беркая да качмас.— Ул тиз үк киенеп алды. Мин аны үгетләп маташмадым. Барыбер файдасыз. Людмиланың ниндирәк заттан икәнен азрак беләм хәзер.

— Кулыгызны бирегез, боек йөзле Капитан.

— Рәхим итегез, синьора Людсения.

Ул минем беләгемә таянды. Акрын гына баскычтан төшеп, өй алдына чыктык.

Кешеләр кинога ашыга. «Минем хыял кызым» дигән трофейный фильм күрсәтәләр бүген. Мин аны былтыр Венада караган идем. Ул картинада бер актриса бер-берсенә үтә охшаган ике хатын ролен башкара. Үзе белән үзе кара-каршы килеп сөйләшә. Шаккаткан идем. Әнә бит, хәтта фильмда да кеше үзе өчен генә уйнамый, бүтән берәүләрнең дә ролен башкара.

— Бүген кино күрсәтәләр,— дидем мин.— «Минем хыял кызым» исемле.

— Ә без әнә ул эскәмиягә утырыйк та кич килгәнен карыйк, эңгер төшкәнен күрик.

— Эңгер, миңа калса, югарыдан төшми, җир астыннан күтәреләсыман.

Людмила моңа сабыйларча гаҗәпләнде.

— Менә мәзәк! Алайса эңгер күтәрелгәнне карыйк!

Бик зур магнолия төбендәге эскәмиягә барып утырдык. Магнолия әле чәчәген коеп бетермәгән. Ләкин хуш исе элеккечә танауны ярып бармый. Юашланган.

Аяк өсте йөргән авырулар бөтенесе дә кинога кереп

тулды. Тирә-як тып-тын булып калды. Кояш инде тау артына кереп яшеренде, әмма ул чәчеп калдырган нурлар әле бирешми, үз эшен бер көе дәвам итә — җылытмаса да яктырта. Ә тегендә, диңгез астыннан тәгәрәп, ай чыга. Ул кып-кызыл. Зур дулкынга тап булды бугай, бәрелеп, өскә сикерде. Сикерде дә кире төшмәде, һавада асылынып калды. Кояшка алмашка килдем, аның урынын алдым дип, уйлыйдыр әле ул, бахыркай. Нигә кояш белән ярышырга инде? Үз вазифасын тырышып, әйбәт кенә башкарса, айга шул җиткән.

Дөнья кайчак миңа чамадан тыш зур савытсыман тоела. Иртәнгә караганда кичен ул тагы да сыйдырышлыракка әйләнә. Бигрәк тә җәйге кичтә. Шушы савытка диңгезләр, таулар, урманнар, далалар, болытлар кереп югала; хыяллар, өметләр, шатлыклар төшеп сыена; иң төбенә бөтен серләр батып яшеренә.

Людмила белән без — җилдә җилфердәп утырган ике үлән кыягы гынабыз. Безне кояш та, диңгез дә күрми. Ләкин алар каршысында безнең бер өстенлегебез бар: без һәммәсен дә шәйлибез, сизәбез; дөньяны үтәдән-үтә күрәбез; бар галәмне күңелебезгә сыйдыра алабыз. Менә сиңа үлән кыягы! Шуңа күрә безгә рәхәт тә, ямансу да. Без тын гына кич килүен карап утырабыз. Безнең тамашабыз шушы.

Людмила үзен егетләрчә тота. Кичке җиләс һава аңа көч өстәде. Йөткерүе дә сирәгәйде. Минем кулымны алып, акрын гына кысып куйды. Кулы баягы кебек кайнар түгел иде.

— «Рәхмәт»,— диде акыллы кул. Ни өчен рәхмәт әйтүен аңлап җиткермәдем.

— Дөнья камил. Карагыз, анда бөтен нәрсә — бөтен ис, бөтен өн, бөтен төс кирәгенчә төп-төгәл. Тик бер генә нәрсә җитешми...— Людмила тәү тапкыр көлеп җибәрде.

— Нәрсә җитешми, Людмила?

— Әйтсәм, көләрсез.

— Әйтегез, көлим. Бергәләп көлик.
— Тозлаган алма.
— Нәрсә, нәрсә?..
— Тозлаган алма.
— Ни өчен хөрмә түгел, әлбә түгел, кишмиш түгел? — дип шаярып тезеп алып киттем мин.
— Алма шул. Кәефем әйбәт, күңелем бөтен, дөньям төгәл чакта миңа шул бер тозлаган алма гына җитешми. Нибары бер бөртек алма... Менә әле дә шулай булып китте.
— Сәер икән...
— Сәер шул. Бер уйласаң, сәер дә түгел. Чөнки аның сәбәбе бар. Сөйлимме?
— Сөйләгез.
— Минем әнием миңа авырга калгач, бер мәл тозлаган алма теләгән, үлә язып теләгән. Ел мизгеле шундый туры килгән, таба алмаганнар. Әнием ымсынып калган. Шул ымсыну гомерлеккә миңа күчкән. Иң рәхәт чагымда тозлаган алма телим. Исәрлек инде — белеп торам. Үзем нәфесемне тыя алмыйм...— Сүзен ул кинәт икенчегә борды.— Мин төнгә каршы, менә шушы мәлдәрәк туганмын. Ә сез ни вакытта?
— Мин иртәнчәк караңгылы-яктыда туганмын. Шуңа күрә Олы инәем ул елны йомырка салмый дуадак йөргән ала казны — аклы-каралы мизгелнең төсе итеп миңа атаган. Минем бәхеттән теге ала каз алдагы язны, оя тутырып, йомырка салган, бәбкә чыгарган, имеш. Әллә чыгарган, әллә юк...
— Олы инәй дигәнегез әбиегез буламы инде ул?
— Юк, Олы инәем. Әтиемнең өлкән хатыны. Аның бичәсе икәү иде.
— Ә-ә-ә, беләм,— дип сузды Людмила,— шәригать! Сезнеке дә икәү булырмы икән? Кирәкми. Икәүнең берсе бәхетсез булачак. Я икесе дә... Хәтта өчегез дә... Ә теге ала каз, мөгаен, язын йомырка салгандыр. Сезнең котыгыз бар. Мин анысын башта ук сиздем.

Җирдән бөркелеп чыгарга караңгылыкка ай ирек бирмәде, сыек яктысын таратып, дөньяны үз карамагына алды. Җиләс кич акрынлап салкынча төнгә әйләнде. Мин Людмиланы өйгә керергә димләдем. Ул башта карышып карады да тиз үк күнде. Чөнки, дәлил итеп, аның үз сүзләрен кабатладым:

— Бәләкәй генә шатлыгыбызны йончытмыйк. Югыйсә безне ташлап китәр ул.— Мин аны палатасына чаклы ук озата килдем.

— Гаҗәп,— диде ул,— мин бөтенләй арымадым. Киресенчә, җиңеләеп киттем.— Күрешергә кулын сузды: — Хуш, мине онытма,— диде кул.

Кайткач, мин байтак заман йоклый алмый җәфаландым. Кино карап килгән ике күршем, янәсе, мине уятмас өчен шым гына чишенеп ятты. Тиз арада алар хырылдап йоклап та китте. Сөмсез ай, әдәпне онытып, бөтен бүлмәне байкап йөри. Кагылмаган, сугылмаган нәрсәсе юк. Урындык артына эленгән каеш прәшкәсенә, гимнастерка төймәләренә хәтле капшап чыкты. Людмиланың йөзенә, маңгаена, кулларына да шулай төшә микән? Җитмәсә, уң кулында аның йөзеге дә бар. Күзләре инде йомылгандыр, йоклыйдыр ул. Тыныч йокы сиңа, Людмила!

Ә нигә минем үземнең йокым качты? Тозлаган алманың тәме, исе нинди икән? Мин аны ашау түгел, гомеремдә күргәнем дә юк. Мөгаен, ул бик тәмле нәрсәдер... Кайчан соң әле бу ай, нәкъ шулай кыланып, миңа йокы бирмәгән иде? Теге чак малайлар белән калага сәяхәткә китәр алдыннан шулай тәрәзә төбенә төшкән иде ул. Ләкин болай ук мазамны алмаган иде. Бәлки, соңрак, дәрт ташып, күңел ярсыган чакларда булгандыр ай белән мондый очрашулар. Булгандыр инде... Моннан ары да булачактыр әле...

Мин иртүк торып базарга киттем. Урамда әле кеше бик сирәк очрый. Бер өй тупсасында төрепкә тартып утырган карттан мин базарның кайдалыгын сораштым. Ул, төрепкәсен авызыннан алып, ихлас өйрәтергә кереш-

те. Ләкин шулкадәр җай, шулкадәр җентекләп сөйли: ул төшендерә бара, мин оныта барам. Карт моны сизенә бугай, яңадан тотына. Бара торгач, бер чама аңладым шикелле. Рәхмәт әйтеп, ары киттем. Икенче урам чатында кәрзинкә күтәргән олы хатынга тап булдым. Ышанычлырак булсын дип, аннан да сораштым.

— Базар әнә бит,— ул ияген чөеп күрсәтте.— Танавың астында.

Чынлап та базар «танау астында» гына булып чыкты. Минем тәүге юл күрсәтүчем чак-чак кына юлдан яздырмады. Теләсә кемнән юл сорасаң, шулайрак та килеп чыга шул.

Карчык-корчык базарда тозлы кыяр, кәбестә, сарымсак, кипкән өрек, бәрәңге бөккәне, эремчек, тагы бик күп нәрсә сатып тора. Мондагы әйберләрнең һәммәсе дә таныш миңа. Мин белмәгән, мин күрмәгән әйбер күзгә чалынмый. Бөтен рәтләрне башта карап, аннан үземә кирәкне сорашып чыктым. «Юк» тан башка җавап ишетмәдем. Кайбер яшьрәк хатыннар шаяртып та алды:

— Бу корсагың тозлаган алма телимени?

— Теләү генә түгел, дау күтәрә,— дип расладым мин.

— Алайса кыз туганын көт тә тор.

— Язган булса, арба тәртәсе дә шартлатып ата, ди.

Бидрә, кәрзинкә, сумка күтәреп яңадан-яңа сатучылар килә торды, мин рәтләр буйлап сораштыра йөрдем:

— Тозлаган алма юкмы?

— Юк.

— ... Юкмы?

— Юк.

Ногыт борчагы сатып торган мөлаем генә бер апа миңа үзе эндәште:

— Баядан бирле карап торам, солдат, **юкны эзләп** базарны биш урадың. Әҗәл даруымыни ул тозлаган алма?

— Әгәр әҗәл даруы булмаса, шулай каңгырып йөрмәс тә идем. Мин аны үзем кабып та караганым юк.

— Минем өйдә кисмәк төбендә берничә бөртек калган иде бугай. Чак кына сабыр ит. Менә шушы дүрт-биш стакан товарымны сатып кына бетерим дә, өйгә китәрбез.

— Миңа дүрт-биш стакан ногыт борчагы да кирәк иде. Үзем генә алыйм да...

— Хәйләләмә, солдат, сиңа борчак кирәкми. Юкка акча әрәм итмә, болай да муеның кыл кебек. Бар, әнә теге агач күләгәсендә көтеп тор.

Мин күләгәгә киттем.

Товарын әллә сатып бетерде, әллә юк, апа тиз үк минем яныма килде.

— Киттек.

Мин аңа иярдем. Бераз баргач, ул шып туктады.

— Һи-и-и, үзеңнең дә эшләрең мөшкел икән. Камытың кыса бит. Җаерак барыйк.

Тар-тар урамнар, кәкре-бөкре тыкрыклар буйлап, әле тегендә, әле монда борылып, байтак ара үттек. Тау чатлыгына кыйшаеп терәлгән фәкыйрь генә өй алдына килеп туктадык. Хатын бәләкәй капканың җеп элмәген ычкындырды.

— Безнең утарыбыз шушы инде.

— Нинди булса да, үз оягыз.

— Үзем корган оя түгел шул, туганкаем. Ятим калган ташландык оя иде, чарасыздан килеп кердек...

Нигез кырындагы тәбәшәк урындыкта бер карчык утыра иде. Капка шыгырдауга ул сагаеп калды.

— Синме бу, Галина?

— Мин, әни.

— Аяк тавышыңны әллә кайдан ук ишеттем шул. Кунак та бар, ахры...

— Әйе, әни.

Өйгә кергәч, Галина миңа аңлатып бирде:

— Әнием бомба шартлаудан шулай күздән язды. Тегендә, Украинада, өебезгә бомба төште. Бөтен дөнья-

быз шунда күмелеп калды. Ярый әле әнинең ихатага чыккан чагы булган.

Галина, өйдән чыгып, сай тәлинкәгә караеп, бөршәеп беткән өч түгәрәк нәрсә салып керде. Алмага да охшамаган.

— Бар байлыгым шул. Тәлинкәсе белән бирә алмыйм, савыт-саба кытлыгы.

Шкаф артына кыстырылган каты сары кәгазьне алып алмаларны шуңа төрде. Мин, бәхилләтмәкче булып, акча чыгардым.

— Әҗәл даруы өчен без акча алмыйбыз. Ходайга шөкер — без украиннарбыз,— дип оялтты мине Галина,— ашаган кешегә шифасы тисен.

Бу ятим өйдән өч бөртек алма гына түгел, әллә ничаклы күңел хәзинәсе алып киттем. И кешеләр! Сез мәңгелек сер. Кемдә нинди юмарт рух ятканын беркайчан да алдан белеп булмый. Галина! Мин сезгә күз төбим. Сезне күргәннән соң минем мәһабәт сарайларда олы бүләкләр алганым, ил узаманнары кулыннан мактау, дәрәҗә кәгазьләрен кабул иткәнем, намуслы, гадел, аек ирләр авызыннан үземә карата хуплау сүзләрен ишеткәнем булды. Болар өчен һәрвакыт ихлас куандым. Ләкин ул куанычлар, Галина, сез рәхим иткән хәзинәнең һәм шуңа охшаш бүтән барлык хәзинәләрнең яктысын да, җылысын да томаламады. Әгәр томалатырга ирек куйсам, мин үз-үземне талаган, бөлдергән булыр идем.

Бәһа куйсаң, бәһаларга сыймас мөлкәтемне күтәреп, мин госпитальгә ашыктым. Әллә ничә тапкыр адаштым, әллә ничә тапкыр юлыма төштем. Имин кайтып җиттем. Туп-туры Людмила янына кердем. Хәле аның әйбәт күренә. Ыспай итеп киенгән, күперелеп торган кара чәченә ак тасма бәйләгән. Ул яшәреп киткән төсле. Кабарынкы иреннәре бөтенләй үсмер бала ирененә тартым бүген. Ул тәрәзә янындагы табуреткада нәрсәдер бәйләп утыра. Балалар башлыгы бугай. Нигә балалар башлыгы бәйли икән?

Мине күргәч, ул, эшен ташлап, «бүген менә мин нindимен» дигәндәй, аягүрә басты.

— Минем кулда нәрсә икәнен белсәгез, үзегезгә бирәм,— дип хәбәр салдым мин, хәл-әхвәл сорашырга да онытып.

— Исәнмесез! — диде ул.

Мин каушап киттем:

— Саумысез? Гафу итегез.

— Әгәр белмәсәм? — Ул минем кулдагы төргәккә күрсәтте.— Кемгә бирәсез?

— Белмәсәгез дә, сезгә инде...

— Менә мәзәк! —«Менә мәзәк»не ул күңеле күтәренке вакытта еш кабатлый.— Үлсәм дә, беләчәгем юк. Мине яшәтәсегез килсә, күрсәтегез тизрәк!

— Мәңге яшәтәсем килә...

Мин ашыкмый гына төргәкне сүттем. Аннан бөрешеп беткән баягы өч йомры нәрсә килеп чыкты.

— Алма? Тозлаган алма?! Ярабби! Нинди кеше сез?! Мин аларны сез юкта гына ашармын,— төргәкне кире төреп, ул тумбочка өстенә куйды.— Рәхмәт, Капитан! Бу онытыла торган бүләкләрдән түгел.

Бәлки, бу алмалар Людмилага кичә генә хаҗәт булгандыр. Ихтимал, бүген аларны кабып та карамас. Ләкин аның шатлыгы да, рәхмәте дә ихлас иде. Каян, ничек табып китерүемне ул төпченмәде. Моның үзендә — бер күркәмлек, әдәплелек, югарылык бар иде.

— Я, утырышыйк.

Утыргач, бәйли торган нәрсәсен ул тагы кулына алды.

— Кызларыма башлык бәйләргә булдым әле,— дип, гади генә хәбәр итте ул.— Тәүге иремнән ике игезәк кызым калды. Дүртләре тулып килә. Берсе атасына, берсе миңа охшаган. Гаҗәп кызыклар.

Людмила бүген сабыр: бәргәләнми, өзгәләнми, куллары да тыныч, хәсрәтсез. Күзләренә текәлеп карарга мин һәрвакыт тартынам, шикләнәм. Мөгаен, алар чоңгылында да бүген давыл басылгандыр.

— Минем дә дүрт яшьлек улым бар,— дидем. Шунда ук колак төбемдә, әйтерсең, улымның әле мин авырмас борын отпускка кайткач әйткән сүзләре яңгырады. Муенымнан кысып кочаклады да ул: «Мин синең берүзеңне генә моннан ары һичвакытта да, һичвакытта да сугышка җибәрмим!»— диде.

— Менә мәзәк! Сезнекенә дә дүрт яшь. Теләсәгез, мин аңа да башлык бәйләрмен.

— Ул егет кеше. Инде кепка киеп йөри.

— Кемгә охшаган?

Мин немец минасының ярчыгы тишкән комсомол билетының эченнән алып, аналы-уллы төшкән рәсем күрсәттем.

— Әнкәсенә охшаган икән. Чибәр булыр. Мин кызларымның сурәтен үзем белән алмадым. Караган саен, эчем өзелеп, елармын дип курыктым.— Ул фотографияне кулына алды.— Хатыныгызның күзләре акыллы. Матур хатыннарга акылның хаҗәте юк дип, бушны сөйлиләр. Матур ахмактан да аяныч нәрсә юк. Табигатьнең иң зур хатасы ул...

Моннан ары без икебез дә, юнәеп, аякка бастык. Тау ягына омтылырга батырлык җитмәсә дә, көн эссесе басылган мәлләрдә, диңгез буена төшеп утыргаладык. Диңгез янында Людмиланың күңеле күзгә күренеп күтәреләә. Без дулкыннарның шартлап чәчрәвен күзәтәбез, сәламәт кешеләрнең дәрья белән алышып йөзгәнен карыйбыз, еракта, офык ярында тѳтәп барган корабльләрне бүлешәбез: берсе аныкы, берсе минеке, берсе аныкы, берсе минеке... Һәркайсыбызның өлешенә байтак тия. Шулкадәр корабларыбыз була торып, үзебез яр башында утырабыз.

Хәлләребез арулангач, Людмила әллә миннән суына төште, әллә, болай басынкыга әйләнде: чәчләремне дә сыйпамый, күрешкәндә-хушлашканда куллары да берни әйтми. Алай дисәң, чак кына күренми торсам, үзе, тәрәзә алдына килеп, тавыш бирә. Мин дә аның янына барырга

атлыгып кына торам. Людмиланың күршеләре дә, минем күршеләр дә безгә инде аерылмаслык гашыйклар итеп карыйлар. Гашыйк булышу — чирнең иң яманы икәнен аңлап, алар безгә теләктәшлек белдерәләр, безне кызганалар. Хәтта Мария Аристраховна да безгә игътибар итмәс булды. Киевтан килгән бер яшь подполковник кына, бик тырышып, Людмилага тозак салып маташты. Урамда күрсә, артыннан иярде, киногa керсәк, мине бар дип тә белми, аның янында сырпаланды. Людмила торган палатага минем алда гына әллә ничә тапкыр килеп ишек шакыды. Ләкин авызы тиз пеште тегенең. «Күрәсез бит, подполковник, мин капитан белән мавыгам»,— диде аңа, үзе аңламагач.

...Егерме биш еллап вакыт үткәч, әлеге подполковник ниндидер эш белән Уфага килеп чыкты. Кешеләрдән сорашып, мине эзләп тапты, өемә килде, чәй эчтек. Теге вакытны Людмилага күзе төшү генә түгел, илереп гашыйк булуын, гомер бакый оныта алмавын сөйләде. «Әллә нинди тылсымлы җан иясе иде шул. Сез бәхетле. Сез аның янында булдыгыз... Ул язны сезгә карата нәфрәтемнең, үчемнең чиге юк иде. Ә хәзер үзем эзләп таптым. Ниндидер сихри көч җитәкләп китерде мине сезгә. Җаным бер юаныч алды менә...» Ул күптән инде хәрби түгел икән. Сүзгә-кылыкка сабыр, юаш күренә. Теге чакта аны, күрәсең, мәхәббәт кенә шундый кыю, чая ясаган...

Людмила өчен мин хәзер берәүне дә алмаштырмыйм, үзем генә булып йөрим. Шуңа күрә мөнәсәбәтләребез талгын, ипле. Җитмәсә, мин аны, күрүегезчә, төрле ирләрнең һөҗүменнән, нәфесле карашыннан саклаучы калкан хезмәтен дә башкарам. Тукта әле! Бу ни могҗиза? Баксаң, мин барыбер кемнеңдер, нәрсәнеңдер вазифасын үтим икән: хәзер менә калкан вазифасын үтим...

Кайтыр вакыт та җитте. Без бергә китәргә тиешбез. Кичтән байтак тышта утырдык. Теге ай бетеп, инде бөкре

генә, зәгыйфь кенә икенче ай туган. Ул күктә түгел, магнолия ботагында асылынып тора. Үрел дә тот. Ләкин миндә аның кайгысы юк. Людмила боек. Әйтер сүзләр кайдадыр адашып йөри. Истәлекләр сөйләшергә әле иртә, вәгъдәләр бирешү — ялганлык булыр иде. Тәүләп ул эндәште:

— Рәхмәт сезгә, Капитан.

— Нәрсә өчен?

— Нәрсә өчен икәнен аерып-ваклап әйтә белмим.— Ул минем кулымны учына алды. Килеп-килеп кысып куйды, ләкин җибәрмәде. «Син үзең генә дә миңа кадерлесең. Артыгын әйтергә куркам...»— диде аның кулы. Янә нәрсәдер өстәп куйды, анысын аңлап җиткермәдем.

Иртәнчәк җиләстә юлга чыктык. Автобус тып-тулы иде. Симферопольгә имин килеп җиттек. Людмиланы да бөтенләй дип әйтерлек йончытмады. Безне вокзалдан ерак түгел бер йортка урнаштырдылар. Поезд кичләтеп кенә китәчәк.

Автобустан төшкәч тә бәләкәч кенә буйлы, өтерге тешле бер сары лейтенант минем тирәдә урала башлады. Нәрсәдер әйтергә теләде, каядыр китәргә ымлады. Аның белән аңлашып торырга әлегә вакыт юк. Чемоданнарны кертергә, Людмиланы урнаштырырга кирәк иде.

Әйберләрне куеп чыгуым булды, «өтерге теш» минем алга килеп тә басты.

— Лейтенант Уточкин! Леня Уточкин! Таныш булыйк! — Ул кинәт башын артка чөйде. Бу мәл ул бугазындагы азыгын йотып җибәргән үрдәк баласына охшап куйды. Әгәр фамилиясен «Уточкин» димәсә, аның бу хәрәкәтенә, бәлки, игътибар да итмәс идем.

— Таныш булыйк. Капитан...

— Беләсезме, капитан, кичкә кадәр сусап үләргә мөмкин бит монда. Җитмәсә, көн заяга үтә.

— Заяга үтмәсен өчен нишләргә кирәк?

— Иртүк вино эчә башларга кирәк. Мин ифрат шәп бер урын беләм. Киттекме?

Бу «һөнәр»гә дигәндә минем дә тамак кыткылдап кына тора ул. Ымлаучы гына булсын! Тик Людмилага белдерми китү килешмәс.

— Мин әйтеп кенә чыгыйм да...

— Ка-пи-тан! — дип сузды Леня Уточкин.— Европаны азат иткән солдат бит син. Үз иркеңнең кадерен бел. Нинди рөхсәт сорап тору тагы? Киттек!

— Хатын кеше анда...

— Хатыннар көтәргә тиеш. Әнә теге җырда нәрсә дип әйтелә әле: «Солдатлар шәраб эчкәнне ярлары көтеп тора...»— дип әйтелә. Җыр ул, брат, точно сөйли.

Кәрлә генә лейтенант мине өтеп бара. Ай-ваема карамый, алып та китте. Аның бу үтә әрсез кылануына эчемнән каршы төшәм, ә гамәлдә буйсынам, һичнәрсә эшли алмыйм.

Леня Уточкин мине вино сата торган зур гына алачык янына алып килде. Алачыкның алгы ишеге бикле, тәрәзә капкачы ябык иде.

— Монысы әйбәт. Аулак булачак,— диде юлдашым. Ул арткы ишекне барып шакыды. Җавап булмады. Шуннан Морзе азбукасы буенча тукылдатырга тотынды. Нинди кодрәт беләндер ишек үзе ачылып китте. Безне агач аяклы әрмән карты каршы алды:

— Ә, лейтенант? Әйләнеп тә килдегезме?

— Илгә кайтам, бабай, ак билет тоттырдылар. Синең агач аягың шикелле, гомерлеккә...

— Минем агач аяк чыдамлы булды, өшемәде, сызламады, үпкәм юк үзенә. Нәрсә эчәсез?

— Нәрсә әйбәт — шуны.

Башта без берәр стакан эчкелтем ак шәраб эчтек, аннан татлы алсуыннан авыз иттек, бара торгач, кызылына күчтек. Кире акка әйләнеп кайткач, Леня Уточкин шап иттереп өстәл сукты:

— Мин бит генерал булыр өчен туган кеше идем. Кавалерия генералы! Хәзер — отставной лейтенант... Буш гильза...

— Исән калуыңа, яшәвеңә шөкер ит, исәр,— дип орышты аны хуҗа карт.

— Тирес корты да яши әнә! Түшемне каплап торган шушы хәситәмне көтүче чикмәненә тагыйммыни? — Ул кулының кыры белән түшен сыпырып алды. Күкрәк тулы орден, медальләре чылтырап куйды.— Егерме өч яшеңдә хыялларың белән хушлашу җиңел түгел. Ой, җиңел түгел!..

Мин ару гына исерсәм дә Леня Уточкинны аңларлык, хәтта кызганырлык хәлдәмен. Без икебез, гүя, ике дөньяда, ике заманда яшибез. Аның өметләре артта торып калган, ә минекеләр, исән булсам, әле алда. Баягы тәвәккәл, гамьсез, шук лейтенант кая булды соң? Монысы бөтенләй бүтән кеше бит. Күрәсең, ул үзенең газапларын, әрнүләрен тыштан ялтыравык кабык эчендә яшереп йөртә. Нәрсә дип юатыйм? Мин тәү тапкыр мондый хәлгә очрадым. Без, исән калганнар, әрмән карты әйтмешли, яшәвебезгә шөкер итәбез. Ә Леня Уточкинга бу гына аз.

Шунысы сәер: лейтенант зарларын шушы урында шып туктатты, кабат үзенең ялтыравык кабыгын киде. Без, дөньябызны онытып, типтерергә тотындык. Әрмән бабаеннан соң, ниндидер вино базына кереп, тагы берәр кружка түнтәрдек, аннан базарга барып чыктык, кайтышлый вокзал буфетына сугылдык. Монда колач җәяргә өлгермәдек, кемдер минем җиңемнән тотты.

— Капитан?! Мин сезне бөтен каланы бер итеп эзлим. Котларым очты. Исән... Ярый исән!

Мин күтәрелеп карадым, ләкин эндәшә алмадым. Тел әйләнми, аңкауга ябышкан.

— Ходаем! Нинди көнгә төшкән...

Тәүдә буфет киштәсендәге шешәләр, аннан тәрәзәләр, стеналар чайкалып китте. Алар авып төшәр-төшмәстән, йорт үзе әйләнергә тотынды. Бөтен нәрсә әйләнә, тик төпсез ике кара күз генә кымшанмый, үз урынында тора.

Мин эреп югала барам, югала барам. Юк, эремим, батам, сеңәм. Шушы ике күз мине үзенә йота.

Мин нәрсәдер дыңгыр-дыңгыр килүдән уянып киттем. Вагонда барабыз икән. Маңгаемда дымлы чүпрәк. Аны кемнеңдер кулы басып тора. Таныйм мин ул кулны. Людмила. Кичәге көннең исерек мажаралары кинәт күз алдыма килеп баса. Мин куркып күзләремне йомам. Ә ул күренешләр торган саен ачыграк, мәсхәрәлерәк төс ала. Күзне чытырдатып йомып кына хурлыктан котылып булмый шул.

— Су эчәсегез киләме?

— Килә.

Кулын җилкәмә куеп, ул минем башымны күтәрде. Куллары эссе...

— Мөмкин булса, көчегездән килсә, кичерегез мине, Людмила.

— Вак-төякне куеп торыйк. Мә, эчегез, сакаллы сабый. Сулышыгыз туктый да куя, туктый да куя бит. Шулкадәр курыктым. Эчегез инде.— Стаканны ул үзе тотып эчерде.

Өстәге сәндерәдән кемнеңдер зур арык аягы сәленеп төшкән. Ул вагон көенә аз гына тирбәлеп бара. Әрмән картының кыркылган аягын асып куйганнармы әллә? Мөгаен, шулдыр... Тәмам саташам, акылдан язам бит инде!

— Мин саташам, ахры, Людмила.

— Хәзер саташмыйсыз инде.— Ул минем башымны янә мендәргә төшерде.— Йоклагыз!

— Сез дә...

— Мин дә йоклармын.

Төн буе Людмила мендәргә баш та терәмәде. Ничә уянсам да, шул бер хәлдә, минем маңгаема дымлы чүпрәк баскан көе утыра иде. Таңга табан хәлем аруланды. Людмила да чишенми генә ятып оеп китте. Гомеремдә тәүге һәм соңгы тапкыр мин аның йөзенә озак итеп

карап тордым. Озын керфекләренә, кабарынкы иреннәренә, киң маңгаена, күпереп торган кара чәченә, бәләкәй генә колакларына тансыгым кайтканчы карап калдым. Минем карашларымны сизеп, бугай, ул күзләрен ачты.

— Нәрсә, Капитан? Нигә шулкадәр текәлеп карыйсыз?

— Аерылышабыз бит. Азак бик карардай булырмын да...

— Вакытыннан элек боекмагыз. Алда — башланмаган көн бар. Елның иң озын көне — 23 июнь.

Моннан да кыска, моннан да тиз үткән көнем булмагандыр. Чакма чаккан шикелле, чагылып кына калды. Үзебез белән бер купеда барган кешеләрне дә, тәрәзә аръягында торып калган җәйге яшел дөньяны да шәйләргә өлгермәдем. Ул көн — Людмиланың күзләрендә генә иде. Күз ачып йомуы булды — янды да сүнде көн. Төнен без Сталинградка килеп җиттек. Поезд монда ярты сәгать тора. Людмила, шунда төшеп, Ростовка китәчәк. Аны ире каршыларга тиеш. Без, әйберләрне алып, вагоннан чыктык. Коеп яңгыр ява. Людмиланың ирен көтәбез. Безнең янга килүче юк. Мөгаен, биш минут, ун минут үткәндер. Торабыз. Сөйләшергә сүз юк. Тиздән башка кеше белән башка сүзләр сөйләнеләчәк. Ә ул юк та юк. Юкны көтмәскә, вокзалга керергә булдык. Вокзал дигәне байтак читтә торган такта бина булып чыкты. Людмиланы шунда илттем. Болдырга җиткәч, ул хушлашырга кулын бирде:

— Хуш, Капитан, бәхил бул... Хат яз. Берне генә...

Мин аны чемоданы-ние белән ишек төбендә калдырдым. Эчкә кертүемне теләмәде. Мин поезд янына ашыктым. Тыным кыскалап туктыйм да янә йөгерәм. Яңгыр көчәйгәннән-көчәя бара. Җитмәсә, җилләп тә җибәрә. Мин үтәдән-үтә чыландым. Перронга килеп җиткәч, үзебезнең составны күреп, тынычландым. Азрак туктап хәл алдым. Кинәт, яңгыр шавын басып, буш перронда куәтле тавыш яңгырады; ул тавыш шундый хәвефле; бу караңгы

хәтәр төндә ул я үзе адашкан, я адашкан берәүне эзли булырга тиеш. Кемне чакыра ул?

— Людмила! Людмила Соколова, кайда син? Людмила!!

Ул минем арттан составның койрыгына йөгереп үтте. Мин аңа әйләнеп карамадым. Вакытыннан соңлаган шушы тавыш, яңгыр эченә кереп батканчы, бер үк сүзләрне кабатлады:

— Людмила Соколова, кайда син?! Людмила! Людмила Соколова!

Бу чакыру минем йөрәгемне телеп үтте. Поездга утыргач та, төшкәч тә, яткач та, торгач та колагымда һәм күңелемдә шул аваз яңгырады. Хәзер инде мин үзем сөрәнлим, адашкан җаным үзе чакыра: «Людмила Соколова, кайда син?!» Җавап юк.

Мин аңа бер-бер артлы ике хат яздым. Мәхәббәт хатлары иде алар. Людмиланың көннәре санаулы икәнен дә беләм, тойгыларымның фаҗигале икәнен дә аңлыйм, сүзләремнең юанычсыз икәнен дә күрәм, шулай да язам. Чөнки янам. Бәлки, хатларым аңа әҗәле алдыннан гына барып җитәр, бәлки аның акыллы куллары бу кәгазьгә кагылып та өлгермәс, шулай да язам. Чөнки әле мин теремен.

Хатларым барып өлгергән. Җавап килде.

«Кадерле кешем!

Язуыма карап, сизәрсез, бармакларым миңа буйсынмый. Хәрефләрем таралып тора. Шулай да язам. Мин бары шуны гына әйтергә телим: мин Сезне, инде Сезнең үзегезне яратып үләм. Симферопольдәге чагыгызны түгел, Ялтадагы чагыгызны яратам. Юк, дөрес түгел! Бүлеп-аерып ваклашу — дөрес түгел. Мин Сезнең бөтен үткән гомерегезне, бөтен калган гомерегезне яратам... Әле мин апрель уртасында ук дөнья белән бәхилләшергә тиеш идем. Теге чак, автобустан төшкәч, мин чемоданыма утырып диңгез белән хушлаштым, таулар белән саубул-

лашым. Сез килеп туктадыгыз. Мин, җәфалануымны күрсәтмәс өчен, Сезне куып җибәрдем. Куып җибәрдем дә үкенеп куйдым. Юксынып калдым. Шөкер, яңадан тап булыштык. Беләсезме, Сез нәрсә эшләдегез? Сез миңа өч ай, тулы өч ай гомер бүләк иттегез. Үпкәләрем беткән иде, йөрәгем көрчеккә килеп терәлгән иде. Өч ай буе мин мәхәббәт исәбенә яшәдем. Өч ай буе мине әҗәлдән саклап торды ул. Элегрәк очрашсак, бәлки, җиңәр дә идек. Соң, соң, соң иде шул... Монысы өчен дә Сезгә, язмышка рәхмәт. Шатланмаган шатлыкларымны, ирешелмәгән бәхетләремне сезгә калдырып китәм. Минем өчен дә шатланыгыз, минем өчен дә бәхетле булыгыз. Боекмагыз...

Людмила».

Гимнастерка кесәмдәге икенче хат менә шушы иде.

Кем учларына башымны салыйм икән? Олы инәемнең йомшак, җылы куллары күптән суынды шул. Аның мәңгелек кара юрганы өстенә берчә яшел, берчә сары, берчә ак япма ябыла. Анда да мизгелләр алмашына...

Олы инәем хушлаша

Зирәк кешеләр әҗәлнең дә нинди көндә, нинди сәгатьтә килерен беләләр, ахры. Минем Олы инәем соңгы елларда сырхаурак булды. Эч-бавыры маза бирмәде. Җәен-кышын диярлек я андыз тамыры, я әрем кайнатып эчте. Ул әрем суы авызга алырлык түгел, зерә әче. Олы инәем чыраен да сытмый эчә шуны. Чиреннән дә, әрем әчесеннән дә зарланмады ул. (Кемгә зарлансын? Йортта ул иң өлкән кеше. Аның үз хәсрәте дә, хәстәре дә, хәтта чире дә юк. Аның авыру җире сызламый, пешкән җире әрнеми. Бүтәннәрнеке генә әрни. Ул эчкән әрем дә әче

түгел, бүтәннәргә генә әче... Әлбәтә, боларны мин соңрак аңлаячакмын.)

Кичкә каршы талгын гына күбәләк кар ява башлады. Тәүге кар. Озакка сузылган кара көз күз алдында ап-ак кышка әйләнә. Ел мизгелен үзгәртү өчен әнә нәрсә генә — кар болытының җир өстеннән бер җилпенеп үтүе генә кирәк икән. Бары шул гына. Ләкин шул ак дөнья күз ачып йомган арада яңадан чем-карага да әйләнә икән. Монысын да мин үзем күреп кичердем.

Һавада беренче кар күзәнәкләре дә тирбәлешә башлаган мәлдә Олы инәем түшәккә ятты. Элек гел эчке яктагы иске өйдә бала-чага белән бергә гомер иткән кеше Кече инәемнән урынны урам яктагы зур өйгә салдырды. Ятар алдыннан ул чәчәкле яңа күлмәген, тәңкәле яшел камзулын киде, башына ап-ак яулык бәйләде. Сәлих агаем белән икебездән үлемтек сандыгын үз янына чыгартты.

«Үлемтек сандыгы» нәрсә дисезме? Ифрат серле нәрсә ул. Әби кешеләр, үз әҗәлләрен ерактан ук каршылап, хәлдән килгәнчә җайлап кына үлемтек туплый. Үзе өчен кәфен, кәфен тегәргә энә-җеп, кәфен эченнән кидерелә торган әхирәт күлмәге[1], үзен юарга сабын, үзенә сибәргә хушбуй һәм башка җеназа кирәк-яраклары әзерли. Монысы — сандыктагы мөлкәтнең кечкенә бер өлеше генә. Андагы төп хәзинә — мәрхүмнең терeләргә таратылачак бүләкләре. Әлбәттә, терeләргә ул үз кулы белән өләшә алмый. Аның исеменнән бүтән берәү өләшә. Искитәрлек йола инде: адәм гүргә керә, ә үзе, туйга килгәндәй, бүләк тарата. Без күтәреп китергән сандыкта Олы инәемнең әнә шул байлыгы иде. Авыр булып чыкты. Байтак тупланган.

— Мин озак юлга җыенам, Вазифа, ике-өч көн генә

---

[1] Әхирәт күлмәге — әхирәткә (оҗмахка) киеп керә торган күлмәк.

шунда ялгызым ятып хәл алыймчы...— диде ул, ястыгына башын терәгәч.

Минем йөрәгем жу итеп китте. Бөтенебез дә каушап калдык. Нәрсә бу! Әллә Олы инәем алмашына башладымы? Алай дисәң, күзләре тыныч, ягымлы, тик бераз йончулар гына.

— Ходаем, аталары да өйдә юк бит, ичмасам! Әллә Сәлихны артыннан җибәрикме икән? — дип үрсәләнде Кече инәем.

— Кайтып җитәр. Әле тиз үк түгел. Тиешле мәшәкатьләрне дә башкарып өлгерербез.

Чынлап та, нәрсә соң әле бу? Олы инәем бит коточкыч сүзләр әйтте. Ә тавышы, торышы шундый, әйтерсең, ул көн дә кичке чәй вакытында сөйләнә торган гадәттәге хәлләрне генә хәбәр итә.

Күңелемнән тәүге өнсез сыктау бәреп чыкты, ә аңым куркынычны кабул итми, аңа ышанмый. Менә шулай, күкнең бер ягыннан давыллап, яшенләп килгән яңгырны икенче яктагы кояш башта исәпкә алмый. Ләкин, күпмедер вакыт үткәч, кояш үзе кара болыт астында торып кала. Өстемә җимерелеп килгән афәт минем зиһенемне томалап кына өлгермәгән әле.

Әтием калада. Мортаза агаем колхоз өчен Уралда агач кисә. Ирләрдән өйдә Сәлих агаем да мин генә.

— Оланнарым, килегез әле,— дип, Олы инәем безне үз янына чакырып алды,— сезнең икегезгә дә үтенечем бар.

Без, ахры, башларыбызны үтә нык игәнбездер.

— Башларыгызны болай имәгез. Сабыр булыгыз. Сезгә йомыш күп төшәчәк бу арада.

— Безгә ни, Олы инәй, йомышыңны кушып кына тор. Без ни ул жибы-жибы гына... Йомыш ни ул — булсын гына, Олы инәй...— Каушый-каушый әйтеп салды Сәлих агаем.

— Үзем кендеген кискән балаларны күрәсем килә. Иртәгә шуларны җыегыз. Утыз көнлегеннән алып утыз

яшьлегенә кадәр һәммәсе дә килсен.— Аның тавышында боеру яңгырап калды.— Һәммәсе дә! Өйдән өйгә йөрмәгез, хәбәр генә таратыгыз.

Хәбәрне «ә» дигәнче авылга таратып җибәрдек. Кирәк кеше үзе белер, белмәгәненең ата-анасы төшенеп алыр. Шулай да гаҗәп хәл бу, сәер тамаша. Олы инәем юк белән булмас. Күрәсең, шулай кирәктер.

Үз теләге белән Олы инәем төнен ялгыз кунды. Урында көе генә иртән бер чынаяк чәй эчте. Бүтән ризык капмады. Мин инде малларга азык биреп, асларны тазартып кердем. Кар туктаган иде. Шыңгырдап торган чалт аяз көн тышта. Көннең саф сабыйлыгы, күкнең зәңгәр гамьсезлеге безнең өйдәге хәлләргә һич тә туры килми. Дөнья үз алдына, без үз алдыбызга көн күрәбез.

Эчке өйдә чәй урыны җыелып бетәр-бетмәстән, безгә кеше агыла башлады. Тәүдә, имчәк баласын күтәреп, чуендай кара янә дүрт малаен ияртеп, Кара Йомагол бичәсе килеп керде. Өлкән игезәкләре Хәбибулла белән Хисбулланы мин беләм. Алар инде мәктәпкә йөри. Икенче игезәкләре, тагы иң бәләкәчләре минем катнашлыктан тыш туган малайлар. Боларын белмим. Йомагол чебешләренең артыннан ук ишектән Өч этәч урамындагы Кадергол картның козгын борынлы Ишморзасы томшыгын сузды. Әсгать белән Хәмитҗан почмакка сыенды. «Биек-биек ызбада яшьләр түгә» торган Фәридә, кереп, мичкә сөялде. (Ул инде тәмам җиткән кыз. Сылулыгына хәйран калырлык. Ләкин әле берәүгә дә күз салмый. Салса, сизелер иде...) Бәләкәч энеләрен я сеңелләрен җитәкләп, яки күтәреп алган үсмер малайлар, үсмер кызлар һаман килә бирде. Ирле-хатынлылар да күренгәли. Кайсылары — бала-чагалы. Кыскасы, аягына басканы, түшендә шуганы, йөгереп йөргәне, егет корына кергәне, кәләш-килен булганы, сакал-мыек кырганы — һәммәсе дә агыла торды, агыла торды. Тәүдә безнең эчке өй тулды. Шуннан олыраклар, бәләкәйрәкләргә урын бушатып, ишек алдына чыкты. Анда да сыймагач, иха-

тага сибелделәр. Тик туган-тумачадан гына беркем дә юк. Чөнки Олы инәем нәсел-нәсәпкә кендек әбие булмады. Аларга бүтән әбиләрне чакыралар. Әйткәнемчә, өй тулы, кура тулы эреле-ваклы адәм балалары. Хәтта усаллыгы, кансызлыгы белән яманаты чыккан Таҗетдин дә калмаган. Ул бөтен адәмне өркетеп тота. Теге кытлыгырак елны минем дә котымны алды ул. Мин ындыр артында үзем ясаган наганнан атып йөри идем. Ату дигәне шул инде: көбәгенә бер чеметем дары саласың да, кабыргадагы тишеге турында шырпы сызып, шартлатасың. Каяндыр Таҗетдин килеп чыкты да минем наганымны тартып алды. «Әһә, кеше үтерергә йөрисеңме әле? Беләсеңме, сельсоветка әйтсәм, бу корал өчен ни эшләтәләр? Төрмәгә ябалар я атып үтерәләр. Башың бетте, малай!» — дип җикеренде. Куркуым табаныма барып җитте. Харап булдым! Таҗетдин шәфкать белми ул. Инәлү-ялвару файдасыз. Мин үз алдыма бетеп, югалып барам. Ул аз гына кире сүрелгәндәй итте: «Ярый, Олы инәең хакына гына коткарам. Түлке, караңгы төшкәч, менә шуннан ындыр артыннан гына килеп, бер бидрә бәрәңге китереп кит. Бәрәңгеңне безнең койрыктагы имән төбенә бушат. Кара аны, бидрәң тулы булсын! Бу хакта һичкемгә ләм-мим...» Ул, минем наганны кесәсенә тыгып, үз юлына китте. Әйләнеп тә карамады. Мин шик эчендә калдым. Вәгъдәсеннән кайта гына күрмәсен инде! Караңгы төшкәч тә, баздан чәлдереп, тулы бидрә бәрәңгене әйткән җиргә илтеп аудардым. Сүзендә торды алай, минем гаепнең очы чыкмады. Шулай да җиңел котылдым. Олы инәем булмаса, баш китә иде... Әнә шул Таҗетдин дә килгән. Үзен тыйнак, ипле тота, әйтерсең, мулла кияве...

Кеше бик күбәйгәч, мин Олы инәем кырына кердем:

— Җыелып беттеләр инде, Олы инәем.

— Яныма керсеннәр.

Бер-ике минут эчендә безнең зур як туп-тулы булды. Бәби күтәргән аналар, оныкларын китергән әбиләр, вак

балалар, урыны җиткәнчә, утырышты. Бүтәннәре баскан көе калды. Нинди генә зат, нинди генә төс юк монда! Кара чәчлесе дә, сары чәчлесе дә, соры күзлесе дә, зәңгәр күзлесе дә, төймә танаулысы да, кылыч борынлысы да, чибәре дә, ямьсезе дә бар. Шуларның бөтенесенә дә тәүге фатиханы минем Олы инәем биргән. Безнекеләрдән бу якка мин генә кердем. Авыруның ихтыяры шулай булды.

Тавыш-тын, ыгы-зыгы тиз үк басылды. Бәләкәчләр тынып калды. Кечкенә балалар бөтенләй өнсез калг чактагы тынлык шиклегә, хәвефлегә әйләнә икән. Менә әле дә өйне бертөрле шом басты.

Олы инәем акрын гына урыныннан торды. Башын җай гына борып, берәм-берәм бөтенесенең дә йөзенә карап чыкты. Кайсыларына озак текәлеп торды, кайсыларына күз ташлап кына үтте. Ара-тирә исемнәрен әйтеп эндәшкәләде дә: «Күптән күргәнем юк иде, Зәбирә, нинди үсеп киткәнсең... Солтангалинең күзе төзәлгән икән... Елак Шатморатның да елаклыгы беткәндер инде... Бәләкәй Акйолдыз атасына ничек охшап бара... Кая, килен, төпчегеңне тагы бер күримче...» Кара Йомагыл хатыны, иренен кыймылдатып, мыш-мыш йоклап яткан кара малаенын йөзен Олы инәем ягына борды. Олы инәем әле исеме дә юк шушы малайга бөтенесеннән дә озаграк карап торды. (Авылыбызның иң яңа кешесе, түшәктә яткан кендек әбисе дөньяга кабул иткән иң соңгы бәби иде ул.) Авыруның карашы инде Таҗетдингә тукталды. «Килгәнсең икән, һәйбәт»,— дип хуплады ул караш.

Олыраклар гаҗәпләнеп, бала-чага аптырап, берәз сабырсызланып нәрсәдер көтә. Шулай карап, барлап алыр өчен генә чакырмагандыр бит. Бер-бер хәл бардыр. Күңелле тамаша булмас, әлбәттә, мондый иртә таңнан...

Олы инәем турая төшебрәк утырды.

— Балалар,— диде ул,— бу якты дөньяга мин сезне берәм-берәм кабул иттем. Ә менә хушлашыр өчен бөтенегезне берьюлы чакырдым. Килгәнсез, рәхмәт. Минем

рәхмәтемне әле аңламаганнар, үскәчрәк төшенер. Өлкәнрәкләр төшендереп бирер. Әйе, исән вакытта күзгә-күз карашып саубуллашыйк дидем. Эчем поша. Дөнья хәлен белеп булмый.

Кемдер сыктап куйды. Теге Фәридә икән. Бөтенесе дә аңа әйләнеп карады.

Олы инәем тавышында миңа таныш булмаган корылык ишетелде:

— Елашырдан булса, балалар, хәзер үк таралышабыз. Мин сезне моның өчен чакырмадым. Әлегә иртә. Вакыт җиткәч, тыймам. Тыя да алмам. Ә хәзергә иркенләп, тыныч сөйләшик.

Шулай диде дә күңелдән күзгә килә торган яшь юлларын ябып та куйды.

— Ул бит, әбекәй, күңеле йомшаклыктан гына...— дип, Фәридәне яклады Әсгать.

Олы инәем баш какты, ләкин сүз белән җөпләп тормады. Күрсендеме, әллә болай тирән итеп тын алдымы,— ул байтак эндәшми торды. Гадәттәге йомшак, җылы тавышы белән сүз башлады.

— Васыять әйтер, үгет бирер өчен җыймадым мин сезне, балалар. Бишектә ятып, имезлек имгәнегезгә дә, җир сөреп, иген иккәнегезгә дә бары фатихамны гына яңартам, теләкләремне генә кабатлыйм: бер-берегезгә игелек күрсәтсәгез, үзегез игелек күрерсез. Онытмагыз шуны.

— Рәхмәт, әбекәй, онытмабыз,— диде Әсгать. Яхшы сүзнең кадерен белә ул.

Олы инәемнең әйткәннәрен бөтенесе дә аңламый, әлбәттә. Моны ул үзе дә сизәдер. Ләкин аңлаганнарына әйтеп, йөрәкләренә изгелек орлыгы салып калдырсам, заманы җиткәч, тегеләренә дә күчәр дип, өмет итәдер, мөгаен. Бер бөртек арыштан утыз-кырык бөртекле башак ярала түгелмени?

Вак балаларда инсаф белән чыдамлылык күпкә җитмәде: боргалана, шаулаша башладылар. Олы инәем

кинәт юрган астыннан чыкты да идәндә торган баягы сандык янына килеп тезләнде. Уң кулы белән сандыкның капкачын сак кына сыйпап куйды.

— Дөньялыкта мин бик күп бүләкләр алдым,— диде үтә тыныч.— Сезнең һәрберегез туган сәгатьтә миңа, рәхмәтләр укый-укый, затлы сөенчеләр бирделәр. Затлы булмаса, затлы дип кабул кылдым. Тавык бирсәләр, каз дидем, бакыр бирсәләр, көмеш дидем, киндер бирсәләр, ефәк дидем.— Ул сәер генә көлеп куйды.— Шулай итеп баеп-череп беттем. Менә күпме мал җыйдым.— Ул сандык капкачын тагын бер кат сыйпап алды.— Дөньяныкы дөньяда кайтырга тиеш. Әлегәчә гел мине бүләкләделәр. Менә хәзер бүләккә каршы үзем бүләк өләшер вакыт җитте. Миңа күпләр тапшырды, мин дә күпләргә тапшырырга тиешмен.— Ул чыңлатып сандыгының капкачын ачып җибәрде. Ләкин берәү дә, муенын сузып, сандык ягына омтылмады.— Төймәсен дә, дөя күреп, кабул итегез. Я, төрткәләшми генә килегез. Бәләкәчләрне алдан җибәрегез...

Беребез дә көтмәгән тамаша башланды. Олы инәемнең йөзе яктырып, кул хәрәкәтләре җиңеләеп, бөтен кыяфәте җегәрлеләнеп, хозурланып китте. Әйтерсең, ул хәзер үз гомерендә иң бөек, иң изге, иң матур эшен башкарачак. Әле булса кымшанган кеше юк. Аптырап көтәләр. Олы инәем Кара Йомагыл хатынына төбәп эндәште:

— Алайса, килен, синең төпчегеңнән башлыйк,— малайның әнисенә ул бик матур имезлек тоттырды. Кырында басып торган бәләкәч кызның муенына кызыл ефәк тасма салды. Хәбибулла белән Хисбуллага берәр каләм эләкте. Шуннан китте!.. Инде балалар, кыюланып, үзләре сандыкны сырып алды. Ләкин кул сузучы күренми, биргәнне инсафлык белән көтәләр. Өләшүченең юмарт куллары берсеннән-берсе затлырак нәрсәләрне чыгарып кына торды. Кемгә таш курчак, кемгә сызгырткыч, кемгә кәтүк, кемгә бәләкәй резинка туп, кемгә

кургаш солдат, кемгә уймак, кемгә елтыравык кашлы булавка тиде. Зурраклар өлешенә мулрак та төште: боларга исле сабын, бармак буе гына савытларда хушбуй, кәкре тарак, кершән, бакыр балдак, тимер кубыз, аллызәңгәрле чәчүргеч, җиз эскәк шикелле нәрсәләр эләкте. Бүләген алган һәркем озак капланып тормады, кире үз урынына баса барды. Буталыш булмады. Шулай да башта шактый мавыктыргыч булган бу мәшәкать байтакка сузылды. Олы инәем йончый төште. Ләкин янына килгән һәр җан иясенең — тәүгесеннән соңгысына кадәр — аркасыннан сөеп, башын сыйпый барды. Олысын да, кечесен дә мәхрүм калдырмады. Нигәдер Таҗетдинне генә сөяргә онытты. Бүләген сузганда, тегенең күзенә бертөрле кызганып карады да башын читкә борды.

— Бөтенегезгә дә өлеш чыктымы? — диде ул азактан.

Эндәшүче булмады.

— Мәхрүм булып калучы юкмы?

Янә тынлык.

— Ярый алайса, болары җеназага калыр,— дип, Олы инәем шап иттереп сандыкны япты.

Шул мәлдә ишек төбендәрәк торган алты-җиде яшьлек чем-кара чәчле бер кыз кычкырып елап җибәрде. Үзе ике учын да алга сузды: «Минем бернәрсәм дә юк... ышанмасагыз, менә карагыз... Кендек әбием мине сөймәде дә...» Олырак бер малай шунда ук үзенең балчык куянын сузды. Теге алмады, әмма елавыннан туктады. Олы инәем өлешсез калган бәләкәч кыз өчен сандыкны яңадан ачты, баланы үз янына чакырып китерде, аркасыннан сөйде, башыннан сыйпады. Сандыкның төбенәрәк тыгылып, кызыл читле зәңгәр яулык чыгарды, аны җәеп, бер кагып алды да, уртага катлап, үз кулы белән баланың башына бәйләде. «Менә сиңа да булды...»— дип, тагы сөеп куйды. Сандыкны инде ул бөтенләйгә япты. Бүтәнчә ул-бу булмады.

Бүләк алган яшь-җилкенчәк тә, бала-чага да зык кубып куанмады. «Кая күрсәт әле... Тотып карыйм әле...»

дип, бер-берсенә ташланмадылар. Мондый сәер хәл безнең авылда да, тирә-якта да булмагандыр, мөгаен. Кеше үз кулы белән үз үлемтеген таратсын имеш... Чынлап та, гаҗәп бит! Сөенергәме моңа, әллә көенергәме? Нәтиҗә чыгарырга хәзергә ашыкмый торыйк. Моның шундый бөек, шундый күркәм күренеш икәнен без күп гомерләр узгач кына аңлаячакбыз — аңларга насыйп булганнарыбыз...

Олы инәем ашыкмый гына кабат түшәгенә менеп утырды. Эреле-ваклы адәм башларына тагы бер карап, гүя, барлап чыкты.

— Күрешү бик һәйбәт булды бит әле. Күзгә-күз караштык. Китеп барсам, һәммәгезгә дә бәхиллегемне биреп калдырам. Һәммәгезгә дә... Өлкәннәрегез, мөгаен, минем каберемә туфрак салырга килер. Моның өчен алдан ук рәхмәт әйтеп куям. Тик бераүгә генә рөхсәтем юк.

Олыраклар, бер-берсенә карап, шомланып калды. Уебыз белән шик астындагы кешене эзлибез. Кем икән ул? Күп көттермәде, табышмакны Олы инәем үзе чиште.

— Таҗетдин,— диде ул, башын ия биреп,— син ятим әниеңне тел белән җәберлисең икән дип ишеттем. Шул дөресме?

Җавап булмады.

— Хәтта аңа кул да ягасың икән дип ишеттем. Шул дөресме?

— Дөрес... Усаллыктан түгел, кызулыктан булды.

Олы инәем башын күтәрде:

— Ишеттегезме? Бөтенегез дә ишеттегезме? Таҗетдин әнисе тәненә җәрәхәт салган. Шул куллары белән каберемә туфрак ташларга аңа рөхсәтем юк.— Тез өстендә яткан уң кулын чак кына күтәрә биреп куйды.— Я, барыгыз инде.

Өйдәгеләр, җай гына кузгалып, бер-берсенә юл бирәбирә, ишеккә юнәлде. Тышкы якта кемнәрнеңдер тирән көрсенүе, шыңшып алуы, буылып елап җибәрүе ише-

телде. Өйдә чакта түзделәр, рәхмәт. Мин иң тәүдә Таҗетдин чыгып ычкыныр дип уйлаган идем. Юк, ычкынмады. Иң соңга торып калды. Кеше беткәч, кулындагы бәләкәй генә хушбуй савытын саклык белән генә сандык өстенә китереп куйды. Аннан, бәргәләнми-суккаланмый, акрын гына өйдән чыгып китте.

Олы инәем күзләрен йомды. Черем итә, ахры. Бәлки кирәгем булыр дип, янында калдым. Кышкы тәбәшәк сары кояшның нурлары аның юрган тышында калган кулларына төшкән. Алар җемелдәп тора. Текәлебрәк карасаң, кояш түгел, Олы инәемнең куллары шулай нур чәчә икән. Ике кул урынында ике кояш кисәге ята юрган өстендә. Әйтәм, башымны куйсам, шундый җылылар, шундый шәфкатьлеләр алар! Кагылу белән бөтен хәсрәтләрне, чирләрне, шикләрне читкә алып ыргыталар. Ә аңа килгән җәфаларны нинди куллар алып ыргыткан, аңа төшкән хәвефләрдән нинди куллар саклаган соң? Бу хакта мин кайта-кайта уйлыйм. Чөнки уйларлык яшькә җитеп киләм хәзер.

Күпме утырганмындыр, белмим. Әмма шушы вакыт эчендә Олы инәем белән бергә үткән сукмакларны, яланнарны, урманнарны йөреп чыктым. Чыктым, чыгып бетә алмадым. Аның белән бергә эчкән чишмәләрдән ятып сулар эчтем. Эчтем, эчеп туя алмадым. Уналты яшемә кадәр мена аның ышыгында яшим. Яшим, ә балалыктан уза алмыйм. Ул төяген алыштырырга, мәңгелек йортына күчәргә җыена. Беләм, ул киткәч, мин елармын. Елармын, ләкин бервакытта да елап бетерә алмам... Тамагыма төер килеп тыгылды менә...

Ул күзләрен ачты:

— Син монда икәнсең, синнай. Һәйбәт.

— Я бер-бер нәрсә кирәк булыр дидем...

— Берни дә кирәкми. Калуың әйбәт... Син булгач, дөнья буш түгел.

— Өләшкән бүләкләрең өчен бала-чага куанып китте,— дип ялганладым мин.

— Куй, сиңнай, юатма мине. Куансалар, начар булыр иде. Ходай әшкәртте: куанмадылар. Мин бит аларга сөенечкә таратмадым. Хатирә бүләге калдырдым. Хушлашыр өчен буш кул биреп кенә өйдән чыгып китә алмадым... Бөтенесен дә күрәсем килгән иде — рәхмәт яугырларны. Морадыма ирештем. Әллә Таҗетдингә катырак хөкем чыгардым инде? Ярый, үзенә дә, бүтәннәргә дә гыйбрәт булыр. Гыйбрәтсез дөнья бармый ул. Ярлыкамый торган языклар да була шулай. Исеңдә тот: ана хакыннан да изге нәрсә юк.

— Беләм, Олы инәем, икеләтә беләм — икегез хакын да...

Ул янә күзләрен йомып торды:

— Үкенечләрем юк минем хәзер. Булса да, үкенергә соң. Менә сине иртәрәк калдырып китәм, шунысы гына аяныч. Канатларың нығып җитмәгән, ис итмәстән имгәтеп ташламагайлары. Балалыктан чыгып өлгермәдең. Хәер, син гомер буе балалыктан чыгып бетмәячәксең. Бәхетең дә, бәлаң дә шунда синең. Ходай ярдәм бирсен! Үзем дә бүген җир белән күк арасында кебекмен. Арымадым да, көчем дә юк. Килеп торып йокы баса...

Ул тагы йоклап китте. Мин чыгып, авыл арасында йөреп кайттым. Халык Олы инәемнең кылыгына тәмам хәйран калган. Ни дип әйтергә дә белмиләр. Төрле имешмимеш таралган. «Әҗәл сәгатен фәрештәләр күңеленә әшкәрткән икән...» — дип күрәзәлек итте берәүләр. «Кендек әбисе акылга зәгыйфьләнеп куймагае...»— дип борчылдылар икенчеләр. Өченчеләр ниндидер гыйбрәтле мәгънә, гыйльләле фәһем эзләделәр. Кешенең тере чакта тереләр белән гади генә, адәмчә генә хушлашып китәргә теләвен берәү дә башына сыйдыра алмады...

Кичен ул башта сеңелем Сәлисә белән энем Ильясны чакырып алды. Алардан соң Сәлих агаем байтак торып чыкты. Минем Сәлих агаем ифрат йомшак күңелле. Күз яшьләре атылып чыгарга гына тора. Әле дә ике күзе тулы яшь иде. «Авырайдымы әллә?»— дип хафаланды

Кече инәем. «Юк,— диде теге,— ул миннән гафу сорады, әгәр аңгармастан җәберем кагылган булса, рәнҗеп калма, улым»,— диде... Минем үтә сабыр Бикә җиңгәм дә, тыела алмый, авыру яныннан сыктап килеп чыкты.

Иң азактан яңа өйгә Кече инәем кереп китте. Ул бик озак торды. Бәләкәйләр көтә-көтә арып, йоклап китте. Сәлих агаем почмактагы бүкәндә бөршәеп утырган. Ул ара-тирә уфылдап куя. Мин торган саен шомлана барам. Эчем өзелә. Чыдамадым, ишекне шым гына ачып, зур якка кердем. Җиделе лампа кысыбрак куелган. Шулай да шәйләп булырлык. Кече инәем Олы инәемнең караваты янында как идәнгә тубыкланган. Тегесе моның башына кулын салган. Шыбырдап кына нәрсәдер сөйләшәләр дә бугай. Менә Кече инәем мыңгыр-мыңгыр килә:

— Нихәтле ел инде көтәчәккә алган куаныч белән яши кебекмен. Ара-тирә кинәт дертләп китәм: имеш, балаларымны да миңа үтечкә генә биргәннәр. Бер карасаң, монысы дөрес тә — аларны мин тудыра тордым, син канат астыңа сыендыра бардың. Сөендем дә моңа, хәвефләндем дә. Балаларым аша мине кабул итүеңә сөендем. Хәвефемнең сәбәбен әйтә алмыйм. Юк, юк... Әллә нәрсә буталдым. Әйтә торганым бүтән сүз иде. Ә-ә.. менә нәрсә: мин бит тораташ түгелмен, синең күңел газапларының сәбәпчесе икәнемне күптән аңладым. Әрнүләремнең чиге булмады. Әйтәм бит, бөтенесе дә үтечкә — шатлыгы да, бәхете, өмете дә... Син чирләп киткәч, изаларым тагы да артты.— Ул шым гына еларга керешә.— Миңлеямал апа! Я языгымны ярлыка, я, кычкырып, үз телең белән каһәрлә мине... Бурычымны кайтара алмыйм, кодрәтемнән килми.

— И, исәр сабый, бурычың да, языгың да юк синең. Мин бернәрсә дә үтечкә бирмәдем сиңа. Һәркемнең бәхете дә, казасы да үзе белән. Сине бит мин үзем яучыладым, онытмаган булсаң. Акылым камил иде.

— Анысы шулай булды. Камил акыл белән үзең димләдең. Әмма акыл бер, күңел икенче икән. Мин дә ул чак

алдын-артын уйлап тормыйча, синең фатиханны кабул кылып, ризалаштым. Баксаң... Кайсысы күбрәк булгандыр — күңел рәхәтеме, вөждан газабымы? Я ярлыка, я каһәрлә, апа. Бу көе ярамый.

— Язығың юк,— дип кабатлады Олы инәемнең йомшак тавышы.— Үткән газапларымның сәбәпчесе син түгел, язмыш үзе — минем язмышым. Ә хәзер минем бер газабым да юк...

— Миңлеямал апа, зинһар,— дип ялварды Кече инәем,— зинһар, шикләремнән коткар мине. Азат ит...

— Синеңчә булсын. Азат итәм. Әгәр гөнаһың була калса, аны үземә алам!.. Сине мин димләдем... Я бар, анда балалар куркышыр.

Кече инәем торырга ашыкмады. Мин сиздерми генә кире чыгып киттем.

Төн уртасында әтием кайтты. Иртә белән Сайрандагы апам белән сунарчы җизнәм килеп җитте. Сәлих агаем барып алды аларны. Тирә-як авылдан бүтән кардәш-ыру җыелды. Олы инәем, һәрберсен янына чакырып, хушлашты, әйтер сүзен әйтеп, бәхилләште. Бу көн кичкә каршы ул авыраеп-авыраеп калды. Төнен тагын аруланды. Ә таң атканда китеп барды. Җан биргәндә янында бер әтием генә булган. Күрәсең, Олы инәем үзе шулай теләгәндер.

Бу үлем мине яртылаш үтерде. Тәгәрәп елый да, буылып үксй дә алмыйм. Катып да калдым. Өч тәүлеккә якын безнең күз алдында әҗәле белән шаярып, Олы инәем безне бу хәлгә күнектерергә, ихтыярыбызны ныгытырга тырышкандыр, бәлки. Безне кинәт аяктан екмаска теләгәндер ул. Ләкин хаталанды. Чөнки аның дөнья белән шулай җиңел, тиз бәхилләшүенә без алдан ышана алмадык. Хәзер дә ышанмыйбыз. Әнә ул, чәчкәле яңа күлмәген, тәңкәле яшел камзулын киеп, ап-ак яулыгын бәйләп, ятып кына тора. Ул арымаган да, тик көче генә юк.

Иртән үк, талпынып-талпынып, ябалак кар яварга

керешге. Көн буе туктамады. Әсгать белән Хәмитҗан, колхоз аранынпан алып, ике ат менеп килде. Алар хәзер авыл буйлап иң куркыныч, иң хәсрәтле оранны кычкырып үтәчәкләр. Әнә, икесе урамның ике ягына чыгып, Түбән очка җилдереп тә киттеләр.

Йөрәк ярып, алмаш-тилмәш ике аваз яңгырады.

— Җеназага барыгыз!

Төш ауганда Олы инәемне гүргә тапшырдык. Аның өстендә кап-кара йомшак түбә калкып чыкты. Ә кар һаман ява да ява. Кара туфрак өеме инде ак дөньяның эченә кереп батты. Кабернең эзе дә калмады... Кинәт бөтенесе дә алмашынды. Әйләнеп-әйләнеп, кап-кара кар яварга тотынды. Кара мамык бөртекләре берчә җиргә тартыла, берчә һавага омтыла, берчә безелдәшә-безелдәшә, өерелеп китә. Җир йөзе караңгыга чумды. Тик Олы инәемнең кабере генә, ап-ак тау булып, кара җир өстендә калкып тора. Кара кар бөртекләре ак тау башына кунмакчы булып киләләр дә кире очып китәләр; кунарга кодрәтләреннән килми, ниндидер тылсымлы көч җибәрми аларны, кире куып тора.

Халык зираттан таралып бетеп бара. Кемдер мине иңбашымнан тотып селкетте. Сәлих агаем икән.

— Әйдә кайтыйк.

— Кая? Нигә?

— ...

Олы инәем безне шулай бөтенләйгә ташлап китте. Шушы ук көннәрдә мин тагы бер үтә авыр, үтә газаплы фаҗигага кичердем. Олы инәем исән чакта, Кече инәем белән аларның икесен дә тигез ярата кебек идем. Дөресрәге, бу хакта уйламый, яратуымны бүлеп-ярып маташмый идем. Олысы дөнья куйгач, Кечесенә карата — күкрәк сөтен биреп үстергән үз инәемә карата — кинәт суынып киттем. Хәтта ятсына башладым. Ул минем кайгымны уртаклашмакчы, башымнан сыйпап юатмакчы итә. Мин читкә тайчанам. Ул ниндидер әйбәт сүзләр әйтә. Мин ишетмим. Һични кыла алмыйм. Ә үземнең рухым

өзгәләнә. Нәрсә булды миңа? Шулай ук Олы инәем бөтенесен дә үзе белән алып киттеме икәнни?Ниләр генә, ниләр генә эшләмәк кирәк? Бу кылыгым өчен Кече инәемнең аягына егылып, гафу үтенердәй, җәза сорардай булам. Тик көчем җитми... Миңа бит инде уналты яшь. Үзем, аулак җиргә тап булсам, тыела алмый сулкылдап еларга тотынам. Бу мин түгел, Олы инәемнең камзул чабуына тотынып китеп барган бала чагым елый. Тиз генә тукталырга чамасы да юк...

Вакыт үзенекен итте. Олы инәем әйтмешли, адашып йөргән җаным үз төягенә кире урап кайтты. Кайтты да кап уртага бүленде. Бер яртысы — хәтер һәм тугрылыкка, икенче яртысы яшәү һәм өметкә әйләнде. Шулай итеп, ике инәемә ике өлеш чыкты — хатирә һәм тормыш. Моннан ары мин икегә бүленгән бер җан белән яшәп киттем. Һәм гомер бакый шулай...

Котлы кул Насыйп

Сугыштан соң байтак гомер үтеп китте. Дөньялар иминләнеп, илгә бәрәкәт килде. Тән яралары бетәшә, күңел җәрәхәтләре уңала төште. Аяксызның — чатанлыгына, кулсызның — чулаклыгына, ятимнең — ятимлегенә, хәсрәтленең хәсрәтенә акрынлап күнегә киләбез. Күнми ни кыласың. Яу кырыннан исән кайтканнарыбыз, бала чактагы кебек, якынаеп, укмашыбрак яши башладык. Үлем белән яшәү арасындагы бердәнбер күпердән алып чыккан уртак язмыш безне тагын бер учак янына туплады. Егет чакта кыз-кыркын өчен ызгышып, кан үчләшеп йөргән ирләр дә, дошманлыкны онытып, гомум учакка тартылды, бер табактан ашар булды. Читтәгеләр белән хәбәр алыштык, сәламнәр күндерештек. Тик кордашларны кычкырып барларга гына куркам. Чөнки алар, элек куе урман шаулаган җирдә сирәк-саяк

серәеп калган агач шикелле, күз алдына килеп басалар. Берсе эндәшә, дүртесеннән җавап юк. Урман турында юкка гына телгә алмадым мин. Авыл янында үтә мәһабәт имән урманы бар иде. Сугышның озын дүрт кышында шушы урман бөтенләй бөлеп калган. Анда-монда бер агач боегып тора. Болар галәмәт юаннар, аударырга, күрәсең, хатын-кыз белән бала-чаганың көче җитмәгәндер.

Әллә нидә бер көтелмәгән могҗиза да булып куя: я хәбәрсез югалган берәүдән хәбәр килеп төшә, я бөтенләй гаипкә саналган кеше үзе кайтып килә. Шуңа күрә көткәннәрнең күңелендә өмет әле булса басылмый — сызлый да сызлый ул өмет...

Йомры Талип үлеп терелгән елны инде бөтенләй онытылып беткән Котлы кул Насыйп кайтып төште. Әгәр шушы очрашу булмаса, бәлки, мин аның турында болай озын итеп сөйләп тә тормас идем. «Насыйпның Котлы кул икәнен бөтен адәм белә, тагын нәрсә өстисең инде?» — дияр идем. Өстисе нәрсә бар икән шул.

Кунак кайтканын ишеткәч тә мин Мыек Шәрәфетдиннәргә киттем — Насыйпның атасын шулай дип йөртәләр. Шәрәфетдиннең бөтен карап торганы — керпе баласы зурлыгы шул кара мыек иде. Мин белгәннән бирле өендә киртә, курасында мал булмады, ә мыекны гомер буе тәрбияләде, карады, саклады. Әйткәнемчә, мыек тәүдә кара иде, аннан агарды, тора-бара саргайды. Шәрәфетдиннең бер мәзәк гадәте бар: өй эчендәге кешеләрне ул төп исемнәре белән атамый, үзе таккан кушамат белән йөртә. Насыйп — алабай, уртанчы улы — пумала, кече улы — колак, хатыны — артистка. Ямлиха җиңги артисткага болай һич тә тартым түгел. Тик бер генә гыйлләсә бар: әйбәт кенә атлап барган җиреннән ул, бер саны гарипкә күрә, кайчак, кыек-мыек басып, тыпырчынып ала. Бар һөнәре шул гына. Ә ире, артисткага чыгарып, әнә ничек югары бәһалый аны... Үги ана булса да Ямлиха Насыйпка карата тел-теш күрсәтмәде. Юаш

булды. Ә Шәрәфетдин каты иде. Берәүгә дә көн бирмәде. Бигрәк тә өлкән улын какты. Авызыннан аракы, теленнән әшәке сүз өзелмәде. Ул гел читтә, ниндидер кәсептә йөрде. Балта остасы иде, ахры. Кайткан арада өенең астын өскә китерде, бөтен урамның мазасын алды.

Колхозлашуның тәүге еллары иде бугай. Шәрәфетдин озак кәсептән, имеш-мимешкә караганда, ару гына котаеп кайтты. Кайтты да уттай эш өстендә бөтен урамны бер итеп эчеп, сүгенеп йөри башлады. Эштән соң кичке эңгер вакытында күрше-күлән нигез буенда әңгәмәләшеп утырганда, япон патшасын сүгә-сүгә, чайкалып, бу килеп чыкты. Эчеп алса, ул гел шулай: кемгәдер бәйләнер әүвәл, ике сүзнең берендә оятсыз әйтеп япон патшасын сүгәргә керешә.

— Өерәм мин япон патшасының ата-бабасын... бөтен нәсел-нәсәбен... бөтен зат-ыруын... Төкерәм мин япон патшасына... Көтүче Нуретдингә түгел, Казна Исхакка да алмаштырмыйм мин аны, инәсен ач этләр талагыры...

— Сүзеңне чамалабрак сөйлә, Шәрәфетдин, бала-чага бар бит,— диде минем этием,— хатын-кыз да ишетер...

— Ишетсен! Хатын-кызга тагын нәрсә кирәк? — дип, учы белән мыегын сыйпап куйды.— Ишетсен!!

— Шушында җитәр, Шәрәфетдин — дип, янә искәртте этием.

— Нишләп әле миңа әмер боерып утырасың, картлач? Имеш право? — дип кәпәренде мыек.— Әллә япон патшасы булдыңмы? Уходи, Ташкент тавыгы! Япон патшасын мин...

— Күптән теңкәгә тия идең...— алтмыш биш яшьлек этием егетләрчә сикереп торды да, селти биреп, Шәрәфетдинне сугып екты. Теге чалкан килеп төште. Байтак вакыт кузгалмый ятты. Аннан, акрын гына торып тезләнде, башын боргалап һушын җыйды. Аякка баскач, этиемә сөзеп карап торды. Менә хәзер ул этиемә ташланачак. Сугышны көт тә тор. Шәрәфетдин бер адым алга

атлады. Чак-чак сөрлегеп китмәде. Нишләптер кул күтәрергә ашыкмый.

— Һай-һай, агай, патша итеп куярлык кеше икәнсең,— диде ул, башын чайкап.— Һай-һай, агай, тамаша ясадың...

Шәрәфетдин, чайкалмый-нитми генә атлап, үз өенә уңайлады. Байтак ара киткәч, җырлап җибәрде.

Ефәк микән, ука микән
Чибәремнең чәч бавы?..
Чибәремнең чәч бавыннан
Сыйпаулары — җан савы.

Бәй! Шундый матур сүзләр дә белә икән ләбаса бу. Килешеп тора.

Моннан ары да аның әшәке сүзләре безнең тирәгә килеп җиткәләде-җитүен, ләкин исерек көе үзе аяк атламады.

Котлы кулларына үз йортында, үз илендә кадер таба алмый, Насыйп әле малай чакта, теге бергәләп калага калач ашарга барган җәйне үк, авылны ташлап чыгып олакты. Иртән олы юл буендагы тары җирен утарга дип киткән җиреннән гаип булды. Эзләп маташтылар. Җир өстендә дә, су астында да сөяге табылмады. Кычкырып елаучы, өзелеп искә алучы булмады. Тары урагы җитүгә ул онытылды да инде.

Ике ел үтүгә, кабартма кесәле чалбар, сары ката киеп, Насыйп янә авылга кайтты. Безне иң шаккатырган нәрсәсе — яшел читле хәрби фуражка иде. Аны күргәч тә, Әсгать: «Яшел башлы кигәвен»,— дип атады. Фуражканы олылар да, кечеләр дә, берәм-берәм кулларына тотып, башларына киеп карады. Шаһидуллага ул: «Нигә, ошаса, ал, тамчы да җәл түгел»,— дип, юмартлык күрсәтте. Башлык кире бирде: «Бер кәпәчне бөтенебезгә дә бүлеп бетә алмассың, үзеңә булсын»,— диде. Кайда йөргәнен, нәрсәләр эшләгәнен Насыйп беребезгә дә тезеп сөйләмәде. Сүз арасында гына аның, байтак җәфалар

күргәннән соң, приютка барып эләгүен, шунда укып ятуын аңладык. Яшел читле фуражканың бер командир бүләге икәнен белдек. Нинди батырлыклар өчен бүләк иткәнен әйтмәде. «Болай гына...»— диде.

Көзгә табан ул тагы шулай кинәт китеп югалды. Бу юлы эзләп тә маташмадылар. «Язган мал булса, ашаган җиренә кайтыр әле...»— дип, ямьсез сүгенеп куйды атасы. Аның авызыннан чыкканны эт ашамас иде.

Бу юлы брәдәк малай озак вакытлар билге бирмәде. Әллә җиде-сигез ел үтеп китте инде. Бер заман җәй уртасында, ике кулына галәмәт зур ике сары чемодан тотып, өстенә кара тройка костюм, аягына тишекле ак ботинка, башына кара мамык эшләпә киеп, муенына яшел галстук тагып, Насыйп кайтып төште. Торганы белән тере картинка! Күрше-күләннең әйтүенә караганда, бер чемоданына ата-анасы һәм энеләре өчен киемсалым, икенчесенә — күчтәнәч тутырган икән. Анысы растыр. Шул көнне үк Шәрәфетдиннең бөтен өй эче баштанаяк яңадан киенеп чыкты. «Тырышуларым бушка китмәде. Малайга тәрбия синдә. Эш чыкты малайдан...»— дип мактанды ак мыеклы Шәрәфетдин, өстендәге пинжәгенең эчен-тышын күрсәтеп. Аягындагы елтырап торган резин галошларны, чыелдатып, бер-берсенә ышкып алды: янәсе, монысын да күрегез!

Икенче чемодан тулы эре чикләвек, өрек, йөзем, төрле-төрле кәнфит, кызыл прәннек, киптерелгән кара җимеш икәнен үзем күрдем. Ул чемоданын ачып, сәке өстенә куйды да хәл белергә кергән әби-чәбиләргә, бала-чагаларга күчтәнәч өләшергә кереште. Юмарт кунак турында хәбәр тиз таралды, ахры. Бөтен урам балалары, бигрәк тә малайлар, Шәрәфетдин өенә ябырылды. Насыйп, үзенең котлы куллары белән зур-зур итеп учлап, һәрберсенең я сузылган куш учына, я җәелгән итәгенә күчтәнәч салды. Килә тордылар, китә тордылар. Бер заман битләренә корым сөрткән яки аталарының мескен бүрекләрен, киез эшләпәләрен бастырып кигән сәер

малайлар күренгәли башлады. Нинди кәмитчеләр болар? Кайдан килгәннәр?

— Агай, агай,— дип башлады Насыйпның бер энесе,— бу малай, менә бу эшләпә кигән малай, әй лә, менә бу корым сөрткән малай бая ук инде күчтәнәч алган иде.

— Үзе алса, атасының кәпәче алмагандыр,— дип кых-кых көлде Котлы кул.— Башыгыздан салыгыз, малайлар.

Тегеләр кушканны эшләде. Кәпәчләргә тагы берничәшәр җимеш яки чикләвек тамды. Насыйпка бәләкәй мутларның тапкырлыгы ошады. Малайлар шунда ук чыгып ычкынды. Кәмитчеләр бүтәнчә күренмәде.

Насыйпны бик тә сагынып, бик тә зарыгып көткән халык күп булган икән. Караңгы төшкәнче кеше өзелмәде. Моңа кадәр аны күрми ничек түздек икән? Карткоры өчен самовар да өзелмәде. «Менә бит, язган ризык теш сындырып керә»,— диде Мансур карт, тешсез авызында каты өрекне әвәләп.— Иртәдән бирле иреннәрем кычытып тора иде, күчтәнәчтән авыз итәргә булган икән... Әбиең дә мәхрүм булып калмасын...»— Ул бер уч җимешне бишмәт кесәсенә алып салды.

Насыйпның кунакчыллыгы моның белән генә бетмәде. Берничә көннән соң ул, шушы урамда бергә уйнап үскән үзенең яшьтәш егетләрен һәм кызларын җыеп, табын уздырды. Ул чакта әле яшь-җилкенчәк мәҗлесендә шәраб эчү гадәте юк иде. Әмма ите-мае, аш-суы мул булды. Кич буе ашап-эчеп, уйнап-биеп зык куптык. Шаһидулланың гармуны, Әсгатьнең чәчән теле алмаш-тилмәш табынга җан да, ямь дә биреп торды. Бәлки, бөтен яшьтәшләр бөтенебез бергә җыелып күңел ачуыбыз беренче һәм соңгы тапкыр шушы булгандыр. Насыйп аркасында...

Ләкин үзебез аңа карата коточкыч ихтирамсызлык, әдәпсезлек, каты бәгырьлелек күрсәттек: беребез дә өебезгә чакырып, түр башына утыртып, читтән кайткан кунакны хөрмәт итмәдек. Насыйпның кунакчыллыгын,

юмартлыгын без кызыкка санабрак, диваналыкка япсарыбрак кабул иттек, мөгаен. Әйе, шулайрак булды шикелле. Үзебез бүртенгәнче сыйландык, үзебез астыртын гына ирештереп тә куйдык тегене. Чөнки ул безнең тар акылга, тар колачка сыймый торган кыланыш күрсәтте. Бәлки, бездән хөрмәт өмет итү аның башына да килмәгәндер. Шулай да аның алдында менә әле килеп оят.

Бу кайтканда без Насыйпның, кайдадыр педтехникум бетереп, Урта Азиядә балалар укытуын аңгарып калдык. Бер ай чамасы авылда йөрде дә ул, кара тройка костюмын лавкачы Зәйнушка ярты хакына сатып, кире Урта Азиягә китте. Бу юлы качып-посып шылмады ул, сәфәре алдыннан күрше-күләнгә, дус-ишкә кереп, берәм-берәм хушлашып чыкты. Поездга кадәр аны ике энесе озата барды. Йөкләре җиңел иде. Буш сары чемоданнар Ямлиха җиңгигә тавык йоны белән суган тутырыр өчен калды.

...Һай-һай, күпме заман үтеп китте! Егерме ел бардыр. Менә мин Шәрәфетдиннәр өенең тупсасына тагы аяк басам. Насыйп белән күрешергә киләм. Карт инде гүр иясе. Мыегы саргайганчы яшәде дә, кылган явызлыклары өчен урам уртасына басып, ил алдында тәүбә итеп, үлеп китте. Хәер, тәүбәсеннән соң ул, акны-караны аермый, байтак газап чигеп ятты. Ямьсез җан бирде Шәрәфетдин: мич янындагы пычрак лаканга башы белән тыгылып, тончыгып үлде.

Насыйп мине ачык чырай белән каршы алды.

— Җәһәннәмнән җәяү качкан тагы берәү менә! Синең хәлләреңне ишеттем. Бирешмәгәнсең, молодец, Кендек...— Ул, гыж-гыж килеп, көлгәндәй итте. Насыйпның тавышы гомер бакый гыжылдавык булды. Бәләкәй чакта ялгыш бәкегә төшкән иде, шуннан карлыгып калды тамагы. Аның электән көлсу йөзе тагы да төссезләнә төшкән, чигә чәчләре нык ук агарган, әмма кысык соры күзләре шул көе — тап та, шәүлә дә төшмәгән көе торып калган, гүя, бу дөньяда алар бетмәс бәхет күреп, төкәнмәс шатлык кына эчкәннәр. Елмаеп торган гамьсез

сабый күзләре — аның йончу йөзендә, таушалып беткән бөтен кыяфәтендә ике якты утрау иде.

Ул күрешергә кулын сузды. Мин ике кул урынына, түп-түгәрәк калын көлчә төсле, ике уч кыстым. Әйтерсең, ике кулының да бармакларын кемдер үтә җентекләп, үтә җыйнак итеп кайчы белән төптән үк кисеп чыккан. Тик кайсы кулындадыр бердәнбер чәнчә бармагы язып-ялгышып торып калган. Күрәсең, кайчы очына эләкмәгәндер. Мин әллә чирканудан, әллә кызганудан дертләп, сискәнеп киттем. Ләкин күрешү куанычына чумган Насыйп моны сизмәде. Бәлки хуш күңелле бу бичара хәзер инде үзенең гариплеген дә сизмидер. Оныткандыр, бахырың.

— Менә бит, әй! — дип, ярыйсы гына каты «көлчә» белән минем аркага сукты.— Җыяр ризык булгач, тагы илгә кайттым. Сагынып үлә яздым. Валлаһи!

— Хәлләрең ничек? Карар күзгә болай әйбәт күренәсең,— дип ялганладым мин.

— Зарланыр урыным юк,— диде ул, гөнаһсыз күзләреннән нур чәчеп.— Исән калдым. Тазалык бар. Аяк-кул бөтен дип әйтерлек. Бармаклар җитешми дә җитешүен... Алтын йөзекләр киясем юк. Әнә ат — тумыштан бармаксыз да яши бит. Ничегрәк яши әле!.. Ә балаларга дәресне мин кул белән түгел, тел белән, фигыль белән бирәм.

Әйе, бу Котлы кул Насыйп иде. Нәкъ үзе иде. Теге замандагы кебек үк, өстендә кара тройка костюм. Ләкин пинжәгенең җиң очлары нык кына сүсәргән бу юлы. Яшел галстугы да майланып, ялтырап беткән. Ак күлмәгенең якасы керне чамадан тыш күтәргән. Минем сынаулы карашымны ул ярты юлдан ук эләктереп алды.

— Алмаш күлмәк барын бар да ул. Ә костюм инде череп баеган чакларымда да бердән артмады. Мин нәфселе түгелмен. Хәтта бәхет тә икәү кирәкми миңа. Берсе ярап калыр иде мәгәр, эчне тишмәс иде...— Минем игътибарымны тартыр өченме, әллә болай гынамы, сул кулындагы (әйе, сулы иде) исән калган чәнчә бармагы

белән түшендәге Кызыл Байрак орденын ике тапкыр сыйпап куйды.

Нәрсә эшләп әле мин бая бу кеше турында «бичара» дип уйларга җөрьәт иттем. Аны җәлләргә, юатырга маташу үзе үк әдәпсезлек, вөҗдансызлык булыр иде. Ул үзенең яралары белән кәпәренми дә, мескенләнми дә. Гариплеге белән сату итми ул.

...Ләкин бу фани дөньяда гариплек белән дә, матурлык белән дә сату итүләр бар шул әле. 1944 елның сентябрь башларында мин күптән түгел генә алынган румын каласы Констанцаны бер көн кыдырып йөрдем. Мәшәкатьсез генә тамаша кылдым. Бу минем чит дөнья, чит йолалар белән тәүге очрашуым иде. Мине русча ару гына сукалаган бер полицай иярте йөртте. Ул каланың үзен дә, кешеләрен дә яхшы белә. Ике очрашу, күңелне боектырып, хәтеремә аеруча сеңеп калды. Үзәк урамнарның берсендә безгә хәйран чибәр, хәйран сылу бер кыз тап булды. Карап туйгысыз. Полицай тегенең җиңеннән тотып туктатты. Тупас, сөмсез хәрәкәтләр белән иягеннән тотты, иңбашыннан сыйпады, битеннән чеметте. Нәрсәдер сөйләде, тыйнаксыз итеп көлде. Мин берчә хәйран калып, берчә аптырап карап тордым. Камил матурлыкка хәйран калдым, урам сакчысының шул матурлык белән әдәпсез кылануына шаккаттым. Кыз киткәндә полицай русчалап: «Бар, эшлә!»— дип, аның очасына сугып калды. Монысы инде бөтенләй башка сыярлык түгел иде. Мин соклануымны җиңә алмадым:

— Нинди чибәр... Бер күрүдә янып үләрлек,— дидем.

— Сатыла. Тулаем түгел, ваклап, вакытлап сатыла. Тик бик кыйммәт,— диде юлдашым тыныч кына.

— Ничек инде сатыла? Үзе шундый матур...

— Матур булганга кыйммәт тә... Мин ул «тәти кызлар»ның бөтен тарифын беләм.

Ничектер көн караңгыланып, сүрәнләнеп киткәндәй булды. Үкенечле, әлбәттә...

Йөри торгач, мәйданга килеп чыктык. Мәйдан тулы

халык. Уртада зур озын арбага җигелгән бәләкәч кенә ишәк бакыра. Ишәкне йонтач очлы бүрек кигән кеше колагыннан тартып бакырта. Арбада галәмәт олы башлы, кыска гына гәүдәле, көтек аяк-куллы өч яшьләр чамасындагы шыр ялангач ир бала ята. Бала кырында калай купы[1]. Ишәк бакыра. Купыга ара-тирә бакыр тәңкәләр чыңлап төшә. Бу күренешнең әче мәгънәсен сорашмый да аңладым: эти кеше үз баласының гариплеген ваклап сата.

Моны күргәч, баягы шук полицай да салпаеп калды:

— Нинди генә көннәргә төшерми адәмне фәкыйрьлек...

Сатлык матурлык белән сатлык гариплеккә бер көн эчендә тап булдым шулай. Кайсысы аянычрактыр, белмим. Бәлки, икесе дә бер иштер...

Насыйпның бармаксыз куллары миңа инде гарип булып күренмиләр. Ничек бар, шулай: матур да түгел, ямьсез дә түгел. Үзем дә хуҗа кәефенә буйсынып, яраклашып өлгердем.

Ямлиха җиңги чәй әзерләде. Кайдандыр бер «кара баш» килеп чыкты. Насыйп шешәне елт иттереп тез арасына кыстырды. Шуннан, учы белән астан төбенә сугып, чос кына ачты да, ике кулына кысып, стаканнарга койды. Бик төгәл, бик гадел бүлде.

— Күрәсеңдер, кулларым төп эшкә ярый бит. Калганын башкару берни дә түгел ул...— Башта ул кых-кых көлде. Шуннан ике «көлчәсен» дә кинәт алга сузды.— Шушы кулларның котына ничәмә еллар буе берәүне дә ышандыра алмаган идем. Тәки, бер килеп, инандырдым, әй.

Берәр стаканны түнтәреп куйгач, Насыйпның күңеле тагы да күтәрелеп китте:

— Бармаксыз калдым, әмма кулымның котын исбат иттем,— дип шул ук хакта сүз яңартты ул.— Бәләкәч-

---

[1] Купы — савыт.

тән... Малай чагымнан ук сиздем мин бу кулларның хикмәтен! Сез генә ышанмый каңгырттыгыз. Их-ма! — Ул бүлт-бүлт иттереп, янә стаканнарга аракы койды.— Әйдә, җөп булсын!

— Ә шулай да бармагы-ние белән кайда кырыктың тырнакларыңны? — дип аның көенә төшебрәк сорадым мин.

— Кешедән ишетсәң, Насыйпның кулында зур бомба ярылган икән дип, шыттырулары бар. Үзем генә сөйләп бирим.— Шешәнең бөкесен ул кире тыкты.— Хуҗасы сөйләгәндә, күңелгә вәсвәсә салмый, тик кенә тыңлап кына утырсын. Менә шулай.

Насыйпның йөзенә кызыллык йөгерде. Димәк, ике стакан аракы шифасыз үтмәде. Тик күзләре генә бераз тоныклана төште.

— Алайса, тыңла: туңып коелды бу бармаклар.

— Ничек?

— Шулай. Ләкин үз эшләрен башкарып һәлак булды алар. Батыр яугирләрчә һәлак булды минем бармаклар...

Ул дәвам итте:

— Мин артиллериядә элемтәче булдым. КП белән ут позициясе арасында катушка күтәреп йөгерүче идем. 1943 нең кышы иде. Шыгырдап торган чатлама суык иртәдә яман бой башланып китте. Безнең орудиеләр КП-дан күз күреме җирдә урман полосасына сыенып алганнар да тегеләрнең позициясен өшкерә генә бирәләр. Полк командиры подполковник телефон аша моннан үзе командовать итә. Ну тавышы, әй! Кушбугаз ир иде. Бер заман еракта ак кар өстендә төрле җиргә сибелгән кара таплар кыймылдаша башлады. Таплар акрынлап зурая бара, зурая бара: танклар! Таныш картина. Тиздән алар ут түкерергә керешәчәк. Давай, тыгыл, давай! Ут кибәненә әйләнүеңне күр дә тор менә! Эчемнән шулай дигән булам, иң алдагы танкка төбәп. Тегеләрнең моңарчы сүлпән аткан пушкалары да дәррәү телгә килде. Көн аяз, тавыш һавага сеңми. Җирне тоташ күкрәү тетрәтә.

Ике яктан да ут өермәсе өерелә. Нәкъ шул вакыт подполковник, ачуланып, телефон трубкасын ташлады. «Өзелде! Линия өзелде. Ялгарга!»— диде. Кече сержант Скворцов шунда ук кабель буйлап йөгерде. Без аны күреп торабыз. Өч-дүрт йөз метр араны имин үтте. Шуннан ул шартлаулар полосасына барып керде. Бер йөгерде, бер егылды, бер торды. Шартлаулар һаман куера барды. Ахры, танклар да ата башлады. Скворцов тагы бер-ике тапкыр күренеп калды да башкача калкынмады. Линия ялганмады.

— Рөхсәт итегез! — дидем мин.

— Итмим! Син бар! — Подполковник рядовой Шихановка боерды. Шиханов шул ук кабель буйлап Скворцов эзеннән йөгерде. Ярты юлга җитәр-җитмәс, аны шартлау төтене ялмап алды. Шул көе күздән югалды, төтен эчендә эреп юк булды. Линия ялганмый калды.

— Рөхсәт итегез, иптәш подполковник! Минем кулым котлы!!! — дип янә мөрәҗәгать иттем. Ачулы командир кинәт кычкырып көлеп җибәрде:

— Кулың котлы булгач, бар!

Мин дә шул ук юлдан йөгердем. Туп шартлавын да, мина пошкыруын да, пуля сызгыруын да ишетмим. Алар минем өчен түгел иде. Кар өстеннән сузылып барган телефон кабеленнән башканы күрмим — дөньяда бүтән нәрсә юк иде. Иелмәдем дә, егылмадым да. Мине котым, тылсымым саклый. Йөгердем дә йөгердем. Мина ярылып иңгән корымлы чокыр янында бөгәрләнеп яткан алыптай Скворцов гәүдәсенә тап булдым. Бик уенчак егет иде. Әле кичә генә, маскхалатка уранып, чегән кызы булып җырлап биегән иде. Хәзер ята. Тукталмадым. Кайтканда алып чыгармын инде. Шихановны шәйләмәдем бугай. Хәтерләмим. Йөгерүемне белдем. «Китә генә күрмә, котым, китә генә күрмә...»— дип инәлә-инәлә йөгердем. Котым ташламады мине. Снаряд төшеп өзгән урынны барып таптым. Бияләйләремне салып ташлап эшкә тотындым. Ике очны да тәүдә үз аппаратыма тоташтырып

тикшереп карадым. Башта КП белән бәйләндем. Эшли. Аннан ут позициясенә тоташтым. Эшли. Шуннан гына өзекне әйбәтләп ялгап, изоляцион тасма белән урап куйдым. Суык кулны өтеп бара икән. Монысын эш беткәч кенә сиздем. Бияләйләремне тапмый изаландым. Аларны бая кызулык белән әллә кая читкә атып бәргәнмен икән. Шуларны алыйм дип, ике-өч адым читкә атлавым булды, таралдым да төштем. Җай гына ауганымны хәтерлим бары. Мине шартлау исәңгерткән икән — азак белдем. Безнекеләр һөҗүмгә күчкән, мин ятып калганмын. Шулай да бәхет бар икән, әй, кемдер, миңа тап булып, тере икәнемне сизгән. Ул арада минем ялангач бармакларым шакырдап туңып өлгергән. Аның каравы, минем котлы кулым аркасында безнекеләр күпме немец танкларын кырып салган. Тугыз бармакның хакын артыгы белән чыгарганнар. Икенче көнне медсанбатка подполковник үзе килде.

— Кулларың чынлап та котлы булып чыкты, ефрейтор. Рәхмәт сиңа! Хәвефле хәтәр мәлдә күз-колаксыз калган полкны бәладән коткардың,— диде.— Онытыла торган батырлыклардан түгел бу,— дип өстәде. Ихлас, шулай диде, әй.

— Онытмаганнар да...— Мин Насыйпның күкрәгендә Кызыл Байрак орденына ымладым.

— Бумы? Бу әүвәлрәк булган эшләр өчен, Ржев хәлләре өчен...

— Ә соңгысы өчен нәрсә бирделәр?

— Бирмәделәр. Бәлки, биргәннәрдер дә, юлыгып ала алмадым. Мине тылга озаттылар.

— Азактан юлламадың дамы?

— Ничек дип юллыйм? «Мин үземнең төп вазифамны башкарганда бармакларымны туңдырган идем, шуның өчен бүләк сорыйм» диимме? — Кинәт аның йөзе агарып китте, куллары калтыранып куйды.

— Бүтәннәр сорый бит.

— Мин бүтәннәр түгел. Минем өлешемә иң олы бү-

ләк — гомер тиде. Ә егерме яшьлек Скворцов белән унтугыз яшьлек Шихановка нәрсә эләкте? Юллап та карамакчы идем берчак, әнә шул икәүдән оялдым. Скворцовның арысландай гәүдәсе әле булса күз алдымда бөгәрләнеп ята. Ә мин чебеш хәтле генә гәүдәм белән һаман йөргән булам.

— Синеңчә уйлый китсәң, тере калганнарның мәрхүмнәр алдындагы бурычы ерып чыккысыз булып чыга.

— Анысы рас, туганкай, ерып чыккысыз... Гомер буе кайтарырга туры киләчәк ул бурычны. Тереләргә, ягъни бер-беребезгә кайтарырга...

Бу кешене мин бая эчемнән кызганып, ничек кимсетмәкче иткәнмен. Баксаң, ул канатлы икән ләбаса! Чебеш түгел, затлы кош, гайрәтле кош икән лә!

Насыйпның үз кулларының котына шик-шөбһәсез ышануының серен менә әле килеп аңладым. Кулларының котыннан аның үзе өчен файда да кирәкми, шөһрәт тә, бүләк тә, мал да кирәкми. Гомер буе ул шушы куллары белән кемгәдер бәләкәй генә булса да изгелек күрсәтергә, яхшылык итәргә тырышты, бүтәннәргә эштә, уенда, кәсептә фарт китерергә, аларны куанычка юлыктырырга өмет итте. Һәм бер заман, бармаксыз калып, кулларының изгелеген исбат итте. Хәзер инде аларның тылсымлы көче хакында да беркайчан да икеләнмәячәк. Чөнки кул — күңел хезмәтчесе. Күңел ни кушса, кул шуны башкара. Насыйп ишеләрнеке — бигрәк тә...

Насыйп теше белән шешәнең бөкесен тартып алды. Калган аракыны төгәл итеп стаканнарга койды.

— Адәм эчендә һәрвакыт Әдәп белән Нәфсе алыша,— диде хуҗа бик җитди тавыш белән.— Без нибары икешәрне генә төшереп, тегеләрнең бәхәсен шөйлә кыздырдык кына. Әйдә өченчесен аткарыйк. Нәфсегә зыян килсен, Әдәпкә куәт өстәлсен.

Без, чәкәштереп, Нәфсене кыерсытып, Әдәпкә дәрман өстәп куйдык.

— Менә шулай, туганкай,— дип Насыйп учын учка сугып алды. Нәрсәнең «менә шулай» икәнен ачыкламады.

Мин дә сорамадым. Хәер, ачыкланасы ачыкланып беткән иде инде. Һәр шәхеснең төп үзәге, аның рухи дөньясының тотып торган бер терәве була. Минемчә, иң ныклы, иң ышанычлы терәү, бәла-казаларга бирешмәс иң каты үзәк — могҗизаларга ышану ул. Насыйп әнә шуңа ышана, һәм, ни дисә дә, аныкы дөрес, аныкы хаклы.

Ямлиха җиңги, әледән-әле өстәл янына килеп, чәй яңартты, табындагы ризыктан җитешергә кыстады. Аның йөрешләре үзгәргән бөтенләй. Атлаганда кыек-мыек китми, тыпырчынып та куймый, туры басып, җай гына, йөзеп кенә йөри. Чөнки аны өркетеп, җикеренеп торучы юк.

— Ишетмәгәнсездер әле, мөгаен,— диде Ямлиха җиңги,— Йомры Талип әҗәл түшәгенә яткан икән. Ямьле җәй айларында гына китеп бармагае. Кереп бәхилләшеп чыксагыз, савап булыр иде. Ни җитте адәм түгел бит, изге күңелле зат.

— Кайчан ди?

— Атна-ун көн чамасымы икән?.. Йөрәген учына кысып тоткан да ауган икән.

Бу хәбәр мине айнытып җибәрде. Теге кышны, Сәмигуллага самосуд булган елны, аның башыннан мескен бүрке очып төшкән иде, ап-ак кар өстенә кып-кызыл каны тамган иде. Шуннан соң ул такыр башын бик үк яшерми башлады. Тора-бара, җае чыккан саен кәпәчен салып, елтыр түбәсен дөньяга фаш кылыр булды. Кемдер аңа әйткән, имеш: «Пеләшлек — ул галимлек билгесе, акыл мөһере»,— дигән, имеш. Нигә бар акылны, бар гыйлемне адәмнән яшерергә? Оят нәрсәмени? Ә ул миңа бүләк иткән самокат тәгәрмәче? Бөтен урам малайлары алдында минем дәрәҗәне ничегрәк күтәрде шул тәгәрмәч — заманында! Бер тәгәрәтеп җибәрер өчен

дөнья мөлкәтен бирергә әзер иделәр. Мин бушка тәгәрәттердем, тимераяк хуҗасы Шәйхаттар ише, мал артыннан кумадым, рәхмәт алдым. Бер рәхмәттә мең бәладән коткарырлык көч барын ул чакта мин ныграк аңлый идем. Бу хакта шундый фәһемле хикәят тә бар.

Борын-борын заманда сусыз чүлдә бик бай бер кәрван адашкан, ди. Сусызлыктан кешеләр генә түгел, дөяләр дә кырыла башлаган. Казага тарыган шушы кәрванга бер юлаучы тап булып, аны су янына алып килгән, ди. Һәлакәттән котылгач, кәрван башы болай дигән: «Әй, юлаучы, изгелегең синең зур булды, әмма ул рәхмәт әйтерлек үк түгел. Син безне бер генә бәладән коткардың. Рәхмәт әйтү күбрәк булыр. Әнә, хәзинә төялгән теләсә кайсы дөямне сайлап ал. Һәрберсендә гомереңә җитәрлек байлык бар»,— дигән.

Рәхмәтнең кадерен белгәннәр борынгылар. Йомры Талипның самокат тәгәрмәче күпме рәхмәт яудырды миңа!

Ямлиха җиңги әйтеп салган күңелсез хәбәрне ишеткәч, миңә шундый хатирәләр килде минем күңелемә.

Нишләптер Насыйп буш шешәгә янә бөке тыкты. Көрсенеп куйды:

— Теге чак калач оеткысын ул салган иде бит. Мин исәргә җитә калды. Янәсе, бөтен урам малаен калачка тиендерәм... Оеткылы кеше була торган иде Талип агай,— диде ул, үзалдына сөйләнгәндәй генә итеп.

Көтмәгәндә, күңелгә бүтән хәстәр, бүтән гамь керде. Без Йомры Талип белән бәхилләшергә киттек. Юл уңаенда тыңкыш Вәлетдингә дә сугылдык. Сугышны Берлинда бетереп, ул түшенә Дан ордены тагып кайтты. Ләкин аның үзе сөйләгән маҗаралы батырлыклары ун орденнан да артып калырлык иде. Арттыру-кушу ягыннан Вәлетдин Талиптан калышмый. Ул барда мәрхүм булачак кеше белән уртак телне тизрәк табарбыз диештек һәм ялгышмадык.

Әҗәлгә дару бар икән

Талипның теге чакта, Олы инәем белән без кәҗә тиресе илтергә баргач, әйткән сүзе раска чыкты. «Мин череп байыйачакмын, көне генә килсен»,— дигән иде. Көне килде. Череп үк баемаса да, еллар хәлләнгәч, нык котайды, нык бөтәйде Талип. Малайларының исән калганнары яудан кайтты, кечеләре үсеп җитте. Кайсысы тракторга атланды, кайсысы автомашинага утырды. Бәгъзеләре, кулына озын чыбыркы алып, мал әйдәде. Үз тормышларын да җитеш кордылар, аталарына карата да итагатьле, ярдәмчел булдылар. Алты почмаклы, биек болдырлы, калай түбәле йорт салдырды Талип. Тәрәзә капкачларын яшелгә, түбәсен ачык кызылга буятты, ләкин, бүтәннәр шикелле, урам якка биек койма койдырмады, сирәк кенә тәбәшәк рәшәткә тотты. «Минем эчемдәгем — тышымда. Курамдагы да урамда булсын»,— диде ул, ихата киртәләгәндә. Курасында малы, кош-корты ишәйде. Өс-башы бөтәйде. Такыр түбә гомер күрмәгән фетр эшләпәгә тиенде. Бу муллыкның игелеген җәмәгате генә күп күрә алмады, ике кыш әүвәл гүр иясе булды. Менә хәзер үзе хәл эчендә, ди,— димәк, карчыгыннан чакыру килгән.

Безне кайсы улыныңдыр бичәсе каршы алды. Авыру түр якта, елтыравык башлы тимер караватта, йомшак түшәккә чумып ята. Шушындый, өрсәң, гөлтләп кабынып көнне өстенә калын юрган ябынган. Күрәсең, хәле мөшкелдер. Кешене кабер салкыны шулай алдан ала, ди бит. Юрган астыннан аның такыр җилкәсе генә күренә, йөзен ул тәрәзә ягына борган.

Килен кеше, һәрберсенә түгәрәк сырма салып, өч утыргыч куйды. Без утырышкач кына, ул каенатасына эндәште:

— Каенатам, әнә хәл белергә килгәннәр, кала кунаклары да бар...

Талип өн чыгармады, тик чак кына кыймылдагандай итте.

— Рәтең булмаса, эндәшмә, Талип агай,— диде Вәлетдин,— арыслан йөрәгеңнең типкәнен тыңлап, без сиңа карап кына утырырбыз.

Авыру ыңгырашып куйды. Димәк, арыслан әле тере. Көч-хәл белән азрак башын борды, бер күзен ачты, ләкин эндәшмәде.

Насыйп, иелеп, түгәрәк учын авыруның маңгаена куйды. Янәсе, ул котлы кул белән кагылса, шифасы булачак. Талип башын янә читкә тайчандырды.

Тыныч кына утырудан башка чара калмады. Безнең авазлар җәннәткә юл тоткан адәмнең колагына юл таба алмый.

— Менә шулай, телдән калмый, сүздән язды. Икенче атна тула инде,— дип төшендерде килен.— Әллә нидә бер җавап кайтара кайтаруын...

Алгы өйдә үк нәрсәгәдер бәреләсугыла, дөбер-шатыр, һәвәскәр мулла Фәрхетдин килеп керде. Бу тирәякта мәшһүр кеше — дүрт тамыр, алты буын аша миңа жизни туры килә. Заманында Фәрхетдиннең итмәгән кәсебе, башкармаган һөнәре калмады. Мин белә башлаганда ул, имгәнгән-сугылган мал алып, мал суеп әвештәвеш итә иде. Ул арык атына утырып: «Иткә-майга! Иткә-майга!»— дип кычкырып үтеп киткәч, вак балалар, аңа ияреп, уен уйный торган иде. Бәләкәй арбаларын тарталар да: «Иткә-майга! Иткә-майга!»— дип сөрәнлиләр.

Бу сәүдәсен ташлап, җизниебез чүпрәк, сөяк-саяк, мөгез-тояк, тимер-томыр җыярга кереште. Аръягында кәсепне еш алмаштырды ул: бидрә, комган төпләде, самовар төзәтте, дуга бөкте, тал чыбыгыннан каз оясы үрде, кирпеч сукты, аркан иште; суга баткан, буранда адашкан, диванага сабышкан кешеләр турында, форсат булганда, кызганыч бәетләр чыгарды — әҗеренә тормады, заказчы ни бирсә, шуңа шөкер итте. Сугыш вакы-

тында бу һөнәренең базары аеруча күтәрелгән, диләр. Кызганыч бәеткә мохтаҗлык зур иде шул. Фәрхетдин бөтенесен эшләде, ләкин ике аягының берсен буразнага басмады. Үзенчә ул акыл белән, хәйлә белән җиңел көн итәм дип уйлады. Хәйлә дигәнен әйтер идем инде — ташка үлчим...

Сугыштан соң җизнәм Уфага юл төшкән саен минем тупсамны читләп узмады. Әйтсәм дә, еш таптамады алай, килү-китүе елына ике-өчтән артмас. Ашап-эчеп алгач, тегенең кызмача башына гел генә бер бик әйбәт хәйлә килә торган булды.

— Апаң самовар торбасы сораган иде дә, менә чама чамага туры килмирәк калды бит әле каһәрең...— ди.

— Ни хак тора соң ул торба?

— Аның төп бәһасы 22 сум 50 тиен инде. Илле тиенен үзем дә куша алырмын,— ди. Ул чак әле акча алмашынмаган иде.

Акча алмашынгач, самовар торбасының бәясе 2 сум кырык тиенгә җитте, аннан 2 сум 70 тиенгә менде. Ләкин мин бәя арту белән исәпләшмәдем, апамны бер тапкыр да торбасыз калдырмадым. Җизнинең:

— Апаң самовар торбасы апкайт дип, артымнан кычкырып калган иде дә, каһәрсезең...— дип әйтергә өлгерми, мин кесәмә тыгылам.

— Ни хак соң ул торба бу көннәрдә?

— Аның аруы ике сум сиксән җиде тиен инде...

— Мә, өч сумлыгын ал алмайса, апам куаныр.

— Знамо, куаныр.

Шулай да берчак шаяру катыш сорап куйдым:

— Синең кулың белә, Фәрхетдин җизни, нигә ул торбаны үзең генә ясамыйсың?

— Материал юк. Кул тими. Болай арзанракка төшә,— дип, бик төпле җавап кайтарды кунагым. Шуннан соң мин аңа бу кадәр үк ахмак сораулар бирмәдем.

Күптән түгел шушы җитмеш һөнәрле маһир ир, һәвәскәрлек күрсәтеп, дин әһеленә әйләнде. Аны сайлаучы

да, тәгаенләүче дә булмады. Күпме адәмнең әдәбе, иманы, гөнаһ-савабы өчен җаваплылыкны үз ирке белән өстенә алды, рухына йөкләде ул. Мондый авыр бурыч алырга аңа, әлбәттә, дин җәһәтеннән тома наданлыгы тәвәккәллек биргәндер. Малай чакта отып алган ике-өч бөртек догасын да ул, рус арасында күп йөреп, әллә кайчан оныткан иде. Берчак, хәмердән авыз итә-итә, хода әшләрен чәйнәп утырганда үзе шулайрак ычкындырган иде. Хәзер килеп, күрәсең, шул догаларын яңадан хәтеренә төшергәндер. Зиһенле, тырыш ир шул.

Ишектән кереп бетәр-бетмәс үк һәвәскәр хәзрәт сузып сәлам бирде:

— Әссәла-мөгаләй-ку-үм! Барчагызга да...

Ул безгә артык игътибар итмәде. Югары дәрәҗәсен саклый белә. Авыру яткан карават читенә утырып дога кылды да үз хәстәрен хәстәрләргә керешге:

— Кордаш,— диде ул, өнсез яткан Талипның юрганын тарткалап,— әй, кордаш, тәңре ихтыярын алдан белеп булмый, үтеп-нитеп китсәң, ясинсыз үтмә дим. Ясин чыгып калыйм үзеңә.

Талип күзләрен ачмый гына башын борды. Фәрхетдин моны ризалык бирү дип аңлады, кычкырып укый да башлады:

— Әгузе биллаһи минашайтан раззим бисмилла рахман рахим-и-и...

Талип юрган астыннан чыгарып кул селтәде. Тегесе укуын дәвам итте. Монысы башта йодрык, аннан кукиш күрсәтте, тегесе, ярты мәетнең сәер гамәлен күреп, отыры тырышты. Монысы ике кукиш сузды. Тегесе, көчәнә торгач, кәҗә тавышлары чыгарып җибәрде. Монысы, ике күзен шардай ачып, муллага җикерде:

— Җитәр дим, сиңа, мөртәт! Тыныч кына үләргә ирек бир...

Мулла ясинын өзсә дә тиз үк чигенмәде.

— Хода хөкемен белеп булмый...

— Син белмәсәң, мин беләм. Хөкем чыккан. Фәр-

ман юлда. Сәгатен генә көтәм.— Олысы-кечесе каршысында гел инсафлы, күндәм, юаш Талипның әҗәле алдында шулай кискен, кырыс сөйләшүе гаҗәбрәк тоелды. Шул ук вакытта эчкә җылы кереп китте. Болай йодрык төйнәп, мөртәттән салдырып, дин әһелен рисвай иткән ирдән өмет өзәргә иртәрәк әле. Көрчеккә килеп терәлмәгән әле бу.

Вәлетдин шымып калган «хәзрәткә» ишек ягын ымлап күрсәтте. Теге аңлады. Зирәклеге бар мәгәр. «Ихтыярыңда, кордаш»,— дип ишеккә юнәлде. Килен аны озата чыкты. Түр өйдә дүртәү генә торып калдык.

— Шулай итеп, дөнья белән бәхилләшергә булгансың икән, Талип агай?— диде Вәлетдин.

— Җитәр, туганнар,— диде ул йомшак кына.— Ашын ашаганмын, яшен яшәгәнмен. Чама белергә кирәк.

— Алайса, әйтер васыятьләреңне әйтеп, бирер фатихаларыңны биреп өлгерденме соң?— дип төпчендә шул ук Вәлетдин.

— Васыятем юк. Дөнья минем васыятемә мохтаҗ түгел. Ул бөек гакыл ияләренең васыяте белән бара,— диде бер күзен ачып.— Фатихамны мин кешеләргә тәнем исән, зиһенем төгәл чакта ук биргәнмен.

— Бер генә дә әйтер сүзең юкмыни шулай? Соңгы сүзең?

Талип байтак шымып ятты. Аннан чалкан әйләнде, ике күзен дә ачып, шундый моңсу, шундый ялварулы итеп карады, хәтта тәнем чемердәп китте.

— Бар. Үтенечем бар,— диде.

— Әйт үтенечләреңне, агай. Бөтенесен дә үтәрбез,— дип вәгъдә итте Насыйп.

Авыру тирән итеп күрсәндә:

— Минем җеназамда бичәләр елар, шуларны юатыгыз.

— Кемнәр? Нинди бичәләр, агай?

— Мин яратып та миңа күңел салмаган хатыннар үкенүдән елар. Шуларны юатыгыз. Мин аларны гафу итеп китәм. Шуны әйтеп юатыгыз. Еламасыннар.

— Юатырбыз, агай, юатырбыз,— дип ихлас сүз бирдек.

— Рәхмәт. Янә... Миңа күңел салып та мин күз салмаган хатыннар, мәхрүм калудан әрнеп, елар. Шуларны юатыгыз. Ул чактагы бәгырьсезлегем өчен хәзер үзем үкенеп бетә алмый елап китәм. Шуны әйтеп юатыгыз. Еламасыннар.

— Юатырбыз, агай, валлаһи, юатырбыз,— дип ант иттек.

— Рәхмәт, узаманнар. Мин ышанып китәм...

Насыйп бердәнбер чәнчә бармагы белән маңгаен уып алды. Нәрсәдер әйтмәкче, ахры. Әйтте шул:

— Ә өченчеләренә ни диик?

— Нинди өченчеләре?

— Үзең сөелеп сөйгәннәренә.

— Ә-ә-ә, аларынамы? Аларын тыймагыз. Еласыннар. Еларга тиеш алар. Әче яшьләре хәләл.— Талип тагы күзләрен йомды да тиз үк ачты. Бу юлы ул күзләрдән иксез-чиксез хәсрәт бөркелә иде.— Гомеремдә күп хыялландым, күп арттырдым, туганнар, гүр авызы төбендә алдаша алмыйм: андыйлары булмады. Миңа сөелеп сөяргә язмады...

Насыйпның урынсыз соравы Талип хыялы корган пыяла сарайны челпәрәмә китергәндәй итте. Колакка хәтта пыяла чыңлавы килеп бәрелде: чың-ң-ң...

Бик озак эндәшми утырдык. Талип та, күзләрен түшәмгә төбәп, тыныч кына ятты. Арада өлкәнебез Вәлетдин өзелгән сүзне тагы ялгады:

— Иртәрәк кузгаласың, Талип агай, иртәрәк... Дим аша салыначак яңа таш күперне күрми китәсең.

— Күпер?— Чирле аз гына башын күтәргәндәй итте. Вәлетдин тегенең нечкә җиреннән эләктерде. Йомры Талип ничәмә еллар инде Дим аша күпер салу турында хыяллана, җыелыш саен бу хакта, халыкны өндәп, оран ташлый.

— Кем сала?

— Хөкүмәт. Шушы көннәрдә генә карары чыкты,— дип имансыз алдашты Вәлетдин.— Ел әйләнәсенә төзеп бетерергә диелгән. Боз кискечләре корычтан эшләнәчәк. Синең ниятең, синең теләгең иде бит ул күпер. Теләгеңне хөкүмәт, кабул кылып, тормышка ашыра, ә син, өр-яңа дагалы итекләреңне киеп, өр-яңа күпердән беренче булып үтү урынына, чокырга посмакчысың. Яхшы түгел, Талип агай. Ул күпердән юл башлап Каешлы Казна Исхак үтсенмени инде болай булгач. Каян килгән Исхакка ул почет?

— Исхакка, почет тагы... Мендәрне аркага кыстыр әле.— Мин мендәрен кыстырдым, ул күтәрелебрәк ятты.— Боз кискечкә, әйтегез, корыч әрәм итмәсеннәр. Башсызлык булыр. Бетоннан гына ясасыннар. Корычның илдә бүтән хаҗәте күп.

— Әйтербез.

— Исхак диген, ә? Менә кемнәргә кала бит дөнья...

— Калдыргач, кала шул,—дип аяусыз раслап куйды Вәлетдин.

— Күпере күпер инде,— дип мин дә сүзгә кушылдым,— Талип агайның таш күпердән дә, чуен күпердән дә үткәне бардыр. Аңысына дөнья күргән кеше шаккатмас әллә ни. Әнә, электр баганалары Казангол үренә менеп җиткән, менә-менә авылга килеп керәчәкләр. Өендә гөлт итеп кояш балкыганын күрми китә Талип агай, шунысы үкенечкә кала...

— Беренче лампа, әлбәттә, закон буенча да, йола буенча да шушы өйдә кабынырга тиеш. Менә монда шарның үгез куыгы зурлыгын асарбыз, тегендә бәләкәйрәге...— дип Вәлетдин лампочкаларга түшәмнән урын да билгеләде.

— Өскәрәк күтәр мендәрне!— Бу юлы Насыйп булышты. Авыру сөялеп утырды,— электр — могҗиза ул. Мин чыра яктысында күз ачкан бәндәмен. Электр илаһи ут ул... Агачларын Казангол сыртында, әйе, күрдем, ә җимешләре менә тәтеми кала...

— Калдыргач, кала инде...

— Нишләп әле син бөтенесен дә «кала... кала... кала...» — дип, каркылдап торасың, Вәлетдин?

— Мин ни, синең сүзеңне генә җөплим.

— Синең җөпләп торуың әллә минем эчемә сары май булып ята дисеңме?— Талипның йөзенә тир бәреп чыкты. Ул тирән итеп сулыш алды. Вәлетдин дә көрсенеп куйды:

— Бер карасаң, күпере дә, электры да пүчтәк. Җансыз нәрсә алар. Әнә бер җан иясе моңаеп ялгыз яши, ялгыз торып кала. Шуны уйласаң, эчләр өзелерлек.

— Кемне әйтмәкчесең?— Талип текәлеп үк карады.

— Кем булсын, Акйолдыз инде.

— Югары үреләсең, энем,— дип теге кырт кисте.— Көлеп сөйләсәң, көлке түгел, чынлап сөйләсәң, ләгатькә сыймый. Акйолдыз — иман ул. Иман хөрмәт ителергә тиеш.

Әйе, Вәлетдин бу юлы шаштырыбрак җибәрде. Мин аңа ярдәмгә ашыктым.

— Акйолдыз җиңгинең күрер күзгә бик күркәм, бик җегәрле тол апасы да бар икән. Ике бөртек күз яше кебек, сеңелесе белән охшашканнар, ди. Дөнья көтәргә Дим уреннән безгә күчеп килгән икән,— дип Кече инәемнән ишеткән хәбәрне салдым.

— Шулай ук охшашканнар диме?

— Суйган да каплаган, ди!

— Акйолдыз тырнагына тырнагы гына охшаса да, фәрештә затыннан булыр. Исеме ничек?

— Аййолдыз,— дип шаштырдым мин, уйлап тормастан.

— Исемен арттырыбрак җибәргәннәр икән җибәрүен. Хәер, анысын үзе кушмаган инде. Дөресен генә әйткәндә, Акйолдызга гомер буе сокланып туялмадым. Күрәсе иде, апасы ниндирәк икән...

— Күрми ни, күрәбез аны. Менә юнәеп аякка бас та...

— У-уф-ф! Юнәеп булмас инде.

— Бу зарыңны җил алсын, Талип агай. Монавы сабан туйлары алдыннан адәм чир хакында уйлармы?— дип, Вәлетдин бөтенләй икенче якка суктырырга кереште.— Әле мәйдан селкетеп биер көнең алда. Менә син түгәрәк уртасында, бер иелеп, бер чүгеп, бер илереп, бер шымып, зыр әйләнәсең. Халык, гөж килеп тамаша кыла, чәбекәй итә, кәпәч чөя. Акйолдызлар, Аййолдызлар һәм башка йолдызлар, сокланып, хәйран калып, күз ата сиңа. Син аның саен купшырак, аның саен дәртлерәк, аның саен өздереп басасың. Шундый өздерәсең — их-ма! Үзең үк, чыдамый, такмак әйтеп җибәрәсең:

Менгән аты кире икән,
Һай, кәрамәт ир икән,—
Төшеп китсә, мәйданның
Билен сыгып биер икән...
Һайт! Һайт! Һайт!

Талип калкынып куйды. Ул, чынлап та, авылның хәтәр такмакчысы, дан биючесе. Аңа торыр бүтән адәм юк. Яшь чагында да шулай булган, әле дә ал бирми.

Вәлетдин һаман үз әңгәмәсен дәвам итте:

— Хатын-кыз зарыгып, моңаеп көтә: «Миңа килеп басса иде», «Мине чакырса иде» дип, тилмерә. Ә син кемгә килеп басарыңны алдан ук төбәп куйгансың. Һәм тыпырдатып килеп тә басасың. Нәкъ үзенә...

— Килен!— дип ярыйсы гына кычкырып чакырды Талип. Алгы өйдәге килен шунда ук йөгереп керде.

— Нәрсә, каенатам?— диде, борчылып.

— Кунакларның, килен, нәгызьләре, асыллары килгән. Әче балыңны мул гына сосып чыгар.

Килене уңган икән. «Ә» дигәнче өстәл өстенә зур яшел кәстрүл килеп утырды. Аның читен эчкә баткан ужау[1] сабы тешләп тора. Бизәкле савытлар тезелде.

[1] Ужау — аш чүмече.

Вәлетдин дүрт тустаганга да, ужау белән сосып, бал коеп чыкты.

— Сабан туйлары шәрәфенә алайса,— диде аякчыбыз. Бер савытны хуҗасына сузды. Хуҗа савытны алырга омтылды да кире дүнде:

— Җыелмас ризыкка кул тидерү хәрам,— диде.— Әйдәгез, рәхим итегез.

Баллары эчәргә җиңел булса да, куәтле иде. Беренче тустаган ук тамырларга йөгерде. Икенчесе белән өченчесе йөрәкне җилкендерде. Без эчкәнне Талип, хозурланып, карап утыра, ара-тирә кысташтыргалап та җибәрә. Без инде бу өйгә нигә килгәнебезне дә онытып барабыз. Дүртенче тустаган күңелгә моң китерде. Вәлетдин, тыңкышлыгын фашлый төшеп, танау эченнән җырлап җибәрде.

Үскән чакта бергә үстек,
Тал тамырлары кебек...

Ярты юлда аңа Насыйп иярде.

Үскәч кенә аерылыштык,
Кош балалары кебек.

Мин җырламыйм. Көем юк. Тыңлап кына утырам. Савытлар бер күтәрелде, бер төште. Җыр инде бөтенләй бәйдән ычкынды. Ачык тәрәзәдән чыгып, илгә таралды. Тыңкыш булса да, Вәлетдин моңлы ул. Җырлары да күңел арбаткыч — бигрәк тә озын көйгә җырлаганда.

Өннәремдә күреп туя алмыйм,
Төшләремә керче, җанашым...

— Их, мандолина булса! — дип, мандолина чиерткән хәрәкәт ясады Насыйп.— Үзем уйнап, үзем биер идем...

Ул юк бармаклары белән юк мандолинаның кылларын тибрәтеп алды. Мин дертләп киттем. Элек аның уйнаганын күргәнем булмады, әмма теге баеп кайткан

елны бик матур мандолинасы бар иде. Насыйп берничә тапкыр биергә омтылып карады, Вәлетдин аңа ирек бирмәде, җиңеннән тартып туктатты. Ни дисәң дә без бер аягы белән гүрдә торган кеше белән хушлашырга килгәнбез. Әдәп кирәк.

Өченче кәстрүлне башлаганда, Талип инде өр-яңа соры пима кигән аякларын караватыннан сәлендереп утыра иде. Әңгәмә бу чак сугыш хәлләре, фронт маҗаралары, безнең солдатның тапкырлыгы, германның юньсезлеге турында бара иде. Талип үзе дә беренче герман сугышында байтак мылтык шартлаткан, байтак чолгау туздырган кеше. Аның гвардин булып йөргәнен бөтен галәм белә. Әле дә анда гвардинлек дәрте, гвардинлек дәрманы кабынып китте:

— Юк, Вәлетдин, германны сүз белән бетереп ташлама син. Ул юләр түгел, без башлырак. Ул көчсез түгел, без гайрәтле. Син германны чүпкә чыгарма, Вәлетдин! Мин шуны җиңеп гвардин булганмын! Син дә гвардин, бу да гвардин, әнә Насыйп та гвардин. Куян аулап кем батырга чыккан? Аю еккан — шул батыр!

— Гвардия, алга!— Насыйп, чәнчә бармаклы кулын югары чөеп, оран ташлады.

Моннан соң әңгәмәнең рәте китте. Без өчебез дә, аягүрә басып, кочаклаштык. Аннан ары нәрсәләр булганы — төштә кебек кенә. Тегеләр, Талип каршысына басып җырлаган соңгы җырның яртысын шулай да хәтерлим.

Әҗәлгә дару бар икән,
Мәхәббәткә бар микән?

Янә шунысы исемдә. Без чыгып киткәндә, Талип кычкырып калды:

— Һай фартауай да егетләр икәнсез! Сезнең белән бер утырулары бер гомер!!

Без чыкканда, Талип өе турында урамда халык гөж

килә иде. Әллә көләләр, әллә елыйлар — ачык кына, өзеп кенә әйтә алмыйм. Торганы белән бер тамаша! Кәмит!

Талип артыннан куа чыккан кара фәрман ун елдан артык кайдадыр адашып йөрде. Бу арада авылда беренче булып электр утын аның өендә Вәлетдин үзе кабызды. Мәйданнарда ул дәртләнеп биегәндә халык, әүвәлгечә хәйран калып, хуплап торды. Акйолдызның апасы Мәргубәне (исеме шулай тонычрак булып чыкты) аңа нык кына димләп карадылар. Күңеле ятмады, тырнагы гына да Акйолдызга тартмаган булып чыкты шул. Сөймәгәнгә сөйкәлмәде ул. Соңгы ызанына кадәр ялгыз атлап килде.

...Ә Дим аша таш күпер әле булса салына. Кемнәрнеңдер уенда, өметендә, телендә салына ул. Ансыз дөнья бармый...

Безне «мәңгеләштерәләр»

Каладан килгән үтә елгыр фотограф Кече инәем белән икебезне авыл читендәге иң калку җирдә зур яссы таш өстенә китереп утыртты: «Үзегезнең данычызга авылыгызның күркәм күренешләрен кушып, илгә чәчәчәкбез. Кайсы гына якка карама — хозурлык. Мәңгеләштерүне үзе сорап тора. Төсле фото уйлап чыгарган адәмгә рәхмәтләр яусын. Шушы матурлыкны чүмереп кенә ала бит ул — төсле фото...» — дип арлыбирле сугылды.

Без бу якны Тау арты дип йөртәбез. Тау артының биек түбәсенә менеп бас та башыңны борып кына бер байкап чык, җиһанның дүрт тарафы синең аяк астында булачак. Шуңа күрә безнең авылныкылар, бишектән төшеп тәпи баскач та, Җир шарының зурлыгын үз күзләре белән күреп үсә. Уңга баксаң, елтырап яткан

Димне, су аръягындагы зәңгәр үрләрне күрәсең, чак кына борылсаң, Ар басулары җәелеп китә, тегендәрәк Сайран авылының әрәмәлеге калкып чыга. Башыңны сулгарак каерсаң, Бәрсүән буйлары, Айгалыш урманнары сине чакыра башлый. Кинәт артка әйләнденме — ап-ак тау башында ап-ак кала — Уфа балкый. Мин кояшлы көнне әйтәм. Болытлы көндә дөньяның чырае кача, тыны кысыла. Ул синнән ятсынгансыман күренә. Ә аяз көнне үзе, атылып, кочагыңа килеп керә. Әйткәнемчә, галәмнең Келәштән башланып Келәштә бетүен без күреп үсәбез, күреп үләбез.

Җәй яңа башлана гына. Әле аяз көнне монар каплап тоныкландырмый. Җирнең яшеллеге — тик яшел генә, күкнең зәңгәрлеге — тик зәңгәр генә.

— Сез утырыгыз, сөйләшегез, хәтерләгез, уйланыгыз,— диде фотограф.— Мин үз эшемне эшләрмен. Миңа игътибар итмәгез.

Итмәссең игътибар, әйтерсең, ул чебен. Чебенгә дә игътибар итми булмый. Ә Кече инәем, чынлап та, безнең тирәдә өтәләнеп йөргән кешене шәйләми дә шикелле. Кыя башына кунган ана бөркет төсле, үзенең туксан еллык гомере түбәсендә тыныч утырып тора. Башын җай гына борып, туган туфрагының төбәкләрен, юлларын, чокырларын, урманнарын, кырларын барлый. Һәммәсе дә төгәл, һәммәсе дә үз урынында булуга ул риза. Димәк, дөньяны миңа бөтен көе калдыра. Ул минем аркамнан кагып куя. Бу инде: «Шуларның һәммәсен дә сиңа ышанып тапшырам»,— дигән сүз була. Эш кушканда, йомыш йөкләткәндә, ул гомер бакый шулай аркамнан кага торган булды. Моны ул Олы инәемнән отып алган иде. Эле-е-ек без өчәү чакта — Олы инәем ә-ә-нә теге таш коймa эченә күчеп китмәс борын мин җанымны өлешләргә бүлгәләми идем. Ә теге ак җиргә кара кар яуган көндә җаным, шартлап, уртага ярылды. Күп заманнар үткәч кенә яңадан ялганды, әмма җөй калды. Мин бары Кече инә-

емнең генә улы булып китә алмадым. Моны ул сизсә дә, сизмәмешкә салышты. Киресенчә, минем күңелемне күрер өчен, җае чыккан саен, Олы инәемне олылап телгә ала. Өч-дүрт ел тышында гына әле миңа шундый зур сүз әйтте: «Шушы яшемә җитеп, синең Олы инәеңнән дә шәфкатьлерәк, акыллырак кеше күрмәдем. Нәрсә эшләп әтиең аны тиңсенмәгәндер инде? Әгәр аның мондый ук икәнен алдан белгән булсам, әтиеңә чыгар башым юк иде. Бер уйласаң, бәлкем, мин дә аңа төс бирмәгәнмендер...» Кече инәемнең бу сүзләре миңа шушы китапны яза башларга хокук бирде. Димәк, көндәше турындагы минем яхшы сүзләрем аны рәнҗетмәячәк. Яшьрәк чакта ул ифрат гарьчел, ифрат нечкә күңелле иде. Күз яше дә керфек очына гына эленеп тора иде. Кайгысы ишәйгән саен, сабырлыгы арта барды. Башта Олы инәем аны бөтенләйгә үз урынына калдырып китеп, гамен арттырды, күп тә үтми гарьчел Мортаза агаем, урам сугышында тукмалудан маңтымый, вафат булды. Кече инәем бу кайгыларны авыр да, сабыр да кичерде. Аннан сугыш. Сәлих агаем, Ильяс энем, мин — өчебез дә яуга киттек. Агаем авыр яралар алып кайтты. Шул яралар аны сугыш басылгач алып та китте. Шушы ук заманда әтием дөнья куйды. Бу җеназаларның бөтенесе дә Кече инәемнең бердәнбер йөрәге аша узды. Әйе, хәсрәтләр уза торды, ул һаман ныгый барды.

Кече инәемнең күз карашы таш зиратка тукталды. Тукталмаслык та түгел шул. Аның ыру агачы инде дүртенче буынга сикерде. Ә корыган тамырлар, сынган ботаклар күпме! Унөч баланың унысы да әнә шул таш койма эчендәге яшел чирәм астында. Бөтенесен дә хәтерли китсәң... Инәем эндәшми. Мөгаен, хәтерләүләргә бирелгәндер. Менә, Назияз күпере ягына әйләнеп, ияге белән ымлап куйды:

— Сине мин гел югалтып җәфаландым... Беренче тапкыр, әле кул баласы чагында, Кара Якуптан ку-

нактан кайтышлый Назияз буенда төшереп калдырган идем. Мин оеп барганмындыр, ахрысы; күпер төбендә чана салулап киткән дә син юрганыңа төрелгән көе очып төшеп калгансың. Юклыгыңны капка төбенә киләп туктагач кына белдек. Атны борып, кире чаптык. Ярый төн айлы иде. Юлдан әллә кайда читтә тәгәрәп ята идең. Уянмагансың да хәтта. Олы инәеңнән ишердек бу хәлне... Уракка алып барсак, арыш эченә кереп адаштың, печәнгә алып барсак, урман арасына кереп югалдың. Чишмә сабан туенда кәмитчеләргә ияреп юк булдың... Танавыңа ис керә башлагач, браматта йөреп олактың, сугышын әйтмим дә инде — я хәбәрсез зарыктырдың, я үле хәбәрең килде... Төшләремдә әле булса сине югалтам да котларым очып уянам.

Мин аны юатмыйм. Чөнки моннан соң да, югалмам дип вәгъдә итә алмыйм. Юлларда әле дә бит сикәлтәләр, салулар бар. Берсендә очып төштең калдың булыр.

Аның теле ачылып киткәндә, мин бүлдермәскә тырышам. Үзенә кирәген ялгар да янә тезәр. Әйе, ялгап алып китте.

— Әнә теге тирән чокырны төшеп бу якка күтәрелгәндә, синең этиең белән тәү тапкыр йөзгә-йөз очраштык. Ул чакта мин утыз яшьлек тол хатын идем. Үзебезнең урам бичәләре белән, тугайда тал кайрысы сыдырып, зур-зур бәйләм кайры күтәреп кайтып килә идек. (Ул заман, язга чыксак, бөтен урамыбыз белән кайры сыдыра идек. Вәликәй бай бәйләменә унбишегерме тиен бирә. Шуңа ризабыз инде.) Шушы үрдә генә кара ат атланган этиең җилдереп куып җитте. Мин аны былтыр Ильяс мәзиннәрдә урак өмәсендә күргән идем. Әмма сүз катышмадык. Әле, аз гына уза биреп, атын шып туктатты да илдә булмаган хәтәр тәвәккәллек күрсәтте. Мин, котым очып, курыктым да, сокландым да моңа. Күпме кеше алдында ят хатынга көпә-көндез әмер бирде бу:

— Вазифа, арткарак кал әле чак кына. Сөйләшәсе

сүз бар!— дип боерды. Әмма тавышы ягымлы иде. Мин, каушап, юлдаш бичәләремә карадым. Арабызда иң кыю исәпләнгән Ямал киңәш бирде:

— Нигә, кал! Тотып ашамас әле.

Мин туктамадым. Иптәшләремә иярә бирдем. Әтиең, таш сын төсле, кымшанмыйча ат өстендә утырып калды. Бераз атлагач, минем аякларым тыңламас булды, тыным кысыла башлады, йөрәк тибешем чигәмә сугарга кереште. Алдымдагы үр текә кыяга әйләнде. Бара алмыйм. Кайры бәйләме, җилкәмә басып, мине җиргә бөгә. Туктадым. Шунда ук тояк тавышы мине куып җитте.

— Бир, кайрыңны ияр алдына салыйм.

Мин карыштым. «Үзем...»— дигән булдым.

— Бир!— янә боерды ул.— Сөйләшергә кирәк. Син йөк күтәреп барганда, мин ничек сөйләшим?

Минем ризалыкны көтеп тормый, иңбашымдагы йөгемне иелеп алып, ияр кашына салды. Мондый чая ирне тәү тапкыр күрәм, әмма аның чаялыгы мине кимсетми. Шулай да зиһенем таралып төште. Тик аның чал керә башлаган түгәрәк сакалын гына шәйлим. Ничәләрдә бар икән?

Сүз башламыйча байтак бардык.

— Минем әле синең тавышыңны да ишеткәнем юк... Ә күңелем күптән синдә,— диде ул тыныч кына.— Минем тормышымны, булмышымны беләсеңдер. Бер авылда яшибез бит. Әле яз. Җәй буе уйла. Ризалыкка ишарәң булса, яучы җибәрермен. Бу адымны мин гомер иткән кешемнең фатихасыннан тыш ясамыйм. Кабатлап әйтәм, миңа яшь бичә кирәк булган өчен генә сүз катмыйм. Син күңелемә кердең,— ул көлемсерәп куйды.— Мәхәббәт дип әйтсәм, минем яшьтәге кешегә оят булыр. Кырык тугыздамын мин.

Мин авыз ачып эндәшмәдем. Оялдым да, куандым да. Оялмасам да, ни әйтер идем соң? Шулай атлы-җәяүле Гөбернатыр урамына килеп кердек.

— Йөгеңне этиеңнәр курасына ташлап китәрмен,— диде ул.

— Юк, рәхмәт. Үземә бир,— дидем. Ул тыңлады. Йөгемне янә иңбашыма салдым. Иңбашымда кайры бәйләме түгел, аккош мамыгы иде. Йөгем җиргә басмый, һавага күтәрә. Менә кайсылай беләде күңелемне синең этиең. Үзе атының муенын каерып борды да кире артына торып чапты. Күп тә үтми, Олы инәең бик ышанычлы кеше аша миңа фатихасын җибәрде...

...Фотограф, әле уңга, әле сулга чыгып, әле каршыга басып, я иелеп, я чүгәләп, я җиргә ятып, шылт та шалт аппаратын шылтлатты. Кече инәем моны игътибарсыз калдырмады, тәүдә үк башындагы яулыгын төзәтте, күлмәк итәгендәге сырларны кулы белән сыйпап куйды. «Әтиең мәрхүм белән бер генә тапкыр да карточкага төшмәдек. Шуңа үкенәм»,— диде ул үз-үзенә. Фотограф вәгъдәсендә торды, безнең сүзгә кысылмады. Әмма байтак йончытты. Аягүрә бастырып та, атлап барган көе дә төшерде. Кешенең эше шул булгач, без сукранмадык, күндек.

— Җиребезне зурлавың өчен рәхмәт, улым,— диде Кече инәем. Ә Кеше гомере ул... Синең бер шылтлатуың ни, минем туксан ел гомерем ни — барыбер.

Фотограф, җиребезне, үзебезне «мәңгеләштереп» үз юлына китте. Без Кече инәем белән кайчандыр һәркайсыбыз үз нәүбәтендә ялан тәпи йөгергән тузанлы тар сукмак буйлап Мөкеш чишмәсенә таба атладык. Шушы чишмәнең салкын суын, учыбызга алып, уртлыйсы килде. Сусаудан түгел, теләктән. Шулай икәүләп бүтәнчә әллә килеп була, әллә юк.

Сукмак тузанында имән яфрагы зурлыгы гына эзләр калдырып, ике пар ялан тәпи түбән таба чишмә ягына йөгергән. Күрәсең, бездән өлгеррәкләр дә бар икән...

Ак кар өстендә кара күмерләр

Туксанның өстенә чыккан Кече инәем бер иртәдә утә боек күренде. Мин хәл-әхвәл сорашкач, «имин» диде, хәтта елмайган да булды. Ләкин барыбер аның күңеле сүрән иде. Ныклап төпченә торгач, әйтеп бирде:

— Бүген таңда мин еладым,— диде.

— Нигә еладың?

— Болай гына... Картлык исәрлегедер инде.

Анасының күз яшьләренә карата улның битараф калуы мөмкин түгел; әгәр әнисе туксанны узган, ә улы алтмышны куып барган булса,— бигрәк тә.

Мин кайта-кайта сораштым:

— Әллә рәнҗеттеләрме? Әллә чиреңне яшерәсеңме?

— Мин җәлләп еладым.

— Кемне?

— Көдрә чәчле яланаяк кызны. Сигез яшьлек сабыйны.

— Кем кызын?

Кече инәем бу сорауга колак салмады, үзенекен дәвам итте:

— Учак кабызырга өйдә шырпы булмагач, ажгырып торган кышкы иртәдә, соскы тоттырып, әнкәсе аны күлмәкчән көе ут күршегә тере күмер алырга җибәрә. Кузны алгач, кире йөгерә бу. Үзләренең ишек төбенә җиткәч кенә, таеп китә дә лып итеп җиргә утыра, соскыдагы утлы күмерләре кар өстенә чәчелә. Ап-ак карны, әйтерсең, кап-кара күз яшьләре өтеп, өңеп ала. Кыз бала шул утырган көе әрнеп елап җибәрә. Ялангач үкчәләре бозга ябыша. Ул бала — мин идем. Бүген таңда уянып, әнә шул сабыйны кызганудан еладым. Тыелыр әмәл юк. Мөмкин булса, аңа иң җылы киемнәремне кидерер, иң татлы сыйларымны бирер идем. Юк шул... Мөмкин түгел. Күпме үкенсәң дә, мөмкин

түгел. Янә... шул мөмкин түгеллек үкенеченнән өзгәләнеп еладым мин...

Менә шулай икән. Бәхетле булса да, бәхетсез булса да, безнең бала чагыбыз озын-озак еллар буена артыбыздан ияреп килә. Дөресрәге, безнең күңелебездән китми. Кече инәемне әйтәм, сиксән елдан артык вакыт үткәч, яланаяк кар өстеннән йөгереп килгән бала чагын кызганып елый. Бу үзе — сабыйлык түгелме? Сабыйлыктыр, мөгаен. Ә сабыйлык — мөгаен, сафлыктыр.

Чәчелеп киткән күмер таплары гына ак карны карага әйләндерә алмый...

1972—1978

Биографик белешмә

Мостай Кәрим (Кәримов Мостафа Сафа улы) 1919 елның 20 октябрендә Башкортстанның Чишмә районы Келәш авылында урта хәлле крестьян семьясында туа.

Башта туган авылында җидееллык мәктәптә, аннан ике ел Уфада рабфакта укый. Ватан сугышы алдыннан гына Башкорт дәүләт педагогия институтының тел, әдәбият факультетын тәмамлый.

Сугышның беренче көннәреннән үк М. Кәрим фронтка китә. Кыска сроклы хәрби курсларны узганнан соң, элемтә начальнигы һәм артдивизиянең штаб начальнигы булып хезмәт итә. 1942 елның августында каты яралана. Яралардан терелгәч, «За честь Родины», «Советский воин» исемле фронт газеталарында корреспондент булып эшли. Фронтта Коммунистлар партиясе сафына баса. Күрсәткән батырлыклары өчен Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң М. Кәрим тулысынча иҗат һәм җәмәгать эшендә: 1951—1962 елларда ул Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе, 1962 елны РСФСР Язучылар союзы секретаре итеп сайлана, озак еллар буена тынычлык саклау комитетының Башкортстан бүлеген җитәкли. Ул коммунистлар партиясенең XIX,

XX, XXII, XXIII, XXIV, XXV, XXVI съездлары делегаты, 1955 елдан — РСФСРның Верховный Советы депутаты. Совет әдәбиятын үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә, 1979 елда, алтмыш яше тулу уңае белән, аңа Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелә.

1963 елда М. Кәрим Башкортстанның халык шагыйре исеменә лаек була. Мостай Кәрим — СССР Дәүләт премиясе, Салават Юлаев исемендәге республика һәм Станиславский исемендәге дәүләт премияләре лауреаты.

Мостай Кәрим күпкырлы талант иясе. Иң элек аның чын мәгънәсендә зур, танылган шагыйрь булуын әйтеп үтәргә кирәк. Авторның дистәләгән шигырь китаплары илебездә һәм чит илләрдә тәрҗемә ителеп, миллионлаган поэзия сөючеләрнең күңелләрен яулап алды.

Шул ук вакытта ул күренекле драматург һәм прозаик та. Аның «Ай тотылган төндә», «Айгөл иле», «Салават», «Ташлама утны, Прометей!» исемле пьесалары, «Безнең өйнең шатлыгы», «Таган» һ. б. проза әсәрләре башкорт, татар һәм илебезнең башка милләт укучыларына яхшы таныш.

М. Кәримнең соңгы елларда язган «Озын-озак балачак» исемле автобиографик повесте да башкорт һәм рус телләрендә басылып чыкты. Бу әсәр татар укучысының да яраткан китабына әверелер дип ышанабыз.

ЭЧТӘЛЕК

Алдан әйтелгән сүз 3
Барысы да әйләнә 4
Кеше тудырырга 8
Бәйрәм ашы — кара-каршы 21
«Калды газиз башым яшь көйгә» 41
Искәндәр Әсгате 48
Мәсхәрә ителгән кала 70
Йомры Талип 99
Ите сиңа, сөяге миңа 107
Ике хөкем 110
Мәзәк өчен генә 124
Гариләргә бәйрәм кирәкме 136
Кавказ патшасының варисы 143
Бояр балалары 162
Акйолдыз 170
Ике хат 227
Олы инәем хушлаша 259
Котлы кул Насыйп 274
Әҗәлгә дару бар икән 290
Безне «мәңгеләштерәләр» 301
Ак кар өстендә кара күмерләр 307

Мустай Карим

(Каримов Мустафа Сафич)

ДОЛГОЕ-ДОЛГОЕ ДЕТСТВО

Повесть

(на татарском языке)

Редакторы *Н. Вәлитова*
Художество редакторы *Г. Трифонов*
Техник редакторы *С. Әхмәтҗанова*
Корректорлары *Л. Нәҗмиева, И. Зөлкарнәева*

ИБ № 2386.

Наборга бирелде 23.11.80. Басарга кул куелды 20.05.81. Формат 70×108¹/₃₂. Типография кәгазе № 2. Гарнитура литературная. Печать высокая. Учетн.-изд. табагы 14,1. Якынча басма табагы 13,7. Усл. кр. отт. 14,0. Тираж 15000. Заказ М-798. Бәясе 1 сум.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.





1 сум.